ISSN 0206–4189
Индекс 73210

12+

# Казан утлары

11.2013





*Шәүкәт Галиев*
*(1928 – 2011)*

# Казан утлары
# Qazan utlari

2013

11
(1093)

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:
«ТАТМЕДИА»
ачык акционерлык җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Айрат Сибагатуллин**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Әлфәт Закиржанов, Камил Кәримов.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир — 562-10-62.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге — 222-09-83 өст. 1612.*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80.*

**Факс** — (843) *222-09-83 өст. 1612.*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рим ИДИЯТУЛЛИН. Энже сүз эңгердә балкый. *Шигырьләр.* ..... 5
Мәдинә МАЛИКОВА. Көмеш билбау. *Роман.* ..... 10
Салисә ГӘРӘЕВА. Горурлыкка таулар өйрәткән. *Шигырьләр.* ..... 81
Рифә РАХМАН. *Хикәяләр.* ..... 85
Айдар ХӘЛИМ. *Хикәяләр.* ..... 105

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Гадел КУТУЙ. Рәссам. ..... 102

**СӘНГАТЬ**

Рәдиф СӘГЪДИ. Зур тарихлы театр. ..... 125
Эльвира ҺАДИЕВА. Рәссамда кунакта. ..... 134
Нияз ИГЪЛАМОВ. Язмыш буразналары. ..... 137

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Гомәр ДАУТОВ. Тәрәзә кыегын кем төзәтер? ..... 149

**ФӘН**

Зәрия ХӘБИПОВА. Атка мәдхия яки «Идегәй» дастаны ат турында ни сөйли? ..... 153
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ..... 161
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ..... 164

**ТАРИХ**

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. «Алтын чор»ның алтын шәхесләре. ..... 167

**ШИГЪРИ ХӘТЕР**

Шәүкәт ГАЛИЕВ. Ышанычым арта. *Шигырьләр.* ..... 176

**МӘШҺҮРЛӘР МӘЗӘГЕ**

Морад ДУСАЙ. Уку зарурияте. ..... 179

**АК ҖИЛКӘН**

Чулпан ГОБӘЙДУЛЛИНА. Хис дулкыны ярга бәрелә. *Хикәя.* ..... 181
Фәнзил ГАЛИЕВ. Шигырьләр. ..... 183
Альберт ХӘСӘНОВ. Табигать турында парчалар. ..... 184
Хикәя яза аласызмы?. ..... 189

«Казан утлары» архивыннан ..... 174
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 190

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман М.МАЛИКОВОЙ «Серебряный пояс»;
рассказы Р.РАХМАН, А.ХАЛИМА; стихи Р.ИДИЯТУЛЛИНА, С.ГАРАЕВОЙ, Ш.ГАЛИЕВА.
«Из сокровищниц татарских рассказов»: А.КУТУЙ. «Художник».
«Искусство»: статья Р.САГДИ, посвященная 80-летию театра драмы и комедии им. К.Тинчурина; Э.ХАДИЕВА. «В гостях у художника»;
Н.ИГЛАМОВ. «Борозды судьбы».
«Литературная критика»: статья Г.ДАУТОВА, посвященная анализу современной татарской литературы.
«Наука»: З.ХАБИПОВА. «Посвящение лошади»; Ф.ГАРИПОВА. «История наших деревень»; страницы из «Татарской энциклопедии».
«История»: Д.ЗАГИДУЛЛИНА. «Известные люди «Золотого века».
«Белый парус»: рассказ Ч.ГУБАЙДУЛЛИНОЙ, стихи Ф.ГАЛИЕВА, рассказики А.ХАСАНОВА.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: картина К.НАФИКОВА «Сабля Всевышнего»; писательница Маргарита НЕБОЛЬСИНА.

# IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: novel by M.MALIKOVA «Silver Belt»;
stories by R.RAHMAN, A.HALIM; poems by R.IDIYATULLIN, S.GARAEVA, SH.GALIEV.
«From treasures of Tatar stories»: A.KUTUY. «Artist».
«Art»: article by R.SAGDI to 80th anniversary of Drama and comedy theatre named after K.Tinchurin; E.HADIEVA. «Visiting artist»;
N.IGLAMOV. «Furrows of fate».
«Literary criticism»: article by G.DAUTOV devoted to analysis of modern Tatar literature.
«Science»: Z.HABIPOVA. «Dedication to horse»; F.GARIPOVA. «History of our villages», pages from «Tatar Encyclopedia».
«History»: D.ZAGIDULLINA. «Famous People of «Golden Age».
«White Sail»: story by CH.GUBAYDULLINA, poetry by F.GALIEV, essay by A.HASANOV.
From photo archives of magazine.
Diary of the social-cultural life.
On our covers: picture by K.NAFIKOV; writer Margaret NEBOLSINA.

*The magazine edits monthly*

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция жавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 01.11.2013, график буенча 01.11.2013.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-2469. Тираж 3820.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2013 ел.



Рим
Идиятуллин

# ЭНҖЕ СҮЗ ЭҢГЕРДӘ БАЛКЫЙ

## Алга таба барабыз

**Чал тарихтан килә исәр сынамыш:**
**Бар кешелек кичергәндә алгарыш**
**Җирдә сугыш сроклары кыскара;**
**Ник дисәң,**
**Адәми зат җан кыярга остара;**

**Беләбез:**
**Сузылган ич сугыш хәтта йөз елга**
**Шау томана булган чакта кешелек;**
**...Ә менә**
**Ике мең дә сигезләрнең җәендә**
**Барды сугыш җәмгысе җиде тәүлек.**

**Дөмектерә адәм бүген бер−берсен,**
**Явызларча, сугыш игълан итмичә;**
**... — Ә син үскәч кем буласың? — дигәчтен,**
**— Бандит булам! — диде бер сабый кичә.**

*******

**Гомер — калын китап, тузган, саргайган;**
**Ә бит бите саен кошлар сайраган,**
**Салкын чишмә бәргән, ярып тауларны,**
**Умырзая туган, тишеп чал карны,**
**Төнен йолдызларга сукмак салынган,**
**Кемдер кемне сөйгән, көткән, сагынган...**
**Күптән кипкән ул китапның буявы;**
**Без — әҗәлнең харап әрсез кунагы,**
**Кысыр гөнаһларны барлап ятабыз,**
**Еллар — көлдә, калган көнне ягабыз,**
**Шунсы гаҗәп: һаман нидер язабыз;**
**Җан — китапта, әгәр дә күз салсагыз...**

Рим ИДИЯТУЛЛИН (1940) – *Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар шагыйре; Башкорт һәм татар телләрендә чыккан берничә китап авторы. Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре. Уфада яши.*

## Сезне ни коткарыр?

**Пәйгамбәрлек исе килә бездән,**
**Баешларга кояш авышкач;**
**Юк, матурлык безне коткармастыр,–**
**Матурлыкның тарту көче бетте,**
**Сере бетте, калгач ялангач.**

**Күрсә Күкләр адәм гөнаһларын,**
**Ай кызарыр, Кояш агарыр;**
**Бодай басуында тоташ кылган,**
**Тәрәз төпләрендә гөлләр сулган,–**
**Ил–йортны соң кемнәр коткарыр?!**

**Китәрбез без, сөйгән ярлар ярдан**
**Куллар изәп күздән югалса;**
**Тыңланмаса моңнар онытылып,**
**Укылмаса шигырь йотлыгып,**
**Сез соң? Сез соң!**
**Калырсызмы икән котылып...**

## Хөкемдар

*Әхнәф хаҗи Әминевка*

**...Бу авылдан бары бер өй калган,**
**Һәм могҗиза калган — тере зат!**
**Наполеонмы үткән бу җирләрдән,**
**Әлләме соң шашкын гарасат?**

**Кайдан килеп, кая киткән алар,**
**Кайсы нәсел, кайсы ырудан?**
**Күк әмерен көтмичә дә кемнәр**
**Язмышларга ясин чыгарган?**

**Кара тәрәзәдә — төссез карчык,**
**Әллә татар, әллә керәшен;**
**Ишек ачып, су да бирмәде ул–**
**Тәмам кыргыйланган күрәсең.**

**Без барышлый гына, юлдан төшеп,**
**Ялгыз йортны шәйләп сугылдык;**
**Яулар да юк, ә дошман күп, бүген**
**Хак хөкемдар — хәнҗәр йә мылтык:**
**(Шомлангандыр карчык).**

**...Капылт, бозлы сагышларга коеп,**
**Ялгызак каз очты каңгылдап;**
**Картлыктагы тау–тау хафаларның**
**Иң–иң яманы ул — ялгызлык.**
**Нурсыз тәрәзәдән, өн чыгармый,**
**Багып калды карчык ятларга:**
**Яшьлегенең очканынмы күрде**
**Сикереп лә менеп тулпарга?**

Нигә вакыт, нигә заманалар
Җылы бөркер җанга кул тыга?
Күпме асыл затның сөякләре
Ята ятим...
Йәгез, бер дога!

***

Яклаучысыз калгангамы икән,
Чишмә — елак, йолдыз — ялангач;
Тетрәнгәнең бармы, үксез сабый
Күзен мөлдерәтеп карагач?

Ниләр булыр икән болай итсәм:
Чишмә җырын йолдызларга сипсәм,
Йолдыз нурын койсам чишмәгә,
Ә сабыйга яшәү тәмен өрсәм?—
Яңарырмын, валлаһ, иртәгә!

Көбә кигән яугир итеп саный
Кеше үзен, кайгы төсен таный
Туң йөрәге шарлап канагач;
Өрерләрме җаннарыңа җылы
Әгәр берчак калса ялангач?—
Ислә һәрчак!

## «Күз яше» кибетендә

Калада кибет бихисап,
Шау импорт күбесендә;
Булдым беркөнне бердәнбер
«Күз яше» кибетендә.

Гавамнан җыеп саталар
Җыен иске-москыны,
Бар борынгы бичәләрнең
Хәтта киндер ыштаны.

Яшь кызлар кошлар шикелле
Киләләр чырык-чырык,
Хуҗа битараф төстәрәк
Утыра кул кушырып.

Мин кергәчтен, ни гаҗәп хәл,
Әйтерсең узды түрә:
— Рәхим итегез, әфәндем! —
Ул басты аягүрә.

Һәм экскурсовод шикелле,
Япмыйча да авызын,
И мактый үз тауарларын,
Чичән — валлаһи газыйм!

— Бусы — чормада сакланган
Юка телемле чыраг;
Чыжылдасын җиз самовар,
Килсә кадерле кунак.

Кул тегермәнен алсагыз
Күрерсез күп файдасын, —
Тары итеп тарттырырсыз
Бөтен мирнең кайгысын.

Бу патефон җанга бәлзәм —
Хафалы ялгызларга;
Ялт сүнәр ялган «йолдызлар»,
Моң сипсә Басыйрова.

Карагыз, нинди толымнар! —
Чем карасы, сарысы;
Кызлар китерә күбесен, —
Килми чәчен тарыйсы...

Яшьләр тагын чыркылдады
Хуҗаның бу сүзеннән;
Көлдем мин дә рәхәтләнеп,
Яшь чыкканчы күземнән.

Хуҗа кинәт, ут капкандай,
Чабулап килде янга:
— Шатлык яше бик дефицит,
Коегызчы бу җамга!

Яшеңне дә онытасың,
Эчсәң шатлык яшьләрен;
Тизләтәсе килә Җирнең
Әйләнмәле күчәрен.

— Кайгы яше үтәме соң? —
Дип аңардан төпченәм.–
Сакланыр өчен алалар
Бер кайгысыз кешедән.

Хәсрәтсез бәндә, көядәй,
Телгәли ефәк җанны;
Газап чиккәннәр тудырыр
Хакка баккан заманны.

— Ә табыш, — дим,— ничек кенә?
— Әнә ике дәфтәрем:
Керем — кош теледәй, чыгым —
Пушкин томы кадәрле.

Корышты картлар, бетәште,
Җеп төсле күләгәсе;
Ә яшь буын елый белми,
Көлгәндә чыкмый яше.

Йөзенә битлек кигәннәр
Гомергә битен юмас;
Мәгәр тук дәверләрдә дә
Ачы яшь акмый тормас.

Күрәм, сез дә карайгансыз,
Якты таңнарны көтеп;
Лампа уты — җанга җылы,
Бирәмен бүләк итеп.

Сез шагыйрьгә кирәклесе —
Лампаның җиделесе;
Энҗе сүз эңгердә балкый, —
Белми шуны күбесе...

...Тагын тамарга чамалый
Җылы бөртек битемә;
Кызлар чыркылдап калдылар
Искелек кибетендә.

................................

Кибет алды. Эскәмия.
Кәрлә карчык утыра;
Сатмак буладыр, күрәсең, —
Күз яшен сыгып тора.

## Иртәгәмне уйлап...

...Кайда калып, кемгә кирәгербез,
Әллә җиргә, әллә күкләргә?
Оныклар да, ахры, онытырлар
Һәм салмаслар сукмак үткәнгә.

Уйлыйм шуны: җирнең бер тамчысы
Ни-нәрсә ул чиксез күкләрдә?!
Җирдә яшен булып яшьнәү кирәк,
Кайта-кайта күктә күкрәргә.

***

Тып-тын кичтә килдем аулак күлгә,
Битендә юк бөртек җыерчык;
Төшәрләр дә очып, иңбашымнан
Фәрештәләр алыр күк кочып.

Гамьсез вакытларны сүтә-сүтә,
Йә, без нинди гамьле эш кылдык?!
Уятасым килми үләннәрне,-
Кычкырыр да идем җир ертып.

Нигә кешеләр дә сызлак җанны
Кочар фәрештәләр түгелләр?!
...Әремнәрне иснәп әрнешү юк, —
Миндә бетәр, ахры, шагыйрьләр.

Мәдинә
Маликова

# КӨМЕШ БИЛБАУ

РОМАН

* * *

Әмма... Әмма теләк бер, вәгъдә бер, ә тормыш, ә табигать икенче. Сырхау кимемәде, укшу бетмәде, тамактан ризык үтмәде. Базарга барып суы белән тозлы кәбестә, тозлы кыяр алган иде. Күзе төшеп ике стакан карлыган сатып алды, ләкин бу юлы аны да кабасы килмәде. Әмир өзеп биргәне генә шифалы иде, күрәсең.

Иртән иртүк бүлмәдәге өч кыз торып, ыгы-зыгы киләләр, юыналар, чәй кайнатып, ашарга утыралар. Майлы ботка исеннән дә укшыган Әминәгә шикләнеп караштырып алалар.

– Ашказаным авырта, – ди ул. Әмма тегеләрнең ышанмаганы күренеп тора.

Кызлар төзелешкә эшкә китә. Әминә урынында аунап кала.

Табибка барырга кирәк иде. Әмма анда иң беренче сорау бер булачак: кияүдәме? Әгәр шунда «Совет гаиләсе» журналын укып баручы табибә яисә шәфкать туташы туры килсә?

Җәмилә Закировна янына барудан исә оят хисе тыеп килде. Әле генә аның белән бергә «Туй күлмәге ак була» исемле брошюра язып чыгардылар. Анда яшь кызларга сафлыкны саклауның сәламәтлек өчен дә, таза гаилә кору өчен дә мөһимлеге бәйнә-бәйнә, тормышчан мисаллар китереп исбатлана. Иренне чын мәгънәсендә бәхетле итү, анда чын егетлек горурлыгын үстерүнең серләре ачыла, хәзергечә әйткәндә, секс турында да кайбер нечкәлекләргә кереп язылган иде. Татар телендә мондый китапның моңарчы басылып чыкканы юк иде әле. Һәркемгә мәгълүм булганча, «СССР да секс юк» иде бит! Бер-берсенә тән ләззәте биргән парлар гына бәхетле була ала, дигән фикер ачыктан-ачык әйтелгән иде. «Бәхетле булыгыз, парыгызны да бәхетле итегез! Шул ук вакытта керләнмәгез дә, кызлар!» Менә шул иде аның төп фикере.

Профессор Әминәне керләнгән генә түгел, муеннан пычракка чумган дип кабул итмәсме?

Ни йөзең белән аның каршына барып басарга? Нәрсә әйтергә? Китаплардан укып карады токсикоз дип аталган бу афәттән котылуның чарасы, дәвасы юк икән. Бар шундый хатыннар, тугыз ай косалар, коры сөяккә калалар. Бернишли алмыйсың, табигать сине шундый итеп яраткан.

Инде чыдар хәлең калмаса, йөктән котылуның чарасы бар барын. Әмма, беренче баланны төшерсәң, бөтенләй нәселсез калуың ихтимал.

*Ахыры. Башы узган санда.*

Табиблар моны һаман тукып торалар. Җәмилә Закировна журналда да язып чыкты.

Тормышын болай башлармын дигән уй Әминәнең башына да килмәгән иде. Ул үзен капкынга эләккән төлкедәй хис итә иде.

Ничек ычкынырга?

Әмиргә һәммәсен дә әйтеп бетереп булмады. Сентябрь ахырында аны тулай тораклан чыгарулары ихтимал. Биредә чит кеше бит ул, бүтән оешмадан, баш редакторның үтенече буенча, өч айга дип кенә керткәннәр иде. Редактор төзү оешмасына ялынырмы? Тегеләр тагын өч ай торырга рөхсәт итәрме? Бик зур яхшылык кылырга теләсәләр дә, вакытны елның бер кварталыннан арттыра алмыйлар, закон кушмый. Законнар да каршы Әминәгә, әхлак кануннары да. Шуңа өстәп, ата-анасыннан оят... Үз вөҗданы да талый...

Холкы-табигате тотрыклы түгел, хисләргә бирелүчән, уйлары үзгәрүчән аның. Кызып китеп, дуамалланган, уйламый кылган гамәлләре өчен соңыннан үкенгән чаклары еш була. Теге чакта, иркен зал аркылы узып, ят егетне биюгә чакырган кебек... Күз күрмәгән кешенең көймәсенә утырып, дәрья киңлегенә ыргылган кебек. Әйе, хәзер бу кыланмышлары исенә төшкәндә дә үзалдына кызарынып чыга ул.

Кая китте Әминәнең чаялыгы, кая китте егетләрдән шаркылдап көлгән чаклары? Саф намусы, чисталыгы, йөз аклыгы гына көч биреп торган икән...

Үз-үзен битәрләде, меңгә төрләнде ул. Әле Әмирнең сүзен тыңлап, ничек кенә булса да чыдарга карар кылды, әле өметсезлеккә бирелде.

Иң аянычы шул: мондый хәлдә ул сөйгәненә терәк-таяныч булу түгел, бернинди ярдәм күрсәтә алмый иде. Киресенчә, кыядан коелган таш кебек юлын кисүе генә ихтимал.

Алай да Әмир һич тә аннан баш тартмый бит! Уллары тууын тели! Сайлаулар үтәр, алар өйләнешерләр, һәммәсе җайланыр...

Әнә, телевизордан тагын аны күрсәтәләр. Авылга барган, сайлаучылар белән очраша. Янында мәгъруր кыяфәтле ирләр — җитәкчеләр. Уртада «Социалистик Татарстан» газетасының бүлек мөдире Хәкимә Гатина кулын болгый-болгый нидер сөйли — тавышын ишеттермәделәр, музыка белән капладылар. Ә менә Әмирнең берничә җөмләсе ачык яңгырады. Кыяфәте гайяр, киеме ыспай-килешле, йөзе ачык, тавышы йөрәккә ятышлы, сүзе төпле-үтемле — чын мәгънәсендә ир солтаны! Әминәнең күңеленә канат үскәндәй булды. Аның хакына һәммәсенә түзәргә була!

Ләкин... Кем ул анда, чак кына читтәрәк басып тора? Йөзе кош тоткандай балкый. Гашыйк икәнлеге чыраенда гына түгел, бөтен кыяфәтендә ярылып ята. Бик бәхетле кеше генә сынын шулай төз, башын югары тота ала. Күренеп тора: алар бер үк хисләр дулкынында йөзәләр...

Бу күренеш Әминәгә яшен сукгандай тәэсир итте. Аңа депутатлыкка кандидат Нуриев янында күренергә дә ярамый, ә менә Луизага бернинди киртә юк икән ләбаса. Янында ул барда — Әмиргә горурлык, Әминә якын килсә — хурлык...

Ул үзен тирән базга убылгандай хис итте. Бөтенләй күзгә күренмәскә, тавышы ишетелмәскә әверелүе яхшырактыр, бәлки?..

Чыннан да шулай бит. Димәк, әгәр дә аңа биргән вәгъдәнне үтим дисәң, бөтенләй юкка чыгуың хәерлерәк бит. Җиңеләеп китәр иде! Әйе-әйе, булмаска, тән җәзаларыннан да, җан газапларыннан да берьюлы котылырга. Югалткач, үкенер, терсәген тешләрдәй булыр үзе дә! Үзәге өзелсен, йөрәге парә-парә телгәләнсен әле!

Һәммәсен бер мизгелдә хәл итү хәерле... Даруларның төрлесен берьюлы күпләп эчсәң, йоклап китәсең дә уянмыйсың дигәннәре берничә тапкыр

колакка чалынганы бар... Йокы даруын аракыга кушып эчәргә бер дә ярамый, диләр. Бу очракта, бәлки, нәкъ шулай итәргә кирәктер...

Әминә үзендә дару тотмый, өстәл тартмасында аспирин да активлаштырылган күмер сәдәфләре. Ак белән кара төймәләр. Алардан мәгънә чыкмас. Кырымда бер журналистның хатыны белән аралашып йөргән иде. Керне агартып юыйм дисән, берничә төймә эч даруы салырга кирәк, диде. Менә дигән итеп агарта. Чак кына алсу төс бирә бирүен, әмма аның зыяны юк.

Аннан кайткач, Әминә шул даруны унбиш кап алып куйган иде. Аптекадагы сатучы хатын: «Бу хәтле дару нәрсәгә сиңа?» — дип шикләнеп сорап та куйды әле. Мөгаен, зыяны зурдыр. «Авылдан сорадылар», — дип ялганлады Әминә.

Дөрес, шактыен бүлмәдәш кызларга бирде бирүен, алай да бер уч тутырырлык калган иде әле. Шуңа өстәп, аптекадан даруларның төрлесен алып чыкты. Чәйнектән кружкага салкын су агызып каршына куйды. Һәммәсе хәл кылынган, бөтенесе әзер, тәвәккәлләргә генә кирәк иде. Тәвәккәлләргә дисән, анысын Әминә булдыра!.. Ә шулай да күңелнең бер почмагында аны ничек тә коткарырлар, моны белгәч, Әмир аның өчен куркыр, игътибарсызлыгы өчен үкенер, дигән өмет яши иде.

Ул капларны ертып, аклы, сарылы, яшькелт-зәңгәрсу сәдәфләрне өстәлгә чәчте, аннары кулы белән сыдырып, учына җыйды.

Нәкъ шул мизгелдә ишек шакыдылар. Йөрәк кабыргаларга бәргәләнеп тибә башлады. Менә бит, килгән! Сагынган! Ярата!

Ул сикереп торып шкаф кырыена беркетелгән көзге каршына басты, тузгыган чәчен тарады. Бераз бизәнәсе, халатны салып, күлмәк киясе иде. Әмма озаклап мәрәләнсән, өйдә юктыр дип уйлап, китеп баруы ихтимал. Ә менә көмеш билбау билдә булырга тиеш. Ул, калтыранган куллары белән көмеш аелны көчкә каптырып, атылып барып ишекне ачты.

Коридорда Нәзир басып тора иде.

Ник килгән? Ни йомышы бар? Хәл белергә дип, Әмир җибәргәнме әллә? Әминәнең йөзендә өмет катыш куаныч күргәч, егетнең авызы ерылды.

— Исәнме, Әминә. Чакырылмаган кунак булып килгәнгә ачуланма. Телефоныгыз аскы катта ук икән, иртән шалтыраткан идем, вахтер сина дәшәргә иренде.

— Исәнме! Кер әйдә.

— Редакциягезгә барган идем дә, син ялда диделәр. Авылыгызга кайтып киткәнсеңдер, дип курыккан идем, ярый әле монда икәнсең. Адресыңны редакторыгыз бирде.

Бу сүзләр Әминәнең куанычына бозлы янгыр булып коелды. Йөзеннән нур качты, күрәсең, бусаганы атлап керергә өлгергән егет аңа сагаеп, кыенсынып карады. Үтә дә сизгер икән үзе, кызның кичерешләрен ап-ачык күреп тора, диярсең.

— Вакытсыз килдемме әллә? Әлфия Зарифовна әйтте, телефонга ышанып торма, бар да кер, диде.

— Уз, утыр.

Егет бүлмә уртасындагы чәчкәле клеенка җәйгән өстәл янына утырды. Кулындагы таушалган конгырт портфелен тезенә куеп, Әминәнең йөзенә текәлде.

— Сиңа бер тәкъдим бар иде.

«Әһә! Менә хәзер әйтәчәк Әмирнең гозерен...»

Әминә караватта яткан сөлгене алып, иреннәрен сөртте. Тезләре йомшарып, егеткә яны белән өстәл янына утырды.

— Авырыйсың, ахры. Белмәдем... Зөлфия Зарифовна да әйтмәде. Бәлки, башка вакытта... — дип сөйләнде сәерсенгән егет.

— Килгәнсең икән, әйт: ни йомыш... — диде Әминә сабырсызланып.

Нәзир портфеленнән «Совет гаиләсе» журналының ел башында чыккан санын тартып чыгарды. Бу ни дигән сүз? Әминә үз журналын күрмәгән дип беләме?

— Менә монда синең очеркың...

«Берәр хата тапканмы әллә?» — дигән шом сызып узды күңелне.

— Шушының нигезендә телевидение өчен бер тапшыру эшләргә иде. Ә бәлки, берне генә дә түгелдер. Уйладым-уйладым да сценариен син үзең язсаң яхшы булыр иде, дигән фикергә килдем. Профессор Ильясова, ишетүемчә, сине ярата. Экранда кара-каршы сөйләшү өчен бу бик мөһим. Телекамера хәтәр нәрсә бит ул, гади күз белән күрмәгәнне күрсәтә... Ә сездә күңел якынлыгы бар... Уңышлы чыкса, тапшырулар циклы эшләп булыр иде. Синдә материал җитәрлек. Язганнарыңны күзәтеп барам...

— Кем башына килде инде бу?

Нәзир ана мөлдерәп карады. Күзләре зәп-зәңгәр, карашы сабыйларча якты икән.

— Бурычны өстәгеләр билгеләп, үтәү безгә йөкләнә.

Әминәнең исә башында һаман бер уй айкала иде: «Әмир әйткәндер... Шөгыле-юанычы булсын, дигәндер»...

Әмма бу исем егетнең теленнән өзелеп төшмәде. Ахырда Әминә үзе тәвәккәлләп сорамый булдыра алмады:

— Башкалар бу хакта ни уйлый соң?

— Эш планына кертү өчен башта синең ризалыгың кирәк бит. Шунсыз сүз кузгатып булмый. Алдан кычкырганның башы авырта.

— Ә Әмир ни ди?

Нәзир, гаҗәпләнеп, кызның кызарынган йөзенә төбәлде.

— Бу арада күргән юк әле аны. Эше бик тыгыз бит, районнан районга чаба. Бөтен көчен биреп тырышырга туры килә аңа. Дус бар, дошман бар, дигәндәй, Әмирне аумакайлыкта, җиң унаена торуда гаепләп, хурлаганнары ишетелгәли. Безнең «Сайлаулар алдыннан» дигән тапшыруда да шулай дип кычкырып әйттеләр. Күргәнсеңдер бит?

Әминә анысын күрми калган иде, дәшмәде.

— Җәмилә Закировна белән кайчан сөйләшерсең икән? — дип үзенекен тукыды Нәзир. — Дүшәмбе планерка, өлгерә алсак, алдагы атнада язылырга планлаштырып та куяр идек...

— Белмим шул... Авырып торам бит әле.

— Дәваланасыңдыр бит. Врач ни ди соң?

Нәзир өстәлдә чәчелеп яткан дару төймәләренә гаҗәпләнеп карады:

— Шушы хәтле дару эчәргә куштымы әллә?

— Болармы? Бу дару түгел... Кер юганда порошокка кушып салалар...

— Чынлапмы? Беренче ишетәм... Миңа да бераз бир әле! Буйдак кешегә бер ярдәмең булыр...

— Алсана кирәк кадәр!

Нәзир өстәлдәге төймәләрнең шактый өлешен кәгазьгә төреп, портфеленә салып куйды.

* * *

Хатын-кыз табибларына, барча хирурглар кебек үк, пычак белән эш итәргә, фаҗигале хәлләрне еш күрергә туры килә. Һөнәрләре шундый. «Хирург кебек шәфкатьсез», — ди кайберәүләр. «Хастаханәдәге кебек, үлемҗитемгә күнеккән», — дигән сүзләр Антон Чеховның бер хикәясендә дә бар. Күңелең чыныкмаса, андый эштә эшләп тә булмыйдыр.

Әмма Җәмилә Закировнаның түгәрәк мөлаем йөзендә моңсу уйчанлык

чагыла, еш кына икеләнеп калганы сизелә, ул хәтта һаман-һаман озаклап юып, дезинфекцияләп торганнан нечкәреп киткәндәй ак бармакларын угалап ала иде.

Алар, гадәттәгечә, профессорның кечкенә бүлмәсенә кереп, өстәл аркылы кара-каршы утырдылар. Ак халат-башлык кигән кешеләр бертөслерәк булып күренергә тиеш кебек. Әмма бу алай түгел. Бу кием төп дикъкатьне кешенең йөзенә җәлеп итә, адәм баласының асылы ачыла шикелле. Җәмилә Закировнаның түгәрәк, мөлаем, уйчан йөзен күргәч, уртача буйлы, җыйнак гәүдәле бу апаны тәҗрибәле шәфкать туташы дип уйларга мөмкин иде.

— Телевидениедән бер тәкъдим бар иде, — дип башлады Әминә һәм сүрән тавыш белән Нәзирнең әйткәннәрен кабатларга кереште. Ә башында бер генә уй: ничек тә булса тыелырга, укшымаска.

Профессор өстәл өстендә яткан бармакларын тоташтырып кысты.

— Күптәнме?

— Әле кичә генә әйттеләр. Ләкин ашыктыралар. Киләсе планеркага кадәр...

Җәмилә Закировна карашын бармакларына төбәгән килеш:

— Токсикоз күптән башландымы? — дип сорады.

Әминә яңакларының пешеп чыкканын тойды.

— Бер атна инде...

— Хатын-кызлар консультациясенә бардыңмы? Исәпкә алдылармы?

— Юк әле...

— Ә ник сузасың?

— Өлгермәдем...

— Әлфия Зарифовна сине үз хисабына ял алды диде. Мондый хәлдә эшләү җинел түгел. Вакытны сузуда мәгънә юк. Әгәр каршы килмәсәң, мин сине карый алам. Ничек уйлыйсың?

— Рәхмәт әйтер идем...

— Әйдә алайса.

...Унбиш-егерме минуттан алар янә шул ук кабинетта кара-каршы утыралар иде.

— Хатын-кызлар консультациясендә исәпкә басарга бик вакыт, — диде профессор йомшак кына. — Йөгең алты атналык.

— Бу токсикоз озакка барыр микән?

— Һәркемдә үзенчә. Кайберәүләрдә дүрт-биш айдан бетә, кайсыларында тугыз айга сузыла.

— Дүрт ай?!

Әминә өчен бу коточкыч булып тоелды. Димәк, ул кыш җитмичә эшкә чыга алмаячак! Ә ничек яшәргә?

— Аның өчен артык борчылмасаң да була, — дип дәвам итте профессор. — Гадәттә токсикоз булачак әнигә дә, балага да зур зыян китерми. Күзәтү астында торганда, билгеле. Әлбәттә инде, мондый очракта өйдә тынычлык-иминлек, кайгыртучан мөгамәлә булу бик мөһим. Булачак әти моны яхшы аңласын иде.

Соңгысын әйткәндә, Җәмилә Закировна, башын күтәреп, Әминәнең йөзенә кистереп карады.

— Бу арада эше бик тыгыз әле... Командировкалардан кайтып керми... — диде буталып Әминә.

— Кайда яшисез?

— Мин төзүчеләр тулай торагында. Әлфия Зарифовна фатир чиратынны алга күчерермен, диде. Киләсе ел ахырына, бәлки...

— Әти-әниләрегез беләме?

— Нәрсәне?

Нәкъ менә шушы сорау профессор өчен чынбарлыкны бөтен аяусызлыгы белән ярып салды да инде. Егет белән кызның мөнәсәбәтләре тирәнгә киткәне турында ата-ана бихәбәр. Мондый хәлгә тарый күрмәгез дип, кыз балаларның башына туктаусыз тукып тора лабаса профессор Ильясова!

— Ә ул кайчан кайтачак соң?

Әминә моны белми иде.

Профессор каршында якын киләчәктә, мөгаен, зур сынауларга, житмәүчелеккә, кимсетелүләргә, гарьләнү-үртәлүләргә дучар ителәчәк яшь хатын утыра иде.

— Үзеннән берәр уең бардыр бит?

Әминә инбашларын сикертеп куйды.

Шунда Жәмилә Закировнаның карашы катыланып китте, йөзенә тәвәккәл катгыйлык бәреп чыкты.

— Әйдә, без болай итик әле. Син хәзер редакциягезгә барып, гаризаңны үзгәртеп яз. Иртәгәдән эшкә чыгарлык итеп.

— Ә редактор...

— Үзара аңлаша алмасагыз, миңа әйтерсең. Үзем барып сөйләшермен. Иртәгә сәгать тугызга монда кил. Мин сине дәваланырга салам. Больничный ачарбыз.

Әминәнең йөрәгенә хәл кергәндәй булды. Димәк, ятар урын да, ашар ризык та булачак. Авыру кешене тулай торактан да куып чыгара алмаслар...

...Хастаханәдә дарулар эчкәч, зиһен ачылды, кәеф бераз яхшырды. Йөрәктәге сызлавыкны аз булса да оныткалап торыр өчен шөгыль кирәк иде. Андый очракларда иң яхшысы — башны эшләтү, бәгырьне утлы күмердәй көйдереп торган бер ноктадан уйларны аеру.

Әминә, алты кешелек палатадагы өстәл янына утырып, телевидение тапшыруының сценарисен язарга кереште.

Каләм иясен илһам килгәндә борчырга ярамый, диләр. Язучыларга уңайлы, тыныч шартлар тудырган, аларны көнкүреш мәшәкатьләреннән арындырган хатыннары турында мактап сөйлиләр. Әйе, хатыннары турында, чөнки исем казанган язучыларның күпчелеге ирләр. Татар әдәби мохитендә бу нисбәттән бигрәк тә Габдрахман Әпсәләмовның хатыны Маһирәне мактап искә алалар. Имештер, ул күпмедер сәгатьләр буе ирен бүлмәсеннән чыгармый утырта, билгеле бер вакытта кайнар кофе гына кертеп бирә торган булган. Ул шулай тырышмаса, Әпсәләмов дистәгә якын роман яза алыр идеме икән әле!

Ә менә журналист теләсә нинди шартларда да яза белергә тиеш. Бардың, күрдең, сөйләштең икән, кайту белән язмаң редактор өстәленә куелсын. Әминә кебекләргә иҗат итү өчен аерым бүлмә турында хыялланырга гына кала. Көндезен редакциядә тоташ ыгы-зыгы, килгән-киткән күп. Эштән соң тулай торакның дүрт кешелек бүлмәсе.

Хастаханәнең палатасы аннан әлләни аерылып тормый иде. Тагын шунысы, бу юлы Әминә өлешчә үз башына төшкән хәлләр, үз йөрәгендә кайнаган хисләр турында яза иде. Кәгазьгә түгелгәч, аларның бәгырьне сызландырып баскан авырлыгы кимегән кебек иде.

Төшке аштан соң бина беразга тынып кала, хасталар йокларга тиеш, дип санала. Жәмилә Закировна белән сөйләшеп алырга жай чыга. «Туй күлмәге ак була» исемле китапчык сатылып беткән, ә халык сорый икән. Китап нәшриятында яңадан бастырып чыгарырга карар кылганнар. Янә бер карап чыгарга, яңа фикерләр, мисаллар белән баетырга киңәш иттеләр.

Профессор соңгы вакытта үз күзе алдыннан үткән төрле язмышлар турында сөйли. Нинди генә хәлләргә тарымый кайбер кыз балаларның

башлары! Һәм күпчелек очракта өлкәннәрнең кинәшенә колак салмавы, төптән уйлап житкермәве аркасында бит!

Менә Җәмилә Закировна сүз сөрешен сак кына Әминәнең үз хәленә күчерде.

— Сез ничә бала?

— Бишәү.

— Барысы да исәннәрме?

— Әнкәй унберне тапкан. Исәннәре бишәү.

— Син беренчесеме?

— Бишенче. Миннән алда дүртәү үлгән. Беренчесе — туганда, икенчесе — яшь ярым тулгач. Тагын икесе бер атна эчендә тамак чиреннән...

— Әгәр дә әниең биш бала табып, шуларны сау-сәламәт үстергән булса, аның тормышы бөтенләй башкача булыр иде, шулай бит?

— Шулай булыр иде дә бит, авыл хатыннары саклану чарасын белмәгән. Ә бала төшерү — зур гөнаһ дип саналган...

— Әниең дә, мөгаен, токсикоздан интеккәндер. Буйга узган, күңеле болганып интеккән, бала тапкан, бала имезгән, бала күмгән, аннары тагын йөклелек, күңел болгану, хәлсезлек, бала табу, имезү, бала чирләү... Шулай утыз ел. Мондый конвейерга эләккән кеше рәхәт яши аламы? Шәхес буларак, җәмгыятьтә үз урынын таба аламы? Әгәр ул бик талантлы булса, Ходай биргән сәләтен үстерә аламы? Аны ачып, илгә, халыкка игелек кыла аламы? Хәзерге хатын-кызларга үз тормышын көйләрәк корырга мөмкинлекләр бар бит. Безгә бер фикерне бик үтемле итеп әйтергә кирәк, берничә тапкыр кабатлауның да зыяны тимәс: аналар тансык бала тапсын. Әйе, кеше бу дөньяга тансык булып килергә тиеш. Бу җиһанда әзерләнеп, көтеп алсыннар аны. Караватын, арбасын, бөтен кирәк-ярагын хәстәрләү дигән сүз генә түгел бу. Син аңа жаныңны ярып бирерлек булырга тиеш. «Алым җәл түгел сиңа, гөлем җәл түгел сиңа, алым түгел, гөлем түгел, җаным җәл түгел сиңа», — дигән җыр сөйгән ярлардан да бигрәк балаларга җырланырга тиеш. Бала, күпләр күз алдына китергәнчә, уйнап юану өчен тәти уенчык түгел. Күпме әниләргә, яраткан эшен ташлап, өйдә утырырга кирәк була! Күпме әтиләргә балаларын дәвалау, сәләтен үстерү өчен икешәр смена эшләргә туры килә. Әгәр хатын-кыз буйга узган икән, ир-ат туачак сабыйга канын биргән дигән сүз. Бу гына җитми, ул ана җанын бүлеп бирсен! Бала тансык булмаса, артык була. Артык бала бәхетле була алмый, ата-анасына да зур борчулар, ә кайчакта кайгы-хәсрәт китерә. Мисаллары күз алдында. Күпмеләр өчен бәхет урынына Алланың каһәре булып туа бала! Сәламәт хатын баланы ел аралаш табып тора ала. Ул шундый итеп яратылган. Хатыннарның күпчелеге Герой ана булып бетәр иде. Тик шунысы: шулхәтле сабыйны тәрбияләп үстерергә мөмкинлеге, көче бармы, гаиләсе тигез-иминме? Ир белән хатын бар вакытын, көчен балаларына багышларга ризамы? Хәзерге вакытта күп кенә хатын-кызлар үзләрен иҗтимагый эшчәнлек мәйданында расларга омтыла. Ике-өч бала табып үстерү дә килә аларның көченнән, хезмәтендә уңышларга ирешү дә. Моның өчек тансык балалар табу кирәк!

Китапка язар өчен сөйли боларны Җәмилә Закировна, әмма сүзләре нәкъ менә каршында утырган Әминәгә төбәлгән кебек.

— Йөрәккә йөгән кигезеп булмый, диләр дә бит, хисләр белән мавыкканда баш та бөтенләй үк мингерәп бетмидер! — дип сүзен дәвам итә профессор. — Выключателе юк аның! Ничек кенә яратсаң да, җан сөйгәнеңне ихтирам итсәң, үзеңне кешегә санасаң, гигиена кагыйдәләрен үтәү тиеш. Бала табу мәсьәләсен хәл итү дә шул ук гигиенага бәйле...

Профессорның һәр сүзе кыек аткан кебек тоелса да, туп-туры бәгырьгә килеп кадала.

Әминәнең күзләренә яшь тыгылды.

— Үзем шушындый булгач, кешегә акыл өйрәтергә ни хакым бар минем?

— Хәзерге хәлеңдә син бу китапның кирәклеген аеруча нык аңлыйсың. Монарчы андыйны, үтемле, кызыклы итеп, саф татарча язган кеше юк бит әле. «Бездә секс юк», — дигән сүздән көлү дөрес түгел. Ә бит чыннан да юк дип санала иде! Шуның аркасында, яшәү өчен искиткеч мөһим мәсьәләләргә күз йомганга күрә, күпме хатыннар бәхетсез булды, күпмесенең җаны кыелды! Еш кына: «Мин ун корсак төшердем, ние бар аның», — дигән сүзләр ишетергә туры килә. Бу һич тә гади операция түгел, организмның табигый эшчәнлеген кинәт бик нык үзгәртеп кую дигән сүз!

— Беренче баласын төшергән хатыннар күпчелек очракта нәселсез кала, бүтән буйга узмый, диләр бит табиблар.

— Бу хакта бик уйлап язарга кирәк. Ул хәтле үк куркыту һәр очракта да файдага микән? Моны ишетеп, коты алынган кыз бала ни кылмас! Үз-үзенә кул салуга кадәр барып җитәләр кайчакта. Ә без ярдәм итәбез. Тик вакытын ычкындырмаска кирәк. Бу хакта бик тә гыйлемле мулла белән дә сөйләшкәнебез бар. «Җан кыю — олы гөнаһ, — диде ул. — Әгәр дә ана карынындагы балага җан ингән булса, аны үтерергә ярамый. Ләкин әгәр дә ана җан иңмәгән булса, йөклелектән котылу җан кыю булып саналмый». Хәзрәтнең сүзләре бик дөрес, авыр хәлдә чарасыз калган кыз балаларны чын күңелдән кайгыртып сөйли ул моны. Ана өстәп: һич кичекмичә табибларга барыгыз, үз хәлегезне яшермичә сөйләгез, кинәшегез, ул кушканнарны җиренә җиткереп үтәгез, дияр идем мин. Андый операциядән соң, әлбәттә, дәваланырга кирәк. Тиешле таләпләрне үтәгәндә, киләчәктә таза гаилә корып, тансык балалар табуга ышаныч зур.

— Ышаныч ук дисезме? Ә бәлки, өмет бар, дип кенә язаргадыр?

— Мин үз күз алдымнан узган язмышлардан чыгып сөйлим. Әйтмәгәнем булсын, андый операциядән соң нәселсез калу очрагы бездә булмады. Һәр операциянең методикасы бәйнә-бәйнә эшләнгән. Алай да, теләсә нишләп йөрегез, аннары безгә килерсез дә һәммәсен җайлап-майлап җибәрербез, дигән фикер кала күрмәсен. Иң яхшысы — тәнгә пычак тигезмәү, билгеле. Операция мең тапкыр әйбәт узса, мең дә беренчесендә көтелмәгән хәл килеп чыгуы ихтимал. Һәркемнең организмы үзенчә, бер үк төрле ике кеше дөньяда юк!

— Җәмилә Закировна... Минем... вакыт узмаган бит әле... Балага җан иңмәгән...

Профессорның бармаклары бер-берсен ышкый башлады. Ул тирән итеп көрсенде дә:

— Әлбәттә, бераз вакыт бар әле, — диде. — Алай да тагын бер кат уйларга кирәк. Һәм, әлбәттә, кинәшергә. Монда өч язмыш бергә үрелгән бит...

— Миңа редакциягә барып килергә кирәк. Телевидениегә дә бүгеннән калмый текстны тапшырырга вәгъдә иткән идем. Берничә сәгатькә чыгып торырга рөхсәт итсәгез иде, — диде Әминә.

* * *

— Исәнмесез, Әлфия Зарифовна!

— Ә-ә, синмени әле бу! Исәнме, исәнме! Утыр, сөйлә. Дәвалангач, хәлең яхшыргандыр бит?

Әминә гадәттәгечә «Т» хәрефе ясап куелган өстәлләрнең кырыйдагысы янына утырды.

— Берничә сәгатькә сорап кына чыктым әле.

— Тагын күпме ятарсың икән?

— Анысын өзеп кенә әйтмиләр шул.

— Эш килеп тыгылды монда. Ә син озаклап дәваланырга карар кылдың инде, димәк?

Әлфия Зарифовна урыныннан торып, тәрәзә янына барып басты.

— Ну что ж, ихтыярың. Тик шуны бел: мондый очракта һәммәсен төптән уйлау, алдан ук күз алдына китерү хәерле. Балалы хатынны тулай торакка кертмәячәкләр. Кайда яшәрсең, нәрсә ашарсың...

Әминә карашын өстәлдә яткан журналның тышына төбәде.

Анда бала тудыру йортыннан чыгып килгән ана тасвирланган иде. Ак халатлы шәфкать туташы әти кешегә ак биләүгә биләнгән сабыен сузган. Һәммәсенең авызы ерык. Журнал эчендә аңлатмасы да бар, анысын Әминә язган иде. «Заря» фабрикасының алдынгы эшчесе — кадерле хатын тансык бала тапкан. Ире дә шунда ук эшли икән. Фабрика аларга фатир биргән. Ачыктан-ачык әйтелмәсә дә, фотоның да, мәкаләнең дә асылында, ипле гаилә корып, имин тормыш белән яши башлагач, бала табу зур бәхет, дигән фикер ярылып ята иде.

— Нуриев ни ди соң? — дип сорады Әлфия Зарифовна.

— Сайлаулар белән йөри бит ул.

— ЗАГСка барып килергә генә вакыт табар иде инде. Әгәр теләсә.

Әминә дәшмәде.

— Мин монда кызыксынып, кайбер нәрсәләрне ачыкладым әле, — дип дәвам итте редактор. — Каян килеп гади авыл малаен шулхәтле кинәт кенә күтәреп җибәрделәр икән? Бу гаҗәп бит. Яшьләрне күтәрергә кирәк, дигән сылтау бар барын. Тик арттан этүче кирәк. Баксаң, Нуриевны Шәйхразиевлар кавеме үз канаты астына алган икән. Булачак кияүләре итеп күрәләр. Әлегә бу нәрсә күзгә ташланмасын өчен генә туйны кичектереп торалар. Сайлау кампаниясе үтүгә, күр дә тор, бөтен республиканы шаулатып туй ясаячаклар.

Әминә урыныннан сикереп торды:

— Анысы булмас! Ул мине ярата!

Аның күзләреннән шундый ялкын бөркелде ки, Әлфия Зарифовна бер мәлгә телсез калды. Башын иеп, читләште, кире урынына барып утырды. Уйлангандай:

— Сине генә микән? — дип сорап куйды.

— Мине генә!

— Ир-егетнең йөрәге күпне сыйдыра. Яр сөю аның яшәешенең бер өлеше генә. Һәм иң зур өлеше дә түгел. Аның янулары-көюләре халык арасында танылу, югары күтәрелү, дан алу өчен. Ул властька омтыла. Ә властьның тәмен татыган, ул каптырган сөйдергечне йоткан адәмнең айныганын күргән юк әле. Менә кайда ул шашып сөю! Һәм гомер буена. Үлгәнче, кара гүргә кергәнче! Ирләр сөяркәләрен ташлый, әмма властьтан беркайчан да йөз чөерми. Бер райком секретаре, эшен дә, хатынын да ташлап, мәгъшукасы белән каядыр китеп олаккан, дигән сүз йөргән иде йөрүен, әмма ул булса да тарихта бер генәдер... Югары күтәрелгән ир заты тирәсендә хатын-кызның төрлесе күп чуала. Теләгәнен сайлап алырга мөмкин. Андыйларның йөрәгендә гыйшык учаклары кабынып-сүнеп тора. Бер кабынганы ике елдан артык янмый. Күпләрне күзәттем, уртача санаганда шулай килеп чыга.

Редакторның сөйләгәннәре бәгырьне ялкын телләредәй өтеп-өтеп ала иде кебек. Ул үзе дә моны сизә, әмма аяусыз иде.

— Мин аны яратам... — дип быдырдады Әминә.

— Син дә үзенчә яратасың. Хәзерге вакытта бөтен язмышымны аның аяк астына ташларга әзермен, дип уйлыйсындыр. Ләкин ул шулай тоела гына. Гомер озын, уйларың үзгәрер. Тукайның «Эштән чыгарылган татар кызы»,

Толстойның Катюша Масловасы яшәгән заманнар күптән үтте. Без бик бәхетле чорга туры килдек: сайлар мөмкинлек бар... – Әлфия Зарифовна башын иеп, карашын өстәлгә төбәде. Тавышын әкренәйтеп: – Әлегә, балага җан ингәнчегә кадәр, – дип өстәде. – Җәмилә Закировна шулай ди.

Редактор бераз тынып торды да, җавап булмагач, сүзен дәвам итте.

– Әгәр дә бала тудырырга карар кыласың икән, туу турында таныклыкка әтисенең исемен яздыру яхшы булыр иде. Суд аша алимент даулап, ямьсезләнергә туры килмәс иде, бәлки...

– Сез нәрсә, Әлфия Зарифовна! Нинди алимент? Ни сөйлисез? Ул баласын ташламаячак. Тик бераз сабыр итәргә кирәк, ди...

– Син сабыр итәрсең дә бит, бала көтә алмый шул. Үсәсе бар аның. Бер балага эш хакының егерме биш проценты санап алына. Депутатларга яхшы түлиләр, баштагы чорда икегезгә җан асрарлык булыр иде.

– Ничек аннан алимент таләп итим мин? Бирсә дә алмаячакмын!

Күпме китапларда аерылган ирләреннән алимент сорамаган хатыннар мактап язылган, телевизордан чыгып, шуның белән горурланучы ялгыз аналар күпме! Әминә алардан начарракмы әллә?

– Сиңа дигән акча түгел бит ул, баланыкы, – диде редактор тыныч кына. – Сабый беренче сулышын алуга тулы хокуклы гражданин булып санала, аны дәүләт яклый, кайгырта. Закон буенча ата кеше баласын тәэмин итәргә тиеш! Ә синең, закон бозып, баланың хокукын кисәргә хакың юк. Тудыра белгәнсең икән, будь добра, яклый да бел. Шактый вакыт эшеңне ташлап, өйдә утырырга туры киләчәк. Алдагыны белеп булмый, авырып китүең ихтимал. Сабый ач ятсынмы?

Әминәнең аяк астында паркет идән дулкынлана башлагандай иде.

Җирдә шактый озак яшәгән, күпне күргән, ә бәлки, үзе дә кичергән апакайның хаклы икәнлеген акыл аңлый, әмма бәгырь түренә капкан учакның ялкын телләре зиһенне ялмап, мигә кадалган дөреслек угын яндырып көл итә иде.

...Алай да, аның әйткәннәре күңелдә яңгырап торды, тора-бара Әминәне якын киләчәгенә күзләрен ныграк ачып карарга мәҗбүр итте. Әмма тәҗрибәле апакай ярып салган хакыйкать тамактан үтәрлек түгел – ачы борычтан зәһәр иде. Ничек инде Әмир аны ташласын! Ничек аны авыр хәлгә дучар итсен! Бераз сабыр ит, диде бит ул... Ләкин күпмегә сузылыр икән аның «бераз» дигәне? Ничә айга? Ә бәлки, редактор әйтмешли, елларгадыр? Чыннан да, сайлаулар узуга Шәйхразиевлар белән арасын боза алырмы ул? Әгәр, тагын сабыр ит, дисә?..

Ничек кенә булмасын, Әминә эшкә йөри алмас. Мөгаен, бала белән тулай торакка да кертмәсләр... Әмма болар җан сөйгән ярыннан ялраган баланы юк итәргә сәбәпмени? Әти-әниләр безне тапканда, үзебезгә читен булмасмы, дип уйлап торганнармы әллә? Җан биргәнгә җүн бирер, дигәннәр. Миллион халыклы Казанда шушындыйрак четерекле хәлгә дучар булган кыз бер Әминә генә түгелдер. Берсе дә ачтан яисә урамда катып үлми... Ахыр чиктә балалар йортына эшкә урнашырга була. Яки балалар бакчасына. Педагог дигән дипломы бар лабаса.

Ләкин бусы бит аның иң ахыргы очракта гына. Әлфия Зарифовнаның сүзләре раска чыкса гына. Ә нишләп әле Әмир аның фикерен расларга тиеш? Нишләп башка ирләр кебек булырга тиеш? Ул берәүгә дә охшамаган, бердәнбер! Аның улы да – аларның, әлбәттә уллары туачак – нәкъ әтисе төсле булачак. Нур чәчеп торган җирән бөдрә чәчле, назлы песи кебе саргылт күзле. Чөнки әтисе аңа җанын бүлеп бирер. Әйе, җанын өрер ул аңа! Хәзергә бераз сабыр итәргә кирәк. Сайлаулар үтсен! Халык аны сайлар, билгеле. Аның кебек башка бүтән бармыни? Аннары алар кавышырлар. Туй ясап.

Хәзер инде көмәнле кәләшнең ак күлмәк киеп, ак бөркәнчек ябынып туйда биеп йөрүе гаеп саналмый. Хәер, Әминәнең буй-сыны үзгәреп өлгермәс. Туйны озакка сузмаслар. Тик менә хәзер бер күз карашын салсын иде. Шул караштан назлы нур бөркелеп, бөтен тәнне иркәләсен, бүрткән бөртеккә жан өрсен иде. Моның өчен күп кирәкмени? Бер карап алуы житә!

...Төнлә күзләрен шар ачып уйланып ятканда, Әминә билен тырнаштырган билбауны назлап сыйпады. Көмеш кыршау эчкә баткан корсагы турында тырпаебрак тора. Тыштан караганда, гәүдәдә үзгәреш сизелми иде әле.

* * *

– Депутатлыкка кандидат Әмир Солтанович Нуриевның ышанычлысы Хөснуллина тыңлый! – дип җавап бирәләр телефоннан. Шундый көр, янгыравык тавыш, куанычыннан нишләргә белмидер кебек. – Ало! Ало! Начар ишетелә! Гозерегезне кычкырыбрак әйтегез, зинһар!

Әминәнең гозере нәкъ менә шул күз күрмәгән, тавышына караганда бик яшь (ә бәлки, хуҗасына гашыйктыр да әле!) кыбырсыкка сөйләрлек кенә инде! Житмәсә әле, кычкырып ди бит!

Нишләргә инде? Әһә, менә радиодан хәбәр итәләр: сайлауларга әзерлеккә багышланган киңәшмә булачак икән. Мөгаен, барлык кандидатлар Казанга кайтачак.

Киңәшмә Югары Советның Ирек мәйданындагы затлы бинасында узачак икән. Мондый җыелышларда эш тәртибе гадәттә төгәл үтәлә, төшкелеккә тәнәфес тә үз вакытында ясала. Житәкчеләр сәламәтлекләрен кайгырта беләә! Ашханәгә кереп ашыйлар да, беразга һавага чыгалар, тәмәке пыскыталар, үзара сөйләшеп алалар. Менә шунда, бәлки, Әмирне күреп булыр. Ерактан гына булса да...

Әминә мәйданда, ишектән унбиш-егерме адым ераграк, ялгызы басып торды. Көн болытлы, пыскак яңгыр ява, Казансу ягыннан ачы җил бәрә иде. Ә ул курткасының изүен чишеп, билбавы күренерлек итеп ачып куйды...

Әнә ул – бер төркем ирләр арасында чыгып килә. Шаулашалар, көлешәләр. Үзенә таба атлаган Әминәне күргәч, Әмирнең йөзе тартышып куйгандай булды. Әмма шундук үзен кулга алды, янәшәсендәге таза гәүдәле, киң чырайлы ир кешегә борылып:

– Журналистлар безне игътибарсыз калдырмый, – диде. – Исәнмесез, Әминә Тәлгатовна! Сез дә интервью алырга килдегезме? Сез танышмы? – дип юлдашына борылды ул. – Бу «Совет гаиләсе» журналы хезмәткәре Әминә Мусина. Юлыгыз уңды, – дип тагын Әминәгә башын борды, тик күзгә туры карамады. – Хәзер Радик Фоатович барлык сорауларыгызга җавап бирәчәк.

Шундый көр күңелле, ачык чырайлы, шаяргандай итеп сөйләнә үзе!

Ә менә янәшәсендәге юан адәм исә бик житди калды, кистереп карады. Багыш районының житәкчесе, Луизаның әтисе Шәйхразиев иде бу.

– Мин... мин хатын-кыз кандидатлардан интервью алырга килгән идем, – дип быдырдады Әминә.

Ул бөтенләй коелып төшкәнен тойды. Тел нидер сөйли, әмма сүзләр зиһенгә барып ирешми кебек. Әмирнең авызы ерылган, ә зур ачылган күзләрендә куаныч түгел, якын итү түгел, сагаю, алай гына түгел, курку ярылып ята иде! Әйе, бер карады ул Әминәнең күзләренә, икенче билбавына һәм... коты очып курыкты. Битенә чаян сикердемени! Жаны куырылып килде, калтыранды, кысылды... Әминәнең үзеннән түгел, аның карынында бүртеп килгән бөредән курыкты ул...

Аның бу халәте бәгырьне чаккандай итте. Жир тишелсә кереп качар иден... Ничек итеп күзгә күренмәс булырга?..

Менә ирләр әкрен атлап, каршыдагы зәңгәр чыршылы бакчага таба киттеләр. Басып калды Әминә каккан казыктай, аякларын кузгатырга хәл таба алмыйча...

— О-о, кемне күрәм мин!

Бу нинди шат тавыш?

Ишектән шагыйрь Ренат Харис чыгып килә икән. Янәшәсеннән атлаган таза гәүдәле, зур житәкчегә охшаган абзыйны арттарак калдырып, ике кулын алга сузып атлый. Кемне күреп шулхәтле сөенгән? Әминә артына борылып карады — һичкем юк. Баксаң, Әминәне күреп куана икән бит ул! Бу инде сина кайсыдыр районның башлыгы гына түгел, бу — зур шагыйрь, бердәнбер калын әдәби журналның баш редакторы!

Әле генә упкынга убылгандай тоелган Әминәне, әйтерсең лә якасыннан тотып алып, күтәреп алдылар да ныклы жиргә бастырдылар.

— Кәефләр ничек? — дип аның кулын нык итеп, ул ук вакытта саклык белән учына алып селкеде шагыйрь. — Килеп ятуыңмы, китеп баруыңмы?

— Эшем бетте минем монда... — диде Әминә.

— Ә хәзер кая? Редакциягәме? Әйдә, утыр, бергә кайтабыз.

Шулай дип, Әминәне култыктап алды да, гранит бордюр янынннан кузгалып борыла башлаган ак «Волга»сына таба алып китте ул.

Йөзе ачылып киткән Шәйхразиев белән Әмир борылып аларга карап калдылар.

— Минем сездә бер бәйләм шигырь ята бит әле, — диде шагыйрь юлда кайтканда. — Каләм иясенең, үзең беләсең, ижат жимеше турында нинди дә булса фикер ишетәсе килә. Мин инде кире какмассыз, алдагы саннарның берсендә урын бирерсез, дип өметләнеп йөрим. Ничегрәк урнаштырырсыз, нинди рәсемнәр ясатырсыз икән, бергәләп уйлашсак, яхшы булыр иде...

Чыннан да, Әминә ялга чыгар алдыннан берничә шигырь керткән иде ул. Аларны шундук укып чыгарга, редколлегия әгъзасы — шагыйрь Илдар Юзеевтан да укытып алырга кирәк иде. Әмма Әминәдә аның кайгысы юк иде шул. Менә хәзер ул оятыннан бит очлары пешеп чыкканын тойды.

* * *

...Иртәсен дә, кичен дә Әмирнең тартышкан йөзе күз алдыннан китмәде. Авызы елмаерга тырышып ерылган, шар ачылган күзләреннән исә дер калтыранган жаны күренеп тора кебек. Кем шундый кызганыч, мескен хәлгә китереп тераде аны? Әминә үзе түгелмени? Ана шатлык, куаныч китерәсе урында!

Кешене көчләп бәхетле итеп булмый, диләр. Ә көчләп ата итеп буламы? Бәхетле ата итеп... Өч ай элек аның бу хакта уйлап та караганы булмагандыр. Юк, әлбәттә! Планнары бөтенләй башка иде. Сине әти ясыйсым килә, мин табасы балага жанынны бүлеп бир, дип аңа бәйләнергә кемнең ни хакы бар? Киләчәк язмышны хәл кылына торган чорда, һич көтмәгәндә аяк чалу бит бу!

«Борчыганым өчен кичер мине, гафу ит, зинһар! — дип эченнән сөйгәненә ялынды Әминә йокысыз яткан төннәрендә. — Миңа синең бер күз карашың кирәк иде. Шул бер карашың белән сөюебездән яралган бөрегә жан өрә ала идең. Хәзер беләм: син моны булдыра алмыйсың. Тик моны телең белән әйтергә авырсынасыңдыр. Мине яратасың, кызганасың, шуңа күрә, котыл йөгеннән, дип әйтмәячәксең. Сүз белән әйтә алмаганыңны күзләрең әйтте... Мин синең муеныңа Алланың каһәре булып төшәрлек йөк асарга тиеш түгел».

Сөюләре чынлап булса, Әмир аны аңлар, алай гына түгел, рәхмәт укыр әле. Дөнья хәлләре үзгәреп тора, Шәйхразиевтан өркә торган чаклар узар.

Менә шунда алар кешечә, матур итеп кавышырлар. Уллары туар. Тансык бала булып туар! Атасы ана куана-куана җанын бүлеп бирер! Шулай уйлап, Әминә ныклы бер карарга килеп, тәвәккәлләде...

...Һәммәсе жиренә житкереп, медицина кагыйдәләрен төгәл үтәп башкарылды. Инде җинел суларга була иде шикелле.

Тик нигәдер Жәмилә Закировнаның кыяфәте пошаманлы иде. Кулына больничный кәгазен тотып, аның бүлмәсенә кергәндә, Әминә моны шундук тоеп алды.

— Утырып сөйләшик әле, — диде профессор. Күзгә туры карамады, кулларын угалады. Әминәнен күнеленә шом үрмәләде: ни булды икән? Мондый очракларда табиблар авызыннан: «Син бүтән буйга уза алмаячаксың», — дигән сүз чыгуы хакында күп сөйлиләр. Әллә?..

— Әйтергәме-юкмы дип уйладым-уйладым да, ахырда синең моны белергә тулы хокукың бар, дигән фикергә килдем...

Әминәнен йөрәге тибүдән туктагандай булды. Хәзер... менә хәзер теге күп табиблар әйткәнне кабатлар микәнни? Бөтен өметләрне кисеп...

— Срок кечкенә булганлыктан, алдан белә алмадык... — дип, башын күтәреп, аның йөзенә туры карады профессор. — Соңыннан гына ачыкланды: синең игезәкләрен туачак иде...

Баш буталып китте. Димәк, икәү... Киләчәктә җирдә тупырдап атлап китәчәк ике Нуриев...

— Ир балалармы?

Жәмилә Закировнаның йөзендә гаҗәпләнү чагылды. Мондый сорауны көтмәгән иде ул.

— Әйтеп булмый... Анысы сонрак билгеле булыр иде... Медицинада иң зур патологияне гинекология бирә. Көтелмәгән хәлләр гел булып тора шул. Алдан белсән, бәлки, тагын бер тапкыр уйлар идең... Егетең белән тагын бер кинәшер идегез...

Әминә үзен буш капчык кебек тойды. Ничек урыныннан кузгалганын, ниләр әйткәнен аңышмады. Урамда карлы яңгыр ява, ачы җил биткә бәрә, әмма ул боларны тоймый, күнелендәге бушлык бөтен дөньяга җәелгән кебек иде.

* * *

...Бер атнадан ул эш урынында утыра иде инде. Күнел яралы, әмма тышкы кыяфәтендә тамчы да үзгәреш сизелми. Тик йөзе генә гадәттәгедән житди, хезмәттәшләре белән дә, килгән-киткәннәр белән дә ачылып сөйләшергә вакыты юк — эше муеннан. Журналга мәкаләләр яза, телевидениедән тапшырулар алып бара, профессор Ильясованың китабын басарга әзерли, шунын өстенә «Социалистик Татарстан» газетасына да язгаларга өлгерә.

...Бер көнне ашханәдә төшке ашны газетада эшләүче Хәкимә Гатина белән бер өстәлгә утырып ашадылар. Хәкимә — тәҗрибәле журналист, газетаның сәясәт бүлеген житәкли, өстәгеләр белән тыгыз аралаша һәм аларның кайсы ничек сулаганына кадәр белеп тора иде. Бу инде сина яшь кызларны гаилә корырга һәм хатыннарны ире белән ипле яшәргә өйрәтү генә түгел. Агачтан уелгандай нык сынлы, юлларда күп йөреп җилләнгән какча янаклы, яше кырыкка житкән бу хатынның күзе күбрәкне күрә, акылы күбрәккә ирешә.

Ашханәдән чыккач, лифтта бергә менделәр, Хәкимәгә кереп, сөйләшеп утырдылар. Сүз үзеннән-үзе сайлауларга барып тоташты.

— Нуриев һичшиксез үтәчәк, — диде Хәкимә. — Мин әле генә ул тирәне әйләнеп кайттым. Ул округында берүзе куелган, көндәше юк.

— Алайса нишләп соң ул туктаусыз очрашып йөри?

— Ансыз барыбер булмый! Гади халыкның да теле ачыла башлады, кайберләренең тавышы бөереннән чыга. Мир авызын бүрегең белән каплый алмыйсың. Аның Шәйхразиевлар кавеменә керергә йөрүен дә халык алдында кычкырып әйтәләр. Ни эш майтарганын бар соң әле синең, дип тә җавапка тарталар. Гел житәкче авызына гына карап торган заманнар үтеп бара кебек. Эстониядә, Грузиядә халык ничек кузгалды, әнә. Безнең татар да сарык түгел!

Анарчы ачылып сөйләшкәннәре, серләшкәннәре юк иде, ләкин тел төбенә караганда, бу хатын Әминәнең башыннан кичкәннәрне белә иде шикелле.

— Кадрәк дигән авылда мин дә очрашуда булдым, — дип дәвам итте ул Әминәгә туры карамаска тырышып. — Нуриевны кочак жәеп каршы алдылар, дип булмый. Кайберәүләр энәләрен нык тырпайткан иде. Мина да чыгыш ясарга туры килде.

— Ни сөйләдең соң?

— Безгә, биек трибунага басып, төпле, үтемле сүз әйтерлек шәхесләр кирәк. Үзең дә күреп торасыңдыр: мөстәкыйль фикер йөртә торган, сәясәттә үз фикерен үткәрә алырлык кадрлар житми. Һәммәсе өстәгеләрнең айт дигәненә тайт дип торырга өйрәтелгән. Хәзер Мәскәүгә каршы аяк терәп сөйләшергә мөмкинлек туды. Үзәкләренә үткәзерлек итеп. Син шундый сүзне әйтерлек кешеләребез күп дип уйлыйсыңмы? Юк алар! Һәммәсе телен тыярга өйрәтелгән! Телен генә түгел, уй-фикерләрен дә йөгәнләргә күнектерелгән! Урыслар, «на безрыбье и рак рыба», диләр. Балык булмаганда кысла да ярап куя. Безгә дә хәзер шул ярап куйганнарны күтәрергә туры килә.

— Бик кыю егетләр бар бит! Марат Мөлеков, Рафаэль Хәкимов, Индус Таһиров, — дип теленә килгән фамилияләрне атады Әминә.

— Алар бер кул бармакларына сыеп бетә! Өстәвенә төрлесе төрле якка каера. Кайсы Мәскәү белән араны бозмаска өнди, кайсылары канлы көрәшкә чакыра. Фәүзия Бәйрәмованың чыгышларын тыңлап барасыңмы? Илгә мөстәкыйльлек яулап алу корбаннарсыз гына бирелмәячәк, ди ул. Кайбер аналар улларын югалтыр, моңа әзер торырга кирәк, ди. Сүзен сүзгә хәтерләмим, әмма мәгънәсе шулай. Мондый сүзләр астына барлык аналар да кул куяр, дип ышанып булмый. Россиянең уртасындагы Татарстанның мөстәкыйльлекне сугышып яулап алуын мин, мәсәлән, күз алдына китерә алмыйм. Аннары Мәскәү белән Казан арасына чик куеп, паспортлар тикшереп, кулыңдагы һәрнәрсәне таможня аша үткәреп салым түләү кемгә кирәк? Эш кешеләренә кирәкми ул. Ә көч тә, милек тә алар кулында. Бандитлар да чик куелуны теләми, мондагылар иркенләп мәскәүлеләрне барып талап кайта, андагылар монда килеп үз эшләре белән йөри. Чынбарлык белән исәнләшмичә ярамый... Мөмкин булганны алырга тырышырга кирәк. Нәкъ менә шул юнәлештә Нуриев кебекләрне файдаланып була. Мәскәү ягына да авышмый, мылтык алып, кылыч тагып, Татарстан чигенә тезелеп басарга да өндәми... Урталыкта ул. Аннан яхшыраклары тулып ятмый бит әле. Ә инде аны кем күтәрә дә кем артыннан этә, анысы кечкенә мәсьәлә. Файдагамы, зыянгамы аның эше, шуны карарга кирәк.

— Ахырда халыкны үз ягыгызга аудара алдыгызмы соң? — дип сорады Әминә.

— Бик үк яратып бетермәделәр шикелле. Залдагыларның сулышыннан шулай сизелде. Әмма аларның Нуриевка көндәш итеп куярлык бердәм кандидатурасы юк шул. Андыйны фәкать монда, Казанда, иң зур житәкчеләр белән алдан сөйләшеп кенә куеп була. Алар урындагы житәкчеләр белән сөйләшә, андагылар үз сүзен үткәрергә тиеш. Алай да халык белән бөтенләй исәпләшми эш итәргә ярамый. Халык исә электән күзгә кылчык булып

кермәгән, яна шәхесләр күрергә тели. Һәммәсе уйланган, исәпләнгән. Аның системасы шундый бит, үзен беләсең. Ә залда кычкырынып утыручыларның ние бар? Оешмасымы, акчасымы?

— Югарыдан тәкъдим ителгәч, ул бит... шул ук партия кешесе булып чыга инде... — диде Әминә ачынып.

— Ә читтән каян аласың? Сәясәттә үтемле сүз әйтү өчен нык әзерлекле, унган, эшлекле булу кирәк. Ә андыйлар яшьтән партия тирәсенә елышты. Ни генә дисәң дә, өстә халыкның каймагы иде. Баскычны әйләндереп куеп була, әмма каймакны аска төшереп, аертылган сөтне өстән йөздереп булмый. Нуриев аста кала торган түгел. Илдә нинди генә хакимият булса да.

— Ә иман?

— Эчен актарып, иманын кем ярып караган? Анысы эштә күренер. Һәрхәлдә, житәкчелек аны хәзерге көндә үзенә кулай дип саный. Зыян итмәс, дип өметләнәм.

Тәҗрибәле журналистның сүзләре Әмирне Әминәнең күңел мөнбәреннән тәгәрәтеп төшергәндәй итте дә куйды. Туктале, чыннан да, ник депутат булып сайланырга шулхәтле атлыгып йөри соң ул? Нәрсәгә ирешергә тели, татарның язмышын ни рәвешле яхшыртырга омтыла?

Баласына — бер генә дә түгел, ике баласына! — жанын бүлеп бирүдән баш тартырлык нинди олы максат куйган ул үз алдына?

Хәкимәнең сөйләгәннәре бу сорауларга җавап бирмәде, әмма авыр шик тудырды: Әмирнең иң зур максаты — илдә барган үзгәрешләрдән файдаланып, шәхсән үзен күтәрүдә генә түгелме икән? Кистереп әйтмәсә дә, Хәкимәнең тел төбендә шундый фикер ята түгелме?

— Син аны үзен күрсәтү өчен генә тырыша, дип әйтмәкчеме әллә? — дип өлкән журналистның күзенә тутырып карады Әминә.

— Анысы гаеп түгел. Үз-үзен кайгырта белмәгән адәм халкын кайгырта аламы? Әгәр дә инде үзен күтәргәндә халкының башына баса башласа, менә шунысы куркыныч.

— Ә син аны басар дип уйлыйсынмы?

— Алай дип уйласам, яклап йөрмәс идем. Әмма күңелдә шигем бар. Хәйләкәр ул, эчендәгесен тиз генә чыгарып салмас.

— Әмир хәйләкәрме?

— Сәясәттә хәйләсез мөмкин түгел. Бу сыйфатын да хупларга кирәк. Ләкин нинди максаттан чыгып хәйләли? Анысы инде мөһим мәсьәләләрне хәл иткәндә кылганнарыннан күренер. Үз дәүләтчелегенне торгызу мөмкинлеге мең елга бер бирелә дер. Ә бәлки, бөтенләй бирелмидер. Әнә, көрдләрне кара: ничә гасыр кан коеп сугышалар, ә халкы төрле дәүләтләрнең чикләре белән бүлгәләнгән килеш кала бирә.

Хәкимәнең күзләре очкынланып китте, йөзе алланды.

— Мондый форсатны ычкындырырга һич ярамый. Бар булган көченне, куәтенне биреп тырышырга кирәк. Үзен татар баласы дип санаган һәркем мәйданга чыгарга тиеш. Артистлар, шагыйрьләр, жырчылар шунда. Вафирә Гыйззәтуллина нинди ялкынлы чыгышлар ясый. Мескенне беркөнне милиционер типкәләгән. Әмма туктамый бит, һаман үз юлында. Кечкенә генә Эстония, Латвия бөтен СССРны тетрәтә. Чөнки халкы бердәм, олысы-кечесе сүзен әйтергә урамга чыккан. Безгә бердәмлек житми. Нуриевны да читкә тибәрергә ярамый дип саныйм. Яшь бит әле, өйрәтербез. Буыны ныгып китәр... — Аннары бераз тынып торды да: — Бәлки... — дип өстәп куйды Хәкимә.

— Син митингларга йөрисеңме соң? Бер дә күзгә чалынганың юк.

— Ә мин ни эш майтара алам?

— Эш майтарганнарга куәт биреп торыр иден. Баш санын арттырып булса да. Сөекле жырчыбызны типкәләргә килгән милиционерның юлына аркылы басар иден! Бер-беребезне якларга кирәк!

* * *

Бу сөйләшүдән соң Әминәгә үзенең борчулары Әмирнең мәшәкатьләре янында бик вак булып тоелды.

Менә очрашсыннар гына, Әминә аңа борчу китергәне өчен гафу үтенер. Алдан уйламыйча, буйга узганы өчен... Ярдәмчесенә кат-кат шалтыратканы өчен... Югары Совет ишеге төбендә сагалап йөргәне өчен... Гафу сорар һәм, инде хәзер борчылырга сәбәп юк, алдагыны уйлап-исәпләп хәл итә алабыз, дияр. Аны сөендерер. Кочагына сыенып һәм онытылыр.

Бу уйлардан аның бөтен тәне кызышып, башы әйләнеп китә иде. Ничек сыенырын, аның тәненә ничек сенеп бетәчәген күз алдына китергәндә, ул үзләрен стенасы тоташ тәрәзәдән торган затлы бүлмәдәгедәй, патша сараендагыдай хис итә иде.

Ләкин... бер үк суга ике тапкыр кереп булмый, дигәннәре хак икән шул. Аларның очрашуы бөтенләй дә Әминә күз алдына китергәнчә булып чыкмады.

Әйе, ул сөйгәненең көрәшеннән дә, жиңү тантанасыннан да читтә калды. Хәтта үзенең бердәнбер тавышын аңа бирү хокукыннан дә мәхрүм иде, чөнки кулына бирелгән бюллетеньдә бүтәннәрнең исеме язылган иде.

...Көткән көн ниһаять килде — ул Әминәне тулай тораактагы бүлмәсеннән кич карангы төшкәч чакырып чыгарды. Әминә кабаланып, халаттан килеш, иңенә курткасын гына салып, атылып чыкты. Әмир аны кочагына алды да, аркасы белән стенага терәп, бөтен тәне белән кысып, онытылып-шашып үбәргә тотынды. Әминәнең сулышы капты, вакыт саны югалды. Күпмедер мизгелләрдән соң аяк тавышлары ишетеп, айнып киткәндәй булдылар. Тын ишегалдында бер узгынчының шәүләсе күренде.

Тулай торакның каршысында киң ишегалды, аның уртасындагы «Комсомолец» кинотеатрының беркатлы бинасы биегәеп үскән тупыл, каен, миләш, шомырт агачлары белән уратып алынган. Жәен алар куе ябалдашлы булса, хәзер инде шәрәләнеп калганнар, уртадагы мәйдан, балалар өчен атынгыч-карусельләр, волейбол мәйданчыгы ярым карангылыкта да аермачык күренеп тора. Алар артында түгәрәк беседка шәйләнә.

Алар шуңа кереп, такта эскәмиягә утырдылар.

— Мин шулхәтле сөендем. Очып барып котларга ашкындым, тик ярамас дип уйладым... — дип пышылдады Әминә.

— Булды, — диде Әмир очынып. — Юллар ачылды. — Ул кулын Әминәнең курткасы эченә шудырып, бармакларын эче турында уйнатты. — Билбауга сыймый башладыңмыни инде? Нишли анда минем малай?

Әминә кинәт үзен эченә чүбек тутырылган чүпрәк капчык кебек тойды. Буш, жансыз, хәлсез, хиссез, телсез курчак.

— Ә нишләп син малай дип уйлыйсың? — дип телен әйләндерергә мәжбүр итте үзен.

— Синең белән миннән малай тумый кем тусын? Күр дә тор, жиде улыбыз булачак безнең. Әкияттәгечә. Борын-борын заманда, кәжә команда, саескан сотник, үрдәк үрәтник булган чагында, яшәгән, ди, булган, ди, Әмир белән Әминә дигән ир белән хатын. Аларның жиде улы булган, ди. Жидесе дә зирәкләр, унганнар, Алып батыр кебекләр. Без үстергән балалар жебеп тормас! Басса бакыр изәрлек, типсә тимер өзәрлек жиде Нуриев. Юк, алай гына аз! — дип кулларын киң жәеп, башын югары чөйде Әмир. — Булгач-булгач ун булсын, безнең өйдә тупырдап ун Нуриев үссен! Герой

ана орденын тактырам мин синең күкрәгенә! Әллә каян балкып, елтырап торсын!

Ул очынганнан-очынды, анын саен Әминәнең күнеле убыла барды.

– Озакламый Мәскәүгә китәбез. Анда депутатларга аерым фатир бирәләр. Үзәктән, иркенне, унайлыны.

Ах, бу сүзләр ике атна элек әйтелсә икән! Кош тоткандай куаныр иде Әминә. Әмма хәзер... Уйлар буталып китте.

– Мин бара алмам шул... – диде ул иреннәрен чак ачып.

– Нишләп? Редакторың көчләп тота алмас, барыбер декретка китәсе кеше.

– Редактордан түгел... – Әминә башын күтәреп анын йөзенә туры карады. – Мин декретка чыкмаячакмын бит...

– Бала тапканчы эштә селкенеп йөрмәкчеме әллә?

– Мин бала тапмаячакмын... Бу юлы...

– Нәрсә?! Ни сөйлисең син?

Әмир анын йөзенә иелде.

– Әйт дөресен!

– Мин... ятып чыктым...

– Кайда? Нишләп яттың?..

– Йөгемнән котылдым...

– Ничек котылдың? Кемнән?!.

Әмир берничә мизгел тынсыз торды.

– Әллә... баладанмы?

Әминә башын иде.

– Ничек алай? Кинәшмичә-нитмичә! Минем каным бит ул!

– Мин синнән сорамакчы идем... Телефонны читләр алды... Үзеңне күреп булмасмы, дип, Югары Совет янына барган идем. Син миңа шундый итеп карадың!

– Ә ни төсле итеп карарга тиеш идем мин сиңа? Үз-үзен кешегә санаган корсаклы хатын андый җирдә чуаламы? Ат дагалаганда бака ботын кыстырган шикелле... Ни калган иде анда сиңа? Сабыр ит, дип әйттем бит мин!

– Вакыт кысты... Профессор әйтте, җан иңгәнчегә кадәр бер карарга килергә кирәк, диде. Муллалар да шулай ди...

– Аларның ни катышы бар? Профессоры, кирәк булса, бала тапканда булышыр, мулласы исем кушарга килер! – Әмир торып басты, әйләнгәләде дә, мангаен учлады.

– Әллә шаярттың гынамы? Уйлап карасаң, бер төн эчендә бит... Андый хәл сирәк очрый, диләр... Шул рәвешле ялганлап, миннән көләсең килгәндер, бәлки? Шуңа күрә уйлап чыгаргансыңдыр. Тагын бер этлегең генәдер... Ә мин, тиле, ышандым тагын. Бәгыремә агулы угыңны кадап туймадың инде. Һаман мине түбәнсетәсең, кимсетәсең килде. Ник көлмисең? Ник ермыйсың авызыңны? Мин улыбыз туарына ышандым! Ялганыңны чынга алдым. Көл кинәнеп!

– Минем сиңа ялган сөйләгәнем юк, – диде Әминә нык итеп.

– Ялганласаң, мең яхшырак булыр иде!

Әмир кинәт аны беләгеннән тартып урыныннан кузгатты да:

– Ялган сүз әйтү әле ул җинаятьнең иң зурысы түгел, – диде. – Ә син, беләсеңме, нишләгәнсең? Әгәр сүзең хак булса... Кеше үтергәнсең син! Минем улымны үтергәнсең!

Һәм кинәт кизәнеп Әминәнең янагына сукты. Пыяла чылтыраган тавыш ишетелде – күзлек төшеп ватылды, Әминә үзе беседканың култыксасына янагы белән барып төште.

— Берәүнең дә, беркайчан да мина бу хәтле кабахәтлек эшләгәне юк! Булмас та! — дип кычкырды Әмир һәм беседкадан чыгып, йөгерә-атлый китеп барды.

* * *

— Тагын борчыйм инде, — диде Нәзир. — Исәнмесез. Редакциягә шалтыраткан идем, өйдә эшли, ашыгыч мәкалә яза, диделәр. — Ни булды? Тешең сызлыймы әллә?

— Тешне суырткан идем шул, — диде Әминә битен яртылаш ураган марля өстеннән киелгән күзлеге аша сынар күзен елтыратып. — Инфекция керттеләр, күрәсең.

— Дәвалыйлардыр бит?

— Дару эчәм.

— Сызлыймы? Вакытсыз килдем, ахрысы.

— Юк, сызламый. Сөйләшә алам. Уз әйдә. Утыр. Син кәгазьләреңә кара, мина түгел. Тапшырулар турында нинди фикерләр бар анда?

— Дәвам итәргә кирәк, диләр, планга керттеләр. Ә син монда тагын форманны югалткансың.

— Ә бәлки, мине экранга чыгарып тормаскадыр? Җәмилә Закировна үзе күренсә, шул җитмәсме?

— Синсез матур булмас шул, — диде нык итеп Нәзир. Сүз шунын белән бетте шикелле, егет йомышын йомышлады, инде саубуллашса да ярый кебек иде. Әмма ул урыныннан кузгалмады.

— Синең белән тагын бер мәсьәләдә сөйләшеп аласы килә иде әле, — диде. — Редакциягә килгән кешеләрне кабул итми җибәрмисез, мине генә кире бормассың ич? Көнкүрештә зур гына кыенлык килеп чыкты әле минем. Гаилә мәсьәләсе...

— Гаилә мәсьәләсендә мин профессор инде, үзең беләсең, — диде Әминә бик җитди итеп. — Урыс әйтмешли, «чужую беду руками разведу» — кешегә килгән бәла-казаны бер селтәнүдә таратып ташлыйм.

— Ишеткән идең микән, Казансу артында журналистлар өчен йорт салдылар. Кооператив. Шуннан бер бүлмәле фатирга акча түләгән идем. Фатирны, үзең беләсең, ялгызакка бирмиләр...

— Белмәгән кая, — диде Әминә. — Мин дә ымсынып караган идем дә, семьялы кешеләргә генә бирәбез, диделәр.

— Мин әнине үзем яши торган апакайга пропискага керткән идем. Ике кеше булып саналдык. Шуна исемлеккә керттеләр. Әнигә яна фатирда яшәү насыйп булмады, яртı ел элек йөрәк чире белән китеп барды. — Бу урында егет башын иеп, авыр сулады. — Тагын ялгыз калдым менә.

— Ник өйләнмисең соң?

— Әйтүе җиңе-ел, — диде сузып Нәзир. — Бер тапкыр авыз пеште бит инде минем.

Дөресен әйткәндә, Әминә бу егетнең гаилә хәлләреннән бихәбәр иде. Күпләр белән аралашырга туры килә, кайсы артистның нинди рольләр уйнаганын, җырчыларның ничек җырлаганын, рәссамнарның нинди картиналар язганын белә, каләмдәшләренең әсәрләрен укый, телевизордан, радиодан тапшыруларын күзәтеп барырга тырыша. Әмма кем белән яши алар, кемнең хатыны нинди дә кайсы кемнең ире — болары аны бөтенләй кызыксындырмый иде. Юл уңаеннан колакка чалынса гына. Бу егетнең йөрәген җилкеткән-сыкрандырган җилләр дә, аңа бөтенләй кагылмыйча, читләтеп искән икән.

— Аерылышканда фатирны аңа калдырырга туры килде, — диде Нәзир эченнән авырлык белән суырып алгандай.

— Ә ник аерылдыгыз?

— Анысын сорау җиңел, аңлатуы авыр.

— Ә балагыз?

— Бала булмады. Тату яши алмадык, бер кычкырышканнан соң ул миңа әйтми-нитми генә ике көнгә больницага кереп чыкты да шуның белән вәссәлам.

Бу сүзләрне ишеткәч, Әминә башындагы бәен төзәткәләгән булып, аска иелде.

— Бүтән булмадымыни?

— Бүтәненең булганын көтеп торыр хәл калмады.

— Бәлки, килешерсез әле.

— Берәүне йортка керткән инде ул.

Нәзирнен бу хакта сүзне озайтасы килми иде.

— Шул хәлләрдән соң кооперативка көчәнергә туры килде дә инде. Бушлай фатир алу миңа бүтән тәтемәячәк. Хәзер менә йортны, ниһаять, тапшырганнар. «Вечерняя Казань» газетасының хезмәткәрләре исемлектә шактый икән, алар бик каты чапканнар, горсовет белән ике тапкыр судлашканнар. Югыйсә, бездән тагын акча каермакчылар иде.

— Димәк, озакламый өй туе булачак, — диде Әминә.—Котлыйм!

— Котлаганчыга кадәр хәл итәсе мәсьәләләр бар әле монда. Исемлекне тагын барлыйлар, тикшерәләр. Ялгыз калганымны белеп алсалар, шундук сызып, бүтән кешене язып куячаклар. Мондый очракта син нинди киңәш бирер идең?

— Әйттем бит инде, өйләнергә кирәк!

Нәзир аның марля астыннан җемелдәгән күзенә озак кына карап торды.

— Син үзең... фатирга кияүгә чыгар идеңме? — дип сорады ул һич көтмәгәндә.

Әминә ихтыярсыздан кеткелдәп куйды.

— Шул-шул менә, — диде Нәзир.

— Фатирга кияүгә чыгучылар бар ул. Бик кирәк булса, үзара килешәләр дә фиктивный брак ясыйлар.

— Үзем дә уйлаган идем. Тик аның кешесен табарга кирәк бит! Хәзерге хатыннарга ышансаң! Фатирыңнан куып чыгарырга да күп сорамыйлар!

— Хатын-кызга ышанычың булмагач, ник минем белән сөйләшеп утырасың?

— Гафу, ялгыш ычкынды. Онытылып киткәнмен. Син егет кеше. Моны һәркем белә.

— Комедия уйнар өчен егет кеше кирәкмени? Телевидениегә күпме артистлар килеп йөри. Шуларның берәрсе белән сөйләшеп кара!

Нәзир аңа өздереп карады да башын иде: бу хакта сүз озайтуның мәгънәсезлеге көн кебек ачык иде.

* * *

Аның тозсыз тәкъдиме Әминәнең күңеленә бер олау ком китереп аударгандай итеп, авыр уйларга салды. Кем инде дустының йөргән кызына, ЗАГСта языйлышыйк, дип әйтә?! Юри-мырый гына булса да. Шундый ахмак сүз сөйли икән, димәк, Әмир белән Әминәнең арасы бозылганын белә, диган сүз. Һәм, кайчан да булса суынырлар да үзара килешерләр, дип тә уйламый!..

...Беседкада булган фаҗигадан — әйе, шулай, Әминә өчен андагы хәлләр аяныч кына түгел, чын-чынлап фаҗига булып тоелды — шуннан соң алар очрашып, ачылып сөйләшмәделәр. Әминә аны суыныр, аңлашырга теләр дип өметләнгән иде. Ярата бит, сагынырга тиеш иде!..

Әмма ул килмәде. Төптәнрәк уйлап карасаң, чакырсаң да, ялынсаң да килмәячәге, ни әйтсәң дә фикере үзгәрмәячәге көн кебек ачык иде бит инде. Холкы кыска, мин-минлеге көчле. Агач башын җил бора, адәм башын сүз бора, дигәннәр. Әмма егет солтаны Әмирнең башын борырлык сүзләр табылыр иде микән?

Әминә эшеннән юаныч табарга тырышты.

Яңа ел бәйрәмнәреннән бер атналык ялы узуга, телевидение тапшыруы ясар өчен авылларга барырга кирәк иде. «Жигули»да дүртәү юлга чыктылар: оператор Николай, редактор Нәзир, тапшыруның авторы Әминә һәм илле яшьләрдәге кечерәк буйлы тиктормас телле шофер Рәшит. Багыш район больницасында профессор Ильясованың методын күптән кулланалар икән инде, андагы бер табибә шул темага кандидатлык диссертациясе дә яза башлаган. Туры шунда барып төштеләр.

...Бер көн район хастаханәсендә узды, икенче көнне аннан егерме чакрымдагы участок хастаханәсендә булдылар, иң соыннан, кичкә каршы Кадрәк авылының медпунктына киттеләр. Әминәгә нәкъ менә авылга кайту — зур каланың ыгы-зыгысыннан, тозлы ком сибелгән урамнарның сорылыгыннан, машиналар ташкыныннан котылып тору кирәк булган икән дә. Дөньяның киңлеге, аклыгы, сафлыгы җан җәрәхәтенә иң яхшы дәва бит ул. И, бу кышкы сахраларның шифасы! Җиле дәртләндереп, чеметтереп кенә исә, кояшы назлап кына нурын сибә. И, ул асылташлар белән чигелгән ак келәмдәй җемелдәп, җәйрәп яткан сахралар! Юл буйларында сыкыга уранып утырган каен-усаклар, яшел учларына кар мендәрчекләрен күтәргән купшы чыршы-наратлар! Һәммәсе иминлек, тынычлык, гүзәллек мисалы. Әрнү-газаплар үтәр дә онытылыр, кире әйләнеп кайтмас. Ә офыкларга кадәр һәм аның артына җәелгән, сокланып туймаслык манзара мәңгелек. Һәм син дә шушы яшәеш тантанасының бер кисәкчеге... Күзләр яктыра, сулыш иркенәя, күңел очына.

— Карале, салават күпере! — диде Нәзир сулга ишарәләп. Чыннан да алтын тәлинкә кебек яктырган кояш янында сары-кызыл-шәмәхә нур тасмалары сузылган иде. Озын түгел, бик үк җитә дә түгел, бер урында укмашкан аксыл болытларны гына манганнар, әмма шулкадәр тансык, ирексездән елмаясың.

Күңел хушлыгы юлдашларның һәммәсен бертигез биләп алган, берберсенә якынайткан иде. Аннары тагын шунысы: алар үзләре дә кешеләрнең күңелен күтәрә торган эш белән йөриләр иде бит. Телевизордан матур булып күренү, ил каршында макталу — һәркем өчен бәйрәм бит ул!

Медпунктның алгы ягында олы көзге тора икән. Керүгә Әминә хатын-кыз гадәте белән аның каршына барып басты да алтын кысалы көзгегә сөрткәләде. Ак якалы яшел пальтосының изүен ачты. Пальтосын ул тулай торак белән янәшә йорттагы ательедан тектереп алган иде. Андагы йомры чал башлы, тәбәнәк гәүдәле яһүд абзый Иллә дә шәп тегә инде! Кышкы калын кием үзе, ә буй-сынны шундый зифа күрсәтә!

Әминә ак төлке бүреге астыннан дугайланып бөселеп чыккан чәчләрен төзәткәләде. Шунда артына килеп баскан егетне күреп, сискәнеп китте. Кистереп, ниндидер бер сихри нурын сибеп карый иде аның зәңгәр күзләре. Салават күперенең зәңгәр нуры кебек куерып, тирәнәеп киткән иде ул күзләрнең төсе. Әминәнең салкыннан алланган бит очлары тагын да әчтән пешеп киткәндәй булды. Алар ничәдер мизгел шулай бер-берсенә көзге аша карап тордылар, сүз әйтергә телләре тибрәнмәде. Ниһаять, Нәзир куян бүреген салып учына йомарлады да эчкә узды.

Илле тирәләрендәге йомры гәүдәле фельдшер Нурия, нык дулкынланган булса да, үзен кулга алырга тырышты, камерага карап, медпунктның

күптәннән эшләп килүе, соңгы вакытта кирәк-ярак, дарулар белән яхшы тәэмин ителүе, үзенең хезмәтен яратып башкаруы турында сөйләде. Күршедән берничә кеше чакыртып кертеп, алардан да сүз әйттерделәр.

Эш беткәч, Нурия кунакларны үзенә чәй эчәргә чакырды. Алты почмаклы өйдә ире белән яшәп яталар икән. Хуҗа кеше Марс — механизатор. Ике уллары йорт салып, башка чыкканнар.

Табында авыл сые: токмачлы аш, бәлеш, катык-каймак, бал.

— Теге... арыш мае дигәнең мунчадан соңгарак куярбызмы әллә? — дип елмайды хуҗа иреннәрен сыпырып.

— Мунча дисеңме? Анысы да бармыни әле?

— Шәһәрдән килгән кунакны мунча кертми җибәрергә, без алай мәнсез түгел... Байтактан өлгертеп куйдым инде. Әнисе, иденең юып чыгарга кирәктер анда.

— Хәзер, хәзер! Себеркеләрне дә барлармын.

Әминә, юлга кузгалыйк, дигән иде дә, Николай:

— Төнгә каршы юлга чыгу яхшы түгел, — диде.

— Кая ашыгасың? Балаң елап ятмыйдыр бит? — диде шофер Рәшит.

— Әзер мунчаны ташлап китү сансызлык була, — дип, хуҗага борылды Нәзир. — Сезнең себерке нинди: каенмы, имәнме?

— Кайсын телисез. Мәтрүшкәсе дә мунча алдында эленеп тора. Кергәч күрерсез. Тастымаллар да шунда.

Егетләр дәррәү кузгалдылар.

— Хәзер чабынып, чыгып карда аунап, тагын чабынып... Эх, бар икән рәхәт чигәселәр! — диде Рәшит.

Алар чыгып киткәч, Нурия керде дә, гаҗәпләнеп:

— Үзең генә калдыңмыни? — дип сорады.

— Калмый нишлим? Өч ир белән мунча кермәм бит инде.

— Соң сезне ир белән хатын дигәннәр иде бит.

— Кайсының хатыны?

— Шәрифҗановныкы.

— Кем сөйли аны?

— Районнан шулай дип әйтеп җибәрделәр.

Әминә башын чайкап куйды, ни «ә», ни «җә» дияргә яхшысынмады. Дөрес сөйләмиләр, гайбәт, дисәң... Табыннарда гел янәшә утыралар, чөнки сөйләшәсе сүзләр, киңәшәсе мәсьәләләр бетеп тормый. Бәхәсләшәләр, турсаешалар, килешәләр, көлешәләр. Бу икәү бер пар икән, дип уйлаулары гаҗәпмени? Күренеп тора: оператор белән шофер алар кушканны гына үтәп йөри.

Әминә бу сорауны җавапсыз калдырдым да шома гына котылдым, дип уйлаган иде дә, әмма ялгышты. Алар хакында сүз бөтен районга таралган иде инде.

Мунчага ул соңрак, ялгызы кереп юынды.

Йоклар чак җиткәч, тагын бер четерекле хәл килеп чыкты: фельдшер, үз өендә дүрт кунакка бик унайлы булмас дип, алдан ук тагын бер фатир әзерләп куйган икән. Нәзир белән Әминәне шунда озатып куйды.

Алты почмаклы искерәк кенә йорт, өйдә хуҗа хатын ялгызы гына иде. Алгы якта табын әзерләгән — аш өлгерткән, чәй куйган. Сые мул, әмма сүзе аз иде, шактый йомыкый булып чыкты апакай, үзенең тормыш хәлләре турында сөйләшәсе килмәгәне сизелде.

Авылның фельдшерын, аның ирен, улларын мактаудан узмадылар.

Табын янында озак юанмадылар, хуҗабикә түр якның ишеген киң ачып, кунакларны шунда уздырды да, тыныч йокы теләп чыгып та китте. Чиста итеп җыештырылган бүлмәнең уңында акшарлаган мич, каршыда өстәл, сулда күпертелгән мендәрләренә челтәр ябылган киң карават тора иде.

Әминә аптырабрак калды. Кем кайда йоклар соң? Ул инде борылып чыкмакчы иде, Нәзир:

— Монда тагын бер кешелек урын бар, — дип аны туктатты. — Бер кичкә, кер мичкә дигәннәр, мин мич артына да риза.

Чыннан анда тар гына ятак бар икән. Мондый җирдә сайлана алмыйсың. Соңгы елларда авылларда, кунарга безгә кайтыгыз, дип чакыручы сирәк, дип артистлар да зарлана. Эреләнде халык, йөрәген май басты. Фатирга шул ялгызлар, фәкыйрьрәкләр кертсә генә инде.

Шулай итеп, Нәзир мич артына посты, Әминә караватка ятты. Талчыккан иде, шундук йокыга талды.

Берзаман кемдер колакны ярып акырып җибәрмәсенме: «А-а-а!...» Әминә сикереп торып утырды, коты очып, караңгыга төбәлде: берәрсен үтерәләрме әллә? Мич артыннан шапылдаган, мышнаган авазлар ишетелде. Кем нишли анда? Ишек ачылып китте, халат төймәләрен эләктерә-эләктерә хуҗабикә керде. Ә мич артыннан чәче-башы тузган Нәзир атылып чыкты, аның артында, битен кара төк баскан бер адәм күренде.

— Ни булды? Ник шаулыйсыз? — диде коты очкан апакай.

Баксаң, аның буйдак улы бар икән, шул кайдадыр салып йөргән дә төн уртасында гына кайткан. Мич артындагы ятак аныкы икән. Ул гадәтенчә утны кабызып тормаган, мыштым гына кергән дә лап итеп ятагына утырган. Изрәп йоклап яткан кунакның корсагына... Нәзирнең ипле генә күренгән авызыннан шулкадәр котсыз акыру ничек чыккандыр!

— Мин сезгә урынны бергә җәйгән идем бит, — дип быдырдады тәмам нәүмиз калган хатын. — Ир белән хатын бер караватка сыярсыз, дигән идем.

Нишләп була иде инде бу хәлдә? Кемгә кая ятарга?

Сәрхуш хуҗа сүзгә катышмыйча мич артына кереп күздән югалды, апакай, үзалдына нидер сөйләнеп, көрсенгәләп, чыгып китте. Нәзир белән Әминә бүлмә уртасында басып калдылар. Нишләргә инде хәзер? Көйсезләнеп чыгып китәр идең дә бит, төн уртасында кемнәрнедер йоклап яткан урыныннан кузгатып, урам буйлап фатир эзләп йөри алмыйсың.

— Бир бер мендәрне, — диде Нәзир. — Идән калды инде миңа болай булгач...

...Иртүк чәй эчеп, хуҗаларга рәхмәтләр әйттеләр дә туп-туры администрациягә киттеләр. Район башлыгы эш урынына җиледә килә, шунда тотып алмасаң, каядыр чыгып китүен көт тә тор.

Зур кабинетына тәңгәл мәгърур кыяфәтле, олы гәүдәле, зур башлы, ник кына чаларган куе чәчле, иллеләр тирәсендәге Радик Фоатович аларны якты чырай белән каршы алды. Районны яхшы яктан күрсәтергә килгән кешеләрне алар ярата! Гаеп эзләп кенә йөрмәсеннәр!

— Кая барсак та бик яхшы кабул иттеләр, хастаханәләр дә, медпункт та бик әйбәт эшли икән. Телевидение тапшыруы кызыклы булыр, дип өметләнәбез, — диде Нәзир. — Безнең эш җиңел барды. Зурлап кунак иттегез. Мең рәхмәт.

Аннары һич көтмәгәндә Әминәгә борылды да:

— Минем монда Радик Фоатович белән ирләрчә сөйләшә торган сүзем бар иде, — диде.

«Мөгаен, телестудиягә яңа камера-фәлән алыр өчен акча сорыйдыр», — дип уйлады Әминә. Андый сүзне тыңлап утыру күңелле түгел, ул кузгалып, саубуллашты да, урамга чыгып, машинага ук кереп утырды.

Администрациянең өч катлы ак кирпеч бинасы каршында, сыкы сарган агачлар белән әйләндереп алынган мәйдан читендә берничә машина тора. Көн аяз, әмма артык салкын түгел, җил исми. Офык сызыгыннан аерылып

өлгермәгән кояш ак дөньяны жанга рәхәт итеп яктырта, алдагы көннең күңелле үтәчәген вәгъдә итә кебек иде. Бернинди ыгы-зыгы, ашыгу, борчылу, хафалану юк, һәммәсе имин, күңелгә ятышлы. Узган төнне булган матавык та үзенә бер кызык булып тоела, җан ярасыннан кан сарку туктаган иде шикелле.

Әнә, Нәзир дә курткасын төймәли-төймәли ишектән авызын ерып чыгып килә.

— Булды!

— Күпме бирде?

— Нәрсәне?

— Акча сорагансыңдыр бит.

— Нинди акча? Чык әле монда, бер сүз бар, — дип, Әминәгә кулын сузды ул. Аннары терсәгеннән тотып, Рәшит белән Николай ишетмәсен өчен, бәс сарган каен янынарак әйдәде. Куртка кесәсеннән сигарет кабы алып авызына капты, зажигалкасын чыгарып кечкенә ялкын телен биетеп кабызды. Моңа кадәр ул Әминә янында тәмәке тартмаска тырыша иде. Ни булган моңа? Ни дигән район башлыгы?

— ЗАГС мөдиренә шалтыратып сөйләштек. Унбиш минуттан безне анда көтәләр, — дип каен ябалдашына төтен өрде ул.

— Анда нинди сюжет төшерәбез инде? — дип сорады Әминә, күңелендә кузгалган шомны сиздермәскә тырышып, мөмкин кадәр битараф тавыш белән.

— Хәзер барсак, язылыштыралар да куялар.

Әминә телсез калды.

— Син анда кем белән барасың?

— Бөтен өмет синдә инде. Йә фатирлы итәсең, йә куышсыз калдырасың. Тагын егерме-утыз елга...

Нишләтәсең инде бу кешене? Чыннан да Казанда утызар ел фатир көткән гаиләләр тулып ята.

— Шәйхразиев мине аңлады. Аңа безнең бер фатирда кунганыбызны ирештергәннәр инде. Борын астыннан елмайды да: «Буласы булган, буявы сеңгән бит инде сезнең, ди. Язылышып бик дөрес эшлисез, ди. Яшьләрне әхлаклы итеп тәрбияләү өчен бер матур үрнәк бу, ди...» Ә син үзең кара. Бирәү дә сине мәҗбүр итми... Теләгән чагыңда аерылышуын оештыру да әлләни читен булмас дип уйлыйм!

Әминә Нәзиргә яны белән борылып, карашын сыкы авырлыгыннан бөгелгән каен тармакларына төбәде. «Бармыйм да йөрмим дә, мин сиңа бер әйттем бит инде!» — диярге кирәк иде. Әмма аның кысылган керфекләре аша төбәлгән карашы каен ябалдашы аркылы берәүнең йөзен күрде шикелле. Күңелдә тавышы терелде кебек. Утлы күмердәй көйрәгән күзләр, хәнҗәр кебек бәгырьгә кадалган сүзләр! «Әй син! Чиксез-чамасыз кыланмышларыңнан соң егылып ятар дип уйладыңмы мине? Зарый-зарый елар дип күз алдыңа китердеңме?.. Җебеп ага торганнардан түгел мин! Синең бәгыреңә дә бер ук кадалсын әле! Карарбыз, нишләрсең икән!»

Бу уй ЗАГС бусагасын атлап кергәндә дә, кызыл тышлы папкадагы кәгазьгә кул куйганда да аның күңелен җилкендерде, йөзендә ачы да, шаян да елмаю уйнатты.

Котлаучы булмады, оператор белән шоферга анда ник кергәннәрен әйтмәделәр, машинада гына көтеп утырырга куштылар. «Тиз чыгабыз», — диделәр.

Шампанский ачылмады, балдаклар кигезелмәде. Әмма ЗАГСта утырган бөдрә чәчле, ыспай киемле түгәрәк битле апаның моңа исе китмәде.

— Шәһәрдән монда кайтып язылышучылар булгалый шул, — диде.

— Төрле кешенен төрле сәбәбе. Ахыры ун булсын. Котлыйм. Кавыштырырга без бик риза, аерылышырга гына монда кайтып йөрмәгез.

Әлбәттә инде бу — юри-мырый кылану, Нәзиргә — фатир алу өчен, Әминәгә Әмирне үчекләү өчен генә кирәк иде. Һәрхәлдә ул үзе шулай дип уйлады.

Казанга кайтып төшкәч, алар икесе ике якка, үз юллары белән китеп бардылар.

* * *

Әмма, без капчыкта ятмый, дигәннәре хак шул. Атна-ун көннән Әлфия Зарифовна Әминәне бүлмәсенә чакырып алды.

— Утыр әле, — диде гадәтенчә. — Карап-карап торам да, тагын бер карап куям әле мин сиңа. Йөрәгең каләмеңнән дә йөгерегрәк түгелме? Әле бер егет белән әвәрә килгән идең, ул арада икенче берәүгә кияүгә чыккансың, дигән сүз йөри. Хакмы?

— Ул болай гына бит, Әлфия Зарифовна! Шәрифҗановның фатир алыр чагы житкән... Әнисе үлеп киткән...

Ул бутала-бутала хәлне аңлатырга тырышты. Редактор очлы күзе белән аңа текәлгән иде.

— Син нәрсә, фиктивный брак ясадык, димәкчеме әллә?

— Фатирын гына алсын, шундук аерылышабыз!

— Вакытлыча күз буяр өчен бүтәнне таба алмаганмы? Ә син акылың белән ахырын уйлап карадыңмы? Миең бармы? — Әлфия Зарифовна бармагын чигә турысында боргалады. — Син ул фиктивный брак турында авызыңны ачып берәрсенә ычкындыра күрмә тагын. Хөкүмәтне алдау бу! Закон бозу! Мошенничество дип атыйлар аны. Берәрсе тиешле урынга житкерсә, җавапка тартуларын көт тә тор. Безнең редакциягә судимый хезмәткәр кирәкме?

— Минем шәхси эшем лә бу...

— Журналның битенә дегет сылауга тиң гамәл бу, беләсең килсә! Бер көнне кушылып, икенче көнне аерылып йөргән җилбәзәк хатын ни йөзе белән бүтәннәргә, әхлаклы булыгыз, дип акыл өйрәтә ала? Син — публичный кеше. Тырнак астыннан кер эзләүчеләр житәрлек. Башка берәү булса, сөйләшеп тә тормас идем, юлыңа ак җәймә, дип чыгарып кына җибәрер идем. Әмма синең каләмең егәрле. Башың эшли, йөрәгең кайнар. — Ул уф итеп көрсенеп куйды. — Их, акылың да төплерәк булып, дуамаллыгың булмаса! Алдын-артын уйлап житкермичә, әллә ниләр эшләп ташлыйсың!

— Бәлки, бу язылышуны берәр ничек юкка чыгарып буладыр?

— Буладыр. Суд аша. Андый җирдә дә таптаныр идеңме әллә? — Редактор бераз тынып торды. — ЗАГСта, Шәрифҗановка кияүгә чыгарга риза, дип әйткәнсеңдер бит? Фамилиясен дә алыштыргансыңдыр...

— Үз фамилиямдә калдым.

— ЗАГС кәгазьләренә кулыңны куйгансыңдыр бит?

— Куйдым.

— Рас кул куйгансың икән, хәзер әллә ни дисәң дә Шәрифҗановның законный хатыны инде син. Беркая бара алмыйсың. Туйсыз-нисез кавышу дәрәҗәгезне күтәрми, билгеле. Әмма анысы әлләни зур гаеп түгел. Тату яши алсагыз, бирсен Ходай, туйларыгыз күп булыр әле. Мәкаләләреңдә үзең дә язасың бит: бәби туйлары, ситсы туй, бәллүр туй, көмеше, алтыны...

Шулай дип, урыныннан кузгалды да якын ук килде ул. Әминә дә торып басарга мәҗбүр булды.

— Ну что ж, тәбриклим! — дип, аның ике кулын учлап селкеде редактор.

— Мина ул егет ошый. Сөйкемле сөяге бар. Ипле-җайлы күренә. Кадерен белсәң, унарсың! Шунысын да әйтергә кирәк: тиле мәхәббәт кабына да сүнә ул. Ә менә дуслык — гомерлек. Рас инде син анның хәленә кергәнсең икән, димәк, дус күрәсең дигән сүз!

Ул шундый итеп сөйләнә, әйтерсең лә, Әминәнең фиктивный брак турындагы сүзләренә ышанмаган, ышанса да, җитдигә алмаган иде.

Кияү яңа фатирына күчте, көләш тулай торагында яшәп ятуында булды. Ахыр чиктә мәсьәләне Әмир хәл итте.

...Газеталар РСФСР Югары Советы депутаты Нуриевның туе турында язып чыктылар. Зур итеп фотосурәтләрен дә куйганнар. «Бигрәк пар килгәннәр инде!» — дип сокланырлык, кызыгырлык иде. Фәрдиянең сүзе дөрес — открытка итеп сатарлык сурәтләр иде алар.

Шуннан соң Әминәнең күңелендәге соңгы өмет чаткысы сүнде.

* * *

Җомга көн эштән соң автобуста кайтып барганда, ул, уйларына чумып, үз тукталышын узып киткәнен сизми калды. Әмма утырган урыныннан сикереп торып, ишеккә ташланмады. Ашыгасы җире, көткән кешесе юк иде бит. «Кая кадәр бара икән бу автобус? — дип уйлады. — Күптән ул якларда булган юк. Карап кайтырга инде әллә...»

Юл ерак, әйләнеч булып чыкты. Автобус шәһәр урамнарыннан чыгып китеп, өч зур завод яныннан урады, кешеләре төшеп беткәч, шактый туктап торды. Талчыккан чырайлы кондуктор хатын бер ялгызы утырып калган Әминәгә: «Нишләп йөрисең вакытыңны бушка уздырып? Эшең юкмыни?» — дигәндәй, кистереп карап алды.

Тулай торакның ишек төбендә куртка-чалбар кигән, юан гәүдәле комендант Хөршидә басып тора иде. Кулында авыр сумка.

— Кайда йөрисең син? — дип, калын кара кашларын җыерып, Әминәгә каршы атлады ул. — Авылга китәсе бар, автобуска өлгермәм, дип куркам.

— Исәнмесез! Ник кирәк мин сезгә? — дип гаҗәпләнеп сорады Әминә.

— Оныттыңмыни, иртәгә утыз беренче март лабаса. Квартал үтте, бездә яшәү срогың бетте. Яңа кешегә ордер биргәннәр. Бүген килеп күренеп китте. Дүшәмбедән эшкә чыгачак икән, якшәмбе килеп урнашам, диде. Ял көннәрне мин булмыйм, шуңа күрә чиста җәймәләрне бүген кертеп куйдым. Аларга орынма. Иртәгә караватны бушатып куй.

Аның сүзләре Әминәне сискәндереп җибәрде. Ничек була соң әле бу? Башка чакта, вакытың чыкты дип, болай тыкырдатып кумыйлар иде бит. Яңа ордерны икешәр атнага соңарып биргән чаклары булды.

— Нәрсә сөмсерең коелды! — диде комендант Әминәнең хафага төшкәнен күреп. — Профкомдагы хатыннар синең хакта, фатирлы егеткә кияүгә чыккан, дип сөйләделәр. Үз өең, үз ирең була торып, бу рәвешле типкедә йөриләрмени? Кавышып бетмәс борын талаштыгыз дамы әллә?

Хөршидә бер тын тынып торды да, җавап булмагач, сүзен дәвам итте:

— Вахтерга әйттем, әйберләреңне чыгарышырга булышыр. Бәлки, тиз арада очрашып-күрешеп тә булмас, сау бул. Тазалыкта, муллыкта яшәргә язсын!

Шулай дип, Әминәнең хәлсез салынып торган кулын тотып селкеде комендант.

...Аннан соңгы төн — сагыш белән, көн вак-төяк мәшәкатьләр белән узды: бар булган әйбер-караны юып, киптереп, үтүкләп, төреп-төйнәп куярга кирәк иде. Кичен, тулай торакның душында гына пычтырдыйсы килмичә, мунчага китте. Анда озаклап парланды, тәнен авырттырыр дәрәҗәдә кизәнә-кизәнә, кат-кат чабынды.

Кайткач, бүлмәдәш кызлар белән сүз озайтып тормады, чәй кайнатып эчте дә урынына сузылып ятты.

Төн карасы авыр уйларны куертты. Хәршидә тутәй кебекләргә: «Үз өен, үз ирен бар», – дип әйтү жинел ул. Ләкин асылда берсе дә юк бит. Өе дә аныкы түгел, ире дә... ЗАГС язуына имза берәүгә ярдәм күрсәтү өчен генә сырланды. Инде хәзер, шул яхшылыгым өчен мина фатирынның яртысын бир, дип бусагасына барып басаргамы? Ни йөзең белән?..

Иртән кызлар кайсы кая үз эшләре белән таралыштылар. Әминә ин килешле киемнәрен – озын кара итәген, ялтыравык җепләр белән чигелгән, сирень төсендәге йөнтәс свитерын киде. Соңгы вакытта мондый матур киемнәрне Төркиядән алып кайтып сата башладылар. Инбашларына сырлар куеп, мул итеп тегелгән күн курткасы да шуннан. Ак береты, кара ботинкалары да. Киеменә карасаң, кемнең кадерлесе икән бу, диярсең...

Әминә чемодан-төргәкләрен аяк очына тезеп куйды. Тимер караватка утырды да янә монаеп уйга талды: башны кая куярга?

Ишек шакыдылар. Әллә соң вахтер хатын аны куып чыгарырга дип килгәнме? Комендант нидер әйтеп калдырдым дигән иде кебек...

– Керегез...

Ишектә Нәзир күренде. Коңгырт күн курткасының төймәләрен ычкындырган, кара фуражкасын артка шудырган.

– Мин әле бу. Исәнме!

Әминәнең тезләре йомшап киткәндәй булды.

– Сәлам. Кер әйдә, – диде ул урыныннан кузгалмыйча гына.

Нәзир аның үзен, шәрә караватын, янындагы чемодан-төргәкләрне күздән кичерде дә, тирән көрсенеп:

– Болай ук булыр, дип уйламаган идем... – диде.

– Ничек булыр, дип?

– Квартал бетте бетүен, тик көнендә үк тыкырдатып куып чыгармаслар, дигән идем. Ял көне бит бүген.

– Шуны уйламасаң, башка гамең юк идемени?

– Бүген иртән уянгач, беренче апрель икәне искә төште. Кем көлдерер икән мине, дип уйлап яттым. Әллә үзем берәрсен көлдерим микән, дидем... Килдем менә... Кайчаннан бирле көтәсең инде мине?

Әминә аңа гаҗәпләнеп карады.

– Сине көтәм дип түгел...

– Алайса ялганла! Юри-мырый гына булса да, зар-интизар булып көттем, диген. Кайберәүләр кат-кат алдый торгач, үз ялганына үзе ышана башлый... Киттек әйдә! Боларның кайсы авыррак? – дип, тәвәккәлләп, аңа таба атлады Нәзир. – Хәзер ишек төбенә чыгарып куябыз да, машина тотабыз.

...Нindидер сүзләр әйтелде бугай, алары истә калмаган. Машина шундук тотылды, ара әлләни ерак түгел иде, тиз барып җиттеләр. Яңа йортның ишегалдында машиналар рәттән тезелеп баскан иде, ишектән ераграк туктарга туры килде. Өстән карлы-яңгыр сибәләп тора, юл читендәге керле кар көртләреннән асфальтка су аккан.

– Зонтикны аласы калган, – дип сукранып алды Нәзир.

– Ә мин әчкәрәк тыккан идем шул.

– Башканы әйтәм әле... – дип төргәкнең авырын машинадан чыгарып, ишеккә таба алып китте Нәзир.

Аңа кадәр Әминәнең бу бусаганы атлап кергәне юк иде әле. Сөтле чәй кебек көнелгә ятышлы төскә буялган коридорлар да, лифт та иркен. Беркайда кер заты юк, акшар, буяу исе күңелне рәхәт кытыклый. Өченче катта, ундагы тимер ишекне ачып кергәч, ике фатирга уртак озын гына коридор бар икән. Эчтәрәк зәңгәр бөркәвечле бала арбасы тора.

— Күршеләрнеке, — диде Нәзир эчке бер мәгънә белән. Аның тавышында ихтирам һәм бераз көнләшү чагылгандай булды.

— Болай булыр дип уйламаган идем, — диде Әминә. — Өй котларга килгәндә күчтәнәчсез яхшы түгел...

— Ниткән өй котлау ди ул. Син монда кунак түгел, хуҗа бит. Сал өсләренне.

Яна фатирга хуҗасы кергән, әмма ямь иңмәгән иде әле. Тәрәзәләргә пәрдә эленмәгән, өстәлгә яшьяулык җәелмәгән. Газ кертмәгәннәр әле, электрда пешерергә туры килә икән. Ике конфоркалы плитка майга каткан. Каяндыр юнәтелгән, шактый кыршылган ике өстәлдә дә савыт-саба теләсә ничек аунап ята.

Әминә өске киемнәрен салды да, алдына тастымал бәйләп, эшкә кереште. Иң элек плитканы тазартып ялтыратты, кабызып, чәйнек белән су куйды.

— Ни пешерим?

— Мин бәрәнге яратам, — диде Нәзир. — Кабыклыны. Көн саен пешереп ашыйм.

— Кабыклы бәрәнге күз күнә генә тәмле. Язга таба анда агулы матдәләр җыела. Кая, бир, әрчим.

— Кран астындагы тартмада. Ал шуннан.

Нәзир, артсыз урындыкта утырып, керфеген дә какмыйча Әминәгә текәлгән иде.

— Бу бәрәнгеләр кабыкларын салдырганны сизми дә калалардыр, — диде ул Әминәнең кулында уйнаган пычакка карап.

— Авылда безнең гаилә зур. Эш муеннан, һәммәсенә житешергә кирәк... Һәр кешегә өчәрдән, безнең икебезгә алты бәрәңге житә.

— Кара син аны, бәрәнге дә ялгызларга сынарлап, парлыларга парлап санала икән... — дип башын чайкады Нәзир.

...Чистарту-тазарту, ашарга пешереп, табын кору кебек мәшәкатьләрнең бу хәтле рәхәт икәнен моңарчы нишләп белмәде икән Әминә? Тәнгә — жинел, ләззәтле хәрәкәт, җанга тынычлык бирә икән ләбаса алар!

Менә өстәлгә чиста тәлинкәләр куелган, уртада ипи, бәрәнге, акмай, чәй, шикәр.

— Син гаепләмә инде, сый-хөрмәт мулдан түгел, — диде Нәзир. — Болай буласын белмәдем...

— Авыл баласына сыйның зурысы шушы бит инде!

— Алай да, әзерләп куйган бүләгем бар!

Нәзир алгы бүлмәдән озынча төргәк алып керде.

— Нәрсә бу?

— Чишеп кара!

Кәгазь эченнән зонтик килеп чыкты. Озын таяклы, вак зәңгәр бизәкле.

— Син бу өйнең бусагасын атлап кергәч, истәлекле бүләк бирәсем килде. Уйладым-уйладым да, янында еш йөртә торган әйбер булсын иде, дигән фикергә килдем... Язуы да бар. Укып кара.

Зонтикның елтыр таягына вак, матур хәрефләр белән:

«Әминәгә.

Жил-давыллардан гомерлек

Ышыгың булсам иде. Нәзирең», — дип уелган иде.

«Нәзирең...» Әминәнең тамагына нидер утыргандай булды, уйлары буталды, теле бәйләнде, хәле китте. Ә бит моны шаяруга сабыштырып, көләргә кирәк булгандыр. Көлке күнә ләбаса бүген!.. Әмма сүзләре нинди бит: «Гомерлек ышыгың булыр идем»... Әминәгә ышык кирәк! Жил-давылларда ялгызың күпме бәргәләнергә була?

Нәзир анын каршында басып тора, бүләктә язылган сүзләргә җавап көтә. Әминә зонтикны күкрәгенә кысты да башын күтәрде:

– Шигырь язарга һәвәслеген элек тә сизелә иде инде...

Әйе шул, теге чакта, Идел буенда, шаян рәсемнәр астында анын шигырьләре иде бит!

Тик моны хәзер әйтергә ярамый. Бу минутта ике арага өченче берәүне кыстырырга кирәкми.

– Шигырьләр языла анысы... Күнел кузгалганда... Әйдә, ашап алыйк әле. Бәрәнге суына!

Йа Раббым! Мондый тәмле бәрәнгене монарчы ашаганы булды микән аларнын? Ниләрдер сөйләнде... Нәзир эшләгән телевидение турында, Әминә эшләгән журнал турында. Икесе бергә ясаган тапшырулар турында... Һәммәсенен көлке, шаян яклары искә алынды.

Нәзир чәй тулы чынаягын күтәрде дә:

– Син уйлама, минем өйдә шәраб запасы бар, – диде. – Тик куймадым. Мин синең сулышыннан исерәм. Башка исерткечне кушасым килми.

Әминә керфекләрен түбән төшерде, әйтер сүз тапмады.

Менә икесенә алты бәрәңге ашалды, ике чынаяк чәй эчелде. Әминә үзе дә белештермичә, тәлинкә-чынаякларны җыештыра башлады.

– Мин хәзер... – дип урыныннан кузгалды Нәзир.

Юыну бүлмәсеннән су шавы ишетелде.

Әминә залга чыкты. Зур диван каршы якнын уртасына куелган иде. «Сулга авыштырсаң, иплерәк булыр иде, – дип уйлады Әминә. – Ә болай бүлмә урталай бүленгән кебек тоела. Япмасы нинди ямьсез тагын!»

Диванга утырырга күңел тартмый иде. Әминә төргәгендә чиста япмасы барын уйлады. «Пикейный» дип атала торган, вак зәңгәр чәчкәле. Әминә төргәктән япманы алды, диванга җәеп утырды...

Күңелен үкенеч хәнҗәре сызып узгандай итте. Ник анын юлы туп-туры шушы йортка сузылмады икән?.. Ник ул Мәскәү аэропортында янгыраган игъланны игътибарга алды, ник чакырган тарафка китте икән?..

Әгәр шундый хәл янадан кабатланып, тирә-юньне янгыратып: «Сине көтәм!..» – дигән чакыру ишетелсә, барыр идеме ул?..

Айлар буе кичерелгән җан газаплары һәм тән сызланулары йөрәккә сөрем булып сарылган... Аннан да бигрәк, яралып килгән балага җан сорап баргач, күз карашыннан атылып бәгырьгә кадалган бозлы уклар һаман эреп бетмәгән. Теге чакта дөрес әйтте Җәмилә Закировна: ничек кенә хисләнсәң дә, бөтенләй үк уйламый булмый, башның выключателе юк!

Бер кич рәхәт чиккән өчен бик кыйммәт түләргә туры килде. Һәм әле дә түли Әминә – үз хатасы аркасында бу көнгә җәрәхәтләнеп килгәне өчен вөҗдан әрнүе белән...

Шәрабларның затлысын сатып алып була, гүзәл манзараларны барып карап була... Тик югалган сафлыкны табып булмый икән...

...Шушы сәгатьтә ул, бронзадан коелып, алтынга манылган борынгы сынга охшаш егеттән ваз кичте.

Әминә күзлеген салып, өстәлгә куйды да, битен куллары белән каплады.

Нәзир сак атлап бүлмәгә керде, анын каршына басып, кулларын битеннән аерды дә иелеп күзләрен үбә башлады.

– Син бүген еларга тиеш түгел, – дип, сулышы белән өтеп пышылдады ул. – Гомер озын, тормыш катлаулы, елар чакларың булыр. Күз яшьләреңне минем күкрәгемә ятып кына түгәрсең... Ләкин бүген түгел. Син белсәң иде, ничек зарыгып көттем мин бу минутларны...

Анын сулышы Әминәнең бәгырен сызлаткан хафаларны өреп тараткандай итте. Икесенең дә җаны җылыга зарыккан, тәне назга сусаган иде. Кавышу сәгате сукты...

...Күпмедер вакыт узганнан соң, сулышы тигезләнеп, тәннең җиңеллегеннән, күңелнең яктылыгыннан рәхәтлек кичергән Нәзир, Әминәне йомшак наз белән күкрәгенә кысты.

— Синең белән җан тыныч. Мин сиңа ышанам. Син — минем тиң ярым. Кайларда йөрсәң дә, ни генә булса да, онытма мин барын.

— Онытмам. Син һәрчак минем күңелемнең ышыгы булырсың.

Аларның сулышы бергә кушылды.

* * *

Менә шушылай кавыштылар алар.

Тикшерүче каршында моны ничек сөйләп утырмак кирәк? «Башта без фатир алу өчен юри-мыртый гына язылышкан идек, аннары мине тулай торактан куып чыгардылар да, анын янына күчәргә туры килде», — дипме? Милиция теленә күчергәндә, шулай килеп чыга да бит инде. Син бер төрле сөйлисен, ә ул бөтенләй икенче төрле уйлый. «Бүтән очрашырга язмасын иде», — дип уйлады Әминә.

Әмма ул тагын шалтыратты.

— Мин сезгә белгәннәремне әйтеп бетердем инде, — диде Әминә. — Берәр яңалык булса йә нидер исемә төшсә, үзем хәбәр итәр идем. Теге юлы шулай килештек бит.

— Сездә яңалык булмаса, миндә бар, — диде Мансур Хуҗиевич. — Телисезме-теләмисезме, очрашырга туры килер.

Тавышы салкын, сүзләре кискен. Әллә... Әмирнең хәле хакында нидер әйтмәкчеме?

— Хәзер киләм!..

Моны әйткәндә Әминә тавышының карлыгыбрак киткәнен тойды.

Бусаганы атлап кергәндә тезләре йомшарып китте: тикшерүченең чырае караңгы, хәтта хәвефле күренде.

— Исәнмесез! Ни булды?

— Саумысез.

— Анын... Нуриевнең хәле... начарайганмы әллә?

Тикшерүче тырпайган кашлары астыннан аңа сынап текәлде.

— Андый сүз әйткән кеше юк.

— Аңына килгәндер бит инде?

— Хәле яхшыга бара, диделәр.

— Үзен күрмәдегезмени? Мондый очракларда тикшерүчеләр зыян күргән кеше белән мөмкин кадәр тизрәк сөйләшергә тырыша бит.

— Сез әйтмәсәгез, монарчы белми идем, — дип төрттереп куйды Мансур Хуҗиевич. — Юкка борчыласыз. Аны кайгыртучылар болай да житәрлек. Утырыгыз.

Әминә, өстәлдә сибелеп яткан кәгазьләрне күреп, сәерсенеп китте: Татар иҗтимагый үзәгенең халыкка мөрәҗәгать-өндәмәләре иде болар. Элекке елларда ябылган татар мәктәпләрен торгызу, яңа гимназияләр ачу, Дәүләт Советы утырышларын татар телендә алып бару, Хәтер көнен үткәрү, республикадан читтә яшәүче милләттәшләребезгә ярдәм итү, армиядәге егетләребезне җәбер-золымнан аралау турында. Ник кирәк икән алар милиция кешесенә?

— Без монда эзләнү мәйданын киңәйттек әле, — диде тикшерүче Әминәнең сораулы карашын тоеп. — Һәм бу мәйданда сезнең шактый сәер гамәлләр кылганыгыз ачыкланды.

— Нинди гамәлләр ул?

— Беренчедән, нинди максат белән сез милләтчеләр арасына барып кердегез?

Әминә тирән итеп сулыш алды — моны аңлату да җиңел түгел иде.

— Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты...

— Чакырып китерделәрме? Әллә үзегез бардыгызмы?

— Эшсез калган чак иде...

— Анда сезнен каләмегезгә лаек эш юк лабаса. Моның ишене сырлап бирүчеләр болай да җитәрлек, — дип, учы белән кәгазьләргә суккалады Мансур Хужиевич. — Эшне андый җирдән эзлиләр димени? Ипи пешермиләр, күлмәк текмиләр, сату итмиләр. Бар белгәннәре — халыкның күнелен кузгатып, урамнарга, мәйданнарга чыгару.

Әминә күзләрен зур ачып, исе китеп аңа төбәлде: кем баласы икәнен онытканмы әллә бу?

— Үз халкыгызның хокукларын яклауга каршымы әллә сез?

— Хокукларны законный юл белән якларга кирәк! Ә алар закон бозып ни генә кыланмыйлар! Мәйданнарга халыкны җыеп, акырыну-бакырыну дисеңме, вокзалларда милиция белән бәрелешүме, Югары Совет түбәсенә үрмәләп менеп, дәүләт байрагын алып ташлап, үз әләмен элеп куюмы!

— Үзенекен түгел, милли байракны!

— Ә ул законныймы? Кем раслаган аны?.. Күпме криминал элементлар елышты ул оешма тирәсенә! Адреналин кирәк аларга!

— Чоры шундый иде бит. Хокукларны яуларга мөмкинлек туган чак... Йә күтәрелә халкың, йә түбәндә кала...

Әминә тагын ниләрдер сөйләнде, әмма сүзләренең тыңлаучы колагына кермичә, читкә сибелгәнен тоеп, туктап калды.

— Хәер, сез листовкалар язмагансыз, митингларда кычкырынып йөрмәгәнсез, — диде Мансур Хужиевич, уйлангандай. — Моннан нинди нәтиҗә чыга? Димәк, сез анда азатлык даулау өчен түгел, башка максат белән барып кергәнсез. Нинди максат? Шуны беләсе иде.

— Мохтаҗларга ярдәм итәсе килде. Бик күпләр авыр хәлдә калган иде бит! Эш кешесенә акча түләү бетте, кибет киштәләре бушап калды. Күпме халык икмәккә тилмерә иде... Без хәйрия җәмгыяте оештырдык...

— Нәрсә хисабына? Хөкүмәт андый оешмаларга ярдәм итми, закон буенча тыелган. Каян, нәрсә алып өләшергә иде исәбегез? Үзегезгә эш хакын кем түли?

— Ярдәм кулы сузучылар җитәрлек. Тик алар белән сөйләшә белергә кирәк...

— Соранучылар сездән башка да адым саен... Күп нәрсә аңлашылмый монда, — дип үзенекен тукыды тикшерүче. — Ә менә икенче яктан килеп караганда, һәммәсе бер җепкә ипле генә тезелә дә куя. Хис кешесе бит сез, күп очракта йөрәк кушканны эшләвегез табигый. Акыл турында салкын дисәләр, йөрәк — кайнар. Анда ургыган хисләр хәтәр. Һәм гел үзгәреп тора: әле ялкын телләре булып күкләргә үрелә, әле кара күмер булып сүрелә... Хатын-кызларда бу бигрәк тә шулай. Балагыз тугач, сезне эшегездән чыгарганнар. Нуриев кушуы буенча...

— Дөрес түгел!

— Ярдәм сорап аңа баруыгыз да дөрес түгелме?

Әминәнең күзләренә яшь тыгылды. Ул башын иеп, иренен тешләде.

— Тик сезне эшегезгә кайтармаганнар, димәк, ул сезне якламаган.

Монысына каршы әйтеп булмый иде. Якламавы бер хәл... Ә менә күз карашы... Әйткән сүзләре... Тик искә төшермәскә кирәк... Тыелырга, җебеп төшмәскә...

Мансур Хужиевич текәлеп аны күзәтте. Әминәнең иелгән башы, тез өстендә бер-берсенә кысылып, агарып чыккан бармаклары анын фаразын раслый иде.

Бераз тынып торганнан соң, тикшерүче:

– Сипкән суы мул булгандыр, күңелегезне кара күмер каплагандыр. Шуннан соң сезнең аның дошманнарына елышуыгыз бик табигый!

– Нинди дошманнар ул?

– Иҗтимагый үзәктә Нуриевның дуслары утырмый лабаса! Һәммәсе милли азатлыкны яклаган булып шапырына шапырынуын да, һәркайсының үз туксаны туксан. Кичекмәстән хакимиятне алыштырырга кирәк, дип ажгыручы егетләр бар. Нуриев өстәгеләрнең җырын җырлый, халыкның ышанычын акламады, дип тә кычкырыналар. Шундыйлар кулы белән аннан үч алу бик тә мөмкин эш. Шулай бит? Бер җаен табып очрашуга чакырасың, хәлен алырлык препарат эчерәсең дә урамга чыгарып җибәрәсең. Алдан сөйләшү буенча, анда аны көтеп торалар...

Әминә, хәйран калып, өстәл аша башын аңа таба сузды:

– Сез нәрсә, мине кеше яллап аны үтертмәкче булган, димәкчеме әллә?

– Заказ биргәндә, үтерү күз алдында тотылмагандыр да, бәлки. Үтемле генә итеп бәргәләргә-типкәләргә генә кушылгандыр. Бераз акылга утыртырга. Тик менә андый егетләрнең йодрыгы бер ычкынса, чаманы югалталар шул... Хәзер менә, күреп торам, үкенеп туймыйсыз.

Әминә, керфеген кагарга да онытып, анын йөзенә текәлгән иде. Ник үрти аны бу абзый? Ник шаярта... Алай дисәң, йөзе житди, күз карашы кырыс. Әминәнең: «Мин теләгәнчә килеп чыкмады шул, артыгын кыландылар»... – дигәнен көтә кебек.

– Ничек инде аны кыйнатырга... Мөнәсәбәтем нинди леге күз алдыгызда бит!

– Тилереп гашыйк булган кеше ни кылмас. Андыйларны күп күрдек инде. Төрмәдәге хатыннарның күбесе шундый статья белән утыра. Иҗтимагый үзәктә мондый гамәлгә рухландырып торулары бик ихтимал. Алар Нуриевка сәяси мәсьәләдә үчле. Сәясәттә каршылык шулай ук хәтәр нәрсә. Канга кан, үлемгә үлем анда.

Бу сүзләр өскә салкын су сипкәндәй айнытып җибәрде, мин-минлек хисен кузгатты. «Нишләп болай жебеп төштем әле? – дигән уй килде башка. – Ахмак сүзгә җавап таба алмаслыкмы әллә?»

Әминә сынын турайтып торып басты.

– Ә минем үз фаразым бар, – диде нык итеп.

– Бик яхшы. Тынлыйм.

– Нуриевның карашлары иҗтимагый үзәкнекеннән күпмедер аерыладыр. Әмма ул татар халкының хокукларын кинәйтү өчен тырыша, урыс шовинистларына ачыктан-ачык каршы сөйли. Алар үчле түгелме? Милициядә дә андыйлар житәрлек. Элек бандит саналган күпме адәм актыгы сезгә елышты! Шулар ачуын алмаган дип кем әйтә ала? Ник үз арагыздан эзләмисез?

Гаҗәпләнүдән тикшерүченең күзләре зур ачылды.

– Менә хәзер чын-чынлап ышандым инде-е, – диде ул сузып.

– Тагын бер фараз барлыгынамы?

– Дөрес юнәлештә эзләнгәнемә. Әле генә песием кебек юаш кына бөрешеп утыра идегез, күр, сыртыгыз ничек тырпайды. Адәм баласы бөтен нәрсәгә сәләтле! Әйттем бит мин, тиле гыйшык теләсә нинди жинаятькә этәрә, дип. Бигрәк тә куәт биреп торучылар булса. Куегыз кулыгызны! – дип өстәленә тагын бер кәгазь кисәге чыгарып салды ул.

— Нәрсә бу?!

— Подписка о невыезде. Сез шәһәрдән беркая да китәргә тиеш түгел.

— Ничек алай? Минем бөтен эшем авыллар белән бәйле.

— Бик кирәк булса, бездән рөхсәт сорарсыз. Мәгез ручка!.. Безнен кадрларга килгәндә, — дип сөйләнде ул Әминә кул куйган арада, — анысы да сезнең кебекләр аркасында. Кем таратты СССР дигән илле илне? Кем жимерде ныклы тәртипләрне? Кем Чечняда сугыш чыгарды? Тәртип саклау органнарының тез астына кем сукты? Милли оешмалар түгелмени?

Аның белән сүз көрәштерү мәгънәсез иде.

* * *

Милиция күзлегеннән караганда, кайберләре дөреслеккә туры киләдер дә. Чыннан да, нәкъ менә илдә болганышлар башланып, бөтен халыкнын хәле авырайган чорда эшсез калды Әминә. Аптыраганнан Татар ижтимагый үзәгенә барып керде. Ләкин болар һич тә тикшерүче әйткәнчә булмады!

...Белгән-күргәннәр арасында «егет кеше» дигән даны таралса да, табигате белән Әминә чын хатын иде. «Бигрәк хатын-кыз икәнсен! Назлар тиз сенә икән үзенә!» — дигән иде гажәпләнү катыш соклану белән Әмир.

Сүзләре расланды, жәйгә таба Әминәнең янә буйга узганлыгы беленде. Токсикоз дигән көйсезлек бу юлы да шактый сиздерде үзен, әмма ирен янында булгач, бөтенләй икенче икән шул. Йөз каралу, гайбәт таралу турында сүз дә булуы мөмкин түгел, вакыт-вакыт больничныйга чыгып тору да табигый саналды. Өч айдан көйсезлекләр бетеп тә китте.

Әминәнең хәле редакторны гына пошаманга салды.

— Декретка киткәнче бераз запас булдыр әле син, — диде ул.

— Йолалар турында бик яратып укыйлар, — диде Әминә. —Туйлар, килен төшерү, солдатка озату турында мәкаләләр бастырдык инде. Күмү йолалары турында да язарга иде.

Редакторның йөзе кырысланып китте. Мәрхүмнәрне күмү тәртибе халыкта борын-борыннан дин белән бәйле: тәһарәт алмыйча, ясин чыкмыйча, догалар укымыйча мәет жирләү мөмкин түгел. Әмма боларны язып та булмый — цензура үткәрмәячәк. Чөнки журнал — партия матбагасы, анда дингә каршы пропаганда алып бару мәжбүри куелган. Гомумән, партия халыкны яктыга, хезмәттә уңышларга, жиңүләргә өнди, ә женаза күнелне күтәрә торган вакыйга түгел, аның турында сүз куерткаңнарын ишеткән дә юк...

Моны икесе дә бик яхшы аңлыйлар иде. Күптән түгел главлит вәкиле Изольда Миронова, кара чәчле, озынча йөзле, янып торган күзле, утыз бишләр тирәсендәге гажәеп чибәр хатын, редакциягә кереп, сәгать буе цензура тәртипләрен аңлатып утырды. Кулында кирпеч хәтле китап. Матбугатта телгә алырга ярамаган заводларның, шәһәрләрнең, фажигаларның исемлеге иде ул. Аңа хәтта һава торышындагы кайбер үзгәрешләр дә кертелгән иде! Күп кенә завод-фабрикаларга якын да бара алмыйсың — кая ул! Хәтта боз яуганын, көчле давыл кубып, йорт түбәләрен куптарганын да телгә алу тыела.

Бик кырыс тавыш белән, журналның соңгы санында киткән сәяси хатага төртеп күрсәтте цензор.

— Ярый әле, без тотып алдык, югыйсә хәрби серне бөтен дөньяга фаш итә идегез, — диде. — «Спартак» аяк киемнәре фабрикасында солдат итекләре тегәләр, дип язгансыз! Бу нинди гамьсезлек!

Чыннан да фабрикада эшләүче алдынгы хатын-кызлар турында язганда: «Алар ир-ат, хатын-кыз, балалар өчен аяк киемнәренең төрледән-төрлесен бик оста тегәләр, солдатларны итек белән тәэмин итәләр», — дигән сүз киткән икән.

— Ни генә язарга ярый соң безгә? — дип сорады хәйран калып, зәңгәр күзләрен мөлдерәтеп, беркатлы Динә Зәбирова.

— Анысын мин сезгә бармак белән төртеп күрсәтә алмыйм, — диде Изольда каты гына. — Әмма артыгыздан пычрак җыештырырлык булмасын. Белеп торыгыз: җибәрелгән хаталарның исәбе алып барыла.

— Анысы нәрсә тагын?

— Анысы шуны аңлата: сез дәүләт серен ачарга омтылгансыз, әле дә ярый безнең хезмәткәрләр аны вакытында күреп алган, дигән сүз. Әгәр без дә күрми калсак, журналның бөтен тиражын юкка чыгарып, янадан бастырырга туры килүе ихтимал. Андый очраклар булгалады. Ишеткәнегез бардыр. Монда язылганнарны яттан белергә тиеш сез! — дип, китабын баш очына күтәрде Изольда.

...Күмү йолалары турында сүз кузгалгач, редактор белән хезмәткәр икесе дә, шул җыелышны искә төшереп, тирән уйга калдылар. Язуын язарлар, әмма цензураның сират күперен ничек үтәрләр икән?

— Үзебезгә кул куярга ярамас, галимнәрдән яздырырга була, — диде Әминә. — Әйтик, танылган табибларның берәрсеннән, тарихчыдан...

— Алар белән үзең сөйләш, — диде сүрән генә редактор. — Тик кара аны, мәкаләләрегез тел-теш тидерерлек булмасын! Миронованың нәрсә әйткәнен хәтерлисеңме?

Зур галимнәр үз эшләрен искиткеч шәп башкаралар, күпләре матур итеп сөйли дә белә. Ә менә күнелләрендә кайнаганны кәгазьгә мавыктыргыч итеп күчерергә авырсыналар. Алардан моны таләп итеп тә булмый, язу осталыгы ул үзенә башка төрле һөнәр бит. Бу очракта Әлфия Зарифовнаның «симбиоз» дигән ысулы ярдәмгә килә: галимнәр, атаклы кешеләр сорауларга җавап бирә, үзе теләгәнне сөйли, журналның хезмәткәре аннан ишеткәннәрен куен дәфтәренә теркәп бара. Соңыннан, киртәсенә кертеп, кәгазьгә күчерә дә автордан укытып ала.

Күнегелгән эш, бу очракта да әлләни авырлыгы булмас кебек тоелган иде. Әмма язарга тотынгач, эчкә пошаман керде.

Җеназалар үткәрүнең коммунистлар куйган тәртибе бар: җыелалар, хушлашу-мактау сүзләре әйтәләр, зур кешеләрне озатканда оркестр чакыралар, зират юлында табутларыннан алда кызыл мендәрчекләргә кадаган орден-медальләрен, төрле оешмалардан килгән катыргы такыяларны күтәреп баралар.

Әмма, атаң-анаң, туганнарың мәңгелеккә күз йомгач, үзеңнең нишләреңне күз алдыңа китерсәң, болары күмү мәшәкатьләренең бик аз өлеше, соңгы ноктасы гына булганлыгы ачыклана икән. Хәсрәте баштан ашкан кешегә анарчы нишләргә? Тынсыз яткан газизенә урынны ничек җәеп, ничек яткырырга? Янында төнне ничек үткәрергә? Ничек юарга, киендерергә? Кабыкка салыргамы, табуткамы? Җеназага кемнәрне чакырырга? Ничек өйдән алып чыгарга? Нindirәк сүзләр сөйләргә? Өченә-җидесенә-кырыгына кемнәрне чакырырга?

Аһ, ничек кирәк икән ул борынгыдан килгән йолалар! Ачы хәсрәттән мингерәп, яшь түгеп кенә ятарга ирек бирми, хәрәкәтләнергә мәҗбүр итә. Авыр кичерешләрдән ин яхшы дәва шул — хәрәкәт бит инде.

Соңыннан, газизенне зиярат кылганда, сыгылып төшеп, җирдә аунап ятудан да догалар уку коткара икән. Чөнки монда сине коммунистик тәгълимат юата алмый, Ходайга сыгынудан башка чара юк! Догаларым барып ирешер, газиземнең гөнаһлары ярлыканыр, урыны җәннәттә булыр, дигән өмет кенә юаныч бирә.

Мәкаләләрдә боларны читләтеп үтеп булмады.

Сәясәткә бернинди мөнәсәбәте булмаган, берәүнен дә шәхесенә кагылмаган, һичкемнең гаебен күрсәтмәгән, фәкать адәм баласының

гомер ахыры турындагы язмалар ил күләмендә ыгы-зыгы куптарыр да, ике кешенең тез астына китереп бәрер, дип кем уйлаган?

Алар, Әминә декретный ялга киткәч, «Соңгы юлга озатканда» дигән баш астында басылып чыкты. Журналның бу санын сорап редакциягә хатлар ява башлады. Сөенергә генә кирәк иде кебек.

Көенечле хәбәр өч айдан соң килеп ирешәте. Мәскәүдә, коммунистлар партиясенең Үзәк Комитетында эшләүче берәүнең хатыны татар икән дә, «Совет гаиләсен укып бара икән. Бу мәкалә турында иренә сөйләгән... Үзәк комитеттан Казанга, динне пропагандалаучы редакторга һәм журналистларга карата катгый чара күрүне таләп итеп, күрсәтмә килеп төшкән.

Берничә айдан редакторны шома гына пенсиягә озаттылар, аның урынына элек цензор булып эшләгән Изольда Мироновнаны китереп утырттылар.

Әминә, тугыз айлык сабыен яслегә урнаштырып, эшкә чыкмакчы иде. Әмма яңа редактор аны үз урынына кире кайтармады.

Хәлләр мөшкелләнде. Бер кешенең эш хакына өч тамакны туйдырып булмый. Акчасын да вакытында бирми башладылар... Ирен эштән кайтуга табынга куярга ипи белән бәрәңгең дә булмаса, такы-токы тамак ялгаганнан соң сабыенны туйганчы имезергә күкрәк сөтең житмәсә, баш бутала икән шул. Житмәүчелек, фәкыйрьлек кешенең тәнен арыктырып кына калмый, акылын саектыра, рухын зәгыйфьли.

Югыйсә Әминә үзенә суккан, каһәрләгән кеше каршына барып басар идемени? Иренә әйтеп тә тормыйча!

Менә тагын сабые аның буш күкрәген суырды-суырды да, башын артка ташлап, илереп елап жибәрде. Гажизләнүдән ми түнде. Кая барырга? Кемгә баш орырга?

Йөрәк түреннән борынгы сынга охшаган егет солтаны калкып чыкты.

«Хәзер инде туйлар узган, туннар тузган бит, – дип уйлады Әминә. – Үпкә-рәнжешләрнең ачысы кимегән, хисләр сүрелгән булырга тиеш. Егылып ятуымны теләмидер. Үзен миннән акыллырак, көчлерәк итеп күрсәтү, чын ир-егет икәнлеген исбатлау өчен генә дип тә хәлемә керми калмас... Ярдәменнән ташламас! Бер сүзе житә: шундук элекке эшемә кайтарып утыртачаклар!»

Бу юлы Әминә аның каршында кечкенә, көчсез булып күренергә дә риза иде. Һәм ул тәвәккәлләде.

РСФСР халык депутатларына хезмәт ияләрен кабул итү өчен Татарстан Югары Советы бинасында аерым кабинет биргәннәр икән. Иркен, шәп жиһазланган бүлмә. Алгы ягында оранжереядагы кебек биек, куе гөлләр үстергәннәр. Өстәл артында көлсу чәчен күперткән Илзирә Хөснуллина утыра. Чырае, нык итеп макияж салган булуга карамастан, төссез – адәм баласының битен иннек-кершәннән бигрәк күңел яктылыгы бизи шул. Ул булмаса – бетте баш! Әминәне күргәч, тәмам сөмсере коелды, тагын да күрексезләнеп китте.

– Рәхим итегез, Әмир Солтанович сезне көтә, – диде урыныннан кузгалмый гына.

Ишектән керүгә, Әминә ялгышканын аңлады. Әмирнең элек очкыннар чәчрәтеп торган күзләрен соры пәрдә каплаган кебек иде.

Исәнләштеләр. Әмир түр өстәл артында утырган килеш калды, Әминә ян өстәл янына утырды. Жан сөйгән ярлар очрашкач үзләрен болай тотмый. Бәлки, авылдашлар, сабакташлар шулайрак сөйләшәләрдер. Аларның да жанга якыннары түгел... Әминә үзенең хәлен аңлатырга тотынды, әмма нинди сүзләр әйткәне хәтеренә сеңеп калмады. Бу минутларда егетнең эчендә кайнаган хисләр аның йөрәген дә сулкылдатты кебек. Катлаулы иде бу хисләр – өзелеп сөю нурларына үпкә, рәнжеш чаткылары кушылган иде. Сикереп торып сөйгәнен кочагына алу омтылышын үч алу теләге

баса. Күзләреннән бөркелгән утны күрсәтмәс өчен, карашын аска төбәгән, иреннәрен ачы көлемсерәү кыскан...

Бу кыяфәтендә ул элеккечә үк газиз дә, шул ук вакытта шулхәтле читят та иде. Менә ул, ялтырап торган коңгырт өстәл тактасында кушырып кысылган бармакларыннан карашын аермыйча, авызын ачты.

— Изольда синең белән эшләргә теләми бит. Мин аны мәҗбүр итә алмыйм.

Әминәнең зиһене авышкандай булды... Кем соң әле бу? Аның тормышын кайчандыр кояштай яктырткан, аннары яшендәй көйдергән Әмирме? Алтынсу, мул чәче шул, ак җин очыннан чыгып торган беләкләрендәге нәфис төк бөтеркәләре, нык бармаклары, шакмаклап уелган тырнаклары... Тик атсыз бармагындагы киң алтын балдак кына ят, «якын килмә!» дигәндәй кисәтеп зәһәр елтырый. Әллә шунын сихере сүрелдергәнме аның күзләрен? Шул ят иткәнме йөзен? Шул салганмы аның теленә йөрәкне шөпшәдәй чагардай сүзләрне?

— Соңгы вакытта мәкаләләрең бөтенләй күренми. Мусина яза белми башлады, дигән сүзләр йөри. Синнән соң журнал да яхшырды, тиражы нык артты. Әнә, нинди шәп материаллар бастырдылар. Күмү йолалары турында, мәсәлән.

Шулай диде дә тынып калды. Әйткәннәренә мөһер сугып, шулайрак шул, кулдан каләм төште әле, дип, сүзен җөпләгәнне көтә түгелме?

«Мин язган идем бит аларны!» — дияр идең дә, моны исбатлауның кирәге юк лабаса. Әмир аның каләмен танымыймыни? Ник сөйли ул боларны, ник кимсетә, юкка чыгара, салып таптый?

Сыгылып төшүен телиме? Каршысында мышык-мышык елап утырыр дип өметләнәме? Әллә соң сикереп торыр да талаша башлар, ямьсезләнер, затсызланыр дип уйлыймы? Тәмам күңелен кайтарыр өчен аңа шул кирәктер, бәлки?

Әминә сул кулын күтәреп, ире бүләк иткән, алтын төскә манылган сәгатенә карады. Аннары елмаеп, бөтен йөзе белән балкып, урыныннан кузгалды.

— Профессор Ильясова белән очрашырга сүз куешкан идек, — диде. — Соңга калмыйм тагын! Яхшы киңәшләрең өчен зур рәхмәт! Сау бул!

Урыныннан кузгалып, ишеккә юнәлгәндә, сынын туры тотарга тырышты ул.

...Ул кичне Нәзир бер сумка тутырып, кәгазь каплар алып кайтты. Аларны кухня өстәленә бушатты, ванна бүлмәсендә кулын юып чыкты да, хәлсез сулкылдаган баласын тотып утырган Әминәгә елмаеп:

— Кая, әнисе, малайны миңа бир әле, — диде. — Иртәдән бирле күргән юк, сагындым. Ә син ашарга пешер. Эш хакын он, ярма итеп бирделәр бүген. Маргарины да бар...

...Тамакны туйдыргач, Нариман да изрәп йокыга талгач, Әминә мөмкин кадәр тыныч тавыш белән:

— Мине эшемә кире кайтармаячаклар, — диде.

— Эш алыштыру — хәсрәтләрнең ин авыры түгел, һәр кешенең диярлек башыннан уза, — диде Нәзир. — Син гел бер урында гына эшләдең, шуңа авыр кичерәсең. Исән муенга камыт табылыр.

Ул төнне иренең назлары Әминәнең җанына иң шифалы дәва булып тоелды.

* * *

Татар иҗтимагый үзәгенә Әминә аптыраганнан түгел, тикшерүче уйлаганча кемнәндер үч алу максаты белән дә түгел — һич юк! — таныш журналистның киңәше буенча барып керде.

Хәкимә Гатина янына Әминә, «Социалистик Татарстан» газетасына мәкалә язып булмасмы дип барган иде. Журналистның өстәлендә кәгазь битләре, иртәгә чыгачак газетаның корректурасы, бер кулында каләме, икенчесендә телефон трубкасы. Грим салынмаган, ирене генә чак кызартылган чыраенда талчыгу, пошыну галәмәтләре.

— Татар иҗтимагый үзәге бөтендөнья татарларының съездын җыя бит, — диде ул. — Ишеткәнсеңдер инде.

— Кешеләрне милләтенә карап аерым җыярга кемнең башына килде икән? Бер милләтне икенчесеннән аеру, бер-берсенә каршы кую дип саналмасмы бу? Андыйга юл куела димени?

Хәкимә тирән сулап, башын чайкады.

— Мин үзем дә ышанмаган идем. Ләкин булдырырлар кебек! Бик күп урыннарда җәмгыятьнең бүлекләре ачылган, съездга делегатлар сайлыйлар. Милли җанлы кешеләр шулкадәр күп икән, шаккатырсың. Америкадан, Кытайдан, Япониядән, Төркиядән, Финляндиядән килергә атлыгып торалар. Хәзер инде Мәскәү теләсә дә тыя алмас кебек. Тимер чаршауны аудардык, илләр арасындагы юлларны ачтык, демократик җәмгыять төзибез дип авыз суы корыталар бит. Аннары безгә куллары җитмәс, бәлки. Күреп торасың, әле Тбилисида митингка җыелган халыкка агу бөркиләр, әле Баку урамнарына танклар кертеп, тәрәзәләргә аталар. Балтыйк буе республикалары аерылып чыгабыз дип яный...

Чыннан да искитәрлек хәлләр бара иде шул илдә. Моңа кадәр ничек тыеп килгәннәрдер, кисәк кенә пар казаны төрле җирдән тишелгәндәй булды да, өтепме-өтә, пешерепме-пешерә...

Әмма ул пар Рәсәйнең читләрендә бит... Һәм әлегә калкып чыкканнарны бастырып киләләр. Ирек таләп итеп, нәрсәгәдер ирешкән халык күренми әле. Киресенчә, аларның фаҗигасе күз алдында: телевизордан урамнарга тезелеп куелган табутларны, газизләренең җансыз гәүдәләре янында сыгылып төшкән аналарны, ятимнәрне күрсәтәләр... Бу күренешләр һәркем өчен сабак түгел микәнни?

Шулай уйлады Әминә. Хәкимәнең исә йөзендә елмаю балкыды.

— Безнең татар да төшеп калган халык түгел. Акыллы, зирәк шәхесләребез бар!.. Һәммәсенең башында Марат Мөлеков тора. Үзең дә күргәнсеңдер. Халыкны кузгатырга тырыша, төрле комитетлар ачкан. Килегез, кулыгыздан килгәнне эшләгез, ди. Мин үзем ул тирәдә еш була алмыйм. Безнең эшне үзең беләсең. Ә син нишләп читтә йөрисең? Халкың язмышы белән бөтенләй кызыксынмыйсыңмы әллә? Мондый чорда каләм иясе посып ятарга тиеш түгел. Әгәр намусы булса, билгеле. Намуслы булыгыз дип халыкка акыл өйрәтүче син идең түгелме? Хәзер менә вөҗданың ни әйтә?

* * *

Каты бәрде Хәкимә! Каршы әйтеп тә булмады, дөрес сүзгә җавап юк, дигәннәр бит.

...Иҗтимагый Үзәк Казан каласының уртасында, халык арасында кара даны чыккан Черек күл буенда урнашкан иде. Урам чатындагы борынгы бина җыйнак, өч кенә катлы, әмма бик затлы: тәрәзәләре өске яктан дугаланып уелган, почмакта, икенче катның балконында сырлап коелган чуен култыкса, түбәсендә гөмбәз, манарачыклар. Булдырганнар егетләр, шәп урынга кереп утырганнар!

Шар ачык чуен капка аша ишегалдына кергәч, Әминә берничә ишекнең кайсын ачарга белмирәк тора иде, урам яктан бер төркем ирләр килеп керде.

— Исәнмесез, Әминә ханым! — дип кулын баш өстенә күтәреп сәламләде

уртадагысы, буйга башкалардан бераз калышрак, кара күн куртка, күн картуз кигән алтмыш яшьләрдәге, шакмаклырак битле, зур күзлекле кеше. Әминә аны таныды — Марат Мөлеков иде бу. — Сезне чакырырга җыенып йөри идем. Житешә генә алмадым. Йомыш бар иде!

— Исәнмесез, Марат Әбдрәсүлович! Исәнмесез! — дип башкаларга да сәлам бирде Әминә. Ул Рафаэль Хәкимовны, Индус Таһировны танып алды. Мәгълүм шәхесләр, зур галимнәр.

— Әйдәгез, кереп сөйләшик әле, — диде Мөлеков.

Кин коридор аша узып, почмак бүлмәгә керделәр. Бер якта зур тәрәзә, стена буйларына урындыклар тезеп куелган, түрдә «Т» хәрефе рәвешендә бер-берсенә терәтелгән ике өстәл.

— Бераз гына көтегез, зинһар, — диде Мөлеков. Үзе курткасы белән кепкасын салып, ишек янындагы элгечкә элде дә, өстәл артына узды. Юлдашлары аның каршына утырды, Әминә ишеккә якынрак урындыкка урнашты. Ирләр кызып-кызып съезд өчен кирәкле документларны язу турында, төрле илләргә телефоннан шылтырату, листовкалар басу турында сөйләшеп алдылар.

Әминәнең дикъкатен түр стенага беркетелгән, кыеклап урталай бүленеп, бер өчпочмагы яшелгә, икенчесе кызылга манылган байрак җәлеп итте. Бу илдә Кызыл байрактан башка әләмнең дә булуы мөмкин микәнни? Ничек аны монда элеп куйганнар? Кемнең башы житкән? Кара даны чыккан Черек күл тәрәзәдән күренеп тора. Казан халкы «Черек күл» дигәндә каршыдагы матур бакчаны, аның аргы башындагы кечкенә күлне түгел, аның каршысындагы саллы бинаны күз алдында тота. Ә анда КГБ. Берәү турында: «Черек күлгә алып киттеләр», — дию, ул кешене табигать кочагына алып баруны түгел, шул бинаның таш базына илтеп тыгуны аңлата. Ничек аннан бәреп кермиләр дә ничек бу адәмне, кулларын богаулап, байрагыние белән алып чыгып китмиләр? Ул бинаның таш подвалларында күпме шундый башсызлар газапланган! Шул сабак түгелмени?

Егетләрнең сүзе озакка сузылмады, эшлекле кыяфәт белән кузгалдылар да, саубуллашып ишеккә юнәлделәр.

— Нишләп анда утырасың, ятим бала кебек? Кил монда! — дип кулын изәде Мөлеков. Аның атсыз бармагында никах балдагы елкылдап куйды. — Син дигәнгә ачуланмыйсыңмы?

— Ничек ачуланыйм ди инде, Марат Әбдрәсүлович... Марат әфәнде... — дип ничектер буталды Әминә.

Хужа аның кыяфәтеннән көлеп куйды:

— Син миңа Марат абый дип кенә дәш. Званием шундый минем: Марат абый. Мәкаләләреңне укып барам. Яшьләрне әхлаклы итеп үстерү, берберенә мәрхәмәтле булу, игелек кылу турында бик үтемле язасың. Ифрат мөһим мәсьәлә. Тик ул моңарчы бер яклы гына яктыртылып килде түгелме? Ничегрәк уйлыйсың?

— Журналда эшләгәндә кулдан килгәнчә тырыштым инде, — диде Әминә. — Жай чыккан саен, мәрхәмәтле, ярдәмчел булырга кирәк, дип үгетләдем.

— Туган-тумачаңа, күрше-күләнеңә ярдәм итү, туры килгәндә кемгәдер хәер бирү яисә суга батканны тартып чыгару гына аз бит әле ул. Ятимнәрне, мохтажларны, бәла-казага дучар булганнарны кайгыртканда кулга-кул тотынышып, бергәләшеп эшләү кирәк. Октябрь революциясенә кадәр татарда хәйрия җәмгыятьләре күп булган, соңрак аларны куып таратканнар. Алга киткән илләрдә алар зур эшләр башкаралар, кайда сугыш чыкса, җир тетрәсә, туфан купса, шунда барып, меңнәрчә кешеләрне коткаралар. Безгә дә шундый оешма булдырырга вакыт. Алын әле шушы эшкә! Үзен

дә күреп, белеп торасыңдыр. Әйтик менә, Спитакта жир тетрәп, шәһәр-авыллар ишелеп төшкәч, әллә кайсы илләрдән азык-төлек, кием-салым, дарулар төяп килеп життеләр бит. Үз байракларын күтәреп, госпитальләр ачтылар. Инглиз, француз, нимес, төрек, рус... Кем генә юк дисән, татар юк! Ник безнекеләр бармады?

— Нишләп бармасыннар? Бардылар! Кызыл Хач оештырды!

— Ә син берәр кайда, татарлар килде, фәлән кешегә ярдәм иттеләр, фәләнен дәваладылар, дигән сүзне ишеттенме? Гәзиттә шундый хәбәр укыдынмы?

— Алар инде Россиядән килгәннәр белән бергә...

— Ә нишләп бергә? Ник без үзебездән жыйган ярдәмне үз кулыбыз белән илтеп бирә алмыйбыз? Ни өчен без анда, кызыл тәре күтәреп, урыс булып йөрибез?

Әминә ни әйтергә белмәде. Монарчы анын бу хакта уйлаганы юк иде. Чыннан да сәер хәл икән шул бу. Татарстанның үзеннән барып, менә без, татарлар, сезгә ярдәмгә килдек, дип әйтеп булмыймыни?

— Чөнки безнен андый оешмабыз юк! — диде тавышын тагын да күтәрә төшеп Марат абый. — Россиядә Кызыл Хач, Төркиядә Кызыл Ай, ә бездә юк! Ә нишләп юк? Син шуны беләсенме?

— Безнекеләр шул Россия оешмасында бит инде.

— Син ул оешмаларнын уставы белән таныш әле. Анда болай дип язылган: мондый оешма мөстәкыйль дәүләттә фәкать берданбер генә була ала. Татарстан Россия составында чакта без аны оештыра алмыйбыз. Мөстәкыйльлеккә ирешкәч, рәсми теркәлергә мөмкинлек туар.

Әминә башын иде: «Була торган түгел икән...» — дип уйлады, әмма дәшмәде.

— Без мона әзерлекле килергә тиеш. Эшне хәзердән үк башларга кирәк. Оешманы булдырып, тиз арада рәсми рәвештә теркәлергә. Хәзергә «Жәмгыяте хәйрия» дип атыйсынмы, әллә башкачамы, анысын уйларбыз. Без милләтебезне бу яктан да бөтен дөньяга танытырга тиешбез. Күз алдына китер: үзебезнен байракны, анын янына Кызыл Айлы әләмне күтәреп, зур-зур йөк машиналарын юл буйлап тезеп, ерак-ерак жирләргә, хәтта башка илләргә алып барсак, ә?

Ул рухланып, дәртләнеп шулай сөйләнә, Әминәнен исә уйлары башкада иде. Икен утырып сөйләштен дә оештын дигән сүз түгел бит әле. Эшне нидән башларга? Кая барып, кемгә сүз кушарга? Ике кул буш, утырырга урын юк, тиен акча юк. Ин мөһиме — өстән бирелгән фатиха юк! Ә бу күзлекле абзыйны «өстәге кеше» дип булмый шул әле!

— Ин элек конкрет бер эш белән шөгыльләнсән иде, дип сүзен дәвам итте Мөлеков. — Мөфти Тәлгат Тажетдин әйтә, Уфадан сигез тонна гуманитар ярдәм алып була, ди. Шуны Казанга кайтарып, мохтажларга өләшергә кирәк. Ул үзе хәзер Казанда, Мәржани мәчетенә шалтыратып сора, кайчан кабул итә икән...

— Анысын гына эшләп була... — дип урыныннан кузгалды Әминә.

Әйе, үгезне мөгезеннән тота торган гына түгел, үгезне мөгезеннән тотарга өйрәтә торган кеше икән бу милли хәрәкәт житәкчесе.

Әминә күрше бүлмәләргә сугылып чыкты. Һәркайсында ике-өч кеше утыра, кереп-чыгып йөрүчеләр өзелми икән. Берсендә «Мәгариф бүлеге» — татар мәктәпләрен ачу өчен тырышалар, икенчесендә — яшьләр оешмасы, өченчесендә чит өлкәләрдән кайтучыларга ярдәм күрсәтергә тырышалар. Күршедә солдатларны яклау комитеты — анда бер маржа түтәй елап утыра. Улы, армиядә кыйнауга түзә алмыйча, качып кайткан икән. Ул арада бер егет атылып кереп:

— Вокзалда егетләрне көчләп армиягә алып китәләр! — диде. Шундук урыннарыннан сикереп торып чыгып йөгерделәр.

Соныннан белде Әминә: ул көнне вокзалда егетләрне поездга утыртканчы сакчылар кулыннан йолып алып калганнар икән.

...Ул чорда тикшерүче Вәлитовның үтенә тигән вакыйгаларның берсе шул булгандыр, мөгаен.

* * *

...Мәржани мәчетенең икенче катында, мөфти Тажетдин бүлмәсенең ишеге төбендә ике егет тора иде. Әминә өченче булып чиратка басты. Озак көтәргә туры килмәде — мөфти хәзрәтләре эшне тиз тота икән. Ак чапанлы, какча яңаклы, сакаллы мөфтинең чырае кырыс, тавышы кискен иде.

— Вәгаләйкем әссәлам, — дип җавап бирде ул Әминәнең сәламенә. Утырырга тәкъдим итмәде, үзе урыныннан кузгалмады. Марат Мөлековтан ни йомыш белән килгәнен белгәч, өстәл тартмасыннан бер бит кәгазь тартып чыгарды.

— Йәмәннән бездәге мөселманнарга дип атап җибәрелгән сәдака бу, — диде. — Биш тонна он, бер тонна үсемлек мае, ике тонна дөге бирербез. Мең кешегә исәпләнгән. Исем фамилияләрен, адресларын, семья хәлләрен, инвалидлык документларының номерларын күрсәтеп, исемлек төзегез дә менә шушы адрес белән Уфага җибәрегез. Соныннан, шул исемлектә күрсәтелгән кешеләрдән ярдәмне илтеп тапшыруыгыз турында кул куйдырып, тагын бер тапкыр җибәрерсез.

— Аны ничек алып кайтырга икән соң?

— Кайтарып та биримме әллә? — дип, мөфти аның аңгыралыгына гаҗәпләнгәндәй кашын җыерды. — Анысын үзегез карагыз инде. Озакка сузмагыз!

Редакциядә һәр эш редактор кушканча, аның белән киңәшеп башкарыла иде... Әминәгә беренче тапкыр җитди эшкә үз башы белән уйлап тотынырга туры килде. Сигез тонна азык-төлек бик күп булып тоелды. Бушка бирәбез, дип торганда, алмыйлар димени, өләшмиләр димени! Казанда күпме халык ипигә тилмерә! Уфалла арбасы белән сөйрәп булса да кайтарырга кирәк аны!

Күнел биреп тырышсаң, чарасы табыла. Исемлекне социаль-тәэминат бүлекләреннән алырга кирәк, ә машинаны «Тататодор» дигән оешмадан сорарга. Редакциядә эшләү чорында күз күргән кешеләр күп, ярдәм итми калмаслар.

Әгәр бу эшкә керешмәсә, Әминә игелек ияләренең шулхәтле күплегенә ышанмас иде. Беркем йөзен җыермады, сүзен кире какмады. «Тататодор» сигез тонна йөкне бер тиен түләтмичә кайтарып бирде, өйдән-өйгә йөреп, фәкыйрь-мескеннәргә күчтәнәч өләшергә теләүчеләр табылды.

Барсы да шома гына бармады, билгеле: юлда кайтканда капчыкларның күпмеседер ертылган, шактый шешәләр шартлаган иде... Йөкне бушатып торыр урын таба алмый баш катты. Азык-төлек сертификатсыз булып чыкты — атна буе аның артыннан чабарга туры килде...

...Озакка сузып булса да, алдан ниятләгәнчә үк башкара алмаса да, ул, ниһаять, бу эшнең очына чыкты. Мең кешегә көтелмәгән җирдән олы күчтәнәч килде.

Хатын-кызларның республика җыенында аны мактап телгә алдылар, газеталарда яздылар, радиодан сөйләделәр. Боларны ишеткәч-укыгач, депутат Нуриев ни уйлады икән? Чырае нинди кыяфәткә керде икән?

Теге чакта, Идел кинлегендә узышкандагы төсле булгандыр үзе дә. Чөнки тагын оттырды бит. Әйе оттырды. Чөнки ил күгендә йолдыз булып

калыккан яна исемнәр арасында Әмир Нуриев якты балкымый, киресенчә, болыт астында калып бара кебек – аны телгә алучы сирәк. Ә менә Әминә Мусинаның йолдызы күтәрелеп килә шикелле.

Олы мәгънәле шөгыль, күп кешеләр белән аралашу рухны үстерде, күңелне киңәйтте, үпкә-рәнҗешләрне эретте. Әмирнең каты бәрелүенә нигез бар кебек тоела башлады. Әминә мине ташлады дип саныйдыр, ир баланы миннән түгел, башкадан тапты, дигән уй бәгырен көйдерәдер. Егет кеше андыйны ничек кичерсен? «Минем баламны үтерден!» – дип кычкырганы искә төшкән саен, тәнне-җанны ялкын теле өтеп алгандай итә... Рәтле хатын-кыз өзелеп сөйгән ярыннан яралган баланы төшерми, киресенчә, ялгыз калса да, авыр яшәсә дә таба, үстерә – күп егетләрнең карашы шундый.

Болай уйласаң, сөйгәне кигезгән тугрылык путасын салырга тиеш түгел иде Әминә...

* * *

...Кеше гомерендә тетрәндергеч тәэсир иткән, уй сөрешен, фикерләү рәвешен үзгәрткән вакыйгалар сирәк була. Әминә өчен шундый вакыйгаларның берсе – бөтендөнья татарларының корылтае булды.

Камал театрының залында андый халыкның җыелганы, андый хисләрнең кайнаганы, андый сүзләрнең сөйләнгәне юк иде әле. Менә трибунага Финляндиядән килгән делегат күтәрелә – озын буйлы, ак чырайлы, татарча сөйли, әмма безнең өчен сәер акцент белән... Менә Кытайда яшәүче сумаладай кара чәчле, кысык күзле милләттәшебез – аның да һәр сүзе аңлаешлы, тик чынлап янгырый. Әнә Япониядән, Америкадан, Төркиядән килгәне... Инде СССРның төрле тарафларыннан килгәннәрен санап та бетергесез. Кыяфәт рәвешләре төрле-төрле, әмма тел бер, хисләр, омтылышлар уртак! «Күпмилләтле татар халкы» дигән гыйбарәнең чын мәгънәсе күз алдында ярылып ята.

Зур, зиннәтле залны шыгрым тутырган халыкка карыйлар да, куанычларыннан тынсыз калалар. Менә без нинди зур халыкның газиз балалары икәнбез лә! Менә нинди җөмһүриятебез, мәркәзебез, дөньядагы иң атаклы театр биналарына тиң мәдәният үзәкләребез бар икән безнең! Һәм аларның биек мөнбәренә күтәрелеп, өйдә генә, газиз ата-аналарыбыздан гына ишеткән телдә сөйләп була икән!

Бу шаккаткыч иде! Нәкъ менә шул көннәрне Әминә, тарихны аерым шәхесләр ясый, дигән тәгълиматның хаклы булуына ышанды да инде.

Андый шәхес баһадир гәүдәле, көчле тавышлы, гайрәтле булырга тиеш иде кебек. Марат Мөлеков исә биек трибуна артында кечерәеп калгандай күренде. Базык гәүдәле, калын күзлекле, алтмышны узган бу кешене урамда күрсәң, гади авыл агае дип уйлавың ихтимал. Әмма залдагы халык аны ил агасы санап олылый, күз карашы белән күтәрә, сулышы белән дәрт өсти кебек иде. Сүзне өзеп түгел, бераз бутабрак сөйли. Әмма һәр әйткәне халыкның йөрәгендә кайнаган хисләргә тәңгәл килә иде.

...Әминә кат-кат залны күздән кичерде. Борынгы Римның Үгез форумында мәйдан тоткан Геркулеска тиң егетне эзләде. Әмма тапмады.

«Мөмкинлеге булмагандыр, – дип аклады аны күңеленнән Әминә. – Мәскәүдә, моннан зуррак, зиннәтлерәк залда, бер генә түгел, йөзләрчә халыкның язмышын хәл иткәндә үз сүзен әйтәдер».

...Әллә аның уйларын сизде микән, бер көнне яшел-кызыл байрак астында утырган Марат абый, күзлеген хәтәр елтыратып:

– Нуриев кайткан иде, сөйләшеп алдык әле, – диде.

Әминә сискәнеп китте, йөзе үзгәргәнен тойды. Ярый әле, Марат абый моны сизмәде кебек, сүзен дәвам итте:

— Югары советта бөтен нәрсә урыслар ничек теләсә шулай кабул ителә, ди. Башка милләт кешеләренең сүзенә колак салу юк, ди. Алайга сабышсаң, монда да бернишли алмыйсың. Казан — урыс шәһәре, Татарстанның үзендә дә урыслар күпчелек. Әмма ил язмышын күпчелек түгел, бердәм булып төйнәлгән гайрәтле азчылык хәл итә! Аңлатырга тырышып карадым, сүземне үткәрә алмадым... Үзалдына ачык кына бер максат куймаган, үтемле программасы да юк.

— Ничек инде программасы булмасын? Бар иде! — дип каршы төште Әминә хисләрен яшерә алмыйча.

Марат абый бер тын аңа текәлеп карап торды.

— Ниндидер брошюра тотып йөри иде, — диде. — Ә син беләсеңме аны кем язып биргәнен?

Әминә белмим дигәнне аңлатып, иңнәрен сикертеп куйды.

— Хөснуллина дигән журналистның күзенә чалынганы бар микән? Ул чакта район газитендә эшләгән бугай.

Әминә бит очлары алланып чыкканны сиздермәскә тырышып, башын иде.

— Ишетүемчә, менә шул укмаштырып биргән Нуриевка «программа» дигән нәмәрсәсен! Без әйткәннәр белән килешмәде. Сез нәрсә, башыгыз җәл түгелме әллә, диде. Башы җәл кеше сәясәт баскычыннан өскә үрмәләргә тиеш түгел! Кызганыч, кешеләребез җитмәде, сайлауларда аны үткәрмәслек көндәш куя алмадык.

Әминәнең сикереп торып кычкырасы килде: Әмир кыю түгелме? Ул халык өчен янмыймы? Аның гайрәте җитмиме?.. Тик дәлилләре юк иде шул...

— Мәскәүдә хокукларыбызны аяк терәп якларлык кешебез юк, — дип нәтиҗә чыгарып куйды Марат абый. — Шунлыктан безгә аерата авырга туры килә. Анда кайберәүләрнең, Татарстан Югары советы председателе Минтимер Шәймиевны Емельян Пугачев кебек читлеккә утыртып, Мәскәүгә китереп, суд ясарга кирәк, дип кычкырганнарын ишеткәнсеңдер. Ике ут арасында калды ул. Мәскәү өстән баса, монда без кысабыз. Әйттем әле мин Шәймиевка, Татарстанның бәйсезлеге мәсьәләсендә нык тормасаң, син безнең егет түгел, урыныннан алып атачакбыз, дидем. Бездә көч җитәрлек!

Соңгысын кадак каккандай итеп әйтте ул. Тик мона ышанырлык түгел иде. Россия дигән дәүләтнең җитәкчеләренә каршы торырлык көч каян килсен аңа? Дөрес, СССР дигән ил таркалгач, аның җире дә, куәте дә кимеде, әмма бәйсезлек таләп иткән милләтчеләрне бөгәрлек, кирәксә сытарлык чаралар да, корал да җитәрлек. Ачулары кабарсамы?..

Башын балта астына куйганын беләме соң бу кеше? Бу хакта уйламый мөмкин түгел! Әмма аның йөзендә икеләнү, каушау, курку кебек хисләрнең тамчысы да юк иде.

* * *

Куш дәфтәр бите зурлыгындагы бу кәгазь кисәге Казан шәһәренең Ирек мәйданындагы афишалар баганасына ябыштырылган иде ул. Кара буяу белән йөрәк сурәте ясалган, аннан тамчы тама, ә аскарак, бала кулы белән язылгандай тигезле-тигезсез итеп: «Референдумда Татарстанның бәйсезлегенә каршы тавыш бирсәң, халкың йөрәгеннән кан тамар!» — дип куелган иде.

Татар иҗтимагый үзәгенең ишегалдында да, бина эчендә дә халык тулгана. Казан тирәсенә танклар тупланган, шәһәргә бәреп керергә әмер генә көтәләр, дип сөйлиләр. (Соныннан бу сүзләрнең хак булганлыгы

ачыкланды.) Кемнәрдер, Ижтимагый үзәктә корал тоталар дигән ялган хәбәр тараткан, имеш. КГБ, кара даны чыккан «Черек күл» янәшә генә, Мәскәүдән ым кагулары да житә. Хәзер бәреп керерләр дә, шундагы бөтен кешене жыеп алып, жир астындагы таш капчыкларга салып бикләп куярлар. Корал турындагы хәбәрләр менә бик шәп сылтау булачак, аны нәкъ шуның өчен уйлап чыгарганнардыр да, мөгаен. Ләкин шүрләп өенә шылучылар күренми, эшләре бик тыгыз.

Әминә туры президент бүлмәсенең ишеген ачты. Марат абый өстәле артында утыра иде.

Башын чөйгән, йөзе алланган, күзлек пыялалары елтырый. Әминәне күреп, кулын изәде: кер, уз әйдә!

Өстәлнең бу ягыннан пеләш башлы, озынча ак чырайлы, чит кыяфәтле ир заты ана таба микрофон сузган, тагын бер ят хатын-кыз стена буендагы урындыкта утыра.

— Журналистлар, Германиядән, — дип тиз генә әйтеп алды Марат абый. Әминә ишек янынарак утырды.

Ир кеше сорауларын немесчә бирә, хатын-кыз аны урысчага тәрҗемә итә иде.

— Өченче көн Грозныйда Ичкериянең президенты Жохар Дудаев белән очраштык, — дип, бүленгән сүзен дәвам итте журналист. — Алар үзләренең армиясен булдырганнар. СССР таркалганда, анда шактый корал калганлыгы мәгълүм. Хәзерге вакытта шуның белән коралланалар. Алар хәрби көчкә таяна. Сездә корал булуы турында мәгълүмат юк. Нәрсәгә таянасыз?

Марат абый хәйләкәр генә елмаеп:

— Бездә көч житәрлек! — диде. — Тик бу хакта Мәскәүдәгеләр белми.

Журналист өстәл аша аңа таба башын сузды, тавышы ук үзгәреп китте. Монда сенсация ярылып ята түгелме?

— Ничек белми... Шундый... серле коралмыни?

— Алар белми торган, — дип көлеп ук жибәрде Марат абый.

— Нәрсә соң ул?.. Безгә әйтә аласызмы?

— Сер итеп кенә, — дип күз кысты Мөлеков. — Безнең корал — халыкның кулында түгел, күнелендә.

Журналист аны аңлаудан гажиз иде.

— Мәскәүләр бездәге русларны үзләре төсле дип уйлый, — диде Марат абый.

— Нинди дип?

— Татарларны чит итә, хәтта күп өлеше дошман күрә, дип күз алдына китерәләр. Хәлбуки, биредә гасырлар буе буыннан-буынга яшәгән руслар татарлар белән аралашып, дуслашып, күпләре туганлашып беткән. Бергә укыйлар, эшлиләр, бәйрәм итәләр. Безнең сабан туе дигән милли бәйрәмебез бар, аның мәйданында рус егетләре күп ярышларда жинә, милли көрәштә батыр калганнары бар. Жилкәләренә тәкә күтәреп, мәйдан әйләнеп йөриләр. Килегез. Күрерсез. Ике халыкны бер-берсе өстенә өстереп, сугышыр дәрәжәгә житкерергә тырышу — мәгънәсезлек. Мәскәүләр шуны аңламый.

— Алай да... Сан ягыннан руслар күбрәк бит...

— Без татарларның гына түгел, һәммә гражданнарның мәнфәгатен кайгыртабыз. Жир-суларга Мәскәү түгел, республикада яшәүчеләр хужа булырга тиеш.

— Сез чыннан да, Татарстанның Россиядән аерылып чыгуын яклап руслар да тавыш бирер, дип өметләнәсезмени?

— Минем моңа иманым камил, — диде Мөлеков.

— Армия Россиянеке, КГБ Мәскәүгә буйсына, милиция шулай

ук. Сез, жирегезгә гаскәр басып керер, канкоеш башланыр, дип курыкмыйсызмы?

– Без моңа сылтау бирмәячәкбез. Россия житәкчеләре халыктан бик ерак, мондагы хәлне аңламый. Алар референдумда үзләренең жиңәчәгенә шикләнми. Шуңа күрә оттырачаклар. Менә күрерсез. Татарлар – борынгыдан үз дәүләтчелеге булган, мәдәниятле, тирән тарихлы халык. Ул, әлбәттә, үзенең дәүләтчелеген торгызачак. Безнең бу ышанычыбызны үз халкыгызга ирештерүегезне сорыйбыз.

Журналист аның дулкынланган йөзенә сәерсенеп карый. Бөтен кыяфәтендә ышанмау ярылып ята. Россия уртасында ничә гасырлар буе йомылып яшәгән бер «нацмен» халыкка шул кыска вакыт эчендә кем милли горурлык хисе сеңдерә алсын да кем аны берләштерсен, оештырсын? Өч-дүрт ел элек кенә барлыкка килгән шушы оешмамы? Аның житәкчесе булган шушы фанатик адәмме?

Алар чыгып киткәч, Марат абый кулъяулык алып битен сөртте дә:

– Якынрак кил әле, – диде Әминәгә. Һәм өстәлендәге кәгазь өемнәре астыннан берничәсен тартып чыгарды.

Ялтырап торган каты кәгазьгә жете төсләр белән зур агач ясалып, «Россия» дип язылган, юан бер ботакта «Татария» дигән сүз, ана бер ямьсез ир белән котсыз хатын менеп атланганнар да, ботак төбен пычкы белән жан-фәрман ышкыйлар. Аскарак: «Марат Мөлеков белән Фәүзия Бәйрәмова Татарияне менә шушылай юкка чыгармакчылар», – дип куелган иде. Астарак кандай кызыл «Әйе» сүзенә кара тәре сугылган: Татарстанның бәйсезлегенә каршы менә шушылай итеп каршы тавыш бирегез, янәсе.

– Мондыйларны Мәскәүдән, Нижгардан вагон-вагон, самолет-самолет ташыйлар, – диде Марат абый. – Күпме акча исраф иттеләр бу эшкә Россия житәкчеләре! Шундый кәгазьләр заводларның ишегалларына келәм булып түшәлгән, диләр. Ә безнең мөмкинлекләрне үзең чамалыйсыңдыр.

Әминә әле генә театрның афишалар тактасына беркетелгән язу турында әйтеп алды:

– Кемнәр шундыйларны ясап элә икән?

– Андыйларны үзебезнең тирәгә тупларга иде! Кеше житми бит!

...Ул кичне Әминә, бала арбасы тартып, үз тирәләрендәге урамнарда листовкалар ябыштырып йөрде.

Узгынчыларның кайберләре:

– Халыкларны сугыштырырга йөрисез, – дип ысылдады. Бәгъзеләренең чыраенда татарлыгы ярылып ята иде.

Янында туктаган ялгыз ир-атның да үз кешебез икәнен чамалап:

– Бәйсезлеккә каршы татарлар да бар, – дип зарланып куйды Әминә.

– Урысның артын ялап туймаганнар икән әле, – диде ир кеше. Ул ераклашуга, буш тротуардан әкрен атлап, сагыз чәйнәп, дүрт-биш егет килеп туктады. Кычкырып сөйләшүләренә һәм кулларын йогышсыз болгауларына караганда, яшьләр иде болар һәм салмыш иделәр булса кирәк. Баганага ябыштырылган плакатны укыдылар, кулына бер төргәк кәгазь тотып торган Әминәгә карадылар.

– Глянь, что тут эта тетка делает! Кара, бу түтәй нишләп йөри! Листовкалар ябыштыра! Мәскәүдән бәйсезлек таләп итә!

– Ты что, дура! Казан белән Мәскәү арасына чик сузарга маташасыңмы? Таможня куймакчымы?

– Мәскәүнең Казан вокзалына бару өчен синнән рөхсәт сорарга тиеш булырбызмы әллә без, падла?

Әминә каршына уналты-унжиде яшьләрдәге бүре карашлы егет килеп басты. Түгәрәк чырайлы, тырпайган кара чәчле – татарлыгы бөтен

кыяфәтендә ярылып ята. Сул кашы җөйле – бокс белән шөгыльләнүчеләрне еш кына шулай җәрәхәтлиләр. Хәзер китереп бәрсә...

Сулышы капкан Әминә бала арбасын гәүдәсе белән каплады.

– Иң беренче баганага без сезнең ишеләрне асып куячакбыз, – дип ысылдады теге анның башы өстендә.

Икенчесе плакатны куптарды, өченчесе Әминәнең кулыннан төргәкне тартып алды да ерткалап өстенә сипте.

– Глянь, менты!

Урам чатыннан бер төркем милиционер килеп чыкты. Берсе эт җитәкләгән.

– Ну, кара аны, тутәй! Тагын күзгә чалынсаң, болай гына котыла алмассың!

Аларның мыгырдануы, аяк тавышлары ераклашкач та шактый вакыт сынын турайта алмый торды әле Әминә.

Бу вакыйга күнелгә шом салды: хәлләр Марат абый күз алдына китергәннән күпкә катлаулырак иде...

* * *

Иртән уянып, тәрәзәдән караганнар иде, исләре китте: гадәттә кеше сирәк йөри торган юлдан төркем-төркем дә, берән-сәрән дә кешеләр уза. Бөтенесе бер якка – мәктәпкә таба бара. Анда сайлау участогы.

Нәзир чәй эчте дә ашыгып киенә башлады.

– Көн буе сайлау участогында күзәтүче булып утырам, аннары иҗтимагый үзәккә җыелырга дип сөйләштек. Соң кайтырмын, – диде.

Әминәнең дә күзәтүче буласы бик килгән иде, әмма баланы карар кеше юк. Ул арба тартып үзләре янындагы мәктәпкә китте, тавыш биреп чыкканнан соң, урам якта шактый гына вакыт күзәтеп торды: халык туктаусыз агыла, һәммәсенең сыны туры, чырае җитди, гомердә беренче тапкыр үз тавышының мөһимлеген, үлчәү тәлинкәсенә салынган шул бер мыскалның бөтен киләчәкне, ил язмышын үзгәртүе ихтимал икәнлеген аңлыйлар кебек. Әйе, йөрәкләр ашкынып тибә, әмма хисләр эчтә ургый, тышка бәреп чыкмый. Әлегә тынлык...

Әмма бу тынлык көчле давыл, гарасат алдыннан була торганга охшый, күкне каплаган соры болытлар артыннан каралары-афәтлеләре ябырылыр кебек. Гомердә булмаган хәл: күпләр асылда Россиягә каршы тавыш бирергә бара бит!.. Урамнарга танклар бәреп кермәсме?

Көн буе җан тынмады, өйдә телевизорның экраны сүнмәде, радио сөйләүдән туктамады. Ниһаять, дулкынланган тавыш куанычлы хәбәр әйтте: күпчелек «әйе» дип тавыш биргән.

Бу көннән соң офыкта куерган кара болытлар таралгандай, афәтле давыллар читләтеп үткәндәй булды. Күкләр аязды, йолдызлар янә җемелди башлады. Тик, ни гаҗәп, әле кайчан гына күзләрне камаштырганнары сүрелә бара, әлек болыт астындарак тоелганнары исә зурая, яктыра иде. Арада Нуриевның йолдызы күзне аерата иркәли. Мәскәүдә кыю, төпле чыгышлар ясаганы ишетелә. Казанга еш кайта, зур җыелышларда, телевизордан сөйли, газеталарга яза. Үз телен санламаганнарны гаепли, ата-аналарга балаларны татар мәктәпләрендә укытуның мөһимлеген аңлата. Депутатларга, укытучыларга бурычларын искәртеп тора. Милләтне тәрәккъкый иттерү юнәлешендә җитәкчеләргә акыллы киңәшләрен бирә, куәт өсти.

Референдумнан соң узган дүрт-биш ел эчендә ул тәмам татарның сөеклесенә әверелде. Күр дә тор, озакламас, ил агасы булып җитешер. Хәзер үк инде йөреш-торышында олпатлык чалымнары сизелә, бил тирәләре сөйкемле генә бүлтәеп килә.

Ул арада Әминә дә кул кушырып утырмады. Җәмгыятьнең исемен «Кызыл Ай»га алыштырып, рәсми теркәтте. Аның уңышлы эшләвен исәпкә алып, хөкүмәт «ГАЗ-53» машинасы бирде.

Менә шул чакта үз җилкәсендә татыды да инде Әминә яңа законнар чыгарып утыручы депутатларның, шул исәптән Әмир Нуриевның, эшчәнлеге нәтиҗәләрен...

* * *

Илләр белән ирләр идарә итә, тәртипне алар урнаштыра. Әминә үзен беркайчан да ир затыннан ким санамады, алай да ир-егетләр генә ат уйната алган мәйданнар барлыгын инкарь итү ахмаклык булыр иде. Сугыш чыкса — иң беренче булып егетләрнең асыллары утка керә, шахталарга төшеп ирләр күмер чаба, авыр йөк машиналарын юлларда алар йөртә. Гадәти тормышта да авырны алар күтәрә, бағананы алар утырта. Табигать үзе кеше затын шундый итеп яраткан.

Сәясәт тә шундый — ир-егетләр көч сыный торган мәйдан. Дөрес, бу өлкәдә дә исемнәре бөтен дөньяга танылган хатыннар бар: Һиндстанда Индира Ганди, Англиядә Маргарет Тэтчер, Цейлонда Сиримаво Бандаранаике, Пакистанда Беназир Бхутто... Ләкин андыйлар бик сирәк, гомуми кагыйдәдән чыгарма кебек кенә. Мәгълүм булганча, аерым чыгармалар төп кагыйдәнең дөреслеген һич тә какшатмый, киресенчә, раслый гына.

Без, барча халык, иң биеккә менгән ирләр-егетләр уйлап чыгарган кануннар, алар урнаштырган тәртип буенча яшибез.

Гаделме ул кануннар? Дөресме ул тәртипләр?

Житмеш ел элек ирләр, революция ясап, кануннарны-тәртипләрне үзгәрттеләр. Нәтиҗә нинди? Ил бөлгенлектән арынмады, салкын сугышта җинелде, таркалды. Димәк, СССР заманында идарә иткәннәрнең гамәлләре дөрес булып чыкмады.

Инде килеп, беркөнне без бөтенләй бүтән, кечерәебрәк калган илдә — Россиядә яши башладык. Хакимияткә Ельцин җитәкчелегендәге төркем менеп утырды, ул үз тәртипләрен урнаштыра башлады. Иң беренче эш итеп, үзенә каршылык күрсәткән Югары Совет бинасына туплардан аттырып, депутатларны куып таратты.

Әмма дәүләт депутатларсыз яши алмый — тиз арада янадан сайлаулар уздырдылар.

Мәскәү уртасында атышлар барган көнне Әминә бик борчылган иде: үлүчеләр бар, дип сөйлиләр, Әмир нишли икән анда?.. Әмма депутат Нуриевны телгә алмадылар, ул ничектер күздән югалып торгандай булды.

Аның исеме яңа сайлауларга әзерлек башлангач калкып чыкты. Әлфия Зарифовнаның: «Властька кабынган гыйшык гомерлек ул!» — дигәне хак иде шул. Бер депутат булганның гел депутат буласы килә. Элекке сайлауларда туплаган тәҗрибәсе дә ярдәм иткәндер, арка терәге дә нык иде — бу юлы Әмир Нуриев җиңелрәк үтте кебек.

Менә алар — яңа илнең депутатлары — Мәскәүгә җыелдылар. Илнең яшәү рәвешен тамырдан үзгәртергә кирәк, моның өчен алар бик күп яңа законнар кабул итәргә тиешләр иде.

Алдагы хакимиятнең нинди кануннар чыгарып, нинди уңышларга ирешкәне, нинди хаталар ясаганы күз алдында. Шуларга карап сабак ал! Халыкка ипле яшәү, нәтиҗәле эшләү өчен кулай законнар кабул ит!

Әмма ник соң алар башны катырып, аякларны талдыра, вакытны бушка сарыф иттерә, акчаны җилгә очыра торган законнарны раслап кул күтәрәләр икән?..

Машина белән юлга чыгу өчен кирәкле кәгазьләр артыннан чапканда, бу сорау күп мәртәбәләр Әминәнең башына килде. Башта һәммәсе совет заманыннан калган тәртип белән ипле генә барган иде. Менә ГАИның «техпаспорт» дигән кәгазе Әминәнең кулында, «техталон» дигән тылсымлы катыргысы шофер Рәмиснең кесәсендә. Аллага шөкер, дип юлга кузгалырга була.

Сентябрь башы, көн матур, күк аяз, күңел хуш иде. Баланы бакчага кертеп, кайтып чәй эчеп утырганда, тәрәзә ягыннан машина гөрелтесе ишетелде. Башкалардан көчлерәк бу тавыш йөрәкне Сәйдәшевның «Совет Армиясе» маршы кебек кузгатты. Шулай булмыйча, Әминә бүген генералдан ким түгел иде. Әнә, аны эшкә алып барырга дип, ишек төбенә «личный» машина килеп баскан. Аның да ниндие диген әле! Бүтәннәрдән зуррагы, биегрәге, зәңгәр буявы белән ялтырап торганы!

— Иртәгә иртәрәк килерсең, — диде ул кабинага менеп утыруга. — Зәйгә барып кайтырбыз. Андагы глава, кил, ярдәм итәрбез, диде. Тугыздан соң аны тотып булмаячак.

— Болай гына юлга чыга алмыйбыз бит әле, Әминә Тәлгатовна, — диде Рәмис. — Лицензия кирәк.

— Нинди лицензия? ГАИдан документларны алдык бит инде!

— Автоинспекциядән дә кирәк икән хәзер.

— Анысы нәрсә тагын?

— Күптән түгел оешкан. Ул биргән кәгазең булмаса, юлга чыга алмыйсың, диләр. Таныш шоферларның башы шуның белән ката бу арада.

— Кайда соң ул автоинспекция?

— Автовокзалда диләр.

— Яле, борыл шунда!

Чыннан да, автовокзалның аскы катындагы иркен залда, озын эскәмияләрне бер якка шудырганнар да, дүрт-биш өстәл куйганнар икән. Алар артында житди кыяфәтле хатын-кызлар утыра, һәркайсының каршысында унбиш-егерме ир-ат чират тора. Кулларында бер үк төсле ак папка.

— Башта документлар тутырырга кирәк, — дип аңлатты берсе. Һәм кулы белән каршы як стенага ишарәләде. — Әнә, тегендә ниләр кирәклеге язылган.

Ә анда... Стенаның буеннан буена кәгазь битләре ябыштырылган. Нинди генә бланклар юк! Боларны ничек тутырып бетермәк кирәк? «Тынычлан, Әминә, тынычлан, — дип күн пинжәгенең түшен сыпыргалады ул. — Мондыйларны гына язмаслыкмыни син!» Һәм ул кәгазьләргә күзен ачыбрак текәлде.

Иң беренче битләргә хөкүмәтнең карары басылган икән. Илдә һәртөрле эшчәнлек, шул исәптән машина белән йөк ташу да, рәсми рәвештә теркәлә, ягъни лицензияләнә. Карарга Борис Ельцин үзе кул куйган.

Әминә бланк кәгазьләрен теге хатыннарның берсеннән сорап алды да, авыр көрсенеп, ишеккә юнәлде.

Сәгать икегә, кулына өр-яңа ак папка тотып, чиратка унбишенче кеше булып килеп баскан иде инде ул... Менә, ниһаять, сары чәчле, талчыккан чырайлы хатын аның папкасын алды. Кәгазьләрне караштырды да, башын күтәреп:

— Сезнең белемегез нинди? — дип сорады.

Гажәп иде бу. Стенадагы кәгазьләрдә андый сорау юк лабаса!

— Югары, — диде Әминә.

— Нинди югары?

— С отличием! — диде Әминә масая төшеп. Хатын исә чыраен сытты.

– Анысын сорамыйм мин. Техническиймы?

– Филологический.

Хатын башын иеп кәгазь кисәгенә нидер язарга кереште.

– Ни язасыз сез анда?

– Направление, – диде хатын борын астыннан.

– Нинди направление?

– Автодорожный техникумга.

– Нәрсәгә ул?

– Укырга... Белемегез технический булса, болай да ярар иде. Сезнең ишеләр курслар үтәргә тиеш.

– Нинди курслар?

– Автодорожныйда өч айлык курслар ачылды. Нәкъ менә шушындый очраклар өчен. Укып чыгып, диплом алгач, килерсез.

Әминә үзенең тәмам чарасыз калганын аңлады.

– Ничек инде мин техникумда укып йөрим... – дип лепелдәде ул. – Аннары... машина хәзер кирәк бит безгә!..

– Әнә, начальник белән сөйләшегез! – дип, артына борылып, караңгы почмакта шәйләнгән көрән ишеккә таба кулын изәде хатын.

Кечкенә бүлмәдә, кыршылган өстәл артында күн курткалы, йомры башлы, иллеләр тирәсендәге абзый утыра, стена буендагы урындыкларда тагын ике ир заты бар иде. Әминә ишектән башын сузгач, сүзләре өзелде, әмма начальник йомшак күңелле адәм иде булса кирәк:

– Керегез, – диде.

Әминә, аягүрә баскан килеш, каушап, тотлыга-тотлыга мәсьәләнең асылын аңлатырга тырышты. Хәйрия җәмгыяте... машинаны бик авырлык белән алдылар... Район җитәкчеләре көзге муллыктан өлеш чыгарырга риза. Фәкыйрь-мескеннәр көтә...

– Закон бит ул, хөкүмәтнең карары шундый-ый! – диде абзый теше сызлагандай чыраен сытып. – Фәкыйрьләрне кызганам, дип, закон бозып булмый бит инде!

Әллә нәрсә булды Әминәгә... Исенә төшкән саен ояла... Ике күзеннән тамчылар сытылып чыкты. Өч ир-ат каршында... Ихтыяры сынды, тыела алмады. Чыгып китәргә дә хәле калмады, аяклары идәнгә беректе.

– Бу хәтле өзгәләнмә әле, – диде начальник сеңлесен юаткандай йомшак итеп. – Ризван Нәбиулловичка бар әле син. Техникумның директор урынбасарына. Мин җибәрде дип әйтерсең. Мә, тот, – дип визит кәгазен сузды аннары...

Техникум шәһәрнең Азино бистәсе ягында икән. Дәресләр беткән, укучылар таралган, Ризван Нәбиуллович үзенең кечкенә бүлмәсендә утыра булып чыкты. Ыспай гәүдәле, көмеш кебек ак, куе чәчле, ачык йөзле абзый икән. Әминә журналист таныкнамәсен күрсәтте, хәлне аңлатты. Көзге муллыкны эләктереп калырга кирәклеген, фәкыйрьләрнең зарыгып көткәнен сөйләде.

– Имтиханнары экстренно әзерләнеп кенә тапшырып булмас микән? – диде. – Владимир Ильич Ленин, әнә, университет имтиханнарын экстренно укып тапшырган бит... Нинди китаплар кирәген әйтсәгез, китапханәгездән алып торырмын да...

– Китаплары юк шул аның, – дип аның сүзен бүлде Ризван Нәбиуллович.

Әминә хәйран калды.

– Ә ничек укыйлар соң?

– Укытучылар сөйләгәнне язып баралар да шуның буенча имтихан тапшыралар.

Инде нишләргә? Чарасызлык дигәннәре менә шушылай була икән ул...

— Кайберәүләр, имтиханнарын тапшыргач, дәфтәрләрен ташлап китә, — диде директор урынбасары уйланып. — Коридордан эзләп карасагыз...

Әминәнең эченә беразжан кергәндәй булды, әмма әле генә озын коридор буйлап узганда, тәрәзә төпләрендә ул-бу күзгә чалынмаганын уйлагач, урыныннан купмады. Ризван Нәбиуллович аңа кистереп карап алды да, урыныннан кузгалып үзе чыгып китте. Ике-өч минут үттеме-юкмы, калын бер дәфтәр тотып, килеп тә керде...

Кичен ире белән улы йокыга талгач, Әминә, кухня өстәле янына утырып, дәфтәрнең беренче битен ачты. «Юлларның төрлесе була, — дип язылган иде анда. — Тары, киңе, озыны, кыскасы, турысы, бормалысы, жир өстеннән сузылганы, таш тезелгәне, бетон түшәлгәне, асфальт җәелгәне... Машиналарның да төрлесе була... «Жигули», «Волга»... «ГАЗ», «КамАЗ», «КРАЗ»...

Йа Раббым! Менәниләр белән баш катыралар икән бу курсларда! Әминә дәфтәрне актаргалады. Аңа соң нәрсәне белергә кирәк? Ә-ә-ә, менә, табылды. ТО-1, ТО-2, ягъни, машинаны беренче тапкыр тикшереп төзәтү һәм икенче тапкыры. Ничә чакрым юл узганнан соң... Ул моны белергә һәм вакытында эшләргә тиеш. Әминә шул ике санны ятлады да дүшәмбе көнне иртүк техникумга юнәлде.

Алла бәндәсе Ризван Нәбиуллович үз урынында иде.

— Килдегез дәмени инде?

— Әйе, мин әзер.

Директор урынбасары өстәл тартмасын тартып ачты.

— Менә, алыгыз, — диде.

Икегә бөкләнгән катыргы кисәгенең эчке ягына Әминәнең исем-фамилиясе, юл техникумында курслар үтүе турында язылган, өч фәннән «4»ле куелган һәм йөк ташучы машиналарның диспетчеры булырга хокукы расланган иде.

Таныкнамәсе булды. Лицензиясен дә язып бирделәр. Әмма соңгысын ел саен яңартып алырга кирәк икән. Һәммә бланкларны тутырырга, шактый гына акчасын түләргә... Яна оешкан булганга күрә, түрәләр ана куыш таба алмый тинтерәделәр, күрәсең, шәһәрнең әле бер, әле икенче ерак тыкрыгына кат-кат барырга туры килә иде. Ә анда чират... Районнардан килеп тулалар... Һәммәсе ир-егетләр. Аларның да нинди диген әле! Озын юлларда талкынган, ачы җилләрдә какланган, авыр тәгәрмәчләрне «КамАЗ» әрҗәсенә ыргытып, беләгенә көч җыйган, төрле халык арасында айкалып акыл туплаган, ГАИ хезмәткәрләре белән аяк терәп бәхәсләшеп гайрәт җыйган. Беркемгә бирешә торганнардан түгел!

Тик хәтта алар да Әмир кебекләр кул күтәреп раслаган кануннарга каршы бернишли алмый. Депутатлар халык белән даими элемтәдә, бар тырышлыклары эш кешесен кайгыртуга юнәлтелгән дип шапырыналар тагын!

Миллионлаган халыкны шушы рәвешле интектерүдә ни мәгънә?

Бу хакта депутат Нуриевтан сорарга җай чыкмады, ахыр чиктә моның мәгънәсен Әминә үзенчә аңлатты: «Мина үчләнүе түгел микән? Машиналы булуыма эче пошкандыр, тинтерәсен әле, ди торгандыр... Шулай уйлап, думада бу законны кабул иткәндә, каршы сүз әйтмичә, авызын йомып, кулын күтәреп утыргандыр...»

Ничек кенә булмасын, кулга машина кергәч, эшләр җиңеләйде. Көзге уңышны җыйган чакта күп кенә районнардан «Кызыл Ай»га бәрәңге, он, шикәр, ярма, кайчак хәтта ит тә бирәләр. Шәһәрдәге эшмәкәрләр сатылмый

калган товарларын, кием-салым китерә. Ярдәм итәргә ашкынып торучылар да күбәйде. Җәмгыятьнең бусагасын атлап кергән фәкыйрь-мохтаҗлар буш кул китми. Әшлә генә!

Шулай өч ел тырышкач, алга куелган олы максатка ирешү юлында да зур адым ясалды: «Кызыл Ай» җәмгыяте, зур колонналар белән, Чечняда барган сугышта зыян күргән качакларга гуманитар ярдәм илтеп тапшырды. Бер генә дә түгел, ел әйләнәсендә өч тапкыр.

* * *

Зәңгәр тентлы «ГАЗ», йөк ташудан тыш, «Кызыл Ай» президентының шәхси машинасына да әверелде. Рәмис хуҗасын көн саен иртән өенә килеп ала, кичен кайтарып куя. Зур түрәләр янына да шуның белән генә баралар.

Югары Советның мәһабәт бинасы каршындагы затлы мәйданда кара «Волга»лар, «Ниссан», «Тойота»лар тора. Мәрмәр белән тышланган болдыр янына килеп туктыйлар, анда үз дәрәҗәсен бик тә белгән, эре кыяфәтле хуҗаларын төшереп калдыралар да, борылып, мәйданның каршы ягына чигенеп, зәңгәр чыршылар ышыгында тезелеп басалар. Тәрәзәләре корымланган машинадан борыннарын да чыгармыйча, сабыр гына көтәләр.

Менә берзаман алып батырлар өчен ясалгандай киң, биек, тоткалары путаллы ишек ачыла, аннан затлы костюм кигән, чәчен тарап, лак белән катырган, саллы гәүдәле ир чыга. Күренеп тора, бик зур начальник. Машиналарның берсе кузгалып, әкрен генә шуышып килә дә, болдырга яны белән туктый. Абзый аның эченә чума.

Алардан күрмәкче, Рәмис тә шулай кылана торган итте бит. Кызыл айлы, зәңгәр бөркәвечле йөк машинасын болдырга яны белән китереп куя, хуҗасы төшкәч, борылып, ялтырап торган бай машиналар рәтенә баса. Хуҗасының чыкканын күргәч, кузгалып, ишеккә таба юнәлә. Әминәгә көлке дә, рәхәт тә. Карасана, нинди заманалар килде! Ни кылансаң да тыючы юк! ГАИ кая карыйдыр!

...Бер көнне шулай «ГАЗ-53» болдыр янына килеп, Әминә кабинага менеп утырган гына иде, янәшәгә кара «Ниссан» килеп туктады. Ишеге ачылып, аннан... Әмирнең иелгән башы сузылып чыкты. Әминә үзе дә сизмәстән янгыратып көлеп җибәрде. Нәкъ теге чакта, Идел буендагы шикелле. Аның күнелленнән җиңү тантанасына катыш үртәү-үчекләү ургый иде. «Әһә, муеныңны сузып астан карыйсыңмы? Шул-шул менә, мин югары, син түбән монда. Чөнки минем машина биегрәк, зуррак!» Тагын чиртте Әминә егетнең борынына. Борынына гына булса бер хәл иде, мин-минлегенә бәрде. Бер мизгелгә күзләр очрашты, ике арада башкаларга күренмәс яшен чатнагандай булды. Җайсыз хәрәкәт белән гранит плиткага чыгып баскан егет тигез җирдә сөртенеп куйды.

Моны болай гына калдыру аның аның холкында түгел, җавабы бирелергә тиеш иде.

...Икенче көнне ул «Кызыл Ай» бүлмәсенең ачык ишегә турына килеп басты.

— Әминә! Син дә монда утырасыңмыни?

Өстенә кайнар су койдылармыни — пешеп чыккандай булды Әминә, йомшарган тезләрен көчкә турайтып, өстәле артыннан торып басты.

— Исәнме, Әмир... Кер әйдә...

— Исәнме-саумы! Син кер дигәч, болай гына узып китеп булмас шул инде.

«Президент»ның кабинеты — аркылысы-буе өч-дүрт адым тар бүлмә

булып, өстәле дә, биш-алты урындык, стена буендагы иске шкаф та – кемнәрдер биргән иске-москы иде.

Олы, затлы кабинетларда, зиннәтле залларда утырырга, кызыл келәм җәелгән баскыч-коридорларда йөрергә күнеккән депутат өчен ошбу куыш күнелне изә торган булып күренгәндер. Бу уй Әминәнең күнелен сыкрандырып узды.

Әмир тезләрен кин ерып утырды, конгырт чәшке бүреген салып, күперенке чәчен бармаклары белән артка тарап куйды. Анын бу хәрәкәте шулкадәр җанга якын иде!

– Мөлеков янына килүем иде, – диде ул. – Әллә кайчаннан бирле чакыра. Кинәшәсе бар иде, ди. Һаман вакыт таба алмадым. Эшләр ничек бара сон? – дип сорады ул.

– Эш күп безнен. Авыл хуҗалыгы министры Марат Әхмәтов ел саен районнарга хат җибәрә, көзге уныштан безнен җәмгыятькә өлеш чыгаруларын сорый. Он, бәрәнге, кәбестә кайтарабыз да мохтаҗларга өләшәбез. – Әминә эчендә кайнаган хисләрне тыярга тырышып, карашын читкә төбәп, сөйләде дә сөйләде. – Узган елны өч тапкыр Чечняга гуманитар ярдәм илттек... Колоннада уникe машина иде: сигез фура, ике бензовоз, автобус, спецназ машинасы... Һәммәсенә Кызыл Ай сурәте ясалган, һәммәсенә Татарстан байрагы белән Кызыл Ай әләме эленгән. Ике мен чакрымнан артык юл уздык шулай. Андагы качакларнын безне ничек куанып, якын итеп каршы алганын күрсән син!..

... – Әминә! Мине күрмичә чыгып китмә әле!

Бу тавыш икесен дә айнытып җибәргәндәй итте. Ишек уемында Марат абый басып тора иде.

– Исәнме, – дип битараф кына баш какты ул Әмир ягына. – Хәлләр ничек?

Тик җавап көтмәде, тагын Әминәгә текәлде:

– Сүзегез бетүгә мина кер әле! – диде дә ишекне ябып, күздән югалды. Күренеп тора: Нуриевнын бер тиенгә дә кирәге юк иде ана!

Әминә башын иде: ул кемнен дә булса Әмирне бу рәвешле түбәнсетүен теләми иде. Үзе ничек шаяртып көлсә дә ярый, әмма бүтәннәр түбәсенә сукмасын, чөнки ул берләнбер – Үгез форумынын Геркулесы! Янәшә бастырып куйсан, Мөлеков анын янында ялчысы кебек кенә!

Унайсыз тынлык урнашты. Әминә башын күтәреп караганда, Әмирнен чыраеннан кан качкан иде.

Ничек тә ана җан өрергә кирәк иде. Мөлековнын кыланмышларын күрмәгән-ишетмәгән кебек кыланырга, башлаган сүзне дәвам итәргә...

– Кызыл Хач һәм Кызыл Ай оешмаларынын халыкара федерациясенә керергә кирәк безгә, – дип сөйләп китте Әминә ясалма, көр тавыш белән. – Элек СССРнын мондый оешмасы «Кызыл Хач һәм кызыл Ай җәмгыяте» дип атала иде. СССР таркалгач, анын исеменнән «Кызыл Ай»ны алдылар, ул оешма хәзер «Российский Красный Крест» дип атала. Татарлар, бу игелекле эштә катнашканда, мангайларына тәре тагып йөрсеннәрмени?

– Дөньякүләм мәйданда Кызыл Хач игелек тамгасы буларак кабул ителгән бит, бу очракта анын чиркәүгә катышы юк, – диде Әмир сүрән тавыш белән. – Ач-ялангачларга ярдәм барсын гына, ник тәре күтәреп килдегез, дип берәрсен борып җибәргәннәрен ишеткән юк әле монарчы.

– Мөселманнар андый эштә Кызыл Айлы байрак күтәреп йөри. «Төрек Кызыл Ае» мәсәлән. Нишләп әле Татарстаннан җыелган ярдәм Россия исеменнән, Кызыл тәреле әләм астында озатылырга тиеш?.. Федерациягә керсәк, татарларны дөнья мәйданында игелекле халык буларак танытырга мөмкинлек ачылыр иде. Бәлки, булышырсын? Милләт хакына бит..

— Милләт хакына аннан мөһим эшләр дә күп әле монда... — Әмирнең карашы тузанланып соры төскә кергән түшәмгә төбәлгән иде. «Әллә кайчан акшарлап куясы бар иде инде шуны. Бигрәк уңмаган инде мин», — дип уйлады Әминә.

Әмир башын борып аның йөзенә текәлеп карады.

— Хәер җәмгыятьләре болай да буа буарлык. Ә син кайчаннан бирле язмыйсың инде?

Әминә монысын көтмәгән иде. Югалып калды.

— Язгалап торам ла. Гәзитләрдә безнең аша мохтаҗларга ярдәм биргән кешеләргә рәхмәт әйтәм. Мондый эшнең мөһимлеген аңлатам...

— Аның ишене мәктәп баласы да яза! Ә синең каләмең асылда тик ята. Тик яткан каләм тутыга ул. Уйлаудан бизгән баш миен дә мүк баса. Еллар буе язмагач, тагын ничек тотынып буладыр, ай-һа-а-а-й!

Шулай дип, нык борчылгандай башын чайкап куйды. Әмма ихлас түгел иде ул.

* * *

...Әмир чыгып киткәннән соң, Әминә күзлеген салып, битен ике учына батырды да, уйларын бер тәртипкә китерергә тырышты.

Ник болай саксыз, хәтта төксе кыланды соң әле бу Марат абый? Шундый да ягымлы, мөлаем кеше ләбаса!

Дөрес, соңгы дүрт-биш ел эчендә Мөлеков шактый үзгәрде — әкренләп сүрелде, йөз-кыяфәтенә олыгаю, талчыгу галәмәтләре бәреп чыкты.

Нинди таза, яшь, хисле иде ул Бөтендөнья татарларының беренче съездын оештырганда, бәйсезлек турында референдум үткәргәндә! Ә чит ил журналистлары белән очрашкан чакларында йөзеннән нинди гайрәт бөркелә иде! Ничек гаҗәпләнеп, сокланып, шул ук вакытта аның морадына ирешәчәгенә шикләнеп карыйлар иде алар.

Әмма халык язмышы өчен хәлиткеч көрәштә җиңүгә ирешкәннән соң, күзгә күренмәс баскычтан әкренләп аска төшә башлады кебек ул.

Бөтендөнья татарларының икенче съездында үзен президент вазифаларыннан бушатуны сорап чыгыш ясады: «Миңа алтмыш дүрт тулды инде, яшьрәк, егәрлерәк кешене сайлыйк», — диде. Ул чакта Әминә, сәхнәгә йөгереп менеп, аның авызын учы белән каплардай булган иде. Яшьләр дә, егәрлеләр дә җитәрлек, тик Марат абыйны алыштырырдае юк иде!

Соңгы вакытта ул йөрәгеннән зарлана, бер-ике тапкыр хастаханәдә дә ятып чыкты. Эшеннән китеп-китеп торгалый, әмма тагын чакырып китерәләр, янә эшкә чума.

Табигый ки, мондый шартларда аның белән килешмәүчеләр, каршылар аеруча нык канат җәйде. Бер җыелышта Марат Мөлековны, азатлык өчен көрәштә йомшаклык күрсәтүдә гаепләп, махсус карар чыгарырга тәкъдим иттеләр. Председатель: «Кем бу карарны хуплый, кулларыгызны күтәрегез!»— диде. Әминә алгы рәттә утыра иде, борылып карамады. Нишләптер тавышларны санап тормадылар. «Кем каршы?» — дип сорады председатель. Һәм бераз тынып торгач: «Каршы бер тавыш», — дип өстәде. Әминәне яшен суккандай булды: «Ничек! Каршы — бер тавыш? Бер мин генә?.. Әле кайчан гына шушы залда баш иеп рәхмәт укыганнар иде бит...»

Бу вакыйга Марат абыйны аяктан егар, аның кешеләргә ышанычын какшатыр, дип уйлаган иде Әминә: «Әгәр мин булсаммы... Биек трибунадан мине хурлаган адәмнәрне мәңге гафу итмәс идем! Үчен алмый калмас идем!..»

Соңрак бер сөйләшеп утырганда, Әминә ул җыелыш хакында сүз

кузгатты. Күнеле түрендә: «Минем теге бердәнбер тавышым турында да беләдер, аны да әйтер», — дигән уй чагылып узды.

Әмма Марат абый сүзне кыска тотты. Баксаң, ул беркемгә, бернинди үпкә сакламый икән! Ул гына да түгел, хатаны үзеннән эзли башлады! Әйе, халык нинди булса, шундый, милләт файдасын кайгырткан кешеләр белән уртак тел табарга кирәк. Шулай уйлый иде ул.

Бер карасаң, моңа нигез дә бар кебек үзе. Әмма бар гаепне үз өстеңә алу дөресме? Һәр чакта да бүтәннәр хаклымы?

...Әминә уйларыннан арынырга тырышып, башын селкеде дә, урыныннан кузгалды. Ул кергәндә, Марат абый өстәлендәге бер өем кәгазьләрне актарып утыра иде.

— Бүген кич без делегация белән Бельгиягә китәбез, — диде ул, эшлекле кыяфәт белән. — Брюссельдә Берләшкән милләтләр оешмасына кермәгән халыкларның форумы үткәрелә. Шунда берәрсенә «Кызыл Ай»ны халыкара оешмага кертү турында сүз катып булмас микән. Син миңа уставыгызның, рәсми теркәлү турындагы таныкнамәгезнең күчермәсен әзерләп бир әле. Башкарган эшләрегез турында кыскача мәгълүмат та кирәк булыр. Чечняга баргач төшкән фотоларыгызның иң яхшыларын сайлап ал.

Аннары авыр сулап куйды да, ярдәм өмет иткәндәй, күзлеге аша мөлдерәп Әминәнең йөзенә текәлде.

— Кайткач, кире бу урынга утырмаска иде исәп, — диде. — Кеше таба алмыйбыз! Берсе президент ярдәмчесе булды. Икенчесе Бөтендөнья татар конгрессы житәкчесе... Өченчесе артык дуамал...

— Әмир Нуриев белән сөйләшеп карамадыгызмы?

Бу сорауның теленнән ычкынганын үзе дә сизми калды Әминә. Марат абый аңа гажәпләнеп текәлде.

— Сөйләшсәк, риза булыр дисеңме? Хәтерлисеңме, кырым татарларын үз ватаннарына кайтаруны таләп итеп, СССР Югары Советына мөрәҗәгать язган идек. Ул бит хәтта шуңа да имзасын сырламады. Танылган журналистлар, иң зур язучылар кул куйды, ә ул баш тартты.

Әйе шул, андый мөрәҗәгать җибәрелгән иде. Аны оештыру белән Нәзир шөгыльләнде. Әмма ул Нуриевның кул куймавы турында Әминәгә әйтмәде...

— Ни калган аңа монда? — дип бик мәгънәле итеп сүзен йомгаклап куйды Марат абый.

Әминә калын күзлекле бу абзыйга гажәпләнеп карады: аның каршында алыштыргысыз ил агасы утыра иде!

Әйе, беренче карашка гади генә күренгән бу абзый — Бөек Шәхес иде. Тик моны халык белми иде. Шәһәр янына килеп тезелгән танклар урыныннан кузгалмаганга күрә имгәнми-гарипләнми калган егетләр дә, балалары исән калган аналар да, йортлары җимерелмичә, имин яшәгән кешеләр дә белми иде моны. Референдумнан соң башын югары күтәреп, үз халкы белән горурланып яши башлаган татарлар да бу хакта уйлап та бирми иде.

Хәер, үз бәясен үзе дә белми иде Марат абый. Үзәктән читтә, эшче халык арасында, Һади Такташ урамында яши. Фатиры — хрущевка. Хатыны — укытучы, ике уллары бар.

Соңгы еллардагы тырышлыклары аны матди яктан берничек тә мантытмады. Икенче тапкыр аны депутат итеп сайламадылар. Милләт җанлы бер эшмәкәр аңа машина биргән иде. Тик ул үзәкнеке булып санала. Җитәкче вазифасын үз өстеннән төшергәч, Марат абый җәяү йөрүгә калды.

Милләткә эшләгән яхшылыклары белән дә башкалар мактана, аның исеме сирәк телгә алына.

...Дөрес әйтә ул: Әмир Нуриев үзенең затлы бүлмәсеннән бу иске бинаның кыршылган куышына күчеп утырмаячак. Фатирының тәрәзәләре дә Кабан күле буендагы Һади Такташ урамына югарыдан кәперәеп, кимсетеп карап тора. Бирелдәге эш хакын да анык белән чагыштырып булмый.

— Әйтер сүзең калдымы әллә? — дип Әминәне уйларыннан айнытты Марат абый. — Булмаса, бар, кәгазьләреңне әзерлә! Ашыгыч бит.

...Бу сөйләшүдән соң бер ай узгач, бер төн, Әмирне кар көртенә суырып алып, Әминәгә зур тетрәнүләр китерде.

Терелеп китәр микән? Чиргә сабышмас микән? Сихәтләнә генә күрсен иде лә!

* * *

Җилле-болытлы көн иде. Черек күл каршындагы тәрәзәләре өстән дугаланып уелган, балкон рәшәткәләре сырлап чуеннан коелган борынгы өч катлы җыйнак бинаның шар ачык капкасыннан милиция «УАЗ»игы килеп керде дә, ишегалды түрендә, биек итеп өелгән кар өеменә елышып баскан зәңгәр бөркәвечле, кабинасына Кызыл Ай ясалган «ГАЗ-53» янәшәсендә туктады. Аннан кара күн тышлы тун, шундый ук бүрек кигән өлкән яшьтәге ир төште.

Тикшерүче Вәлитов иде бу. Тышкы ишектән бина эченә кергәч, як-ягына каранды ул. Саран яктыртылган коридордагы ишекләрнең берсе ачык булып, аннан сөйләшкән тавышлар ишетелә иде. Вәлитов тавышсыз гына атлап шул якка юнәлде, сак кына үрелеп, эчкә карады.

Каршыдагы өстәл артында Мусина утыра иде. Кыска киселгән, дулкынланып торган куе кара чәчләре астыннан күзлек пыялалары гына ялтырап күренә, карашын кулындагы паспортка текәгән. Аңа яны белән бер хатын утыра. Башын чуар шәл белән ураган, өстендә таушалган куртка. Йөзе, куллары кояшта янгандай карасу — коньяк кешеседер, күрәсең. Менә ул күзләрен озын, нечкә бармаклары белән каплап, үксеп елап җибәрде:

— Ник мин чечен булып тудым икән?.. Яһүди булып тусам, мең яхшырак булыр иде!..

Әминә башын күтәрде, тик әйтер сүз тапмады булса кирәк, дәшмәде. Ул аптыраган кыяфәттә иде.

— Керергә мөмкинме?

Ике хатын да сискәнеп ишеккә борылдылар. Ят хатын кабаланып күз төпләрен шәл чугы белән сөрткәләде дә, тикшерүчегә куркынган карашын төбәде. Әминә урыныннан торып басты.

— Мансур Хуҗиевич! Сез ничек монда?!. Берәрсен эзлисезме әллә?

— Саулармысез. Сезгә йомыш бар иде.

— Исәнмесез... Узыгыз. Утырыгыз.

Тикшерүче бүреген, күн перчаткаларын салып, ишек янындагы урындыкларның берсенә утырды.

— Бу... безнең оешманың үз кешесе, — диде Әминә чечен хатынының шомын таратырга теләп. — Сез ашыкмыйсыздыр бит? — диде аннары тикшерүчегә карап.

— Сөйләшеп бетерегез. Мин коридорда да көтеп тора алам.

— Безнең сүз сер түгел, — дип урынына утырды Әминә. — Грозныйдан килгән Әнисә апа бу. Исемнәребезгә карасаң, безне бертуган диярлек.

— Сугыштан качып килгәннәрмени?

— Әйе шул... Өйләрен бомба төшеп җимергән, граната шартлап, үсмер улының аягы өзелгән. Ирен каядыр алып киткәннәр, ике ел инде хәбәре юк икән.

— Сугыш тынды бит инде. Хасавюртта килешү төзеделәр. Кире кайтырга уйламыйсызмы? — дип сорады Мансур Хуҗиевич.

— Кая? — дип сорады хатын. — Грозный шәһәре тоташ хәрабә! Кайберәүләр аны инде торгызып булмаячак, яңа урында төзергә кирәк, дип сөйли... Аяксыз бала белән кая кайтып егылыйм? Ничек яшим?

Әминә кулындагы паспортны Вәлитовка таба сузды. Кызыл катыргыга көмеш белән герб уелган, аның өстенә «СССР», астына «Паспорт» дип язылган иде.

— Бер үк ватанның тулы хокуклы гражданнары бит без. Ничек инде моннан барып, үзебезнең илнең шәһәрен бомбага тоталар? Балалар өстенә граната ыргыталар? Бернинди гаепсез кешене кулга алып юк итәләр? — диде Әминә.

— Сугыш... — диде Мансур Хужиевич.

— Кем белән? Үзебезнекеләр беләнме? Үз шәһәрләре өстенә бомба яудырган ил җитәкчеләрен кем дип атарга?

Әминә тикшерүчегә төбәлгән, гүяки акылга сыймаслык бу золымда аның да гаебе бар иде. Мансур Хужиевич күн перчаткаларын каккалап, тамагын кырып куйды. Чечен хатыны каршында моны аңлату читен иде. Әминә Әнисәгә таба борылды. Йөзе ачылып, тавышы ягымлыланып китте.

— Улыгыз русча укый аламы?

— Беренче класста рус теле керә иде. Аннары ике ел укырга йөри алмады, мәктәпләрне бомба ташлап шартлаттылар бит...

— Әйдәгез, болай итик әле. Бездә балалар өчен китаплар, альбомнар, буяу-карандашлар, уенчыклар бар. Улыгызга кирәкне сайлап алырсыз. Бигүк затлы булмаса да, киемнәр дә табылыр. Сез борчылмагыз, безгә кеше өстеннән төшкәнне генә түгел, өр-яналарны, сатылып бетмәгәнне дә китерәләр. Менә шушы абый кебек химаячеләр, — дип Вәлитов тарафына күз сирпеп алды ул. — Дөге, ярмалар, он бар. Хәзер үлчәп бирерләр. Иртәгә төштән соң килегез, аңарчы мин кайбер кешеләр белән сөйләшеп куярмын: улыгызга кирәкле дарулар бар микән, булмаса, табу ягын кайгыртырбыз. Сезне уңайлырак тулай торакка урнаштырып булмасмы... Әйдәгез, күрше бүлмәгә озатып куям...

Шулай сөйләнә-сөйләнә чечен хатынын җитәкләп алып чыгып китте ул.

Тикшерүче як-ягына каранды.

— Сезнең монда тыгынрак икән, — диде ул борылып кергән Әминәгә. — Президент званиесендәге җитәкчегә лаек кабинет димәс идем. Ә үзегез килгән бер кешегә ярдәм итәргә алынасызмы? Сезне каян белеп килгән соң әле бу хатын?

— Узган елны өч тапкыр Чечняга гуманитар ярдәм илттек бит. Шуның хәбәрен ишеткән.

— Күп идеме инде ул ярдәм?

— Колоннабыз зур иде. Азык-төлек, кием-салым, төрле кирәк-ярак, дарулар төялгән сигез фура...

Әминә, мавыгып китеп, дәртләнеп мактана башлагач кына коридордан карлыккан тавыш аның сүзен бүлде:

— Мохтаҗларга ярдәм моннан өләшенәме?

Ишек янында сынын бөгә төшеп сәер кыяфәтле бер ир заты басып тора иде. Сырган чалбар, таплы бушлат, кирза ботинкалар, постау бүрек кигән. Саргылт төк баскан арык чыраена караганда, утызлар тирәсендәдер, әмма яшькелт күзләренең карашындагы өметсезлек аны картайта иде.

— Кирәгез, — диде Әминә җитдиләнеп. — Сез кем соң?

— Милиция майоры Востряков!

— Кем-кем?

— Милиция майоры... Вакытлыча эшсез калдым...

Төрлесен ишетеп, төрле адәмнәрне күргән Әминә хәйран иде. Ул, ярдәм сорагандай, Вәлитовка күз салып алды, тегe ишеккә аркасын куебрак

борылган, карашын өске дугаланып уелган тәрәзәгә төбәгән иде. Әйтерсең лә, үзен танытмаска тырыша.

— Без фәкыйрьләргә, ятимнәргә, гарип-горабага ярдәм итәбез, — диде Әминә. — Ә сез кем турында сөйлисез? Ялгыш килмәдегез микән?

— Үземне әйтәм! Әллә башымны элмәккә тыгыйм микән? Өйдә хатыным ими баласын тотып ач утыра... Үземне беркая эшкә алмыйлар!

Востряков сөйләгән саен гасабилана, хәтта ярсый бара иде.

— Туктагыз әле... Утырып сөйләгез. Ни булды?

— Бер атна элек кенә колониядән чыктым...

Ир затының бутала-тотлыга сөйләгәннәреннән шул аңлашылды: милициядә эшләгән җиреннән җинаятьчел төркем белән бәйләнешкә керүдә, кеше үтерүдә гаепләнеп хөкем ителгән дә, бер ел элек колониягә озатылган булган икән. Менә хәзер чын җинаятьчеләрне тапканнар, моны аклаганнар, иреккә чыгарганнар.

— Бәхетегез бар икән! Котлыйм!

— Ниткән бәхет ди ул? Суд милекне конфискацияләргә дип карар чыгарган иде. Кулга тотарлык бөтен нәрсәне алып чыгып киткәннәр. Мин колониядә чакта хатыным күз кунарлык киемнәремне сатып бетергән...

— Хәзер инде, аклангач, әйберләрегезне кире кайтарып бирергә тиешләрдер бит?

— Аларның кайсын кая пыран-заран китереп бетергәннәр инде!

— Акчалата бирсеннәр соң!

Ир заты Әминәнең аңгыралыгына гаҗәпләнгәндәй, тынып торды.

— Хөкүмәттән акча дәгъвалап йөрүнең ни икәнен белмисезме әллә? Айларга, елларга сузыла ул. Анарчы ничек яшәргә?

Әминә аның кыяфәтен баштанаяк күздән кичерде. Алмаслар шул, төрмә кошы икәнлеге әллә каян күренеп тора.

— Бездә кием-салым бар-барын. Тик менә сезгә яраклысы табылыр микән? Күреклерәк булсын иде бит...

Көтмәгәндә Мансур Хужиевич телгә килде:

— Килешле костюм кирәк. Тукымасын табып булыр иде дә бит, тектерү яклары ничек сездә?

Востряковның чырае яктырып китте, сыны турайды.

— Хатын тегә минем! Ательеда эшли иде!

— Күксел габардин. Өч метр. Ярардыр бит?

Востряков сөенеченнән нишләргә белми, шул ук вакытта ышанып та житми иде кебек.

— Сездә шундый товарлар да өләшәләрмени? — диде ул шаккатып.

— Җайлы чакка туры килдегез бит, — диде Әминә. — Бай химаячегә тап булдыгыз.

— Аны ничек алырга соң?

— Иртәгә шушында килегез, — диде Мансур Хужиевич.

— Әйткәннәр иде аны... Ышанмаган идем, — дип таптанды Востряков.

— Кем әйтте? Ни дип?

— Күрше карчыгы. Аның кырык яшьлек инвалид кызы, караваты ватылып, аягын сындырган. Янасын алырга хәлләреннән килми, ике ай идәндә ятты бичара. Зарын сезгә сөйләгән икән, узган атнада карават та, матрас-җаймаләр дә китерделәр, дип сөйләде. Куанычы эченә сыймый. «Бар шунда, хәленә керми калмаслар», дип ул үгетләп җибәрде.

— Ә бүген ярмалар алып китегез. Төрлесеннән. Тары ярмасы, борчак, манный, он... Әйдәгез.

Әминә кире әйләнеп кергәндә, Мансур Хужиевич уйчан, гаҗәпләнгән кыяфәттә иде.

— Каян алып бетерәсез соң сез бөтен кешегә кирәк нәрсәне?
— Ә сез менә костюмлыкны каян алмакчы?
— Кибеттә товар юк чакта хатын кайдадыр юлыккан да алган иде. Ә минем нәкъ шундый костюмым бар. Ята иде шунда.
— Караватны да сезнен кебек бер игелекле җан бирде. «Яшьләр үзәге»нен кунакханәсе бар бит. Шунын директорына бардым. Башировны беләсез микән... Шуңа үтенеч язган идем. Башта үзе барып караган, аннары караватын да, башкасын да илттергән...
— Мондый эшне хөкүмәткә йөкләргә ярамый, — диде Мансур Хужиевич уйланып. — Боларны фәкать сезнен кебек җәмәгать оешмалары гына башкара ала...
Аннары бераз тынып торды да:
— Сез теге кәгазьне бүгеннән юк дип санагыз, — диде.
— Нинди кәгазьне?
— «Подписка о невыезде» дигәнне. Барыгыз кирәк жирегезгә... Мин дә сезгә ярдәм сорап килдем бит әле. Кире бормассыз, дип өметләнәм.
— Кушыгыз гына! Кулдан килгәннең бөтенесен эшлибез!
— Хастаханәгә барып, Нуриев белән сөйләшергә кирәк.
— Хәле яхшыра, дигәннәр иде бит!
— Аныкы яхшыра. Ә менә безнең хәлләр бер килеш тора. Чөнки ул сорауларга җавап бирүдән баш тарта. Бәлки, сезне тынлар?
— Ә хатыны?..
— Луиза Радиковнаны борчу урынлы булмас, дип уйлыйбыз. Аннары шунысы: Төркиядә иде бит ул. Ә сез монда, стена аша гына булгансыз. Бер генә сорауга җавап кирәк: ул кичне Нуриев кайда булган, кемнәрне күргән, нәрсә ашаган һәм эчкән.
— Нишләп бер генә дисез? Өч булды бит инде...
— Һәм ничек ул сезнең йорт янына килеп егылган. Моны фәкать сез генә әйттерә аласыз.
— Нишләп мин генә?
— Нишләп икәнен үзегез белмисезмени? — дип, куе кашлары астыннан кистереп карады тикшерүче. Әминә дәшмәгәч, сүзен дәвам итте:
— Бүген шәһәр советында зур җыелыш, көн тәртибендә Төркиягә барып кайтунын нәтиҗәләре дигән пункт та бар. Луиза Радиковна чыгыш ясаячак. Димәк, ул аннан китә алмый. Бик җайлы вакыт. Баш врачка әйтелгән, сезне борчымаслар, иркенләп сөйләшерсез. Хәзер үк кузгалсак, яхшы булыр иде.
— Әгәр... мин барырга теләмәсәм?
— Ул чакта... бик каты үгетләргә туры килер. Ничек тә күндерергә.
— Әгәр күнмәсәм?
— Сез депутат түгел бит... — дип көлемсерәде Мансур Хужиевич. — Закон кушканча сөйләшеп була!
— Ә депутат белән закон кушканча сөйләшеп булмыймы?
— «Депутатская неприкосновенность» дигәнне беләсездер бит. Шулай булгач, өстәгеләр безгә карышса да үтеп китә, ә гади гражданнар ярдәм итәргә бурычлы.
Әминә авыр сулап торып басты.
— Бер шартым бар, — диде. — Анда барганчы өйгә сугылып чыгарга кирәк булыр...

* * *

Ишек ачылуга ак җәймә белән капланган ятактан торып басты ул. Йөзендә гаҗәпләнү чагылды. Аннары гүяки болыт күләгәсеннән кояш чыктымыни: ирен читендә сөйкемле чокыр пәйда булды, күзләрендә таныш

очкыннар кабынды, хәтта чәчләреннән нур сирпелде кебек. Кайчандыр, патша сарайларыннан да күренмәс әкияти манзара балкыган зур тәрәзә каршында, зиннәтле бүлмәдә, затлы нигъмәт тулы табын янында ул шушындый иде. Шулхәтле якын, шулхәтле газиз, үз тәненнен-җанының яртысы... Ул кочагын җәйде, Әминә, кулларын сузып аңа таба атлады, башын күкрәгенә салды. Күнелен әйтеп бетермәслек куаныч биләп алды. Ул терелгән, үзгәрмәгән, һаман элеккечә!

— Әллә төш күрәм инде, — дип аның башын сыйпады Әмир. — Каян белдең минем сине көткәнне?

— Үзем сагынып килдем...

— Мин чакырдым сине. Теге чактагы кебек. Хәтерлисеңме, бию кичәсендә...

— Мин үзем бардым!

— Юк, мин чакырдым!.. Ә теге кичне син чакырган идең... Чакырдың, килдем... Ә син чыкмадың... Газаплама мине...

Әмир кайнар пышылдап бер кулы белән аны күкрәгенә кысты икенче кулы белән баш артыннан чәчен авырттырып умырып тотты да, үзенә тартты. Бу авырту шулкадәр татлы иде!..

Шул мизгелдә Әминәнең колагын өтеп бер пышылдау килеп ирешге: «Мин сина ышанам... Онытма мин барын!»

Ул ике учын Әмирнең күкрәгенә терәп, артка каерылды, борылып ишеккә карады. Аны кочкан куллар йомшап киткәндәй булды.

— Кем бар анда?!

Әминә чәчләрен рәтләде.

— Әмир! Ниләр булды ул кич?

— Дөресе шул: мин сине шундый сагындым, түзәр хәлем калмаган иде...

— Ә килер алдыннан кайда булдың? Кемне күрдең?

— Шуны сорарга килдеңмени?

— Мансур Хуҗиевич, тикшерүче, зарлана. Кем кыйнаганын әйтмисең икән. Аннан алда ниндидер ярамаган нәрсә эчкән булгансың...

Әмирнең йөзе сүрелде, күзләрендәге очкыннар юкка чыкты.

— Милициягә ялландыңмы әллә?

— Җинаятьчеләрне табып, утыртырга кирәк бит!

— Кемгә кирәк? Ниндидер милиционерны начальнигы мактасын өченме? Кысылмаган җирен юк!

Әминә башын иде. Калтыранган куллары белән сумкасының биген ачты. Ул анда бер-ике алма, әфлисун салган иде. Хастаханәгә күчтәнәчсез бармыйлар бит инде. Ләкин аларны биреп булмый иде... Капшанып сумка төбеннән көмеш билбау тартып чыгарды.

— Минем моны кияргә хакым юк инде...

— Куй шунда, — диде Әмир, башын читкә борып. Әминә бер-ике адым алга атлап, билбауны ак чүпрәк белән капланган тумбочкага куйды.

— Сина тагын бер сүз әйтәсем бар иде. Теге чакта... тынлар хәлдә түгел идең...

— Әйтергә иде. Авызыңа йозак салмаган...

— Һәммәсен сүз белән әйтеп бетереп булмый... Күз карашыннан аңладым... Сина шулай җайлы булыр, дип уйладым...

— Кайчан синен мина җайлы эш кылганың бар? Мине кайгыртсаң, улыбыз тупырдап үсеп килер иде инде!

— Ике улыбыз... — дип пышылдады Әминә.

— Әйе, агалы-энеле... Икәү дә, өчәү дә! Әйткән идем бит мин сина!

— Безнен игезәкләребез булырга тиеш иде... Кичер... Мин синен өметләренне аклый алмадым...

Әмир ятагына утырып, башын иде. Иннәре салынып төште...

...Соңгысын әйтмәскә кирәк булгандыр. Җан яраткан кешенең болай да сыкрап торган йөрәк ярасына ник инде учлап тоз салырга?

Әмма ул әйтте. Моннан ары беркайчан да чакырмасын һәм үзе дә килмәсен өчен әйтте моны Әминә.

* * *

— Мансур Хуҗиевич? Исәнмесез. Сезнең белән депутат Нуриевның ярдәмчесе Илзирә Хөснуллина сөйләшә. Әмир Солтанович сезнең белән очрашырга тели иде. Бүген сәгать өчтә килергә мөмкинлегегез булыр микән?

— Әмир Солтанович чакырганда мөмкинлек табарбыз инде.

...Затлы бина, мәрмәр идәннәр, кызыл паласлар сузылган баскычлар, җем-җем елкылдап янып торган алагаем зур бәллүр люстралар. Өстән-аска тавышсыз шуышып йөри торган лифтлар... Тыныч, буш, мәһабәт бина... Тормышның түбән катламнарында күбрәк айкалырга күнеккән тикшерүче, мондый урыннарга килгәч, гадәттә фәлсәфи уйларга бирелеп ала. Бар бит кешеләр: эшкә дә театрга баргандай йөриләр. Андыйларга гадәти конторларга төшеп утыруның фаҗигагә әверелүе гаҗәпмени?

Пыяла куышта актан киенгән милиционер утыра иде, тикшерүчене күргәч, торып басты.

— Тыңлыйм сезне!

Җавапны тыңлагач, телефон трубкасын күтәреп шалтыратты да:

— Хәзер төшеп алырлар, — диде.

Баскыч борылышында ак якалы зәңгәр күлмәк кигән, көлсу чәчен күпертеп куйган, урта буйлы, нечкә билле хатын-кыз күренде. Утызлар тирәсендәдер. Буй-сыны ыспай, ә менә төскә-биткә уртача: борыны юка, җеп кебек сызылып каралткан кашлары астыннан күзләре сагаеп, эчке курку белән карый, нык кызартылган иреннәре көчәнеп елмая. Сөйкемлелек җитми ханымга. Ә бәлки, туташкадыр? «Ялгызга охшаган, мөгаен, баласы да юктыр», — дип нәтиҗә чыгарып куйды тикшерүче.

— Исәнмесез. Рәхим итегез, Әмир Солтанович сезне көтә, — диде хатын тавышына мөмкин кадәр бал өстәргә тырышып.

Тыштан да, эчтән дә елкылдап торган тимер лифтта өскә күтәрелделәр, сары каймалы кызыл келәмгә тавышсыз басып, коридор буйлап үттеләр, алтакталар эленгән ишекләрнең берсен ачтылар. Алгы бүлмә буш иде, эчтәге ишеккә беркетелгән алтактага «Россия Дәүләт Думасы депутаты Нуриев Әмир Солтанович» дип язылган.

Зур бүлмәнең түрендәге өстәл артыннан йомры җирән башлы, текә муенлы, киң җилкәле ир кеше торып басты.

Ике атна элек кенә ул шәһәрнең иң хәерче хастаханәсендә, башы марляга уралып, телсез-хәлсез яткандыр дип кем уйлар?

«Урын кешене бизәми, кеше урынны бизи», — диләр тагын. Сафсата! Тәмле-сыйфатлы ризык белән тамагын туйдырып, юындырып-кырындырып, шушылай ыспай киендереп, ислемай сибеп, шушы урындыкка мендереп утыртсаң, дүрт саны төгәл, мие череп акмаган теләсә кайсы бәндә егет солтаны булып күренәчәк!

Мансур Хуҗиевичка исә бу адәм хастаханә ятагында чакта күңелгә якынрак тоелган иде. Гадирәк, эчкерсезрәк кебек.

Хәзер исә ялтыравык киң өстәл ике араны атлап үтеп булмастай итеп бүлеп куйган иде кебек.

— Узыгыз, уз!— дип, ике кулын сузды Нуриев. — Менә монда утырыгыз! — дип, ян өстәл кырыендагы урындыкка күрсәтте. Шулай итеп, ике арада

дистанция калдырды. Дустанә сөйләшергә теләгән начальниклар, кагыйдә буларак, урыннарыннан күчеп, каршыга утыралар. Ә бу алай итмәде.

— Рәхмәт инде сүз тынлап килүегезгә, — диде. — Повестка белән үзегезгә чакыртсагыз да бернишли алмас идек.

— Сезне болай гына чакырып булмый, — диде чак кына көлемсерәп Мансур Хужиевич. — Адвокатыгыз телефоннан шалтыратып, ник борчыйсыз андый зур кешене, дип кызыксынса гына инде.

— Һе-һе, — дип, бармаклары белән җирән бөдрәләрен тузгытып, көлеп куйды Нуриев. — Кайларда гына йөрми, ниләр күрми ир-егеткәй белән ат башы... Җырда да җырлана бит... Малай чакта ук шактый кыен ашаган булды... Андыйларны тикшерә китсәң... Сезгә дә эш күптер.

— Буш тотмыйлар.

— Төркем-төркем бандалар оешып, Казанны бүлешеп бетерделәр, дигән сүзләр йөри. Исемнәрен дә атап әйтәләр: «Жилка», «Квартал», «Перваки»... Әле анда бер өере кәбахәтләрчә үзен даһи шагыйребез Һади Такташ исеме белән атаган, диләр... — Бу урында Нуриев йөрәге әрнегәнне белдергәндәй көрсенеп куйды.

— Шагыйрьнен үзе түгел, урам исеме белән. Яшәгән җирләрендә укмашалар, шуна карап төркемнәренә кушамат тагалар, — дип аның сүзен җөпләде тикшерүче.

— Кайчан шуларга чик куелыр инде! Балаларны урамга чыгарырга куркыныч! Күптән тамырларын корытырга кирәк!

— Ил болганып, дәүләтнең нигезе какшаганда, җинаятьчеләр азына шул инде. Андыйның тамырына чабар өчен балтаның үткен, нык булуы кирәк. Хакимият кулындагы балтаның диюем. Җинаять өчен гадел җәза бирелергә һәм ул котылгысыз булырга тиеш. Сез бирәсез безгә коралны, ә бездән аны дөрес куллану таләп итеlә!

Нуриев, тикшерүченең карашыннан күзләрен яшергәндәй, өстәлендә яткан газеталарны тәртипкә салгандай итенде.

— Таләп куючылар табылыр анысы... Минем сезнең белән конкретрак сөйләшәсе килгән иде. Бу... хастаханәгә эләгүем мәсьәләсендә... Җинаять эше ачуга ук барып житмәгәндер шәт?

— Ә сез ничек уйлыйсыз! Дәүләт думасы депутатын эштән чыгарып кыйнап ташлаганнар. Мөгаен, үтерергә теләгәннәрдер. Покушение на убийство. Уголовный кодексның утызынчы статьясы. Депутатка һөҗүм — аеруча куркыныч җинаять. Ул ачылмый калырга тиеш түгел. Төптәнрәк уйлап карагыз әле: нинди дошманнарыгыз бар?

— Бәреп үтерергә ажгырганнарын белми идем әле моңарчы...

— Әгәр дә сез гади генә сорауларга җавап бирергә риза булсагыз, бу очракта безнең эш күпкә җиңеләер иде.

— Сорагыз — җавап бирәбез...

— Сез берәр төрле психотропный препарат кулланмыйсызмы?

— Наркоман димәкчеме әллә мине?

— Һәрхәлдә каныгызда билгеләре табылган бит... Анализлар шуны күрсәтә...

— Анализ ни күрсәтмәс... Хатын командировкада иде. Бала әбисендә. Өйдә ялгызым... Ялгызым... Яшереп булмый, бераз салып та куелды. Суыткычта барын капкаладым. Текиласы, мангосы, помидоры, колбасасы бергә кушылган. Анализ ясаганда ул җәһәннәм катнашмасы нинди булып күренмәс?

— Берәр төрле дару да эчмәдегезме?

— Дару?.. Күмер төймәсеннән башка нәрсә капканым да юк. Анысы да алай-болай ашказаны үзен сиздергәндә генә. Хәзер дә бар булганы менә шушы.

Шулай дип, Нуриев өстәл тартмасыннан өч-дүрт дару кабы чыгарды.

— Бирегез әле! — дип кулын сузды тикшерүче.

— Нәрсәгә ул сезгә?

— Экспертиза ясатырбыз.

— Анысы ник кирәк тагын? Язуы өстендә бит. Ни икәне болай да мәгълүм.

Шулай дип, Нуриев капларны кире тартмага салды.

— Сез аларны күптәннән эчәсезме?

— Әйтәм бит, аның ишене гомер капкан юк иде. Сихәтләнеп бетү өчен кирәк дип, табиблар әле бирде.

— Башка берәр кеше кулыннан дару алып капмадыгызмы?

— Томана карчык түгел лә мин теләсә кемнән дару сорап йөрергә... Хаста да түгел.

— Бәлки, үзегезгә сиздерми генә эчергәннәрдер?

Нуриев аңа шаккатып текәлде:

— Кемнәр? Ник?

— Экспертлар әйтүенчә, андый матдәләрне кайбер им-томчылар да кулланалар икән. Әйтик, берәр чирдән дәва дигән булып. Кемдер бозган, сихерләгән, күз тидергән, шуны кире кайтарырга ярдәм итә дип. Яисә сөйдергеч рәвешендә...

Соңгы сүзләрдән Нуриев дертләп китте.

— Миңа сөйдергеч эчергәннәр, димәкчеме әллә сез? Ходай язмаганны...

— Кызганычка каршы, андый хәлләр булгалап тора шул. Табындашларыгыз кемнәр...

Нуриев сорауны тыңлап бетермәде.

— Нинди табындаш! Өйдә берүзем идем дидем бит.

— Ә бәлки, хатыныгыз китәр алдыннан суыткычка куеп калдыргандыр? Шул ук текилага кушып, мәсәлән?

— Луизамы? — Нуриев башын чайкап куйды. — Юк инде, ана кагыла алмассыз. Ул кадәресенә юл куеп булмас. Текиланы мин шул көнне алып, кесәмә салып кайттым.

— Димәк, сез кичен өегезгә кайтып, текила эчкәнсез, авокадо белән помидор ашагансыз. Аннары төнгә каршы өегездән чыгып киткәнсез. Җәяү... Ник персональный машинагызны чакырмадыгыз?

— Кая чыгып киткән?.. Беркая да китмәгән...

— Алайса ничек соң Мусинаның тәрәзә каршына барып чыктыгыз?

— Шул текила галәмәтедер инде. Әйтәләр аны, урыс аракысыннан яхшысы юк дип... Нәфес бит, төрлесен татып карыйсы килә. Тәмам башны бутаган. Ник чыгып киткәнмен, кая барганмын — берни хәтерләмим...

— Ярый әле, шунда егылгансыз. Башка җирдә булса, бәлки, игътибар да итмәсләр иде. Карда озак ятып каты салкын тигезүегез ихтимал булган. Ә бәлки, Алла сакласын, бөтенләй уянмаска... Мусина коткарды сезне. Бер генә дә түгел, ике тапкыр.

— Нишләп ике?

— Сезне тәрәзәсеннән күреп, «Ашыгыч ярдәм»гә шалтыраткан — бер. Кемлегегезне ачыклар өчен аны чакырырга туры килде. Ул сезне таныды — бусы икенче.

Тикшерүче депутатка сынап текәлде. Әминәнең аны күргәч ничек үксеп елаганын әйтергәме? Үз-үзен белештермичә, кулларын үбә-үбә ничек өзгәләнгәнен? Менә хәзер өстәлдәге газета битләрен актаргалаган тынгысыз бармакларны... Нуриевның карашы каядыр почмакка төбәлгән, чырае агачтай җансыз кебек иде. Юк, хискә бирелүчән, нечкә күңелле хатынның

ул чактагы хәлен бу минутта сөйләп утыру урынлы булмас. Әмма бу кеше анын йорты турына очраклы гына барып чыкмаган, һич юк!

Тикшерүче башлаган сүзен дәвам итте.

– Унбишенче хастаханәдә билгесез сукбай булып ятсагыз, ничек дәвалdescribed иде дә кайчан сихәтләнер идегез әле. Мусина кемлегегезне әйткәч, сезне шундук махсус клиникага күчерделәр. Ә анда нинди аппарат, дару кирәк, һәммәсе бар. Теләсә кайсы профессорны чакырып китерәләр...

Нуриевнең чырае агарынып китте:

– Миннән сорамадыгыз бит кемне кая алып килергә. Анысы инде сезнең эш... Җинаятьне тикшерүдә үз фаразларыгыз бардыр.

– Фаразлар бар. Сезне урам бандитлары кыйнагандыр, дигән фикер, мәсәлән. Җинаятьнең бердәнбер шаһиты – сез. Алар ничәү иде, кыяфәтләре, киемнәре, йөз чалымнары. Ни дип килеп бәйләнделәр? Кулларында берәр төрле әйбер бар идеме?

– Әйттем ич инде, хәтерләмим, дип. Бу очракта минем үз фаразым бар.

– Нинди инде ул? Бәлки, безгә дә әйтерсез?

– Машина бәргәндер, дип уйлыйм...

– Ләкин судмедэксперт әйтүенчә...

– Ә минем белүемчә, – дип анын сүзен бүлдерде Нуриев, – җинаять эше кузгатыр өчен каза күргән кешенең гариза бирүе зарур. Минем андый гариза биргәнем юк. Ә бәлки, урам баганасына башымны үзем бәргәнмендер! Текила галәмәте тәэсирендә! Психотропный дигәнегез дә шуллыр әле, мөгаен!

– Ә үзегез җинаятьне тамырыннан корытуны таләп итмәкче, – диде, теше сызлагандай чыраен сытып, тикшерүче. – Таптап-изеп ташлаган адәм актыкларыннан үч аласыгыз да килмимени сон?

– Бөтен эшегез мина килеп терәлгәнме әллә? Бандитларын да, төркемнәрен дә белеп торасыз лабаса. Мин төртеп күрсәткәнне көтеп тормагыз, җыештырып алыгыз да ябып куегыз! Халыкның җаны тынар иде!

– Ябып куяр өчен суд карары кирәк. Суд булсын өчен җинаятьне исбатларлык дәлилләр кирәк. Вещдоклар. Күргән-белгән кешеләрнең шаһитлык итүе. Әгәр дә безнең гражданнарның һәркайсы, намусы кушканча эш итеп, күргәнен-белгәнен ихластан сөйләсә, хулиганнар, бандитлар бу хәтле котырына алмас иде. Кыйналганы да, таланганы да курка. Судка барып шаһитлык кылсам, йә үземне, йә баламны үтерерләр дип котлары оча. Бер янагына суккач, икенчесен куеп тора дигән сүз бар бит. Күпчелек шундый. Мин инде сезне андыйдыр дип уйламаган идем. Куркак диясем килми... Мондый очрак белән бәйләп, матбугатта исемегезне чыгарасыгыз килмидер, бәлки?

– Ә сез менә шушы минутта бирегә, камераларын сөйрәп, «Эфир» журналистлары бәреп керүен теләр идегезме әллә?

«Эфир» телевидениесынын журналистлары чаялыклары, әрсезлекләре белән дан тота. Эләктерсеннәр генә! Бигрәк тә урысларга тел тидергән кеше килеп капса — кинәнәчәкләр. Алар каршында: «Текила эчкән идем, мием түнгән. Төн уртасында, «Кызыл Ай» җәмгыятенең җитәкчесе Мусинанын тәрәзәсе турына барып, башымны урам баганасына бәреп ярганмын...» – дип, лыгырдап утыра алмассын! Кара данынны миргә сибәчәкләр. Кеше күзенә күренерлеген калмас. Дөресен сөйләсән, бөтенләй адәм хуры булачаксын!

– Сонгысын әйттердегез инде, – дип дәвам итте Нуриев. – Ярылган

баш ярылган, яралары төзәлгән. Үткәнне кире кайтарып булмый. Кемнедер утыртып куйганнан мина ни файда?.. Ирләр бит без, бер-беребезнең хәлен анларга тиеш... Сул тарафка кыяклаган чакларның да булуы ихтимал.

Нуриевның чырае кинәт ятырып китте, ул тикшерүчегә якын, үз итеп, елмаеп карады.

— Нишләп әле без һаман минем хакта гына сөйләшәбез? Сезнең хәлләр ничек соң? Гаиләгездә иминлекме? Фатир яклары ничек? Милициядә хезмәт хакы ташка үлчим дип сөйлиләр. Думада да бу мәсьәлә күтәрелде. Берәр теләгегез, тәкъдимегез булса, әйтегез...

— Кызыксынуыгыз өчен рәхмәт. Өйдә иминлек әлегә. Урамнардан аермалы буларак... Ничек мин сездән ярдәм сорыйм, үзегез ярдәм итмисез бит, — дип борын астыннан әйтеп куйды да урыныннан кузгалды тикшерүче. — Китәргә мөмкиндер бит? Сау булып торыгыз. Тагын берәр тапкыр һөҗүм итсәләр...

Нуриевның чырае каралып чыкты:

— Нишләп әле алар гел-гел мина килеп ябышсын?

— Үч алу максаты белән һөҗүм иткәннәрдер дигән фараз да бар бит. Башта җаен табып нәрсәдер эчергәннәр, аннары артыгыздан килеп...

— Андыйга бүтән юл куймассыз бит инде?

— Алар сорап тормый. Депутатская неприкосновенность дигәненә дә төкереп тә бирмиләр. Үз җилкәгездә татыдыгыз. Без генә якын килә алмыйбыз.

— Бөтен ышаныч сездә инде! — диде Нуриев йомшарып. — Мондый хәлләр турында бүтән сөйләшергә язмасын иде. Күнелле шартларда очрашып, җиңүләрегез белән котларга насыйп итсен Ходай. Уңышлар телим! Исән булыгыз!

...Алгы бүлмәдә утырган зәңгәр күлмәкле хатын, тикшерүчене күргәч, аягүрә торып басты. Аның сөрмә тартылган соры күзләрендә сагаю, шөбһәләнү ярылып ята иде. «Ә бу хатын нәрсәдер белә бит... — дип уйлады Мансур Хуҗиевич. — Кызганыч, чакырып, сорашып булмаячак. Нуриев моңа юл куймас, мөгаен. Кирәкмәгәнне әйтеп ташламагае, дип шикләнер. Куркыр өчен бардыр сәбәпләре...»

* * *

«Артыграк әйтеп ташладым, — дип уйлады Әмир тикшерүче чыгып киткәч. — Ул кадәр үк ачылырга кирәкми иде. Кем белә бит аның бу хәтле киребеткән икәнлеген. Казына да казына... Луизага барып ябышмагае!.. Алдыртырга кирәк аннан бу эшне. Алдыртырга да туктаттырырга...»

Шулай дип уйлап, өстәлендәге селектор аппаратының төймәсенә төртте ул.

— Илзирә, кер әле.

Илзирә сискәнеп китте, сумкасыннан кечкенә көзге алып, агарынган чыраен карады, ак якасын төзәтеп куйды. Йөрәгенен тарсылдап тибүен басарга тырышты. Ни сөйләде икән анда тикшерүче? Ни әйтер хәзер ана хуҗасы? Әйе, хуҗасы... Эш буенча гына да түгел — җанының, тәненең хуҗасы!

Ул, сугып җибәрүләреннән курыккан кебек куырылып, кабинет эченә атлады.

— Ни булды? — дип сорады Әмир, аның йөзенә карагач.

— Ә нәрсә?...

— Төсен качкан. Чирләмисеңдер бит?

— Башым авыртып тора...

Илзирәнең йөрәге тигезрәк тибә башлады: хуҗа тыныч күренә, әле

генә чыгып киткән адәм аңа андый-мондый хәвефле сүз әйтмәгән булса кирәк.

— Миндә баш даруы бар. Биримме?

— Рәхмәт. Мин... эчтем инде, — дип ялганлады Илзирә.

— Нишләп анда торасың? Якынрак кил. Утыр.

Илзирә әле һаман тынычланып житә алмыйча, сагаеп кына ян өстәл кырыена барып утырды.

— Безнең монда үзгәрешләр булырга тора бит әле, — диде Әмир аның йөзенә туры карамыйча. — Үзең беләсең, гомер буе депутат булып булмас, аллагыны уйларга туры килә. Мине Мәскәүгә эшкә чакыралар. Мәдәният министрлыгына.

— Министр итепме?..

Илзирә хуҗасының югары күтәрелүенә куанырга тиеш иде кебек, әмма аның тавышында хафалану чагылды. Әмир, карашын аска төшереп, башын селкеп куйды.

— Юк, милли республикалар буенча бүлек житәкчесе итеп. Без монда... кинәштек тә... — Ул тел очына килгән «Луиза белән» дигән сүзне йотып өлгерде... — бу тәкъдимне кабул итәргә кирәктер, дигән фикергә килдек.

— Мәскәүгә китәсезмени? Кайчан?

— Министр кайчан приказга кул куяр... Монда сиңа да бер тәкъдим бар иде. Казансу арты районы мәдәният бүлегенең житәкчесе Смирнованы министрлыкка алалар. Шуның урынына сине куйсак, ничек уйлыйсың?

Шактый югары урын, дәрәҗәле, тотрыклы. Алга таба үсәргә юллар ачыла. Бу инде сина «депутат ярдәмчесе» дигән вакытлы шөгыль түгел! Егерме тугыз яшенә житеп, күзгә күренерлек бернинди эш майтара алмаган, шәһәргә дә күптән түгел генә килеп урнашкан кыз, мондый сүзләрне ишеткәч, сикереп торып, мең рәхмәтләр укырга тиеш иде. Әмма Илзирә кузгалмады, чырае ачылмады, киресенчә, күзләрендә соң дәрәҗәдә гажизләнү чагылды. Ничек була соң әле бу: хуҗасы Мәскәүдә яшәячәк, ә ул... монда каламы?

Әмир аны сүзсез аңлады. Урыныннан кузгалып, янына килде дә иңенә кулын салды. Илзирә аның беләгенә ябышты.

— Мин синсез яши алмыйм...

Әмир аның башын сыйпады. Хатынның көлсу чәче лак белән катырылган иде, уч төбен керләндергәндәй итте.

— Шулай шул инде ул, яратам дигәндә газапларына да әзер булырга кирәк... — диде Әмир ниндидер эчке бер мәгънә белән. — Мин синең төшеп калуыңны теләмим. Аягында нык басып торсаң иде. Алда ни булмас...

— Ташлама мине!..

— Казан белән Мәскәү арасы ул хәзер ике урам арасы кебек кенә. Самолетлар очып тора, поездлар йөреп тора.

Илзирә аягына басып, аны үбәргә үрелде. Әмир сак кына читкә этәрде.

— Сабыр... Ни булды әле сиңа? Эш урынында ярамаганын беләсең ләбаса. Монда син фәкать депутат ярдәмчесе генә. Калганы кеше күзеннән читтә!

— Бүген кил, яме? Килми калма!

— Бүген булмас. Районнан кунаклар килә.

— Ә иртәгә?

— Иртәгәсен карарбыз. Мин хәзер китәргә тиеш. Шоферга әйт әле, әзер торсын.

Илзирә чыгу ягына борылгач, Әмирнең йөзе кырысланып, карашы катыланып китте. «Сөям» дигән була үзе. Сөю түгел, саташу бу! Сөйгән ярына теләсә нәрсә эчерәләр димени?»

Тикшерүче «психотропный препарат» дип атаган нәрсәне анын бокалына фәкать шушы хатын гына сала ала иде.

Кичне ул анын янында үткәргән иде шул. Әйе, текила эчтеләр, табында авокадосы да, помидоры да, тагын төрле тәм-том бар иде. Кәеф күтәрелеп, тамак туйгач, Әмир гадәттәгечә аны, биленнән кочып, үз янына диванга тартырга тиеш иде. Әмма ана әлләни булды. Күз алдын томан сарды, колагында көлү тавышы янгырады: «Ха-ха-ха! Ха-ха-ха!» Кин Идел, яр читендә ялгыз өянке, комлыкта баш очына зәнгәр йөзгечләр күтәргән кыз... Анын Югары Совет бинасы янында, зәнгәр чыршылар янәшәсендә, курткасынын чабуын ачып, көмеш билбавын күзгә ташланырлык итеп күрсәтеп, басып торган чагы...

«Мин сине шундый сагынды-ы-ым!...» – дигән тавыш ишетелде ана.

«Киләм! Хәзер киләм!» – дип җавап бирде Әмир күнеленнән.

– Син кая? – дип, анын җиненә ябышты Илзирә.

– Онытып җибәргәнмен... Килергә тиешләр бит мина...

– Кая, озатып куям...

– Озатмыйсын беркая да... Кайчаннан бирле син мине җитәкләп йөри башладын әле...

Урамга чыккач, узып барган «Жигули»ны туктатты да:

– Четаев урамына, – диде ул.

Каян белде икән ул Әминәнен кайда торганын? Ник кирәк иде ул ана? Ләкин белә иде, кирәк иде. Анын дөньяда яшәгәнен белеп торырга кирәк иде. Рәхәт яшәгәнен...

Алай да бу теләк, бу хис күнелнен ин тирән бер почмагына кереп поскан иде бит инде. Бөтенләй сүнгән, көмеш билбаулы кыз тәмам онытылган кебек иде. Ничек болай ялкын теле кебек үрләп чыкты да тәкатьсез итте сон әле ул? Хәзер менә шушы минутта аны иннәреннән кочып, күкрәккә кысасы килә... Алтын кысалы күзлеген салдырып, мөлдерәгән күзләренә карап: «Ничек яшисен минсез? Бәхетлеме син? – дип сорыйсы килә. – Мин бүләк иткән көмеш билбауны киясенме?»

Машинадан урам чатында төшеп калгач, кыр-кырыйларына тездән югары итеп кар өелгән юл буйлап, тар аулак урамнан бераз барды да, туктап өченче каттагы тәрәзәгә төбәлде ул. Алтынсу пәрдәләр аша йомшак яктылык сибелә, ана берәүнен янган йөрәгеннән ургыган ялкыннын шәүләсе дә кушылган кебек иде. Менә ул пәрдәне ачып карар. Күрер һәм... Әмир ана әйткән иде бит, күзләрем лазер кебек, шунын нурлары белән сине чакырдым диеп... Хәзер дә чакыра. Ул сизәр, йөгереп чыгар...

Каршы йорт артыннан биш-алты ир заты килеп чыкты. Кычкырып сөйләшүләренә һәм кулларын йогышсыз болгауларына караганда, яшьләр иде болар һәм салмыш иделәр булса кирәк. Мөгаен, сыраны артыграк чөмереп җибәргәннәрдер.

– А этот дядька что тут делает? Бу абзый нишли монда?

– Күзгә чалынганы юк. Безнекенә охшамаган.

– Клевый такой! Портфель тоткан!

– Глянь, это же депутат!

– Күзенне ачыбрак кара! Каян килсен монда депутат? Кайчан күрден? Бер шешәдән сыра чөмердегезме әллә?

– Листовкаларда анын чырае иде!

– Нинди листовкаларда?

– Сайлаулар алдыннан... Минем әни баганаларга ябыштырып йөрде... Төргәге белән өйгә алып кайта иде... Эшсез өйдә ята бит... Ә бу тип листовка тараткан өчен акча түли...

– Әһә, акчасы күп, димәк!

– Долларлары диген!

– Депутатларда бабло күп! Бир әле, абзый, портфеленне! – дип дипломатка ябышты берсе.

– Анда акча юк. Кесәдәгесен хәзер бирәм, шауламагыз... – дип, сул кулындагы дипломатын ычкындырмаска тырышып, уң кулын пальтосының эчке кесәсенә тыкты Әмир.

Әмма тегеләр тынычланырга уйламыйлар да, аны уратып алып, таптаналар иде. Тәрәзәдән төшкән яктылыкта Әмир аларны бик яхшы хәтерләп калды. Бигрәк тә берсен. Бүре карашлы, кыек борынлы, киң чырайлы, уналтыунжиделәр тирәсендәгесен. Сул кашы җөйле – бокс белән шөгыльләнәдер дә, шунда бәреп ярганнардыр. Урам хулиганнары, идән асларында спорт бүлмәләре ясап, тәннәрен ныгыталар, йодрыкларын чарлыйлар... Бу да шундыйлардан иде, мөгаен... Әмиргә ул беренче булып сукты....

...Тик моны тикшерүчегә әйтергә ярамый. Чөнки бер әйтү белән генә бетмәячәк, кат-кат кабатларга мәҗбүр итәчәкләр: прокурорга, адвокатка... Суд каршына бастырып... Аннары, мөгаен, журналистлар килеп бәйләнер... Алар инде төбенә төшми калмаслар: кайда идең, кем белән идең, кая бардың, ник бардың...

Теленне тыярга туры килә. Алар каршында гынамыни?

Бәясе өч тиенгә тормаган менә шушы томана хатын алдында да уйлаганыңны әйтеп булмый. Югыйсә:

– Во-он! Күземә күренәсе булма! – дип кычкырырга тел кычытып тора да бит...

Баштук бәйләнергә кирәк түгел иде. Якын китермәскә иде. Ләкин...

Бу очракта да бәгырь парәсе, йөрәк ярасы сәбәпче булды...

Сайлауда җиңүгә ирешкәч, ничек канатланып кайткан иде ул Казанга! Сөйгән ярының да дөньясы түгәрәк, күңеле күбәләк икәненә бер шиге дә юк иде...

Ә ул, бергәләп шатланасы, очынасы урында, аның куаныч балына дегет салды...

Тулай торак янындагы беседкада үз-үзен белештермичә Әминәнең янагына сукканнан соң, Әмирнең хәле бик яман иде. Күк биеклегендә өермәгә юлыгып канаты каерылган, упкынга убылган бөркет үзен шулай хис итәдер... Юанырга кирәк иде ана, онытылырга кирәк иде. Ләкин ничек?

Фатирына кайтып керүгә ул, нишләгәнен белештермичә, телефонга ябышты.

– Кил! – диде.

– Кая?

– Казанга. Адресны беләсең.

– Ничек? Төн уртасындамы?

– Ярдәмчемме син минем, юкмы? Миңа ярдәм кирәк! Шушы минутта!.. Юлда машиналар йөреп тора. Биш сәгатьтән көтәм!

Илзирә чыннан да ул әйткән сәгатьтә килеп җитте. Иртәнге биш иде бу, күңелнең аеруча нечкәргән, тәннең сусаган чагы.

Нindидер сүзләр әйтелде бугай, истә калмаган. Әмирнең тәненә – бушану, рухына ирлеген раслау зарур иде.

Ә Илзирә мондый сәгатьләр турында күптәннән хыяллана иде инде.

Шуннан соң алар әледән-әле очраша торган булып киттеләр. Луиза – әхлак иясе, туйга кадәр үзенә якын китерә торган түгел. Әмир кебек таза, дәртле егетнең хәлен аңламый да, кызганмый да.

Бу очракта Илзирәнең кул астында булуы бик уңайлы килеп чыкты. Ул инде студент чагында үз-үзен онытыр дәрәҗәдә гашыйк булган, егетен кызганган, аның хәленә кергән. Егет хәленә кергән кыз белән

ни буласы билгеле... Аннары тормыш сукмаклары аерылу да гадәти күренеш...

Хәзер ул ирекле, ни кыланса да килешә, берәүгә дә зыян салмый. Аратирә очрашып сөешү икесенә дә бик рәхәт һәм кирәк иде, Әмир өйләнгәч тә бу шулай булып калды. Ахыр чиктә Луизаның да йә җаваплы эштән арып кайткан, йә вакытсыз чагы... Нәрсә күп сөйләп торырга: югарыга күтәрелгән шәхеснең сөяркәсе булу — бик тә табигый, бу гамәл аның ирлек абруен күтәрә. Әхлак ягыннан карасаң да гаепләп булмый: мөселманга дүрт хатын фарыз! Күпләр шулай дип саный.

Саграк булырга гына кирәк: алай-болай бала табып куймасын тагын! Хәер, хәзерге вакытта андыйдан саклануның чаралары җитәрлек. Һәммәсе җайга салынган, борчылырга сәбәп юк иде шикелле. Тик менә вакыт уза торгач, бу хатыннан күңел бизә башлады.

Мәхәббәт кешене бизи, диләр. Шулайдыр. Әгәр чамадан ашмаса. Әмма артыкка китсә, сөю хисе дә файдага түгел. Күзе тонып, башы мингерәп, «үлеп» гашыйк булган кешене күргән һәркем моны белә.

Баштарак күренми иде кебек, тора-бара Илзирәнең күз төпләрендәге вак җыерчыклар күзгә ташлана башлады. Дөрес, ул аларга шәмәхә сөрмә сылап куя. Әмма бу аны бизисе урында, курчак кебек җансыз итә шикелле. Күзләре шундый ялварып карый, эт булса койрыгын болгар иде.

Аның гел ярарга тырышуы, килешсез сырпалануы тәмам күңелне кайтарды. Борыч җитми бу хатынның ашына... Кәнфит суырып кына тамак туймый! Аннары шунысы: бүген рәхәт чигүне генә кайгыртып яшәп булмый, киләчәк турында да уйларга кирәк бит! Бу хакта ачылып сөйләшүгә Әмир юл куймый куюын, әмма сөяркәнең кыланмышларыннан зурракны өмет иткәне сизелеп тора. Ахмак! Берәр буйдакны каптырып, үз оясын коруны кайгыртырга кирәк иде! Тик нишлисең, хис томаны сарган башта ми сыегая шул инде...

Араларны кырт кисеп өзеп булмый, бергә эшлиләр бит. Эшеннән чыгару да хәвефле — әллә ниләр кыланып ташлавы бар.

Мәскәүдән эшкә чакырып тәкъдим килгәч, Әмир бу четерекле мәсьәләнең дә үзеннән-үзе хәл кылыначагын уйлап, тынычланып киткән иде. Ул китә, срогы чыккан сөяркә монда кала. Әйе, срогы күптән чыккан, чөнки яшәүнең түмен һәм рәтен белгән ирләр бер үк хатынны сөяркә итеп ике елдан артык тотмый.

Шундый вакытлы иде мәскәүләрнең тәкъдиме! Күңелнең иң нечкә җирен сызландырып торган берәүдән дә ерагаясың. Мондагы кебек, әледән-әле очраклы рәвештә йөзгә-йөз килеп, йөрәк җәрәхәтен тырнап торулар бетәр. Үзләреннән-үзләре аның тарафына тарткан аякларны тыясы булмас. Әйе, читкә китәргә теле иде Әмир. Җырда да җырлана бит: «Үз ярың да ят була икән, читтә йөреп күңел керләнсә...» Әмир күңеленең керләнүен генә түгел, мүкләнүен теле иде. Әйе, мүк бассын аны, иң бәхетле минутларны искә төшереп, сызланырлык булмасын!

Һәммәсе җайга салынган иде бит инде. Илзирәне дә шундый шәп урындыкка утырту мөмкинлеге табылган иде. Бугазы тыгылсын, үте сытылса да, үч алудан тыелсын, астан кисәргә җыгырмасын!

Ә ул әнә нәрсә уйлап чыгарган: сөйдергеч эзләп тапкан!

«Ни генә уйлап чыгармый бу хатын-кыз дигәнең! — дип уйлады Әмир. — Кыланмышлары акылга сыя торган түгел! Чыпчык кебек хатыннар бөркеттәй ирләрне аулап, канатларын бәйләп куя кайчакта. Бәйләсә генә бер хәл иде, сындырып упкынга ыргыта! Сак булырга кирәк. Йөрәккә якын алмаска...»

Әмма йөрәк акылның киңәшен тыңламый, үзенчә сыкрана иде.

* * *

Соңгы елларда кайбер йортларны Казанда моңарчы күрелмәгәнчә җиһазлый башладылар. Бу бина шундыйларның берсе иде. Тыштан караганда, гадәти кебек кенә, ә эченә керсәң!

Киң генә бүлмәнең бер ягы озын тар өстәл белән бүлеп алынган, аның артында кара костюм, ак якалы ыспай егет утыра.

Арырак — зур яшел пальма, аның янында аквариум, аның эчендә кызыллы-зәңгәрле, киң койрыклы балыклар суүсемнәр арасында йөзеп йөри. Икенче стена буенда кечкенә генә куыш ясалган — анда кием элгечләре. Халык күп айкала торган урын түгел, шунысы да җитә. Аның янәшәсендә ак күн белән тышланган диван.

Илзирә килеп кергәч, егет, тигез тешләрен елкылдатып, авызын ерып, аягүрә торып басты:

— Исәнмесез! Хуш киләсез. Рәхим итегез! Сезнең икенче тапкыр килүегез, шулай бит?

«Һәммәсен каян исендә тота икән?» — дип уйлады Илзирә.

— Әйе, икенче... — диде ул йөзен сытып.

— Салыгыз пальтогызны! Булышыйммы?

— Кирәкми.

Илзирә зәңгәр чәшке бүреген, шундый ук якалы көксел пальтосын салып, элеп куйды.

— Сез бүгенгә язылмаган идегез, — диде егет.

— Роксана мина, соравын булса, теләсә кайчан мөрәҗәгать итә аласың, диде. Сорау туды — килдем.

— Әлбәттә, әлбәттә. Аз гына утырып торыгыз! — дип диванга ишарәләде егет аның төксе кыяфәтенә игътибар итмичә. — Анда алдан язылып килгән кеше бар әле. — Ул кул сәгатенә күз салып алды. — Кырык минут үтте инде. Хәзер чыгар.

Шулай дип, почмактагы ачык ишектән эчкә кереп китте ул. Бераздан кире чыгып:

— Хәзер, — диде дә үз урынына кереп кунаклады.

Моңарчы Илзирә сихерче-күрәзәчеләрнең үзләрен дә, килгән кешеләрне кабул итә торган бүлмәләрен дә бөтенләй башкача күз алдына китерә иде. Китаплардан укыганы, киноларда күргәне бар: аларның куышы караңгы, почмакларында әллә нинди шәүләләр шәйләнә. Зур өстәл өсте генә яп-якты итеп яктыртылган, анда йодрык хәтле пыяла шар елтырый, кәрт чәчелеп ята. Күрәзәче исә кара киемнән, күзләре елык-елык итә. Ул карлыккан тавыш белән аңлашылмас телдә ниләрдер сөйләнә...

Әмма монда бөтенләй башка — әле генә баеп киткән эшем кешесенең «офис»ы кебек иде бу. Әйе, бинасы да заманча, исемнәре дә бүтән: элек «багучы», «күрәзәче», «сихерче» булсалар, хәзер «экстрасенс», «астролог», «изотерик». Әйтүләренә караганда, бөтен гамәлләре фәнни нигезгә корылган.

Соңгы вакытта алар ифрат ишәеп китте. Кайберләрен телевизордан күрсәтәләр, бәгъзеләре чир-чордан иза чиккән халыкны клубларга җыеп, һәммәсен берьюлы дәвалый. Күпләр, шифасы тиде, дип тә сөйлиләр. Ә инде «бәхетсез мәхәббәт» (халыкча әйткәндә, «кысыр гыйшык») дигән йөрәк чиреннән дәвалаучыларны әйткән дә юк: кирәк икән сөйдерә, кирәк икән биздерә — ни телисең. Илзирәнең исә бу төр хастасы азганнан-аза бара, түзәр әмәле калмаган иде. Газаптан котылу чарасы бер генә: Әмир хатынын аерсын да ана өйләнсен. Ләкин менә һаман суза бит. Бу хакта авыз ачарга ирек бирми, сүзне икенчегә бора йә назлап хәлне ала... Аннары кистереп сорап та булмый — өстенә бастыра торганнардан түгел.

Берәрсенә эченне бушатудан да тыелырга туры килә, сере читкә сибелсә, Әмир шундук аннан йөз чөерәчәк.

Чарасызлык китерде Илзирәне бирегә. Томана да түгел бит үзе, югары белемле, аңлы хатын. Юк-барга ышанып, хәләл акчасын шарлатаннарга үз куллары белән — күп очракларда чират торып! — илтеп бирүчеләрне ахмакларга саный. Ләкин менә үз башына төшкәч, бүтәнчәрәк уйлыйсын икән. Шулхәтле кешеләрнең һәммәсе дә шыр дивана түгелдер. Кемнәрдер файдасын күрәдер. Югыйсә меңнәрчә халык клубларга агылыр идемени дә «дәвалаучы»ларның ишек төпләренә чиратка тезелер идемени?

Арадан берсенең монарчы беркайчан ишетелмәгән исеме матур яңгырашлы, серле тоелды: Роксана! Еш колакка чалына. Әмма кем ул? Каян? Кайсы милләт кешесе? Исеменә карап, моны һич әйтеп булмый. Илзирә аның телефонын эзләп тапты, шалтыратып, чиратка язылды. Ә ана бер атна алдан басалар икән. Бу үзе генә дә өметне ныгыта торган фал бит!

Билгеләнгән вакытында килде, киңәшләрен тыңлады, «дәва»сын алды. Йөз илле мең тәнкә акчасын шушы ак якалы егеткә калдырып чыгып китте. Роксана, күпләр кебек, акчаны доллар белән саный икән. Даруы — утыз доллар, ә бер долларны бу вакытта, ягъни туксан җиденче елның башында, биш меңгә алып була иде.

Әй, кадалсын ла йөз илле мене! Тик ярдәме генә тисен иде! Аннан гына бөлмәссең — депутат Нуриев ярдәмчесенә яхшы түли.

Әмма ярдәме тимәде шул. Киресенчә! Роксана биргән сөйдергечне эчкәч, Әмир киенде дә чыгып китте. Һәм олы казага тарыды...

Табигый ки, Илзирәнең җен ачулары чыккан иде. Сихерченең, яки үзе әйткәнчә, изотерикның чыраена бәреп кемлеген әйтергә һәм акчасын кире таләп итәргә килгән иде ул.

Ләкин бу юлы да алдан ниятләгәнчә барып чыкмады. Эчке ишектән бер юан хатын белән чөкердәшә-чөкердәшә Роксана үзе килеп чыкты, Илзирәгә елмаеп сәлам бирде:

— Исәнмесез. Бер генә секунд, — дип, теге хатынга каракүл тунын кигезеп, сумкасын тоттырып, ишекне ачып, озатты. Аннары, тураеп баскан Илзирәне назлы хәрәкәт белән иңеннән кочып алды.

— Әйдәгез, әйдә! — дип, эчкә алып кереп китте.

Анда урындыкка утыртты, үзе өстәле артына узды, аның тартмасын ачып, конверт алды да, Илзирәгә таба шудырды. Таныш конверт. Илзирә акчасын шуңа салып биргән иде.

— Менә акчагыз. Бирегез! — диде.

— Нәрсәне?

— Мин сезгә ни биргән идем? Шуны! Әйткән идем ич, әгәр кире уйласагыз яисә кулланырга җай чыкмаса, кире китерерсез, дип.

Илзирә челтәрле ак күлмәк кигән, салам чәчен эре дулкыннар ясап иңнәренә төшергән, нечкә кара кашлы, озын кара керфекле бу хатынга (ә бәлки, кызгадыр?) беренче күргәндәй шаккатып текәлде. Теге кара костюмлы егетне алып кереп, янына бастырсаң, кияү белән кәләш диярсең. Шундый яшь, шундый чибәр! Заманасы бүтән, сихерчеләре дә бөтенләй башка.

— Ул миндә юк...

— Кая куйдыгыз?

— Сез әйткәнчә эшләдем... Эчердем.

— Эчтемени?

— Эчте...

— Аннары нишләде?

– Киенде дә чыгып китте... Шуннан соң килгәне юк...

Роксананың чырае җитдиләнде:

– Сез миңа теге килүегездә дөресен әйтмәгәнсез. Ә йөрәк мәсьәләсен хәл иткәндә ихлас булу кирәк.

– Нәрсәне дөрес әйтмәгән? Хатыны белән мәҗбүри генә яши, эш өчен кирәккәнгә генә. Яратуын мине генә ярата.

– Хатыны белән ничек кенә яшәмәсеннәр, аралары нык. Ә менә ярату мәсьәләсенә килгәндә... Сез бит миңа аның карточкасын күрсәтмәдегез, исемен әйтмәдегез. Тойгыларын белеп булмады. Ә сезнең хисләрегездә ул бердәнбер булып чагыла. Тик аның өчен алай түгел икән бит. Монда хатыны белән сездән башка тагын берәү бар! Мин биргән эликсирны эчкәч, аның уйлары буталган, хисләре көчәйгән. Һәм ул күңеле тарткан, җаны сөйгән яры янына ашкынган. Тик ул кеше сез түгел.

– Нишләп сөйгәне янына булсын? Миннән киткәч, аны урамда кыйнап ташлаганнар!

– Эликсир тәэсирендә ниндидер сугыш чукмарлары янына разборкага чыгып китмәгәндер, шәт? Крутойлардан түгелдер бит? Хәтта крутой булса да... Алар да бит гел сугышып кына яшәми, сөешә дә! Ә менә, көтмәгән җиргә барып кереп, көндәше тукмап ташлаган булуы ихтимал.

Илзирә күз яшьләренә буылып, башын иде.

Роксана өстәл артыннан чыгып, хуш исле кулъяулыгы белән аның битен сөртте.

– Салындырма башыңны, – диде. – Тураеп утыр әле. Күтәр керфекләреңне, гөлгә кара, – дип тәрәзә төбендә кып-кызыл чәчәккә төрелгән, колачка чак сыярлык зигокактуска ымлады ул. Кыш уртасында чәчәк ата торган бу гөлне халык арасында «декабрина» дип атыйлар. Роксана ике учын Илзирәнең башы тирәсендә әйләндерә башлады.

– Исеңә төшер әле, – диде. – Бу беренчесе түгел бит... Унҗиде яшеңдә син үлеп гашыйк булган идең... Ул да сине яратты. Мәхәббәтегез елларга сузылды. Тәмам бер җан, бер тән булып беткән идегез. Һәрхәлдә сиңа шулай тоела иде. Әмма ул сине ташлады, күз алдында башка берәү белән чуала башлады. Сиңа хәзергедән дә авыррак иде. Үлсәм иде, дигән чакларың булды. Әмма узды бит, онытылды...

Чыннан да, ул чакта да йөрәкнең сыкрануына түзеп булмас кебек иде. Ә менә хәзер искә төшергәч, күңелнең бер кылы да тибрәнмәде. Яна хәсрәт искесен баскан... Алай да элек кичергән хисләрне хәтергә китерү бүгенге кичерешләр ялкынына су бөркегәндәй итә, сызлануны киметә икән. Уйлар тынычланып киткәндәй булды, күзләр ачылып, каршыдагы гөлнең чәчкәләре тагын да жетерәк, мулрак тоела башлады. Ах, нинди гүзәл тәлгәшләр! Тик ник аска карап чәчәк аталар икән?

Роксана аның башын сыйпады.

– Хикмәт анда түгел, синдә, – диде. – Үзең шундыйларны сайлыйсың.

– Мин түгел, ул. Бервакыт төн уртасында Балкыштан Казанга килергә кушты...

– Төн уртасында нинди эшләр эшләнгәнен белгәнсеңдер бит... Димәк, үзең теләгәнсең. Табигатең шундый синең: газаплана-газаплана сөя торган. Берәүләргә мәхәббәт куаныч алып килсә, икенчеләргә әрнүләр китерә. Нихәл итәсең, синең табигатең соңгысына ятышлырак шул. Аңлап җиткермәстән, каты күңелле кешеләргә тартыласың. Моннан соң белерсең инде. Яр сайлаганда, акылыңны ныграк эшкә җигәрсең!

* * *

«Ватаным Татарстан»га «Кызыл Ай»нын эшчәнлеге турындагы чираттагы мәкаләсен алып баргач, Әминә үзенен уй-борчуларын Хәкимә Гатинага да сөйләп алды.

— Фридрих Шиллернын сүзен исенә төшер, — диде Хәкимә. — Хәтерлисенме? «Мавр үз эшен эшләде, мавр китсә дә ярый». Мөлеков та тиешлесен булдырды, хәзер анын кирәге калмады.

— Ничек алай?

— Ә менә шулай! Ил язмышын хәл иткәндә, халкы өчен башын балта астына куярга әзер торган шәхесләр кирәк иде. Революциягә тин вакыйгалар күтәелә, алда ниләр буласын һичкем белми иде. Мен рәхмәт Марат Мөлековка. Төп мәсьәләләр тыныч юл белән хәл кылынды. Хәзер инде һич курыкмыйча хокукларны яклап биек трибуналардан кычкырып сөйләп була. Нуриев кебек итеп. Шәп сөйли бит, ә?

— Сөйләмәсә, әйбәтрәк булыр идеме әллә?

— Кем алай ди? Сөйләсен. Халыкны яклый, милләтне үстерергә өнди. Шунын өчен депутат итеп сайланган да ул. Безнен житәкчеләргә Мәскәү каршында үзләренен эшен ифрат жаваплы һәм утә дә катлаулы итеп күрсәтү өчен андый кеше бик кирәк. Таләпчән дә үзе, әмма берәүгә дә йодрык янамый. Анын сүзен ишеткән-укыганнар һәммәсе мөкиббән. Шундыйларга килде замана!

Әминә монда ни дип әйтергә дә белми аптырап калган иде. Берничә мизгел тынып торганнан сон Хәкимә:

— Мина калса, синен хакта да, үз эшен эшләде, инде китсә дә ярый, дип әйтеп була кебек, — диде.

— Каян китим? Кая?

— Син ул «Кызыл Аенда» күпме әвәрә килеп йөрергә уйлыйсын?

— Беләсен бит инде, безгә халыкара оешмаларга керергә, татарларны бөтен дөньяда игелекле халык итеп танытырга...

— Син сон үзен сизәсенме бу илдә андый оешмаларнын да вакыты узып барганын? Ни генә дисән дә, тормыш әкренләп жайга салына, сонгы вакытта бер сынык ипигә тилмерүчеләр күп күренми. Дәүләтнен нигезе ныгытыла, хакимияттә утыручылар, гражданнарыбызны кайгыртуны тулысынча үз өстебезгә алабыз дип сөйләнәләр. Күр дә тор: сезнеке кебек оешмалар бернинди ярдәмсез, яклаусыз калдырылачак. Кая барып, ни генә кыра алырсыз икән? Өстә Нуриев кебекләр утырганда, сәясәт мәйданында Мусина кебекләргә урын юк.

Мона каршы чәчрәп чыгарга омтылды Әминә, әмма шундук сүрелеп, башын иде, чөнки редакциядәге яраткан эшеннән кысып чыгарылгач, яклау эзләп Әмиргә барганы исенә төште...

— Синен кебек сүзнен гел дөресен генә сөйләп, яна юллар ярып йөрүчеләр кирәкми аларга, — дип дәвам итте Хәкимә. — Өстән кушканны үтәүчеләр булса, шул житкән. Шулай булгач, алдагы көндә нишләренне уйларга вакыт түгел микән? Бәлки, каләменне ныклап эшкә жигү дөресрәк булыр?

Мондый уйлар Әминәнен үз башында да шактыйдан айкала, тик ул бу хакта кайда да булса сүз кузгатырга тәвәккәлләмәгән иде әле.

* * *

Сигезенче Март бәйрәме унаеннан телевидение тапшыруы бара. Исемнәре илгә танылган ир-атлар хатын-кызларны котлыйлар. Уртада гадәтенчә иркенәеп, тезләрен кин ерып, уйчан чырайлы Әмир Нуриев утыра.

– Хатын-кыз чын мәгънәсендә бәхетле булсын өчен, аны ин беренче чиратта авыр эшләрдән азат итәргә кирәк, –дип сөйли ул. – Табигать тарафыннан йөкләнгән зур вазифаны үтәргә шартлар тудырырга кирәк аңа. Ул кешелекне киләчәккә алып бара. Бала таба, имезә, тәрбияли. Без, ирләр, бәби таба алмыйбыз. Безнең бурычыбыз – хатын-кызны авыр эшләрдән бушатып, гаиләне матди яктан тулысынча тәэмин итү. Безнең вазифабыз – әниләребезне, хатыннарыбызны, кызларыбызны кадерләү, аларның тормыш күген каплаган болытларны тарату. Без алар өчен чыннан да алтын багана булырга тиешбез.

Моны карап-тыңлап утырган Әминә көлеп җибәрде: «И хыялый, һәммә хатыннарга синдәй алтын бағананы каян җиткерәсең? Бердәнбер бит син! Бердәнбер!»

Үгез базарының пәһлеваны иде бу ир-егет. Бер кулында чукмар. Бик хәтәр күренә. Әмма ул беркайчан да аның белән көчлеләргә кизәнмәячәк. Икенче учында өч алма. Өчесе дә саф алтын. Тик берсе дә ул теләгәнчә түгел.

Бу гайяр ирнең кайчандыр Алып батыр кебек җиде ул үстерү – алай гына да түгел, хәләл җефетен Герой-ана итеп, ун бала тәрбияләү(!) турындагы хыялын әллә соң Әминә генә хәтерли микән? Хатынына андый таләп куйды микән ул?

Хәлбуки, Луиза Нуриеваның Герой-ана булырына зур өметләр баглап булмый әле монда. Бердәнбер кызлары мәктәп яшенә җитте инде, икенчесе туар дигән сүз ишетелми. Чөнки зур урында утыра Нуриева – шәһәр советының мәдәният бүлеген җитәкли ул. «Вечерняя Казань» газетасында аны «Первая леди города Казани» дип атыйлар. Чибәр, белемле, зыялы. Заман хатыны, эшлекле дама, зур җитәкче Луиза Нуриева! Миллионнарга өлге итеп куелган! Рәвеш-кыяфәтенә караганда, ул моңа һичшиксез лаек! Андый шәхесне, билгеле инде, ел аралаш корсак күтәрттереп, бала имездертеп, өйдә утырта алмассың.

Хәер, Әмир моңа ризасызлыгын сиздерми. Киресенчә, җай туры килгән саен хатынын мактап сөйли. Иллә дә матур гаилә инде!

Әминә, керфеген кагарга онытып, телевизор экранына текәлгән, йөзендә үртәү-үчекләү катыш сөеп елмаю, күнеле тулы куаныч. «Сөйлә, алтыным, сөйлә! Өйрәт халыкны дөрес яшәргә!

Минем өчен сүзләреннең мәгънәсе мөһим түгел. Тавышың гына яңгырасын, йөзеңдә рәхәт яшәвеннең чалымнары күренсен. Мең рәхмәт сине шушылай күтәргән язмышка. Мең рәхмәт халык алдында абруеңны югары тотарга ярдәм иткән хатынына. Син шушындый күз күрке булганда, минем өчен дөнья яктырак. Исән генә була күр. Яшә генә!»

*2012-2013.*



Салисә
Гәрәева

# ГОРУРЛЫККА ТАУЛАР ӨЙРӘТКӘН

## Без — татарлар

Без оныттык изге тамырларны –
Мең ят белән каннар катышкан!
Без түгелме, илбасарлар белән
Ничә гасыр тоташ тартышкан?!.

Манкорт булып үсә яшьләребез,
Оныкларда – шул ук юнәлеш.
Ә бит коллык зынҗырлары өчен
Болгар – Казан белән түләнмеш!..

Югала моң. Иман, оят кача,
Рәнҗетелә милләт йөрәге.
Сәләтлеләр чит халыкка күчә,
Югала Тел – милләт терәге!..

Без киләбез мең ел тарих буйлап:
Упкыннарны ничә кичелгән!
Мең ел аша безгә аваз бирә
Югалган һәм тере исемнәр!..

Без оныттык изге тамырларны.
Бүген өчен яши күбебез!
...Тик Казанда – Идел, Уралларда
Нигезебез безнең, төбебез.
Шуны сөйли туган телебез!..

## Сердәшем — каен

Хәтеремдә һаман күк күкрәтә
Кайгыларның кара болыты.
Вакыт үзе җилы тыны белән
Күз яшьләрен тора корытып!..

Салисә ГӘРӘЕВА — *шагыйрә; «Уралым», «Тау сукмагы», «Йолдыз яңгырлары» һ.б. китаплар авторы. Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Һ.Такташ исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

**Бакчамдагы ялгыз каенымны**
**Җилфердәтеп җилләр иделәр.**
**Күршеләрем: мондый елак каен**
**Кайгы чакыра ул, диделәр.**

**Каенымның андый гаебе юк:**
**Гомерем буе аны сынадым:**
**Иңнәремне кайгы сарган саен**
**Каенымны кочып еладым!**

**Вакыт юа, хәсрәт онытыла,**
**Күкрәүләре уза болытның;**
**Ничә еллар елап, каенымны**
**Яшем белән генә корыттым!..**

**Чыдамады минем хәсрәтемә —**
**Ярамады ачы күз яшем!**
**...Корыса да, йөрәк ярылудан**
**Саклап калды Каен — сердәшем!..**

## И!

**Нинди төсләр, ничә төсмер**
**Таба синдә чагылышын!**
**— И! — дип әйт: фикер төсмерен**
**Сөйләп бирер тавышың!..**

**— И, Җаным! И, бердәнберем!**
**— И, балам! И, сөйгәнем!**
**Йөрәгеңә барып җитсен**
**Өзелеп: — И! — дигәнем!**

**— И, кадерлем! И, ягымлым!**
**Бөтенесе сиңа бит!**
**Кайгылы чакта: — И! — дисәм,**
**Кына гөлем шиңә бит!..**

**И, Җаным! Кайттыңмени, аһ?! —**
**Шулай диюем була,**
**Бәхетемнән, шатлыгымнан**
**Чишмәдәй күңлем тула!..**

**— И— и — и! — димен җан өзелгәндә**
**Сагыну — сагышымда...**
**... Сизәрсең шул бер аваздан**
**Хагын да, ялгышын да!...**

## Туган җиргә торам бәйләнеп

**Табигатьнең гади баласы мин —**
**Бер каены, гөле, үләне...**
**Таң җилләре, чәчләремне тарап,**
**Шул турыда хәбәр сөйләде.**

**Ялан кырда үскән чәчәк кебек,**
**Кояш нурын эчәм көнозын.**
**Чылтыравын тыңлыйм чишмәләрнең,**
**Биек тауга менәм ялгызым...**

Үткән елгы шиңгән яфракларны
Юри генә ачып карачы:
Яфрак асты саен гөжләп торган
Серле, ят бер дөнья табарсың!..

Күзем алмыйм сары үзәгеннән
Кояш карап торган чәчкәдән:
Таҗларына бал кортының җиңел
Аягыннан ширбәт чәчрәгән!

Чыклар ярып иртән суга төшәм,
Сукмагыма карыйм әйләнеп:
Гүя үзем шушы сукмак белән
Туган җиргә торам бәйләнеп!..

## Туган бусагам

Карлыганның кара җимешедәй,
Татарымның балкый карашы.
Әремнәрдә — кайгы-хәсрәт тәме,
Упкыннарда — Җирнең ярасы.

Юллар гизеп, кая борылсаң да,
Тап буласың чая татарга:
Тамыр җәйгән җирен яшәртә ул,
Форсат бирә чәчәк атарга!

Идел буендамы, Себердәме,
Уралдамы — тау йә үрдәме, —
Бер җан, бер тән булып Татар яши,
Уртак, охшаш бөтен күргәне!..

Ач чагында ул икмәген сона, —
Авызыннан өзеп булса да!
...Кайда татар — шунда туган җирем,
Туган йортым, туган бусагам!..

## Галәмгә нур оча йөрәктән

Мин яшәдем Урал якларында —
Тамырлары тауның — чын таштан!
Биек сыртлар, чал кыялар монда
Күкнең үзе белән тоташкан.

Бер карауга якын тоелса да,
Тезелеп киткән күксел сыртлары, —
Ерак иде офык сызыклары,
Ай үзе дә шунда йоклады...

Тауга менсәң, сансыз йолдызларның
Тию мөмкин иде берсенә!
Ләкин беркем йолдыз тоталмаган:
Таш кыялар шуңа көрсенә.

Ә мин менә... тотар сыман идем.
Кагылыр кебек идем Айга да:
Кеше мәңге хыял белән яши, —
Кеше булып яши кайда да!..

Шул омтылыш, биеклекләр өне,
Кайтавазлар кала йөрәктә.
...Мин яшәдем Урал якларында,
Горурлыкка таулар өйрәткән, —

Галәмгә нур оча йөрәктән!..

## Җәй уртасы

Җәй уртасы. Бар табигать хозурлыкта:
Янып пешкән алма кебек тулышкан ул!
Җәйге чиллә — Табигатьнең алмаз таҗы —
Тоташ бәйрәм иде безгә тумыштан ул!..

Колмакларга кара: күккә үрләп бара,
Яшел чатыр корып безнең өстебезгә!
Җәйге чиллә — Табигатьнең алмаз таҗы,
Тоташ бәхет булып күктән иңде безгә!

Яңгырлары яшен тулы, күкрәү тулы,
Куыкланып, көтмәгәндә явып китә!
Иген кыры, болын тулы чәчәклекләр
Дәррәү кинәт, күпер булып, авып китә...

Гөрләвекләр тула чирәм арасына,
Ап—ак казлар, каңгылдашып, коеныша.
Болынлыкта утлап йөргән бияләрнең
Куенына колыннары сыеныша!..

Су өсләре чуарлана тамчылардан, —
Әллә ага, әллә кайный инешебез!
Җиләк тулы чиләкләрне тоткан килеш,
Җиләклектән безнең кайтып килешебез...

Баш очына табак кадәр әрекмәннәр
Куеп, яшел «зонтикларны» күтәргәнбез.
Яланаяк, бер төркем кыз, көлә—көлә,
Йөгереп үттек озын агач күпердән без.

Җәй уртасы. Көннәр озын — бер айга тиң!
Баш очында кояш көлә — алтын табак.
Җәйге таңда кояш кебек сөйгән ярым: —
Сөям! — диде, вәгъдә бирде, көлеп карап.

Җәй уртасы. Яшәп туймас хозур заман —
Озайтасы иде аны, сузасы иде!
...Шушы гүзәл табигатьтә бер гомерне
Мең сандугач кебек сайрап узасы иде!

**Редакциядән:**

*Бу айда шагыйрә үзенең юбилеен билгеләп үтә. Каләмдәшебезне бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Рифә
Рахман

# ХИКӘЯЛӘР

## Әҗер

Әгъдәс, үзе белән санлашмыйча, теләгәнчә яшәгән, ирне ир дип белмәгән хатынының торган саен усаллана баруыннан, бер сәбәпсез быжгылдавыннан тәмам йөдәде. Телевизордан хоккей караганына ачуы килгән бер ялда, малаеннан ачкыч ярattырып, йорт өстендәге антеннаны бордырtканын белгәч:

— Гел болайга китсә, көннәр җылыткач, гаражда яши башлыйм, — дигән иде, шулай эшләде дә. Әтисенең үзләреннән китүе почык борынына да сабак бирер. Алай дисәң... сабакны ул моны сизеп алган күршеләреннән дә, әтисеннән дә вакытында шәпләп эләктерде.

Антенна, һава дулкыннарын эзләп, икенче якка караган көнне җан аткан командасы җинелгән. Әгъдәс үзе дә сабый дисәң дә сабый инде. Бу җинелүне эшкә баргач ишетеп, артыгын пошмаган да кебек иде, күршеләре кайткан чагында, улыннан зарланып, каршысына чыккач, җене котырды. Хоккейчыларның пешмәгәнлеген әнкәсеннән куркып чормага менгән Вахитка кайтарып калдырды. Ишектән керә-керешкә каешын перәшкәле башыннан тартып чыгарды да этажеркадагы аяк киемнәрен тигезләп тезеп торган улының арт ягына эләктерде.

Сабак бирәм, дисә дә, карусыз, йомшак күнелле, күндәм Вахит кызганыч иде. Каеш төшергән кулы шуннан бирле сызлаган шикелле. Аны үзе белән алса да була югыйсә, тик менә пионерлагерьга путевкасы яначак, ишегалдындагы иптәшләреннән дә аерылачак. Өе бар килеш, ниндидер бер алама җирдә яткыру да инде...

Әгъдәс, шулай итеп, гаражда һәм ялгызы гына яшәргә булды. Җәйге ялга чыгуга, Нурия өйдә юк вакытны туры китереп, көндәлек кирәк-ярак, савыт-саба, кием-салым җыйды да, машинасына тутырып, шунда күчерде. Иске холодильник, өстәл-урындык, җимерек караваt ише нәрсәләр анда болай да бар иде — сатып аласы да, өйдән китерәсе дә булмады.

Әгъдәскә барыннан да бигрәк тынычлык кирәк. Нуриянең, аның турында, берәр хатынга киткән, өстемнән сөяркә тоткан дип уйлыйсын, гарьлегеннән чәч йолкыйсын белә ул. Нәкъ менә шуны тели дә. Һәр хәлдән җиңүче булып чыгарга өйрәнгән хатыны буылсын, янсын. Гаражда яшәүне

Рифә РАХМАН – *язучы; «Керфекле тәрәзәләр», «Күзләрең төймәләнсә» һ.б. китаплар авторы. Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Ф.Хөсни исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

суза алганча сузарга кирәк. Әгәр тиз генә кайтса, сөенәчәк; күрдеңме, миннән башка яши алмыйсың, кемгә кирәгең бар соң синең, дип, алга таба Нурия Әгъдәснең күзен бөтенләй ачырмаячак.

Көннәр жылы, машина артында йөргән одеял, мендәр ярап торыр; иллә дә мәгәр салкынайтса, чүплеккә ташламыйча, бер кирәге чыгар кебек, кәгазь тартмаларда илтеп куйган иске-москы житәрлек. Узган еллардан калган ялларын да алган, теләсә, хатынын тагын да ныграк акылга утыртырга санаса, әле ноябрь башларына кадәр гаражда калырга булдыра.

Дачада умарта тотарга исәбе бар Әгъдәснең. Узган ел, оя ясарга дип, инструментлар да алып куйган иде, һич вакыт таба алмады. Отпускага да кыш алсаң гына чыгасың, диделәр. Ризалашмады. Хатыны:

– Кеше ирләре гаиләсе белән чит илләргә йөри башлаган бер заманда син дачада бергә яшәргә ял да ала алмыйсың, жебегән! Шушы мокытка биргән гомерем әрәм! – дип котырынган иде, менә бит, яхшыга булган. Жебегән түгел, каткан, дип тиргәсен – ул аны хәзер ишетми дә, күрми дә.

Кемнәр генә йөридер ул чит илгә?! Ишегалдындагы өч йортта яшәгән үз тирәсендәге ирләрнең барысын белә, тик менә шулардан берсененң генә дә кайдадыр ял иткәнен хәтерләми. Башка танышлары арасында Төркиягә баручылар бар-барын, алары да хатын-кызлар гына булып, ишәк кебек өсләрендә атна саен товар ташый. Бик кычытынсаң, бар, ирең эшләгәнгә карап утырма, син дә «челнокчы-киләпче» булып кит! Ә менә Әгъдәс ыгы-зыгылы, күп кешеле коллективта эшләп тә арыган, ялгызлыкта гына ял итәр.

Ял дигәннән, күршесе Назыйм гаражын сатмаган булса, ятарлар иде хәзер аның базындагы исе борын ярып кергән әче балны уртлап кына. Анысы да инде, әйтми-нитми, яңа хужасы белән таныштырып та тормыйча, юньләп саубуллашмыйча, икенче урынга китеп барган. Әгъдәстә сакланган запас ачкычларын да алмаган. Кооператив каравыллаган Рәхмәтулла абзыйсыннан ишетмәсә, йөри иде әле ул аптырап, чирләп киттеме, бер-бер башка хәл булдымы, күренми дип.

Назыйм булса, комачауламас иде анысы. Кышын эш дип салмыйсың. Жәен хатын сизә дип. Анда-санда гаражда төшереп кайтканың да ел буе колак итен ашарга житә. Әче балдамыни хикмәт! Күңелнең тынычлыгында! Хәзер менә үзе генә калыр, балта-пычкы белән маташыр, арып киткәндә, киштәләрдә аунап яткан тузанлы китапларны укыр. Кич буе өйдә акырып утырган телевизордан да котылыр, Нуриянең иптәш кызлары белән телефоннан ирләр чәйнәвен дә ишетмәс.

Шуларны уйлап, эш өстәлен көйли генә башлаган иде, Назыйм гаражыннан мәче чинаганын ишетте. Тычкан-мазар гаражларда күренми. Баздагы пыяла банкаларда сакланган әйберләрне алар ничек ашасын ди?! Бәрәңге тоткан кеше дә юк диярлек. Язгы тирәдә елын елына базга су төшә.

Мәче тагын чиаклады, тагын, тагын... Кешенекенә тартымрак тавышы Әгъдәснең болай да әрчелгән нервларына ук тия башлады. Кем керткән инде ул мәчене, әй?! Туктале, миндә сакланган ачкычлары бар, ачыйм да чыгарыйм, дип, күрше гараж янына килде. Шул чак эчке яктан әле генә килеп торган тавыш нигәдер юкка чыкты. Кыштырдау да, башка бер аваз да ишетелмәде.

Тын калып көтте. Беркем дә юк иде. Әллә колагына гына ишетелгән инде? Кире китәр алдыннан алай да юри генә:

– Кем анда? Нәрсә булды? Жен-пәри ояламагандыр бит? – дип сораса, үзе дә көтмәгәндә, эчке яктагы сабыйныкына тартым бер тавыш:

– Абый, ач, ач, алар килгәнче, коткар! – диде дә елап ук жибәрде.

Керсә, машинасыз гаражның түрендә иске-москылар өстендә ун-унике яшьләр тирәсендәге бер малай утыра. Бите-күзе тырналып беткән, чәчләре пумалаланган, киемнәре пычракта аунаган кебек.

— Кем син? Нишләп монда? — дип сорады Әгъдәс.

— Минем әтиемнең кибетләре бар. Мәктәптән кайтканда таныш түгел абыйлар тотып алдылар да, машиналарына утыртып, монда алып килделәр. Әтиең сатарга бик оста, инде менә үзе дә сатып алучы булып карасын. Тынынны чыгармыйча гына утыр. Без акча сорарга киттек. Ул бирүгә үк, кайтырбыз да өенә илтеп куярбыз, диделәр.

Әгъдәснең шушындый хәлләр булганын ишеткәне бар, әмма Мәскәү кебек җирләрдә генәдер дип уйлый иде. Хәзер кемдә күп акча булсын, кешенең көнен көнгә ялгап ятканы, сатуы да бармыйдыр, кибетендә алырлык әйберсе дә юк бит анын, дип уйлады һәм:

— Энем, акча табарлармы? Бирерләрме? — дип сорады.

— Белмим... — дип елап җибәрде малай.

— Алайса, син шушында утырып тор. Мин әтиенне эзләп табыйм. Телефоныгызны гына язып алыйм да...

— Абый, китмә инде, мин куркам, үтерсәләр...

— Аларга акча кирәк, дисең бит. Акча юк килеш, сине кем үтерсен?

— Бирмәсә, үтерәбез, диделәр бит...

— Әйдә алайса, мин сине үземнең гаражга бикләп куям, тик тынынны чыгарасы булма! Анда йокларга карават та, ашарга ризык та бар, мин әйләнеп килгәнне озак булса да, тыныч кына көт. Көндез ут кабызсаң, ярый, төнгә килмәсәм, утынны яндырма, — дип, Әгъдәс малайны үз гаражына алып керде. Аннан, чыгып, ишекне бикләде дә шәһәргә кайтып китте.

Өенә тиз генә кайтмас кебек иде, нишләсен, кайтты. Уклау, чүмеч ише әйберләр күтәреп ишек ачкан хатынына да исе китмәде, бер кырыйга этте дә залга узды. Малае киштәдәге тузаннарын сөртеп йөри иде. Күнеленең йомшаган чагы иде: кочаклап пәп итеп алды:

— Молодец, улым, син гел эштә!

Аннан тумбочка өстендәге телефон трубкасына үрелде.

Нурия иренең акланууларына, куркып кына ишектән узуларына гадәтләнгән иде, болай батыр кылануына аптырап калды. Нидер булган бит моның белән! Өйдә юньле бер киемен калдырмаган югыйсә, тагын нәрсә кирәк булган? Әллә чынлап аерылырга исәпли инде? Документларын җыештырырга гына кайткан булмагае! Алайса нигә туп-туры телефонга таба китте? Ул кирәге чыкмаган уклау белән чүмечне үзе дә анышмастан күтәреп ире артыннан барганлыгыннан оялып киткәндәй булды, тышка чыгармады. Әгъдәскә ачуының катылыгын күрсәтергә теләгәндәй, аларны, кухняга чыгып, раковинага тондырды.

— Ватасың бит! Эшләп алмаганнын кадере юк шул! — диде Әгъдәс.

Башка бер чакны, ошамаган сүз ишетсә, пырлап, иренен якасына ябышкан Нурияне алмаштырдыларммыни?! Дәшмәде. Нәрсә эшли микән дип кызыксынуы көчле иде, янадан ире янына залга керде. Инде эш тапмый торган кебек Вахитка ул да матур итеп эндәште:

— Барысын ялт иткәнсен бит, улым, инде ял итсән дә була!

Әгъдәс кат-кат кемнедер җыя иде. Сүз башлаган саен, телефонның теге башында трубканы ташлый иделәр булса кирәк.

— Сенлем, тыңлагыз әле, үтенеп сорыйм, миңа Закир Шәмсиевичны чакырыгыз инде!

Сенлем дигәне нәрсә дип җавап биргәндер, Нуриягә ул ишетелмәде. Сабырлык та икән соң бу Әгъдәстә! Ул кабат шул ук номерны җыйды:

— Башта ук, Закир Шәмсиевичнын өйдә юклыгын әйтсәгез булмыймыни?! Йә, кайдалыгын белим дә үзем генә барып күрим.

Телефон тагын өзелде. Трубка Әгъдәснең кулында ашарга сораган каз бәпкәсе кебек пипылдый. Йөзен борчу баскан бер сурәттә, диванга барып

утырды. Ул Закир Шәмсиевичнын телефоны милициягә тоташтырылганны, кызы исеменнән милиция начальнигынын секретаре сөйләшәдер дип башына да китерми иде. Аннан әтисен сорап, чакыртып, төн дә, икенче көн дә үтте. Малайны Әгъдәснең гаражыннан табып алсалар, эш харап иде. Үзенә эзләп чыгарга кала инде.

Әгъдәснен беркемгә аңлаешсыз бу гамәлләреннән Вахитнын да, Нуриянен дә йокысы качты. Телевизордан кино караган булып, сорашмыйнитми генә Әгъдәсне күзәттеләр. Ахырда ул түзмәде, Вахитка, әйдә, дигән ым какты да йөгереп диярлек чыгып китте. Малай әнисенә карады. Аңа серне белү кирәк иде, ул да эндәшми генә баш селекте.

Әгъдәс, Закир Шәмсиевич яшәгән урамга кадәр барырга да Вахитны анын өенә записка тоттырып кертеп җибәрергә булды һәм, тегенди-мондый хаталар җибәрмәсен өчен, машинага утыргач, эшне сөйләп, аңлатып бирде. Улы әтисен әнисеннән дә курка, аны гына өйрәтергә, орышырга бик махир дип саный, әтисенен юашлыгы өчен эченнән генә гарьләнә иде. Кинодагы кебек хәлләрдән күзе шар булды. Бераздан аңа боларнын барысы бик кызык бер уен тоелды, әтисенен ни өчен бер билгесез кешеләрдән шулкадәр курыкканын аңламады. Әгъдәс үзе бара-нитә калса, аңа шик төшәчәк, күзәтеп торсалар, артыннан киләчәкләр дә малайны таптырачаклар, дип уйлый иде. Вахиткә нәрсә?! Берни белмәгән шикелле, Зөфәрнен иптәше мин, өйдәдер бит, дигән була да керә.

Зөфәрнен иптәше, дигәч, чыннан да, ишекне шундук ачтылар, ачтылар да, бүлмәләрнен берсенә дәштеләр. Анда милиция киемендәге кеше бик арыган кыяфәттә телевизор карап утыра иде. Малайны күргәч, сорау яудырырга тотынды. Син кем? Соңгы тапкыр кайчан күрдең? Кайдан бербересезне беләсез? Уртак иптәшләрегез бармы? Вахиткә, унайсыз булса да, алдап җавап бирергә туры килде. Бер кирәкле җавап та ала алмагач, милиционер телевизорны тагын кабызды, Вахитны шунда ук онытты.

Әгъдәс улына Зөфәрнен әтисеннән башка бер кешегә дә һичбер нәрсә сөйләмәскә кушкан иде. Ярый әле хуҗа кеше ишеккә үзе озата килде. Вахит аңа, «тсс» дип бармак күрсәтте дә Әгъдәснен хатын тоттырды. Анда бүген Зөфәр белән булган хәлләр язылган, милициягә берни дә сөйләмәскә кушылган, шул очракта гына ярдәм итәчәкләре, гараж артында очрашырга кирәклек әйтелгән иде. Ул малайга үзен көтеп торырга кушты.

Закир Шәмсиевич өйгә куелган кизүгә, кибеткә барып килергә кирәк, бик кирәкле документларым калган, өйдә шуны булса да эшләп утырырмын, дигән булды. Һичкемнән курыкмавын, шуна күрә озатып йөрүченең һич кирәк түгеллеген әйткәч, малай белән бергәләп чыгып китте. Каравылга куелса да, милиционерга барыбер иде бугай. Ярар соң, диде дә тагын телевизорына текәлде.

Урам башында көтеп торган Әгъдәс аларны үз машинасы артыннан ияртте. Анын милициягә ышанычы беткән, җепнең башы шундагы бер-бер кешегә барып тоташмый микән, дигән шиге бар иде. Юлны буташтырасаташтыра бик кызу барган булдылар. Анда да «Химик» юлына кермичә, узып китеп, аларнын гаражларына янәшә урамга борылдылар. Бу урамда йортлар сирәк, тәртипсез урнашкан, кеше дә аз яши. Машинаны күзгә артык ташланмаслык урында калдырып, гаражларга җәяүләп кенә киттеләр.

Ике арада сазлыграк җир иде. Узган ел тар гына канау казып, суны җыйдылар, тар күпер астыннан куелган торбаларга җибәрделәр, тирә-якны бераз чистарткан кебек иттеләр. Анысы яхшы булган, тик менә түмгәкләрне тигезләп, вак тал төпләрен алып бетерә алмадылар, алар янадан үсеп чыккан. Гаражга узу шактый михнәтле икән.

Капкадан кермәүләре барыбер дә дөресрәк булгандыр. Янына сак куюлары ихтимал. Әллә шул ук каравылчысы белән бергәләп эшләгәннәр.

Юк, анысы булмас, Рәхмәтуллага аракы табылса, житкән. Төнен эт өрсә дә, кеше йөрсә дә, чыгып та карамый, салып ала да йокы бүсә. Нигә дип бүген анын булмәсендә утлар яна торгандыр.

Угрыларнын Закир Шәмсиевич белән бәйләнешкә кермәүләре дә сәер. Әллә анын үзе генә берәр жирдә очраганын, ялгызы эзләп чыкканын көтәләрме? Әллә хәбәрне дөньялар тынгачрак, милиция саклыкны югалткач салачакларммы? Шайтаным белсен!

Гараж ишегалдын прожекторлар яктырта. Хәтта төнлә дә берничек тә анда керергә ярамый! Караклар, кем белә, әллә малайнын юкка чыкканлыгын күргәннәрдер дә каравылга ук басканнардыр. Күрше, дигән булып, артыннан гаражына килеп керсәләр… Атага хәбәр бирмәгәннәр икән, Әгъдәс аннан киткәч, гаражга барганнар булып чыга түгелме? Димәк… Юк. Һичшиксез, шулай!

Әгъдәс малайга, әтиенне эзләп тапсам, фәләнчә итеп, гараж артыннан кагарбыз, син курыкма, күрше гараждан тавыш килмәсә, шундый ук итеп шакылдат, дип киткән иде — анын да какканын ишеткәч, стенанын арткы ягындагы төнлек тирәсендәге кирпечләр какшый башлаган иде, шуларны сүтеп алырга — артык тавышланмыйча гына керештеләр.

Узган атнада, гараж артларын карап йөргәндә, тәмам аерылган икән бу, стенасы да бер ярты кирпеч калынлыгында гына, кеше-кара күргәнче рәтләргә кирәк, замананын начар чагы, машинаннан да жилләр исәр, башка вак-төяге дә кызганыч, дип уйлап куйган иде. Бердән, күченү мәшәкате белән кичектерелде. Аннан, шушында яшәгәч, үз жае белән рәтләнәчәк дип уйланылды. Инде теләсән-теләмәсән дә яхшылап рәтләргә кала.

Артык тавыш чыгармыйча, стена сүтү шактый озакка сузылды. Эшнен нәрсә белән бетәсен беркем белми иде. Малай сыярлык кына тишек ясадылар да тартып бу якка чыгардылар. Барысы Вахит саклап калган машинага таба йөгерде. Түмгәкләр дә, агач төпләре дә онытылды. Курку үзе көч биргән кебек иде. Машинада бер-ике сүз генә алыштылар, артыгын сөйләшеп-нитеп тормадылар. Вакыты ул түгел, житмәсә, йөрәктә борчылу хисе иде. Закир Шәмсиевичны, үз өенә илтмичә, шәһәрнен бөтенләй икенче башында калдырдылар.

Ай узды. Газеталар фәлән кешенен малае югалган, бу хәлнен Закир Шәмсиевич исемле директорнын һөнәре белән бәйле булуы бар, дип язып чыкты. Кемнәрдер башка фаразлар тәкъдим итте. Ни милиция, ни башка бер кеше Әгъдәс белән бәйләнешкә кермәде. Әйберләрен күчерешкәндә дә, гаражны ремонтлап йөргәндә дә, яна күршеләре күренмәде. Закир Шәмсиевичтан да һичбер хәбәр юк иде.

Бераздан бу хакта шәһәр онытты. Яна жинаятьләр турында сөйләделәр, аһылдашкан-уһылдашкан булдылар.

Гомер бакый бугазында утырган, яшәргә көн бирмәгән Нурия дә ни шул көнне, ни аннан сон сорашмады.

— Кайда йөрдегез сез? — дип, Вахитны да тинтерәтмәде.

Бер көнне машина куярга дип барса, күрше йозагын бөтенләй башка кеше бикләп тора. Әгъдәснен гараж күршесе тагын яна — яшь кенә, әле машинасы да юк егет икән. Теге вакыйгалардан сон ин гажәпләндергәне шул булды. Бер күрешкәннәрендә гаражны, әйбер куеп торырга булса да ярар дип, ашыгыч сатылгач кына алганлыгын әйтте. Танышлары аша ниндидер милиция майорыннан бик очсызга гына эләктергән икән…

Яллар үтмичә кайтмам, хатынны елатканчы тырышам, дигән Әгъдәс теге кайтуыннан гаражга йокларга дип китмәде, икенче көнне кире өенә күченде. Шундый ук малае бар бит анын да… ничек әнисе белән генә калдырасын, дип уйлады. Лагерьга да жибәрмәде, берәр жиргә бергәләп барып кайтырбыз әле, дигән булды.

Нурия бу серле хәлләрдән сон, малае белән ирен шаккаттырып, ни галәмәт,

тынычланып калган иде. Әллә Әгъдәснең үзеннән китеп барганлыгына чыннан да ышанган, әллә кайчан да бер барыбер китәр, шуна барып житкәнче, акылга утырыйм дип уйлаган. Анысы мөһим түгел. Алар өйләнешкәннәренең беренче көненләге кебек ниндидер рәхәтлектә яшәп киттеләр.

Тагын атна-ун көн узды дигәндә, ял иртәсендә Әгъдәсләрнең фатирын шакыдылар. Ишекне үзе ачты. Закир Шәмисевич басып тора. Елмая. Кулында — зур гына ялтыравык пакет. Өйгә чакырды. Керде. Күтәреп килгән пакеты — Әгъдәскә рәхмәт йөзеннән алып килгән күчтәнәчләр булып чыкты. Кара яндырып, туганнар кебек сөйләшеп чәй эчтеләр. Нурия алар белән бергә утырмады, чәй генә ясап торды. Анда да кухня ишегенә терәлеп — инсафлы хатыннар кебек бер читкә китеп, аларның сөйләшкәнен шаккатып тынлады.

Киткәндә Закир Шәмсиевич:

— Улымны исән калдырганыңны мәңге онытмам. Нинди йомышың төшсә дә, тынлармын, үземдә булмаганны кешедән табып булса да бирермен, — диде.— Зөфәрне, тиз генә паспорт ясатып, чит илгә җибәрдем. Кара син бу милицияне, аэропорт кассаларын да кисәтмәгәннәр. Малай белән әнисе үз исемнәренә билет алып китте. Алай дисәң, паспорт ясаучылар ни караган? Загранпаспорт бик тикшертелеп бирелә дигән булалар тагын.

Әгъдәс гараж күршесенең кем булып чыкканлыгын әйтмәде. Яшисе килә иде. Закир Шәмсиевичның бүре оясын дер селкетүе бар... Ул чагында милиция иң башта аны эзләп табачак. Ә менә малайны... Закир Шәмсиевичны тынласаң, Әгъдәсне ишетеп торган кебек иде:

— ... алар табып бирәсенә ышан син! Мин хәзер телефоннан сезнең белән бәйләнешкә кертмәгәннәренә дә аптырыйм.

— Үзем дә аңлата белмәгәнмендер инде, — дигән булды Әгъдәс.— Әле кемлегемне искә алмаулары, ары таба эзләтмәүләре яхшырак та...

Әгъдәс малайны да, әтисен дә гомерендә янадан очратырмын дип уйламаган иде. Алар, инде ул пенсиягә чыккач, бер дә уйламаганда суд залында очраштылар. «Химик» кооперативын ниндидер бер бай кулына төшерергә йөри, аз акча бирәчәкләр дә сүттерәләчәкләр икән, дигән сүз чыккан иде — хак икән. Беркөнне барысын җыелышка чакырттылар да:

— Монда зур бер кибет төзеләчәк, гаражларының бәясе ияләренә түләнәчәк. Хәзер яңа закон, приватизацияләнмәгән әйбергә дәүләт хуҗа, — диделәр. Сазлык урын һичкемгә кирәк түгел дип эшне озаккарак сузганнар, документларны әле яңа илтеп тапшырганнар иде. Теләгән кешеләргә районның икенче башыннан җир бүленеп биреләчәк тә салырга рөхсәт ителәчәк, имеш.

Әгъдәс бу хәлләргә борчылды. Аяклары да сызлый, олыгаеп та бара. Машинасын сатарга туры килмәгәе. Анысы да үзе белән картайган картаюын, тик аның гомеренә җитәр әле... Әгъдәс борчылып кына калса да, башкалар риза булып тормаска, карарны юкка чыгаруны сорап, судка бирергә уйлаганнар, кооператив әгъзаларының култамгаларын да җыярга керешкәннәр. Араларыннан судка кешеләр билгеләгәндә, исемлеккә Әгъдәс тә эләкте.

Судья яшьрәк кенә бер егет кисәге иде. Кооператив рәисе, бу — хәзерге заман кешесе, миһербанлы булмас, эшебез барып чыкмас, дип уйлаган иде, барып чыкты. Үзенә сүз чираты тигәч, әйткәненә ышандырырга теләгән шикелле, егетнең йөзенә ныклабрак караса, Әгъдәс шаккатты: ул кайсыдыр чалымнары белән үзе кайчандыр үлемнән коткарган малайга охшаган лабаса!

Судья егет Әгъдәс абыйсын баштан ук таныды. Ачылган эш белән танышканда ук, гаражның исеменә игътибар иткән һәм үзен коткарган кешене исемлектән эзләп тапкан иде ул. Әтисенә биргән сүзе бар иде шул: үтенече төшкәндә бу абыенны беркайчан да кире какмаска! Судка гариза шул үтенеч бит инде, үтенечнең дә ниндие! Эш бер Әгъдәстә генәмени?! Гаражны җимертсә, үткәненә хыянәт итәр кебек иде ул. Документларның

барысының да акча төртеп кенә эшләнгәнлеге ап-ачык. Житмәсә, кооператив инде приватизациягә документ жыеп өлгергән, тапшырган. Шулай икән, ике дә уйлыйсы юк: «Химиклар»ны үз урынында калдырыр! Эшне югары жибәрсәләр, кирәкле кешеләрен табар!

Судтан чыккач, гаражлашлары эшнең уңай якка чишелүенә бик каты гажәпләнделәр. Болай гына тотынган идек, артыннан йөрсәң, була икән бит, әй, диештеләр. Әгъдәс берни дә әйтмәде. Әле аның йөрәгенә малайны коткарганда кереп оялаган шом, үзе күреп тә белмәгән милиция майорыннан курку һаман да яши иде. Ә бәлки, гаражлар урынына кибетне аның бер-бер кешесе салмакчы булып маташадыр... Холык та, яшәү рәвеше дә атадан – улга, улдан – оныкка күчә...

## Разведкада

Әсхәдулла сугыш башланганда пединститутта укый иде. Менә-менә көтелгән диплом кулларыбызга керер һәм сайлаган һөнәр буенча эшкә юллама алырбыз дип хыялланып йөргән көннәре. Ул үзе гомерен укытучылыкка бирермен дип бик нык өметләнә, күп кенә иптәшләре кебек, алда дәһшәтле сугыш тора дип шөбһәләнми. Институт эчендә йөргән имеш-мимешләргә ышансаң, Германиядәге разведка инде дәүләт чикләренә немец дивизияләре килеп житкәнне, хәтта аларның кайчан Советлар Союзына һөжүм ясаячагын да житкергән. Әсхәдулла исә боларга дошман сүзе, куркаклар фикере дип кенә карый. Инде ТАСС 13 июньдә бу хәбәрләрне кире дә каккач, аның Фашистлар Германиясенең Көнбатышта алып барган сугышлары СССР чикләрен бервакытта да узып чыкмас дигән ышанычы тагын бер кат ныгыды.

Татарның, төтен чыкса, юкка түгел, дигән сүзләренең хаклыгын 22 июньнең таңы бик ачык раслады. Егетләрне, бер-ике дәрес узуга, ишегалдына жыеп тезделәр дә иртәнге өч сәгать утыз минутта Фашистлар Германиясенең бөтен чик буенча һөжүме башланганны, әле тыныч халыкның моннан хәбәрсезлеген, тиздән аларга да радиодан житкереләчәген әйттеләр. Чит телләрне яхшы белгән егетләр һәм кызлар шушы көннән үзләре алдында Ватанны саклау дигән изге бурычның беренче планга куелуын аңладылар. Бу хакта даими рәвештә укытучылар алдан ук сөйләшүләр алып барды, политсәгатьләрдә аңлату эшләре уздырылды. Житмәсә, Икенче Мәскәү пединститутында алдагы елда гына хәрби факультет та ачылып, ул булырга мөмкин сугыш ихтыяжларын күздә тотып эшкә керешкән иде.

Әсхәдулла әлеге дә баягы хәрби факультет каршындагы тәржемәчеләр курсына язылды. Аларны 1941 елның октябрендә «Карл Либкнехт» дип исемләнгән пароходка утырттылар да, берни аңлатып тормыйча, каядыр алып киттеләр. Юлда атна узып, билгеләнгән урынга килеп төшкәч кенә белделәр: факультетның тыңлаучыларын һәм курсантларын Ставрополь шәһәренә эвакуацияләгәннәр икән.

Институтның дәресләре «Лесное» санаториесында алдан махсус хәзерләнеп куелган бүлмәләрдә дәвам итәргә тиеш булды, эвакуацияләнгән халыкны исә бөтен шәһәр буйлап тараттылар. Әсхәдулла ялгыз карчыкның бер бүлмәле кысан хрущевкасында өйдәш сыман яшәп китте. Егеткә сөйләшеп утырырлык та кеше юк иде. Марфа түтәй көндезен капка төбендәге карчыклар белән сөйләшеп утыра, кичләрен картада бага, китаплар укый, тегесен-монысын караштыра. Алай да егетне чәй кайнатылган жылы өйгә кайтып керү сөендерә.

Сугыш чорының кыенлыклары үзен әле артык сиздерми иде. Әсхәдулланың көне-төне укуга бирелә һәм көндәлек күңелсезлекләргә, яшьлек ялгызлыгына, әти-әнисеннән ераклыкка артык игътибар итәргә вакыты да калмады диярлек. Курсантларга гади тәржемәче генә итеп түгел, булачак офицер да, разведчик та итеп карыйлар. Дошман армиясенең

төзелешен дә, сугыш стратегиясен дә, солдатларының психологиясен дә, алар кулланган хәрби төшенчәләрне һәм яшерен мәгънәле сөйләмне дә өйрәтәләр. Немец телен белүгә бигрәк тә каты таләпләр куела.

Хәрәкәттәге армия сафына Әсхәдулла совет ягының фронттагы эшләре яхшырып киткән бер вакытында килеп эләкте. Курсларда алган белемнәренен кирәге беренче көннән үк чыкты: Әсхәдуллага тәржемәче дә, разведчик та булу язган икән.

Дошман арасына йөргәннәрнең тормышы кызыклы да, хәвефле дә иде. Әле сугыштан соң мәктәп балалары белән бер очрашу вакытында аннан, Әсхәдулла абый, разведчиклар тормышыннан иң исегездә калган вакыйганы сөйләгез әле, дип сорадылар. Ул анысын уйлады, монысын... үлемле-югалтулы һәм нинди дер бурыч үтәп узган көннәр бер-берсенә шактый охшаган, хәтерендә кайсыдыр артык җете эз калдырмаган кебек тоелды. Разведчикның максаты — сугышта җиңү өчен кирәкле мәгълүмат табу, кыен чаклары да, җинелрәк вакыты да булгандыр анысы, кайсы көнен аерып куясың, диде дә сорауга туры җавап бирүдән качты.

Чынлыкта Әсхәдулла күнелендә сөйләрлек вакыйгалар хәттин ашкан иде, ә менә сөйлисе килгәнен, мәңге онытылмаслыгын сөйләргә курыкты, үзе дә онытырга тырышты. Сталин сәясәтенең озын кулы сугыштан соң да шактый иптәшләренең башына җиткән иде, шунлыктан бергә хезмәт иткәннәрнең, туганың кебеккә әверелгәннәрнең гомерен куркыныч астына куямдыр дип уйлады. Хәер, беркемгә дә әйтмибез дип бирелгән вәгъдәсе дә аны бу гамәлдән саклап килде.

Күңел төпкелендә йөрткән көлке дә, уйландырырлык та вакыйганы ул, инде ярты гасыр узгач, мәктәптә укып йөргән оныгына инша язганда файдалану өчен, анда да, балалар мине аңламас дигән шик белән, куркып кына сөйләде.

1945 елның апрель айларында Көнчыгыш Пруссиядә башланачак күпьюнәлешле операциягә әзерләнеп йөргән чаклары — шушы өлкәгә урнашкан дошман көчләрен Фашистлар Армиясеннән аерып алырга, диңгезгә китереп кысарга һәм өлешләп юкка чыгарырга кирәк. Елгалар, күлләр, коры елгалар, сазлыклар белән тулы матур бер җир иде ул Көнчыгыш Пруссия дигәннәре.

Сугышка хәзерләнеп йөргән көннәрнең берендә Әсхәдуллаларның разведчик-тәржемәчеләр төркеменә яшь бер егетне дә китереп куштылар. Яңа гына фронтка килеп эләккән, алардан тәҗрибә алырга да, рухи ныклыкка да өйрәнергә тиеш. Әсхәдуллалар белән фашист разведкасы арасында әллә ничек кенә шулай язу белән килешенмәгән кануннар оешкан иде. Егеткә өлкән иптәшләре, әгәр юлыбызда немецларга тап булсаң, тыныңны да чыгарма, үзеннең барлыгыңны сиздермә, аларны да күрмәмешкә салышып үт, безнең өчен кирәкмәгән кешенең җанын кыюга, тормышыбызны куркыныч астына куюга караганда, офицерларнымы, кирәкле кәгазьләрнеме кулга төшерү мөһимрәк, диде. Имеш, бу хакта фашист разведчиклары да шулай уйлый икән, әмма моны командование кешеләренә һич тә сиздерергә ярамый.

Язгы салкын үзәкләргә үтә торган төн иде. Әсхәдулла белән иптәше, теге егетне дә алып, разведкага чыгып киттеләр. Аларның юлы коры елга ярының өс сукмагыннан, фашистларныкы исә шул елганың үзәненнән уза, һәм бу гадәтне ике як та һич кенә дә бозмаска тырыша. Бу юлы да шулай булып чыкты.

Елга уртасына җитәрәк еракта кыштырдаган, пышылдаган тавышны ишетеп тынып калдылар да барысы сукмакларга сузылып яттылар. Дошман разведчиклары алар турысына якынлашып килә иде.

— Бүген руслар разведкага чыкмаган, ахрысы, — дип дәште алар турысына җитәрәк, бер немец солдаты.

— Шулай кебек. Тавыш-тыннары сизелми, — дип җөпләде икенчесе.

— Аларныкын белмәссең тагын, без узганны көтеп, бер-бер куышта утырулары да бар, — диде өченчесе.

— Юктыр. Төне нинди бит! Җанына уза торган салкын,— дип каршы төште тагын беренче тавыш.

Бу юлы да хәлләр югыйсә гадәттәгечә бара, әмма немецлар аларның килгәнлеген абайламаган икән. Инде эшне бетереп, куелган бурычларны үтәп, кайтыр якка чыккач, коры елганың урта турысына якынлашканда, тагын дошман разведчикларының сөйләшкәне ишетелде. Тагын шым калдылар.

— Карале, болай бер дә кызык түгел икән. Әллә беләсе бар әйберләрен белеп бетергәннәр инде бу урыслар,— диде таныш тавыш. — Бер-беребезне тоеп торган килеш курка-курка гына разведкага йөрергә гадәтләнгән. Бүген ичмасам ник бер тычкан кыштырдаган тавыш ишетелсен!

— Әйе шул, — дип җөпләде икенчесе тагын. — Әллә нинди тыныч төн бу. Рус ягына узгач, сизмәгәйләре дип, тыннар кысылды.

Таныш юлда дошман разведчикларының шәүләсен шәйләмәгән, тавышларын ишетмәгән немецлар, үч иткән кебек, шул турыда гына тукталып, инде кычкырып диярлек үзара сөйләшә башладылар, куркыныч чикне узганны белгәнгә, тәмәке көйрәтергә дип тукталдылар. Моны тын калып көтү ялыктыра иде. Төн җилсез булса да, җир салкын, үләннәргә чык төшеп килә. Разведкага тәүге тапкыр чыккан яшь егетнең нервлары чыдамадымы, яткан җире унайсызрак килдеме, һичкем уйламаганда-көтмәгәндә, авыр таш кебек аска — елга чокырлыгына тәгәрәп төште дә китте. Кычкырмады да, ухылдамады да үзе... Шап итеп аяк асларына барып ятканга охшады.

Әсхәдулла да, иптәше дә бер сүз дәшмичә сукмакта ята бирделәр. Эшнең ни белән бетәсен һичкем чамаламый иде.

— Моның белән нишлибез инде? — дип сорады разведчикларның беренчесе. — Иптәшләре дә бер-бер хәбәр бирми. Үзе әнә телен бөтенләй югалткан.

— Аны юкка чыгарудан гына рус армиясе җиңелмәс, — дип мыгырдады икенчесе.— Күрәләтә дошманына гомер бүләк итү булуы гына...

— Инде моны да тере дисәң... Бу яшь солдат урынына үзеңне куеп кара, — диде өченчесе. — Сугыш башланмаса, әле аңа яшисе дә, яшисе булыр иде.

Әллә, чыннан да, телсез-һушсыз калган — егет һаман да һичбер өн салмады. Бераздан немецларның өчкә кадәр кычкырып санаганы ишетелде —аны бер сулышка селкеп торып, елга өстенә ыргытулары икән. Разведчикның олы гәүдәсе баш өстеннән очып узды да шапылдап югарыга — яр өстенә килеп төште.

Әсхәдуллалар анда да дәшмәде, бу эшләрдән бөтенләй хәбәрсез сыман, һаман да шым тордылар. Немецлар нигәдер, әллә кеше кадәр кешене шулай биеккә ыргыта алуларына шаккатып, әллә бу гамәлләрен бер кызыкка алып көлештеләр. Аннан берсе:

— Беги, пока живой! — дип кычкырды. — Передай друзьям привет!

Шунда Әсхәдулла түзмәде:

— Рәхмәт! Без моны онытмабыз! — дип әйтеп салды. Немецлар тагын көлеште. Бераздан аларның үз юллары белән китеп барганнары ишетелде.

Елга өстенә менсәләр, яшь солдат әле дә куркуыннан тынсыз-һушсыз калып ята. Күпме тырышсалар да, алар аны юньләп рәткә кертә алмады. Әзрәк кайда икәнлеген аңларлык хәлгә китергәч, инде коры елганың өске юлыннан гына егетне, җилкәләреннән кочтырып, штабка алып кайттылар.

Командирлар яшь разведчикны беренче тәҗрибә белән котлаганда да, ул эшнен нәрсәдә икәнлеген анлар хәлдә түгел, күзләрен алартып, мин кайда, дигән сыман карап утыра иде.

Әлбәттә, разведкада булган хәлне Әсхәдулла белән иптәше беркемгә сөйли алмады, беркайчан да, моннан соң да сер итеп сакларга сүзләр беркетештеләр. Араларында шома колаклар да утырган тулы бер мәктәп каршысында, фашистлар белән разведка юлында дуслашып беткән идек, дип әйтәсеңмени?! Ә хәзер, сөйләсән дә, моны бер хыял җимеше дип кенә уйларлар, Хуҗа Насретдин мәзәкләре кебек кенә тынларлар да, немец солдатларын искә төшереп, бер көлешеп алырга сәбәп итәрләр. Ә бәлки, оныгының иншасында телгә алынган хәл балаларга кеше гомеренең кыйммәте турында аңлатыр? Һичбер сугышларны уйлап тапмаган, теләмәгән гади немец солдаты да, советныкы да – хакыйкатьтә имансыз хакимнәр кулындагы бер корал гына, әмма ул коралны да, теләсән, атмый калдырырга була икән, дип әйтер?..

## Дуңгыз исе

Хажирә ферма эшеннән тәмам туйды. Ашатыйм дисән – ризыгы юк, тырышып йөргәненне беркем күрми, тормыш итәрлек акчасы булса иде. Язга чыкканда:

– Курмы бетте, исәпләп салыгыз, – дип, мөдир өстеңдә тора.

Дунгызларыңны күрәләтә ачтан үтерәсеңмени?! Көн саен чиләкләп өеннән ташый башлый Хажирә. Инде анысына үги әнисе тузгына. Капчыкка печән-салам салып эшкә киткәндә артыннан:

– Башкалар өенә алып кайтканда, синеке колхозга илтү! – дип кычкырып кала. – Кайчан кеше кебек булырсын?!

Ул кешеләр кебек түгеллеген үзе дә белә, тик менә, теләсә дә, үзгәрә алмый. Әнисе әйтмешли, әллә теләми микән?

Ферма җыелышында:

– Дунгызлар таш идәнгә ятып чирли, шуңа күрә асларына саламны калын салырга кирәк, йә өстеннән такта җәегез, – дигәч, кызлар рәхәтләнеп көлде. Ачы теле Фагыйлә:

– Кайдан чыккан бу өч сыйныф бетергән зоотехник? – дип, иптәш кызларына каш сикерткән булды. Ферма мөдире электереп алырга гына тора:

– Үзгәрәсеңме инде син, Хажирә, юкмы?! Бөтен кызлар кеше төсле, син генә мөгезле.

Эләктермәгәе, бу юлы да ахырда барыбер Хажирәнеке өскә чыкты. Фәгыйләнен ярты дунгызы кырылганда, өйдән салам ташыган Хажирәнекеләрдән ник берсе үлсен?! Авылга яшь бер ветеринарны эшкә җибәргәннәр иде, шуларны ишеткәч:

– Молодец син, Хажирә апа! Дунгыз дип тормыйсың, кешегә караган кебек карыйсын, – дип мактады. Председательгә барып, идән җәйдерү турында сөйләшкән. Башка берәү оештырса, Хажирәнеке иң артка калган булыр иде, ул менә төзәтү эшләрен аныкыннан башлаткан. Көнчелеге бугазына килгән Фәгыйлә ничәнче көн борынын җыерып йөри.

Фәгыйләнен мондый кыяфәтен күргәч, Хажирәнен күз алына, алар авыл буйлап эштән кайтканда, авыз-борыннарын күлмәк якасы астына тыгып, яннарыннан узып китүчеләр килә. Фермада кием алмаштырырга да бүлмә юк. Шул тирәдә йөргән һәммә кешегә Фатыйма карчыкныкы кадәр бер йорт, анда да, кайчан кермә, ирләр җыелган булыр. Йә гайбәт сатарлар, йә, эш беткән шикелле, тәмәке тартып утырырлар.

Их, менә мунча кебегрәк берәр нәрсә салсалар икән ул!.. Бар исне фермада гына калдырып, ыспайланып, ясанып-төзәнеп кайтырлар иде.

Юынып та бетерә алмыйсың әле син аны еллар буена сеңдергәч! Һич югы азрак киләчәк бит инде ул.

Кышын клубта киносы да, вечеры да иртә башлана. Бигрәк тә шимбә булса, чыкмыйча каласың килми, ә эш вакытың җәйдәгечә тәмамлана. Кызлар өйләренә кайтып тормыйлар, берәр җирдә качып-посып кына кием алмаштыралар да, ферма йортында капкалап, туп-туры клубка китәләр. Шул чакта юынып алырга мунчасы, кием сакларга чоланында шкафлары булса... Клубка килеп кергәндә үк, шәһәрдән кайткан студент кызлар да, әле мәктәпкә йөргәннәре дә, егетләр ишетерлек итеп:

– Ферма кызлары чыкты, фу, авыз-борыннарыгызны томалагыз! – дип әйтерләр идемени?!

Хаҗирәнең мунча, эштән соң юыну кирәклеге турында сүзләрен дә иптәшләре һаман көлкегә алалар. Тагын да шул ук Фәгыйлә:

– Дуңгызлардан бет ияреп кайтыр дип уйлыйсың мәллә? – дип, тешсез авызын ыржайткан булыр. – Без юынмыйча да чиста.

Авылны аркылыга узып, урам саен хуш ис калдырып, көненә ике мәртәбә өенә кайта Хаҗирә. Ашауны ферма бүлмәсендә генә оештырсаң да була, югыйсә! Тәмәкене урамда гына тартасы! Дежур көнне шуның исеннән башың чатнап ярылырдай уянасың, ферманы әйләнеп чыккан саен, янадан йокыга китә алмый ятасың. Яхшыга дигән киеме дә шул дуңгыз исле, тәмәке төтенле бүлмәдә эленеп тора бит аның!

Хаҗирә өйләренә бар киемен тышта калдырып керә. Кайткан саен, юарга сала, чистасын кия. Әле анысында да, әнисеннән читенсенеп кенә, ис барыбер киләдер дип куркыбрак, табынга килеп утыра. Ризык исен дуңгызныкы бозмасын янәсе. Күршеләренә керсә дә түргә узмыйча, тупса өстендә генә утыра. Хаҗирәгә:

– Кыш бит, ишек кырыйлары бозланган, – дисәләр дә, кул селки, урам якта түгел имеш, ишек бозына терәлмәгән. Борчылмасыннар өчен генә, калын сырмасы белән билгә кадәр уранып куя, йә аны, калын итеп бөкләп, астына сала:

– Менә болай бөтенләй суык түгел. Булса да, мина тими ул.

– Суык тигәч, әйтү соң була, кер! – ди тагын бер кат Габдрахман абыйсы.

– Тисә, ягылмаган, ватык тәрәзәләреннән җил искән абзарда тияр иде инде ул! Дуңгыз исе киләдер шикелле... Идәнгә утырырга өйрәнгән мин. Ферма өендә урындык житми. Ял итәм дип керәсең, ялың шул идәндә була инде. Мамык сырмаңа утырып, бер кырга чөмәшәсең.

Сүзен бирмәвен күргәч, Гатифә апасы үзенчә үгетләргә тотына:

– Өйгә кергәнсең бит инде. Исең булса, ул да сиңа ияреп кергән. Ишек төбендә утырсаң да, түрдәге сәкегә кунакласаң да, барыбер борынны ярып киләчәк. Сасыдан курыксаң, авылда да ач торасың инде. Безнең дә – ярты көн абзарда.

– Ул бит җигелми торган ат, сыер янында...

– Йә инде, йә. Нинди ис булсын: үзенә генә тоеладыр. Минем борын иснең ниндиен дә шунда ук сизә. Ике көннең берендә фермада, өйдә болай да юктыр дисеңме?!

Укытучы халкы шулай инде. Бик тә ышандырырга тырышып, кәефен кырмый гына аңлата. Әйтмиләр генә алар: дуңгызны түлке барыбер яратмыйлар! Авылда дуңгызны беркем дә яратмый. Аны аңларга күп акыл кирәкми: бөтен җирдә иң әшәке кешегә, имансызга «дуңгыз» кушаматы тагалар. Ә менә Хаҗирә дуңгызны да, исен дә ярата, шул иснең үзеннән килгәнен генә җене сөйми.

Үскән, киртә җимерергә торган, ачлыктан мыркылдап нервына тигән дуңгыз – бер нәрсә, ә менә ап-ал булып дөньяга килгән, күз ачарга да

иренгән төсле кулында яткан сабыйларың — икенче... Өеннән урлап төшкән сөтен дә эчерә Хажирә аларга, саранрак булсалар, орышып, әниләреннән дә эчерттерә. Бала тапкан ана дуңгыз яман да хәтәр нәрсә! Хажирә орышкан була булуын, үзенең коты ботына төшә.

Дуңгыз фермасы булса да, алар авылында беркем дә чучка асрамый.

— Урыс ризыгы ул, нигә мөселман авылында үстерелергә тиеш?! — ди Габдрахман да. — Урыс авыллары сыер-сарык үрчетә, ә без менә — мырык! Дуңгыз асрасаң, үзең дә дуңгызга әверелерсең, ди иде бабайлар, бу сүз дөрескә охшаган. Хатынның әтисе, дуңгыз итен сугышта да ашамаган, башкасы юк дип тормаган. Шуның өчен генә исән-имин кайттым, өстемә гөнаһның андыен булса да алмадым дип сөенә.

Колхоз җыелышында дуңгыз фермасын ябып, сарык үрчетү мәсьәләсен күтәреп тә караган иде:

— Коммунист башың белән! — дип чат ябыштылар. — Әйтәм җирле, малаенны сөннәткә утыртып кайттың!

Председатель акыллырак булып чыкты.

— Сүзең хак анысы. Тик менә дуңгыз рентабельле бит!

— Рентабельле булса, урыс үзе үстерсен! Урам тулы сукбай эт. Үстерәсе дә юк. Чит илдә ашыйлар дип, бер дә сугымга эт асраугa күчкәнебез юк.

— Анысы шулай шулаен. Тау башы урамына янәшә салынган булгач, җәй буе ферма ягыннан искән җил сасысын җитәрлек алып килә. Аннан аз табыш килсә, башка җиреннән күбрәк табар да идек әле... Тик менә разнарядка Казаннан ук төшә бит. Ана Мәскәүдән килә диләр.

— Мәскәүдән синең ферман да, дуңгызларың да күренми. Картага бармак төртеп, кайда дуңгыз асраганны билгеләп утырмый бит алар. Сүз белән әйтәләр дә бетте! Ә син үзеңчә яши бир!

— Коммунист башы белән! Партия кушканга каршы килеп! — ди авыл куштаннары, рәис булып рәис каршы төшмәгән бер чакта.

Алар районнан вәкил килгәндә шулай сөйләшә, башка бер чакта, кирәкле кеше дип, шул Габдрахманның да бер алдына, ике артына төшә. Фермада дуңгыз асрау әнә шундыйларга файдалы да ул. Якындагы марига-урыска дуңгыз сатып көн итү начармыни?! Чучканың артык башын районнан килеп кем санаган да, имчәк саен тапкан баланың берсе кимүне генә кем исәпкә алып торган?!

Мондый халыкка тагын нәрсә сөйлисең, ди Габдрахман, тагын да шул кич утырырга кергәч. Ачыккүзлеләр — гомер бакый укыган нәсел. Әниләре мулла кызы иде, әтиләре дә төшеп калганнардан түгел. Совет заманы дип тормыйлар, Габдрахманның өлкәнрәк туганнары барысы да — муллалык итүдә. Бездә яшәсәләр, күрерләр иде дә күрәсең. Киров өлкәсендә торгач, әллә чын иман китергән, әллә тәрегә карап чукына — аңа игътибар иткән кеше дә юк! Югыйсә алар ягына басу чиге аша гына чыгасы.

Мулла булсалар да, бер дә төшеп калмаганнар. Барысы да рәтле урыннарда утыра, һәркайсының үз районнарында сүзе йөри! Гади урыска синең дин тотуың ни дә, тотмавың ни. Моны өстәгеләр болгата. Эшен эшлиме? Эшли! Планын үтиме? Үти! Яхшы җитәкчеме? Яхшы! Габдрахман уйлавынча, кешенең бәясе эшендә күренергә тиеш.

Борчуы булса, берәр нәрсәгә башы катса, Хажирә гел Габдрахманнарга керә. Дәрескә план төзеп утырган җирдән генә, ана борылып карап та тормыйча, һәр сүзенә җавабын шунда ук биреп кенә тора ул. Хажирәнең, кеше керде дип, аларның эштән бүленмәвенә ачуы килми. Ул бит монда көн саен. Укытучы халкының иртәгегә планнарын төзегәч, йә фермага, йә клубка дежурга китәсе бар. Дуңгыз исен иснәп карасыннар әле алар да, кәчтүм киеп. Сумка тотып кына йөрмәсеннәр, диләрдер инде.

Бер жыелышта:

– Укытучыларны шунын белән дә жәфаламыйк инде! Балаларыгызны тәрбияләсәләр яхшымы, дунгызыгызга карап килсәләрме? – дигән иде Хажирә, беравыздан:

– Икесе дә! Аларнын тагы башка нинди эше бар? – дип кенә авызын яптырдылар.

Кизү торган укытучы дунгызны нишләтсен?! Абзарга кереп, сәлам бирә дә чыга. Менә Хажирәне мәктәпкә дежурга куймыйлар бит. Дәрес тә укытканы юк. Күршеләрен кайвакыт ферма эшенә дә кушалар, әйтерсен, укытучылар да төшеп, тегесенә-монысына булышмаса, дунгызлар кырылып бетә. Дунгызлар, сазлыкта йөрсә дә, кырылуын абзарындагы шакшыдан, ачлыктан кырыла ул! Янында карап тормасан, ач, хәлсез ана дунгыз дистәләгән баласын шунда ук үзе ашап бетерә.

Ферма эшеннән түгел, шул эшне оештыра белмәүләреннән тәмам алжыды Хажирә. Ферманын икенче башыннан жилкәсендә апара ташудан туйды. Югыйсә янәшәдә абзар тулы ат. Барысы диярлек жигүгә өйрәтелгән. Эшсез ятканы да бар бит инде. Жик! Апаранны гына булса да ерактагы абзарларга китереп бир! Мөдир:

– Киләчәктә сыек ризык тагаракларда агып киләчәк, – ди.

Әле ул киләчәк кайчан киләчәк? Хажирә үзе дә аяксыз калган дунгыз хәленә килгәчме? Анын шулай баш катыруын берсе дә яратмый.

– Эшләгәненә акчанны аласын бит, алдына кара да йөр, кайчан гына без зарплат күрә башладык сон? Шунысына шөкер ит! – диләр.

Акчадамыни хикмәт?! Аны, эшләрне жайласалар, күбрәк тә алып булачак. Дунгызнын симерүе эскалаторлардан, йөгерек тагараклардан да тормый анысы. Елын елына идарәдәгеләр әзерләткән, фермага дип бүлеп калдырган ризык язга кадәр житми. Бу хәлләр һаман саен кабатлангач, көздән үк яхшылап исәпләп булмый микәнни?! Әллә сон кызлар, мөдир әйтмешли, күбрәк урлап ташлыйлармы? Барысынын да абзары тулы мал, котүгә йөргән һәр малнын корсагы шоп-шома булып кабарган, сырт йоннары ялтыраган. Берсеннән дә сасы ис килми. Кич кайткач, кырылган, юылганнар.

Китәргә кирәк фермадан, китәргә! Тик кая? Башка бер эше булмаганда. Анын жәен хезмәт көне эшләп бирерлек биш баласы юк, ә аны, сүзгә калмыйм, ашлыгын-саламын житәрлек алыйм дисән, тутырырга кирәк. Китүнен бердәнбер юлы – кияүгә чыгу. Әмма монысы узган елдагысы кебек булырга тиеш түгел.

Фермадан кайтып, мунча юынып, ятарга әзерләнеп йөргән чагы иде. Кыш дип тормыйча, эчке күлмәге өстеннән телогрейка гына киеп, бәдрәфкә чыгып китте. Бер очтан капкаларны да бикләп керермен дип уйлады. Анын янына килүе булды, кинәттән ачылып китте дә каршысына ике ир килеп басты. Сөйләшеп тә тормадылар, авыз-борынын томалагач, кулларындагы толып шикелле бер нәрсәләргә төреп, ат арбасына илтеп салдылар. Як-якларыннан саламнар белән жылыткалагач, инде авылны чыгып ук барганда, шуларнын берсе:

– Унайсыз түгелме? – дип сорады. – Тавышланмасан, авызынны чишәрбез.

Тавышланып ни файда?! Япан кырда кышын кем очрасын?! Синен кычкырганынны кем ишетсен?!

Арба кырына утырып барган ир Хажирәнен авызына бәйләгән чүпрәкне чишеп жибәрде. Сулышы иркенәеп китте. Ни курку, ни кычкырасы, ни еласы килү теләге юк. Ирләрне бу үзе дә аптыраашта калдырды булса кирәк. Чана артындагы чыгынтыга басып, дилбегә тотканы:

– Сине Илгизгә исән-сау алып кайтып житкерергә сүз бирдек. Бездән

курыкма! Хәзер төн. Барыбер берни эшли алмыйсың. Теләсәң, иртәгә кире кайтырсың, — диде.

Олтанлы киез итек кигән, башына япкан, телогрейкалы булса да, эчке күлмәктән... Кеше көлдереп, йә кая, нинди Илгизгә бара инде ул? Төшеп калса да, нишли ала? Ычкынса да, ерак китмәячәге, тотып алачаклары көн кебек.

Алар авылындагы Илгиз — әле мәктәп баласы гына. Тагын бер Илгизне ул күреп белә дә белүен... Узган елгы сабантуйлар вакытында, Нократ аръягындагы Күкшел Пүчинкәсе дип йөртелгән бер авылга баргач, кичке уенлыкта танышканнар иде. Атта, чанада, толыплар салып килгәч, шуннан булмый, кемнән булсын?! Ул авылга кышын тик ат юлы гына. Анысы да ниндидер... Алайса... Хаҗирәне әлеге Илгизгә урлауларыдыр инде.

Хаҗирә фаразының дөреслегенә ышаныр өчен генә:

— Пүчинкә малае мәллә? — дип сорады. — Ник болай төнлә алып китәсез? Көндезен килеп, әнидән сорасагыз ярамыймы? Әтисе юк, әнисе үги дип көлүегездер инде. Егетләр, әллә соң кире алып кайтып кына куясызмы? Күңелегездә бер яманлык булып калачак бит инде бу эшләр. Алай да кая илтә мине бу атлар?

Ферма эшчесенең тозлап-борычлап сөйләшкәне аз түгел. Илгиздән ишеткәннәренчә, ниндидер дуңгыз карауچының мондый җөмләләр белән, китапчарак сөйләшүе чанадагыларга кызык тоелды булса кирәк:

— Бүре оясына кадәр инде, кызый, — дип җавап бирделәр.

Хаҗирәнең коты алынды. Илгизне бүре дип атап, шаяртуларымы бу? Юри генә әйтүләреме? Сабан туенда күргән егет дип ялгышамы, әллә башка бер-бер кешеме? Шул сорауларга тизрәк җавап табылсын өчен кебек, чана салулый-салулый урман юлыннан алга ашыкты. Артык җылы төн булмаса да, кар явып тора, толып эчендә, киез итекләрдә туңарлык түгел иде. Оешып ятуы, кыймылдый да алмавы гына ардыртты.

Теге чагында Илгизнең кайсы якныкы, кунакмы, авылныкымы икәнлеген сорашмаган иде шул. Алар капка төбенә житәрәк ике-өч сүз алыштылар да аерылыштылар: Хаҗирә өйгә кереп китте, ул нишләгәндер, белмәде.

Шактый озак, өч-дүрт сәгать чамасы баргач, яктырак бер урынга килеп чыктылар да атны сулга бордылар, бераздан «тпру»лап туктаттылар. Егетләр чанадан төште. Шыгырдатып, капка кебек бер нәрсәне ачканнары ишетелде. Һаман да бәйләнеп чанада ятса да, моны гына аңларлык иде. Жигүле атны ишегалдына кerткәч, Хаҗирәне бәеннән ычкындырдылар, толыбы-ние белән күтәреп алдылар да җиргә бастырдылар. Алар кар кебек ишелеп җиргә төште.

— Әйдә, өйгә уз! — диде чынлыкта да ул җәен танышкан Илгиз.— Таныдыңмы мине? Шаккатмадыңмы? Сине булачак киленнәр ярышына китерттем.

Ни дигән сүз бу?! Хаҗирә юл буе, үзен кияүгә урладылар, ахрысы, кем йортына ничек килеп керер, дип уйлап барган иде, ә монда... ниндидер ярыш...

Койманың тыш ягында шактый караңгы иде. Капка төбендәге баганадан сүрән генә якты төшә, шундый ук бер лампочка ишек алдын яктырта. Башка җирләрдән һични сирпелми. Ай качкан, күк томаланган бер төн. Хаҗирәнең керфек очларына кар кунып, яшь кебек эреп барып, муен тирәләрен бераз туңдыра башлаган иде инде, ярый, бераздан явудан туктады.

Бу йорт ялгызы гына мәллә соң? Ишегалдының бер ягыннан — койма өсләреннән куе агачлар күренә. Хаҗирәнең күңеленә шом төште. Юан бүрәнәле йорт та, агачлар да, серле караңгылык та аны урманчы каралтысына китереп атканнары турында әйтә. Димәк, янәшәдә башка бер йорт юк, һичкем яшәми... Монысын ук көтмәгән иде.

— Нәрсә аптырап торасың? — диде Илгиз. — Урман каравылчысы мин. Абзанның йорты булыр бу. Әйдә, кер!

Хажирә карышмады, Илгизнең артыннан чоланга керде. Карышмавын яхшырак, берни дә булмас әле дип өметләнде. Егетләр кире киттеләр бугай. Капканың ачылганы-ябылганы ишетелде. Әллә үз атлары тышка бәйләп куелган иде микән?

Илгиз авыр калын ишекне каерып ачты да, кулыннан тотып, Хажирәне йортка уздырды. Зур гына ишек каты иде. Телогрейкасын салырга теләмәде.

— Өстемдә кием юк минем, — диде.

Тышка чыкканда рәтле-башлы киеп тормаган иде, инде искереп беткән сырмасын сәдәфләп үк куйды. Шул килеш түр бүлмәгә үтте.

— Ә сиңа аның кирәге дә юк! — диде артыннан кергән Илгиз. — Сез монда барыгыз да эчке күлмәктән генә.

Түр урындыкларда, янгырда шәлберәйгән кош балалары шикелле, ярымшәрә ике кыз утыра иде.

— Таныша тор. Килендәшләрең. Ленура белән Мансура. Игезәкләр, — диде зур канәгатьлек белән Илгиз. — Арагызда бәйге уздырып, сезне хатынлыкка сайлыйм. Гәүдәләре сылулыгын күрсәтеп, алар әнә үзләре үк күлмәк-кофталарын салды.

Инде монысы нәрсә? Исән калуын калды, адәм рисвае булдымы?

— Мин катнашмыйча да җинелергә риза! — диде Хажирә. — Тик тимә генә!

— Ә мин тияргә дә уйламыйм! Урман каравылчысының башка кешесе юк аның: хатыны бер һәм бер дигән булырга тиеш! Биесен дә, җырласын да, ашарга да пешерсен һәм матур да булсын! Фигурный!

— Ә син?

— Мин шуның кочагында ял итеп кенә яшәргә бурычлы.

— Алайса урман бетә икән...

Теге кыз, телләшеп торганы өчен, китереп сукмагае дигәндәй, куркышып карап тора. Кеше ышанмастай хәлләр. Сөйләсән дә, тагын үзеннән генә көләрләр. Дуңгызларын калдырып, больницага да йөрми иде, гомерендә бер чит авылга сабан туена барды, аның да ахыры ничек тәмаланды. Юк, тәмамланмаган иде әле, аның ничек бетәсен беркем белми.

Илгиз, Хажирә утырсын өчен, икенче бер урындыкны кызларныкы янына куйды да телогрейкасын сәдәфләре өзелерлек итеп тартты.

— Юк, үзем чишәм, нәрсә котырасың? — диде Хажирә. Аның теге кызлар кебек чебеш хәлендә күренәсе, курыкканлыгын сиздерәсе килми иде. Илгизгә Хажирәнең тотышы ошады. Киемен җибәрде, үзе салганын көтте. Ә ул берни дә булмаган, барысы да гадәти шикелле кыланды. Урындыкны кырыйгарак тартты да, сырмасын салып аркасына элгәч, җәелеп килеп утырды. Табуреткадан башканы урындык дип белмәгән Хажирәнең авырлыгыннан шәһәр җиһазы шыгырдап куйды. Урманда яшә дә шуны ал инде ә?! Әмма ана да исе китмәгән бер кыяфәттә ул:

— Йә, кызлар, нишлибез? Миннән ферма исе килмиме? — дип сорады. — Дуңгыз исе?

Күршеләренең һичберсенә сәер тоелмый торган бу сорауны ишеткәч, Илгиз кычкырып көлеп җибәрде:

— Дуңгыз караучыдан — дуңгыз, бәрәңге үстерүчедән бәрәңге исе килергә тиешмени?

Аннан соң авыр сулады да монсу гына:

— Карт кешене карасаң, картлар исе сеңәме? Менә мин көз көне генә әнкәй мәрхүмәне күмдем... — дип әйтә куйды.

— Юк, кеше урлаучыдан да дуңгыз исе килә, — диде Хажирә.

Кызларга жан керде. Елмаештылар. Илгиз аларга бер караш кына ташлаган иде, тагын урыннарына сеңделәр.

«Кияү егете» радиоалгыч янына килде. Өстәлдә яткан пластинкаларын сайлаштырган булып маташты. Радиоалгыч өстендә уйната торган җире бар иде, кечкенә бер түгәрәкне шуның тимер чыбыгына киертте дә, кабызгач, инәсен куеп, музыка әйләндерергә кереште.

Көе таныш кебек иде, тиз генә сүзләрен исенә төшерә алмады. Ул да булмады, Әлфия Афзалова кызгандырырлык тавыш белән «Яшь гомер»не жырлап җибәрде. Илгиз Хаҗирәне вальска чакырды. Нигә әле, мин дуңгыз карауччы гына, вальс әйләнә белмим дип торырга: бик булдырган кыяфәт белән, ул уң кулын Илгиз җилкәсенә, сул учын — аныкына салды. Йорт зур, түр бүлмәсе бик киң иде. Бу сиңа ферма өе түгел. Вальс әйләнсәң дә, сигезле уйнасаң да була. Житмәсә, шып-шыр. Өстәл, урындык, тар гына караваттан башка һични юк. Хаҗирә барыбер егетнең аягына басып бетерде. Басмагае! Аның аягында олтанлы итек кенә ләбаса!

— Кызлар, әйдәгез! — диде Илгиз, нигә әле без генә биибез дигәндәй. Алар, бер карусыз парлашып, вальска керде. Көй мәңге бетәр кебек түгел иде. Туры киләме-килмиме дип тормадылар, уйнаткыч башындагы инә пластинкадан кырыйга төшеп шыгырдый башлаганчы әйләнделәр.

— Чәй эчеп алыйк әле, — диде аннан Хаҗирә. — Тамак кипте.

Чәй мәтрүшкәле, бөтнекле иде. Болары тагын исенә җәй көнендә ферма янына кайтарылып ташлаган хуш исле печәннәрне китертте. Илгиз кызлар алдына бал, кура җиләге вареньесы куйды. Шикәр белән ипидән башканы күрмәгән Хаҗирә, балны калактан тамыза-тамыза, өстәлне буяп бетерде. Бер туячак идеме ул, юкмы? Егеткә чәйне икенче бүлмәдән генә ясап кертәсе. Кызларны түгел, аны сынау кебегрәк булды әле бу.

Өстәл астында табуреткалар булган икән. Үзенә куелганын яткырып, янына утырып, терсәкләрен як-якка сузып, чәйне тәлинкәдән генә шупырдатып чөмергән Хаҗирәне карап тору кызларга көлке тоелды, борын астыннан гына елмаештылар. Илгиз исә дуңгыз караучылар барысы да шулай эчә микән әллә дип шаккатты.

Хаҗирә чәйне ярата. Өйдә булса, бер савыт шикәр бетерә, уникедән дә кимне эчми, монда да шулай эшләмәкче иде, Илгиз, бездә зур самавыр түгел, тагын кайнатасы, көтеп тор, дигәч, сигез чынаяк белән канәгатьләнде. Соңгысына заварка чәйнегеннән генә әйләндертте.

— Бүгенгә житәр, — диде Илгиз. — Иртәгә жырда, ашарга пешерүдә ярышырсыз.

— Юк инде, сөйләшеп утырыйк, — диде йокысы качкан Хаҗирә. — Теләсәләр, әнә кызлар караватка барып ятсын. Минем иртәгә чуар дуңгыз Валюшканы бәбиләтәсем бар иде. Шуна да эч пошып тора. Миннән башка исән-сау китерер микән? Монда ятуын ятарсың да, аларны кем карар? Апара цехына тозлаган балык китергәннәр. Кызлар рәхәтләнә инде. Дуңгызларга тими дә. Сасыган дип тормыйлар, сыптыралар гына! Мина балык кирәк түгел. Акшар булса житә. Ферма йортындагы мичне гел мин генә кимереп бетерәм. Ай саен агарталар. Ветеринар, сиңа нидер житми, Хаҗәр апа, ди, калиймы шунда, акбур кимерергә куша. Күршеләр укытучы минем. Сорасаң, кызганмыйлар, бирәләр. Кызыл балчыкка ябышып кызган мич акшары барыбер тәмлерәк..

Хаҗирәнең сөйләгәне җыен юк-бар булса да, үзенә алай тоелмый иде. Илгизгә дә, кызларга да кызык күк санап, каравылчы Әптеринең төнлә исерек килеш кереп, дуңгызлар арасында йоклаганын да, колаксыз кала язганын да, Мәчтүрәне ата дуңгыз егып, сазлыкта әвәләвен дә, ферма мөдиренең хатын-кызга хирыслыгын да, ишеткән-белгәненең берсен дә калдырмады.

– Ну сүз икән синдә! – диде Илгиз. – Сабантуйда бик тыныч кыз кебек кенә күренгән идең. Сина өйләнсән, дуңгыз, ферма, саз, ис турында гына сөйләшәсе икән.

Хажирә аптыраганрак кыяфәт белән:

– Дуңгыз карагач, дуңгызны сөйләшәсең, дуңгыз исен иснисең инде. Мунча керенеп чыккан идем, бүген ис килмәскә тиеш! – диде. – Әллә соң эчке күлмәгемнән дә киләме?

– Юк!!!

Хажирә әкиятләрен тыңлап, таң атты. Ул арада кемнәрдер капканы дөбердәтте. Илгиз исәнгерәми калды, өстенә күлмәк тә киеп тормыйча, Хажирә капкага таба йөгерде:

– Үзем генә ачам!

Илгиз аның артыннан атылып чыкса да, куып тотарга өлгермәде, тыштагылар Хажирәнең тавышын инде ишеткәннәр иде. Капка келәсен уйнаткан берсе:

– Мин бу, Хажирә, Әсфәндияр абыең, дуңгызларыңның бәбиләсе вакытында төнката авылдан чыгып качмасаң! – дип кычкырды.

Илгиз курыктымы, барып, капканы ачты.

Ферма мөдиренең Илгиз янында эчке күлмәкчән Хажирәнең басып торуын күреп, күзе шакмакланды:

– Мин сине эштән башканы белми дип торам, Тьфү! Дуңгызлар турында болай да юри генә әйтүем иде. Төнлә чыккан жиреннән кермәде дип, әнкәң йөгереп килгәнгә генә эзләп чыктык. Яңа яуган кардагы чана эзе буенча барып таптык. Ә син менә нишләп ятасың икән!

Әсфәндияр хәйләле. Ул яхшы дуңгызчыны югалттым дип әнисеннән битәр курыкты. Түлке бу кызга баш бирергә генә ярамый иде. Әнә бит Хажирә акланып та, аңлатып та тормады. Ул авылдашларына:

– Мин хәзер чыгам, – диде дә телогрейкасы артыннан кереп киттте. Илгиз ана төренеп килгән толыпларын чыгарып бирде. Алмадылар. Чанада толып та, сырган юрган да бар иде.

– Кара, кызый, дуңгызларың балалагач, ярышны дәвам итәбез әле, – дигән булды Илгиз, толыпны киеп алгач, аркасыннан кагып.

Хажирәне яңадан урламадылар, килеп тә сорамадылар. Ул Илгизне нәрсә белән шаккаттырсын? Һаман дуңгыз турында гына сөйлисең, диде бит үзе дә. Капканы шул кичтән соң әнисе бикли, кирәк булса дип, чоланнарына иске чиләк куеп йокларга ята башлады. Анда да, Хажирәнең барлыгына ышанмагандай. Төн уртасында, ике булмаса бер, караваты янына килеп карый торган иде әле.

Бу хәлләр авылның бар халкын шаккаттырды. Хажирәнең нигә төнлә ат арбасында авылдан елга артындагы урманга китеп баруын да аңламадылар, анда ниләр булганын да белмәделәр. Күршеләренә кергәч, тупса өстенә утырып, сер итеп кенә сөйләгән иде дә, тегеләр, инде исән-саулыгына шөкер ит, дигәч:

– Әй лә, шөкер итеп кенә, ни булыр? Мине кая гына барсам да, дуңгыз исе коткара. Шуңа чыдаган кеше генә минем белән яшәп кала, йә исе артыннан килеп эзләп табалар, – дип көлде.

Гадел
Кутуй

# РӘССАМ

Юлбасарлар кулына эләккән шәһәрдә кеше бик аз калды. Халык кичә үк, дошман ыргыткан бомбалардан өйләргә ут капкач ук, ашыгыч рәвештә шәһәрдән чыгып китте.

Даны дөньяга таралган рәссам Макс Латис та китәргә әзерләнгән иде. Ана махсус автомобиль бирелде. Хатыны һәм баласы, кул астына эләккән төенчекләрне алып, машинага кереп утырдылар. Ләкин рәссам үзенең иң кыйммәтле картиналарыннан берсен күтәреп өйдән чыкканда, каршыдагы йорт өстенә бер-бер артлы берничә бомба төште һәм көчле янгын күтәрелде. Шәһәр өстендә дошман самолетлары ешайды. Рәссамга ашыгырга кирәк иде. Ул «каһәрләр!» дип, күккә карады һәм китәргә кирәклекне онытты. Аның йодрыклары үзләреннән-үзләре йомарландылар, күзләрендә яшендәй ут очкыннары күренделәр. Бу минутта ул, хатынының: «Әйдә инде, утыр!»— дип кабат-кабат әйтеп торуын да, баласының: «Әткәй, киттек!»— диюен дә ишетмәде. Күзләре янадан ялкын эчендә калган йортка төштеләр. Шушындый минутта, бүтәннәргә ярдәм күрсәтергә кирәк чакта, шәһәрдән ашыгыч чыгып китүне ул җинаятькә санады һәм калырга булды.

Латис кулындагы картинаны машинага куйды, хатынын, баласын үпте һәм янган йортка ишарә ясап:

— Безнең йортны да, безнең картиналарны да әнә шундый язмыш көтә. Беразын коткара алмаммы... Мин сезне куып җитәрмен. Сез ашыгыгыз! — диде.

Латис ханым иренең әкәмәтрәк табигатьле кеше булуын һәм ялгыз калганда аның ярдәмгә мохтаҗлыгын яхшы белә иде. Ул бит, исенә төшерүче булмаса, ашарга-эчәргә кирәклекне дә оныта, әнә хәзергедәй үзе дә сизмичә, бер аягына галош, икенче аягына ботинка киеп йөри. Ләкин Латис ханым иренең иҗатка, сәнгатькә бирелгән булуын да бик яхшы белә. Аның ире иң куркынычлы минутта да сәнгатьне ташлаячак түгел иде. Шулай да хатын аңа:

— Әйдә инде, Макс, бергә китик,—дип ялварып карады.

— Ярый, ярый. Мин озакламам, хушыгыз,— диде рәссам, һәм моннан бер генә минут элек бизгәк тоткандай калтыранган кеше хәзер ни өчендер елмаеп куйды. Ләкин елмаю шул ук минутта югалды да. Рәссам тагын бер тапкыр: — Хушыгыз! — диде.

Машина кузгалып китте һәм озакламыйча күздән югалды.

Макс Латис янган йорт янына барып, аны сүндерешүгә катнашты. Өенә кайтып керүгә, тәрәзәдән бик озак урамга карап торды. Өйдә аңардан башка бер кеше дә юк иде, ләкин ул, кемнәргәдер мөрәҗәгать иткән сыман:

— Әнә карагыз, нәрсә калды. Кил, кызым, кара — бала табу йорты иде бу. Син дә шул йортта тудың. Гөнаһсыз бала күкрәгеннән атылып чыккан иң беренче яшәү авазыннан да кыйммәтлерәк аваз дөньяда юк, кызым. Әгәр дә мин композитор булсам, шул авазны кушып симфония

язар идем. Ә фашистлар шушындый изге йортларны бомбага тоталар. Әнә тагын, тагын яна башлады.

Рәссам, «күрәсенме, ничек яна» дип, артына әйләнеп карады. Янында кеше юклыкны аңлагач: «Ә... әйе, киттеләр... Ә мин ник калдым соң?»— диде һәм: «Әйе, хәтерләдем!» — дип, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, буяулар алып, рәсем ясарга кереште.

Аның хезмәте өчен иң кыйммәтле вакыт — иртәнге һәм көндезге сәгатьләр иде. Ләкин бу турыда ул бөтенләй уйламады, чөнки дөрләп янган йортлардан төшкән яктылык ана җитәрлек иде.

Ул төн буе һәм икенче көннең төшлегенә кадәр эшләде. Рәсем ясалып беткәнче, арыганлык аның уена да кермәде, ә иң соңгы буяу салынуга ул үзен көчсез хис итте, хәтта басып торырлык та хәле калмады. Куе чәй булсын иде хәзер аңа! Макс, гадәтенчә, хатынын чакырды, аның озак җавап бирмичә торуына гаҗәпләнде. Бары тик кичәге вакыйгаларны хәтерләгәч кенә, чәйне үзенә әзерләргә кирәклекне аңлады. Ләкин чәй эчеп тормады, урамга чыгып китте.

Төнлә белән шәһәргә фашистлар керделәр. Өзлексез талаулар башланды. Ату, кычкырып елау тавышлары ишетелде. Рәссам, тәрәзә янында торып, тавыш килгән якка карады. Кул фонарьлары яктысында карачкыл шәүләләр — фашистлар күренде. Әлеге бала табу йорты да күзгә чалынды, йорт янган, кара күмергә әйләнгән, ләкин ни гаҗәп: шул кара күмерләр уртасында — багана һәм баганада йортның вывескасы калган.

Макс Латис яңа картина янына килде һәм аны, иң кадерле әйбер итеп, кая яшерергә белмичә, озак вакыт аптырап йөрде. Ахыр чиктә рәсемне ул, иске бер материя белән каплап, ишегалдына чыгарып куйды; күренмәсен өчен аны такталар һәм буш тартмалар белән каплады.

Таңда аның өенә бер офицер килеп керде.

— Кем монда хуҗа? — диде ул офицер.

— Рәссам Латис.

— Ишеткәнем бар, кая соң ул үзе? Качтымы әллә?

— Юк, качмады, семьясын озата китте,— диде Макс, гомерендә беренче тапкыр ялганлады.

— Ә син аның картиналарын сакларга калдыңмы?— Офицер, биргән соравына җавап көтмичә, түргә узды һәм стеналарга эленгән, идәндә сөялеп яткан картиналарны карарга кереште. Чит кеше өендә үзен хуҗаларча тоткан бу көтелмәгән офицерга Макс чирканып карады һәм аңа каршы бернәрсә дә эшли алмавына үзен тиргәде. Офицерның биленда хәнҗәр бар иде. Ул шул хәнҗәрен алып:

— Монсы кирәкми!

— Монсы начар!

— Монсы рюссиш! — дип, берничә картинаны буйдан-буйга кисеп чыкты һәм катып калган Латиска әмер бирде: — Калганнарын сакла. Бераздан генерал үзе кереп карар!

Офицер чыгып китте, ә Макс, «Күрдеңме, рәссам, кыргый бандит безне нишләтте!» дигәндәй, аңа күз текәгән яралы картиналарга карап калды. Туралган рәсемнәр телгә килгәндәй тоелдылар. Ул алар янына килде, «Әткәй... әнкәй... кызым... сөеклем!..» дип, рәсемнәрдә ясалган кешеләрнең йөзләреннән сыйпады. Ә рәсемнәрдәге яраланган кешеләр: «Безнең йөрәкләребез сызлый»,— дип кычкыралар, «Кач, рәссам, кач, сине дә алар чәнчеп үтерерләр»,— дип әйтәләр кебек.

Макс яраланган картиналарны нәүрәпкә чыгарды. Аннары әллә кайдан күп-күп итеп керосин табып керде, керосинны идәнгә, стеналарга һәм офицер сакларга кушкан картиналарга сибеп чыкты. Калтыранган

кулларына шырпы алды. «Тукта, мин нишлим? Акылдан яздыммы әллә?» дип, нәрсә эшләвенә хисап бирергә теләде. Ләкин озак уйлап торырга вакыт юк, ашыгырга кирәк иде... Ул шырпы кабызды һәм өйгә ут төртте...

Икенче көннең таңында күзәтче партизаннар урман авызында ярым үлек хәлдә бер гәүдә таптылар. Беренче күрүдә аны кем дияргә дә белмәделәр. Бер аягында ботинка, икенчесендә ботинка түгел, оек та юк. Бу кеше ерак һәм куркынычлы юл узган булырга кирәк. Аның ялан аягы бик нык яраланган, чиләнеп беткән, өстенә кигән күлмәге дә әллә ничә урыннан ертылган. Башында яхшы эшләпә, бер кулында — шырпы, икенче кулында — күкрәгенә кысылган хәлдә картина, искиткеч картина. Аны күрүгә күзәтчеләр хәйран калдылар: ике катлы җыйнак йорт ут эчендә, үрелә-үрелә җәелгән ялкын уртасында: «Укыгыз, күрегез!»— дигәндәй, кычкырып торган сүзләр — «Бала табу йорты». Алтын хәрефләр белән язылган бу сүзләр йөрәккә үк барып керәләр. Алар ялкыннан да көчлеләр. Юк, алай түгел, ялкын үзе «бала» сүзеннән курыккан, оялган сыман читкә үрелә. Югарыда — шул дәһшәтнең хуҗасы — кара свастикалы бомбардировщик очып йөри. Түбәндә ишелеп төшкән стеналар һәм алар астына кысылган ак күлмәкле хатын. Аның кулында яңа туган бала. Шәфкатьле ана, янгыннан һәм җәрәхәтләнүдән саклар өчен, баланы алга сузган. Бала илереп елый. Күлмәгенә ут капкан, гәүдәсе кысылган ана әрнеп-әрнеп нәрсәдер кычкыра. Картина астында өч сүз — ана кычкырган сүзләр булырга кирәк:

— Гитлерга мең нәләт!

Күзәтчеләр картинадан күзләрен ала алмыйча бик озак карап тордылар. Ярым үлек хәлдә яткан юл кешесен алар штабка алып киттеләр. Гаҗәп кешене анда бик тиз таныдылар. Өч-дүрт партизан берьюлы:

— Латис, атаклы Макс Латис бу! — дип кычкырдылар һәм аңа ашыгыч ярдәм күрсәтергә керештеләр.

Рәссам аякка тиз басты. Отрядта врач белән шәфкать туташлары да бар иде — алар аның яраларын дәваладылар.

Латисның отрядта калырга теләве партизаннарда горурлык тудырды. Үткен күзле рәссам атарга өйрәнде һәм озакламый яхшы пулеметчы булып шөһрәт казанды. Төннәрнең берсендә ул отряд белән бергә шәһәргә налет ясады. Көтелмәгән бу һөҗүмнән дошман бик нык киселде. Урамнар немец солдатларының җыеп бетергесез санда үле гәүдәләре белән капланды. Хурланган кызлар, җәзаланган балалар, кабергә тереләй күмелгән картлар өчен үч алуга Латис шат иде.

Бөек иҗат һичкайчан югалмый. «Гитлерга мең нәләт» картинасы турында газета-журналларда мәкаләләр чыкты. Картина Мәскәүгә җиткәч, аны карар өчен меннәрчә халык күргәзмәгә агылды.

Рәссамның, партизаннар белән бер сафта торып, дошманга каршы көрәш алып баруы бөтен дөньяга таралды. Аның исеменә газеталарда котлау телеграммалары басылды, радио аша сәлам хатлары укылды. Соңгы хатта түбәндәге сүзләр бар иде:

«Сөеклебез Макс!

Синең исән-сау булуың һәм сугыш кырында батырларча көрәш алып баруың безне чиксез дәрәҗәдә шатландырды. Без Н. шәһәрендә урнаштык. Өйдән алып чыккан картиналарыңны хөкүмәткә тапшырдык. Халык аларны бик ярата. «Гитлерга мең нәләт» исемле картинаңны безнең дә, мондагы халыкның да бик күрәсе килә. Изге эшеңдә уңышлык телибез. Көннәрең бәхетле узсыннар. Сәламебез сиңа бетмәс көч бирсен. Дошман җиңелер һәм без янадан туган калабызга кайтырбыз.

Үбеп: хатының һәм балаң».

*1941*



Айдар
Хәлим

# ХИКӘЯЛӘР

## Гобәйдулла үрдәкләре

*Уфа Татар милли хәрәкәтенең күренекле вәкиле Мәсгуть ага Салихов истәлегенә*

Аны, гадәттәгечә, чыелдау тавышы уятты. Кесә телефонының уч төбедәй кечкенә экраны, йөзне яктыртып, иртәнге дүрт сәгать утыз ике минутны күрсәтә иде. Йә, рабби! Әле нәкъ ярты сәгать вакыт бар икән. Утыз минут! Мең сигез йөз секунд. Кадерен белсәң, гасырга тиң бәракәт бит бу!.. Янәшәсендәге Сәрбикамалы да уянды, әмма урын өстеннән ире аша атлап төшәргә кыймады, күкрәген юрган чите белән каплаган хәлендә тыелып калды һәм Гобәйдулласының төшкәнен көтте.

Картка сиксән ике яшь инде. Әмма, Ходайга шөкер, әлегә сау-сәламәт, таза, буыннарын шыгырдатмый-нитми, яшьләрчә житез кузгала. Һичкайчан ашыкмый, ашыкканнарны да жене сөйми. Шуңа да һәр гамәлне жиренә житкереп, кем әйтмешли, келтемпиен келтемпигә туры китереп, кемгәдер юк кына күренгән нәрсәдән дә таудай тәм, ләззәт табып эшләргә ярата. Менә әле дә идәндәге чүәкләрен кәмпүтер төгәллегендә аяк очлары белән эзләп табып, жәһәт кенә урыныннан шуып төште, капшана-капшана алгы якка чыкты, черт итеп сукыр лампа булып хезмәт иткән кечкенә көчәнешле электр утын кабызды. Ике тәрәзәгә караңгыдан буылып кышкы таң сарысы саркылды. Ихатасындагы сөт куесы сыман якты бәс сарган өянкеләр, башка жиләк-жимеш агачлары аңа иман садакасы сорап килгән ак сыннар булып күренде. Бәрәкалла!

Әйе, аның һәр адымы төгәл уйланылган, бер хәрәкәте белән икенче хәрәкәте арасындагы вакыты һәркайсы елларга тиң минут-секундларга салынган иде. Бисмилласын әйтеп, өстәл өстендәге чәчкәле пыяланың капкачын ачты, тулыр-тулмастан ике генә кашык катык капкандай итте. Катык ачый төшкән иде. Монда да әтнәкесе бар: ачый гына башлаган катык ашказаны бизләрен эшләтеп жибәрә ул.

Эчке ыштаныннан килеш юынгыч янына килде, битен-башын, беләкләрен чылатты, шундый ук тәфсиллек белән эһ кенә иткән аваз

---

Айдар ХӘЛИМ (1942) — *шагыйрь, прозаик, публицист, җәмәгать эшлеклесе; татар, башкорт, рус телләрендәге күпсанлы китаплар («Тилергән сирень», «Татар вакыты», «Талант. Шәхес. Шагыйрь» һ.б.) авторы. Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге премиясе лауреаты. Чаллыда яши.*

чыгарып, аякларын юынгыч тагарагына күтәреп куйды, балтырларын, аякларын тәһарәтләндерде. Урындык башында торган чалбарын-күлмәген, жинсез сырмасын киде, чалбар балакларын күтәреп, тезләре өшемәсен өчен эчке ыштаны өстеннән кәҗә бәрәне тиресеннән ясалган куныч башларын, мамык оекбашларын киде. Балакларын төшерде, җайсыз түгелме дигәндәй бер-ике адым атлап карады. Нидер шыгырдагандай итте — идән ул, буыннары түгел. Дивардагы сәгатькә күз ташлады. Бер минут — алтмыш секунд үткән дә иде. Бар, кире кайтарып кара син аны, вакыт дигән нәрсәне. Инде монысын башкарырга да чират җиткәндер. Өстәл янына килде, эчтәрәк торган савыттан янәшәдәге касәгә зәңгәрсу төстәге андыз суын салып, йотыштырды. Бу гамәлдән соң чеметем генә утырып тору зарур. Андыз — карт тән-җан өчен үтереп кенәләр дә шифалы чимал. Анарда яшьлек сихәте бар. Ел саен капчык-капчык җыя ул аны. Тамырларын киптерә, тураклап, ваклый. Аны урыслар «девясил» дип йөртә, имеш, «девять сил»дан алынган ди. Юк, кая ди ул. Һәрвакыттагыча, урыс аны бездән үзләштергән инде. Безнең «дәвачы» дигәннән алынган. Дәвачы үлән. Мәгънәле бит!.. Шифалы тамыр, ягъни мәсәлән. Геродотта да бар ди бу хакта. Анарда тугыз гына түгел — туксан тугыз шифа!.. Тагын сәгатькә күз ташлады. Янә дә бер минут үткән. Инде ашказанын майларга да вакыт җиткәндер. Хатыны мөдирлек иткән газ плитәсе янәшәсендәге өстәл янына килеп авызы капланган икенче савытны ачты, аннан соргылт төстәге сыеклыкны икенче бер касәгә койды һәм тәмләп кенә йотыштырды. Солы суы була монысы. Гобәйдулла аны ашказаны мае дип атый. Озак яшисең, яшеннән соңлабрак картаясың килсә, ашказаныңны, эчәгеләреңне тәрбиялә. Майла. Чистарт. Озаклап, җиренә җиткереп чәйнәп аша. Үнәчеңә дә, карыныңа да көч китермә.

Ул сукыр утын сүндерми калдырып борау, винт бормалары шикелле боргаланып төшкән баскыч буйлап аска, йортының беренче катына төшә башлады. Сүндереп азапланмый, ни өчен дигәндә, менә хәзер секунд эчендә йокы бүлмәсеннән Сәрбикамалы чыгып, савыт-сабаларны шалтырата башлаячак.

Әйе, йортының бормалы текә баскычы кебек, Гобәйдулланың язмышы да ай-һай бормалы булды. Анасы бик яшьли үлеп калган. Үги ана тәрбиясендә үсте. Какмады-сукмады, рәхмәт төшкере. Вакыты җиткәч, ул үзе дә өйләнде, өч баласы булды, шөкер. Атасы вафатыннан соң үги анасы зәхмәт сугып урын өстенә ятты һәм бүтән тормады. Ашавы да, башкасы да шул урын өстендә булды. Аһ, нинди түзем сорый иде мондый азагы-чиге күренмәгән газаплар!.. Егерме биш ел яшәгән хатыны аналарын тәрбияләүдән баш тартты һәм, бу хакта бер-ике тапкыр каты гына итеп сүзгә килгәннән соң, ике бөлигъ булмаган баласын алып, китте дә барды. Татар-мөселманда күрелгән хәлме? Аһ, ничек кенәләр үзгәртте дөньяны, дөньясы белән кешене, аеруча хатын-кыз дигәнеңне бу сәвит власте!.. Пролетар дуслык дигән булып урыс-улакка әйләндек тә куйдык. Хатынының мондый пырдымсызлыгын Гобәйдулла һич кенә дә аңлата алмады. Зиһене җитмәде. Аптырагач, яна замана бозган хатын-кызның мондый кыйланмышларын, шаяртып, «Безне мәхәббәт кавыштырды, «любоф кына аерды», дип аңлата торган булып китте. Биш ел буе үзе карады ул үги анасын. Күгәрчен баласы кебек, кулыннан ашатты-эчертте. Күтәреп барып, күтәреп кайтып, мунчаларына кадәр кертте. Әмма ир-атка гарип ананы үз кулларын белән госелле итү җинел эш түгел шул. Кемнәрне генә соратып карамады хатынлыкка Гобәйдулла. Әмма бу мәхшәргә килергә беркем дә атлыгып тормады. Хәзерге заманның гаиләсеннән өч тиенлек бизнесын артыграк күргән хатын-кызлары өйдә гарип үги ана барлыгын гына белеп алдылар да,

тәртәләрен кирегә бора торган булдылар. Ә менә Баулы кызы Сәрбикамал, әйе, һич арттырмыйча әйтә, кияүгә чыкмый сакланган кырык яшьлек кыз, насыйп иткән киявеннән утыз яшькә яшьрәк булуына карамастан, озак уйлап тормады — аның консервы калае кебек калтырап торган «Ока»сына калтыранмый-нитми керде дә утырды. Тагын да биш ел анаһы инде яшь килен карады. Ыһ дип тә авыр сүз әйтмәде ул аналарына. Шунысына шөкерана кылдылар — ун елдан артык урынында яткан аналары бакыйга аларга рәхмәтле булып китеп барды.

Ә-ә-әй, онытып тора икән Гобәйдулла: әле анасы исән чакта ук тагын бер көтелмәгән вакыйга булды бит. Үзе белән өлкән улы да төнге эсминәдә чакта йортларына ут төрттеләр. Күрәсең, алар эштә чакны көтеп кенә очырылган кызыл әтәч йорттан торынбашларны гына калдырды. Булган аз-маз акчалары, дукәмәтләре дә янгында көл булды. Ярый әле Сәрбикамалы яланөс килеш, юрганы-ние белән аналарын уттан алып чыккан!.. Шул көннәрдә үк халыкта утны аны ташлап киткән һәм ниндидер Гавриил белән иснәшә башлаган хатынының яна килгәненнән көнләшеп һәм, имеш, Гобәйдулладан үч алып төрткән икән дигән сүз таралды. Кулыннан тотмагач, нәрсә әйтәсең? Шулайдыр да, бәлки. Шул көнне, шул сәгатьтә Гобәйдулла Ходай Тәгалә каршында иманга килде — намазга басарга, Сәрбикамалын өрмәгән җиргә утыртмый хөрмәтләргә, булдыра алганча бәхетле итәргә ант итте. Чынлап та бәхетле бугай ул. Бәхетле булмаса, адәм баласы шундый нурлы итеп елмая, иренә һәм күрше-күләнгә шул кадәр хөрмәт күрсәтә аламы? Ничә карама, авыз читендә елмаю чокыры. Сәрбикамал — Гобәйдулласын, Гобәйдулла Сәрбикамалын күзенә карап аңлый. Дөрес, балалары булмады. Гобәйдулласының ата булу чоры узганлыгын яхшы аңлаган Сәрбикамал бала табам дип артык колак итен ашамады.

Алар кайвакытта намазларын, форсатына карап, бергә, кайвакытта аерым укыйлар. Әмма багышлаулары бер һәм бердәм: и, Ходай, бәрәкәтле тормыш, озын, иманлы гомер бир!.. Сәрбикамал ифрат та хуҗалыкчыл җан булып чыкты. Аның кар базындагы тозланган, пешектерелгән яшелчә, салат-мазар, җимеш сулары тутырылган тар бугазлы һәм киң карынлы пыяла савытлары, приказ көткән солдатлар кебек, айт дигәнгә тайт итеп сикереп чыгарга гына торалар. Камыр ашлары турында әйтәсе дә юк: әче-төче коймак, онлаган коймак, тары тәбикмәге, мулла беләге дисеңме, тутырган тавык, какланган каз дисеңме... Ул пешергән аш-суларның хуш исләре янәшәләрендә генә аккан инеш үзәне буйлап килә дә, мин сина әйтим, барлык Бөгелмә-Бәләбәй калкулыкларын сугара. Гобәйдулла елына ике-өч ай аша биш-алты тапкыр елкы малы чала, карын маена ит тә кушып, Сәрбикамалы белән икәүләп «Зиләйлүк»не көйли-көйли казылык тутыра. Хатын ирен, ире хатынын якын итмәсә, шулай күнел биреп эшләп буламы?! Юк, әлбәттә!.. Аларның әлеге мәһабәт йорт-ихатасы урынында җимерек келәт кенә иде. Янгыннан йортсыз-җирсез калган көнендә үк сатып алды аны Гобәйдулла. Һәм көнендә үк төзи дә башлады. Үзе бураткан дүртпочмаклы бурасын алтыпочмаклы итеп кинәйтте, аннан ике катлы итеп үстерде, аннан шул ике катны әле менә үзе төшә башлаган бормалы винт кебек баскыч белән тоташтырды. Менә әле дә чегән бароны кебек кара сакал-мыеклы, Пушкин кебек кара бөдрә янаклы абзагыз шул караңгы винтның бормаларындаборгалана-боргалана кара борау, юк, дөрес түгел, кара башлы агач корты кебек, йортының беренче катына килеп тә чыкты. Аның бөдрәләренең шомырт каралыгы хак. Халыкта аны юкка гына «чечен» дип йөртмиләр. Монысы да, ягъни чеченлеге дә хак. Аның үзеннән башлап артка чигенгәндә җиденче ерак бабасы Галирахман урыс әрмесендә егерме биш ел хезмәт итеп, Кафтауда имам Шамил алып барган азатлык яуларында катнашкан. Урыс ягыннан, кәнишне. Нишләтәсең,

татар язмышы!.. Грнадир бабасының, күрәсең, күзе һәрдаим ачык булган, татарларга хас яхшы хезмәт иткән, Высакаблгаруди янарал аңа чечен кызы Сәйдә белән мөселманча никах укытырга һәм туган якларына кайтып, жир алып төпләнергә рөхсәт иткән. Бөгелмә калкулыгы буйлап көнчыгыштан көнбатышка карап аккан Бөгелмә инеше буендагы уймак кебек утарларында Галирахманнан туган Сафарахман, Сафарахманнан туган Сабиррахман һәм тагын да өч буын Рахманнарның дәвамлы кан тибеше бит ул тереләрдән дә тере Гобәйдулла хәзрәтебез...

Беренче каттагы утын кабызмый гына янәшәдәге янкормадан таштай авыр башмакларын өстерәп чыгарды, мышный-мышный аларның төн ката суынган эченә мамык оеклы түмәрдәй аякларын тыкты. Бауларын бәйләп тә тормаганга күрә, башмакларының телләре олы әрекмән яфраклары кебек тышка чыгып калды. Шул ук янкормада капшанып, итек мае савытын, ышкысын эзләп тапты, борып ачты һәм майны итек йөзләренә кызганмыйча сылап, парадка баргандай тырышлык белән ышкылый, аннан кара бәрхет белән ялтырата башлады. Тирәсендә караңгы булып та, тәрәзәләрдән саркылган таң сарысының саран яктысында күзгә кебек шомарган итек йөзләрендә үз йөзе чагыла башлагач кына ышкудан туктап, тышкы ишегенең авыр келәсен ачты һәм бисмилласын әйтеп, тышка чыкты. Аны ап-ак кар исе аңкыган саф һава, азат иркенлек каршылады. Биредә таң сарысы офыкларга саркылып зәңгәрләнә һәм куера иде. Йорт почмагында көтеп торган таягын үрелеп алганда таякның карны эретеп бозга каткан уклы очы шартлап урыныннан купты. Сәгате әле егерме минуты барлыгын күрсәтә иде. Йорт белән абзарны берләштергән япма астында буявын салган шпрот консервысы сымак ямьшек «Ока» машинасын «Әссәламегаләйкем!» дип, калаеннан сыйпап сәламләде, Сәрбикамалы утырып килгәнгәме, шушы калай машина кисәге ана гел генә нур чәчеп торган кебек. Ул капкасының йозагын өч тапкыр борып ачты да, урамга бүселеп чыкты.

Аны үрдә, ап-ак бәс эчендә оеп калган иң биек агач башларыннан да югарыдарак үрдәге мәчет манарасы, инде шул манараның дүрт кырлы хәнҗәре очында нурланган ярымай һәм шушында, якында, култык төбендә генә челтерәп аккан инеш тавышы каршылады. Инеш тә, мәчет тә, манара да, ярымай да, шөкер, исән-саулар икән. Әлегә урлап та, талап та китмәгәннәр. Ихатасына терәлеп кенә торган бу мәчетне Гобәйдулла үзе төзеде. Әүвәлдә мәхәлләсендә берьялгызы намаз укыса, аннан өчәү, аннан —сигез, аннан — егерме ике булсалар, хәзер инде иртәнге намазга бишалты, башка намазларга — ун-унбиш, жомга намазына кайбер очракларда ике йөзләп мөселман йөри. Менә бит вакытында башкарылган иманлы гамәл нинди бәрәкәт китерә!.. Атлаган саен коры карларны таягының очлы угы белән бер тапкыр чыелдатып, шул ук карларны табаннары астында икенче тапкыр шыгырдатып, башмакларының һаман да шул сыер телләрен жилләрдә жилфердәтә-жилфердәтә Гобәйдулла үз мәчетенә таба атлады. Чиү! Шыгыр-шыгыр! Чиү! Шыгыр-шыгыр. Үз мәчете шул. Булмыйча ди тагын! Ул ирексездән елмаеп куйды. Әнә теге ихластан да дүрт кырлы көмеш хәнҗәргә охшаган манарага ярымай куйганда кран угының корыч арканы чәбәләнеп калды. Һич кенә дә ычкындыра алмадылар. Гобәйдулла озак уйлап тормады, оегын салып ташлады да, яланаяклап кранның угы буйлап кырык метрлык манараның хәнҗәр кыры буйлап очына үрмәләде. Астан караганда көмеш хәнҗәр аның үз гәүдәсе аша үткән кебек иде. Ычкындырды ул арканны. Һәрнинди биеклек һәм бөеклек ихласларны ярата шул. Ихласка ил куанган. Ихласлык үзе дә биеклеккә тиң. Шуна күрә намаз ихласлыкны беренчел шарт итеп куя. Ул галәм кебек чиксез. Шуна

күрә һәркемнең үз ихласлык үлчәме бар. Берәүнең ихласлыгының чиге — икенченең ихласлык башы гына. Кайвакыт шул ихласлыкның башламын ук гамәлсез чынбарлык боза. Җимерә. Мондый чакта «шайтан котырта» диләр. Котырта, күңелең тыныч, һаман да шул ихлас булмаса. Мондый очраклар Гобәйдуллада да булгалады. Әмма намазын калдырмады һәм, Аллага шөкер, калдырмый. Шартларыннан чыгып, намаз шәрифләрен басып та, утырып та, — күңеленнән — яткан, бөгелгән, хәтта һавадан сикергән халәттә дә башкарды. Кабул гына итә күрсен. Сикергән халәттә дигәне дә хак. Менә шундый саф ихласлыкка ия булу, Аллаһы Тәгалә барлыкка китергән тереклекне биектән күрергә теләү тойгысы аны җитмешкә җитеп барган көннәрендә иннәренә парашют кидереп җиде кат күкләргә күтәрде. Әйе, Аллаһтан башка беркем һәм бернәрсә турында да уйлый алмый торган халәтне эзләде ул Җир йөзендә. Таба алмады кебек. Шайтаны котыртса-котыртмаса да, канәгате канмады кебек. Мондый халәт Җир белән Күк арасында асылынып торган халәттә генә бардыр кебек тоелды аңа. Тугыз тапкыр сикерде ул парашютта. Башта бер, аннан ике, аннан өч мең метрдан. Һәм үзе эзләгән халәтне тапкандай булды. Ул, арыслан йөрәкле, акбарыс чыдамлыгына ия ир-узаман, бер чакрымнан сикергәндә «Лә иләһа иллаллаһ!» кәлимәсен бер, ике мең метрдан сикергәндә — ике, өч мең метрдан сикергәндә өч тапкыр әйтергә өлгерде. Рәхәт!.. Син зәңгәр күкләргә колач салгансың, ә үзең Аллаһ хозурында... Инде киләсесендә иң кыска «Гасыр» сүрәсен укырга өлгерермен дип унынчы кат сикеререргә уйлаган иде, табиб-инструктор, елмаеп, «Бабай, йөрмә давай, сиңа тугызы да бик җиткән, җиргә төшеп әбиңне кара!» — дип, аның нәфсесенә чик куйды. Тазалыгы Аллага шөкер кебек, әбисе дә янында кеткелдәп кенә йөри. Әмма меңгезмәделәр аны башкача күккә. Аларның да үз ихласлыклары бар икән. Саулыгы өчен курыктылар бугай...

Ул коры карны табан астында һәм таягының уктай очында сайратып, челтерәп аккан авазларга таба китте. Мең еллар чамасы элек бирелә Бөгелмә дигән матурлардан-матур татар авылын нигезләргә сәбәпче булган ул мәңге туңмый торган Бөгелмә чишмәсе. Урыслар аны «Бугульминка» дип очсыз кушымча өстәп кенә үзләренеке итмәкче булганнар. Бар, кушарсың татарны урыска кушымча белән генә. Бугульминка дигән урыс елгасы булуы мөмкинме?! Кемнәрнеңдер расларга тырышуынча, мең еллык шәһәрне нәкъ биш йөз елдан соң басып алган баскынчылар гына нигезләгән, имеш. Анысы Бөгелмә түгел, Бугульма дип атала икән. Урыста шундый да «бугульмалы» шәһәр була аламы?! Әгәр Татарстан Бөгелмәсен саклый алмаса, аның исемен ватмый мәңгегә дөрес саклау өчен вакытлыча гына булса да халыкара банкларга салып торырга кирәктер, бәлки? Рәсәй Бөтендөнья Сәүдә Оешмасына сугым малы кебек сөйрәп кертелгәч саклап булырмы бу исемне?! Ә менә милләтләргә килгәндә, ул алар хәтеренең иң биек җирендә саклана. Шуңа да Бөтендөнья картасында Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгы дип атала бу төбәк. Татар-мөселманның атаклы Чыршылы, Тайсуган, Эстәрлебаш мәдрәсәләре эшләгән, Риза казый Фәхреддин, Мифтахетдин Акмулла, Гариф Гомәр кебек галим-язучыларыннан башлап бүгенге Бәләбәйнең татар гимназиясе директоры, атаклы педагог Нурмөхәммәт Хөсәеновларына кадәр үстергән ул. Татар миллиятенең иң укымышлы ноктәсе. Әйе, ноктасы түгел, дөнья күзенә кереп торган ноктәсе. Юкка гына шушы ноктәне саклау өчен утызынчы елларда Һади Атласиның һәм аның кебек дистәләгән акыл ияләренең башлары бүкәннән тәгәрәмәгән. Бөгелмә!.. Аһ, Бөгелмә җаный!.. Шушы биеклектәге мәчетенең хәнҗәр кырларын бөгелә-бөгелә агып кайраган Бөгелмә-сукай!.. Ана, бәлки, миллион ел бардыр. Бәлки, дистә миллион еллардыр. Нигә көләсез? Менә

бу өянкеләрнең һәр яфрагына миллион еллар. Ә менә аңа, азан әйтү өчен, унбиш кенә минут калган!..

Ул кабаланып инеш ярына килде һәм, үзе түшәп ясаган үркәчкә басып, сак кына эндәште:

— Кил-кил-кил!.. Кил-кил-кил!..

Ул гүя иркен тугайларда чабулап йөргән колыннарына«гөл-гөл!» дип чакыру салды.

Юк. Алай түгел. «Кил-кил!» дип ул шушы Бөгелмә инеше ярларының куышлары астында кыш чыккан үрдәкләрне чакыра. Юк, алар йорт үрдәкләре түгел. Үрдәк үрчетүче йортлар юк хәзер. Кыр үрдәкләре алар. Алар исән. Әнә, әле китеп өлгермәгән таң сарысының җимерелеп өскә килгән көн яктысы белән кушылуыннан кыска гына мизгелгә бар булган караңгылыкны ертып, суларның көмеш көзгесендә кайтарыла-кайтарыла үзенә таба йөзеп килгән үрдәкләрен куандырырга ашыкты:

— Кил-кил-кил!..

Үрдәкләр унлап иде. Су салкынын сизепме, Гобәйдулланың температурасы күтәрелгәндәй булды. Үрдәкләрнең нәсел тамыры гамәл дәфтәрендә миллион елдан исәпләнәдер. Гобәйдулла шул гомерне бер генә көнгә булса да озайту өчен бак-бакларны көн саен, кабат-кабат ашата. Үрдәкләр бак-бак дип кычкырмый. Алар Гобәйдуланың үзе кебек тыйнак. Өйрәнгәннәр. «Кил-кил!» дип аваз салуы була, киләләр дә житәләр. Башмаклары белән лашпырдап, Гобәйдулла тиз генә капкасы аша үтте һәм кечкенә полиэтилен токчайда Сәрбикамалы суын кайнатып эчерә торган солысын алып чыкты. Алтын да алтын, бу да алтын. Пешкән солы. Кил-кил-кил!.. Гобәйдулла көмештәй куерып, ничектер шуышып аккан агымсуларга учлап сары алтын сибә башлады. Көмеш бөртекләр, үз артларыннан кибәк-кабык калдырып, су өстендә өерелә, аннан сайланып кына төпкә бата башладылар. Буш кабыкка алданмаган үрдәкләр салкын суга чумып бөртек чүпләргә дә ашыкмадылар, гүя алар болай да рәхмәтле Гобәйдуллаларының янә дә рәхимлек күрсәтеп, үзләрен ялгыз калдыруын үтенә иделәр. Температурасы төшкән Гобәйдулла исә, шуны аңлагандай, тешләре арасыннан:

— Ашарсыз, нибуч... — дип ике генә кәлимә сытып чыгарды да мәчет ихатасына керде. Биредәге кар аяк астында сайрамый, чөнки карларны мәчет каравылчысы Сөләйман инде таңның үзеннән иртәрәк уянып, тунга кадәр көрәп куйган иде. Кызык зат ул Сөләйман. Әле кичә генә сөйләп торды. Мәчеткә бер шикле мосафир кереп, «Сез, Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгы татарлары, берегез дә татар түгел, сез Мең башкортлары буласыз» дип коткы таратып, ниндидер кәгазьләр калдырырга булгач, ул бу сәер кәгазьләрне тегенең кесәсенә кире тыккан һәм «Син, энем, исән чагыңда моннан ычкын... Үзеннен тирмәнә кайткач, син татар, урыс, чуаш, марины сепаратка салып аерттыр да, шулардан башкорт килеп чыкса, мин дә башкорт языылырмын» дип колагына пышылдаган. Һәм теге ут капкандай чыгып та йөгергән...

Эчтә аны Сөләйман үзе каршылады.

— Әссәламегаләйкем, мөәзин абзый!..

Каравылчыда йокының әсәре дә юк иде. Мөәзин белән кул кушырып күреште. Бүтән бер сүз дә ишетелмәде. Димәк, барысы да тәртиптә. Шикле кәгазьләр таратып дөнья болгатучылар булмаган. Мөәзин абзый өстен, башмакларын салып икенче катка күтәрелгәндә сәгатенә күз ташлады. Әле өч минуты калган иде. Миһрабның ике канатында дүрт мөселман кардәше мәчет намазы укып маташа. Хуш. Миһраб каршына басып ул да үз бурычын үтәде. Шул арада, шөкер, тагын да ике мөселман өстәлгән

икән. Миһраб каршына килде, микрофонның ябен япькә тыкты һәм уч төпләрен кыйблага каратып колак яфракларына терәде азанның да беренче авазларын яңгыратты:

— Аллаһы әкбәр!.. Аллаһы әкбәр!..

Нинди сөенеч: аларның Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгының иң биек җирендә иман нуры белән яктырган, чиста итеп юылган, тузаны сөртелгән, идәннәренә ямь-яшел келәмнәр җәелгән, уч төбе кебек җылы үз мәчетләре бар. Азанын әйтеп бетергәндә алар инде җидәү иде. Иртәнге азаннан соң мәчеткә ашыккан инсаннар килеп җитсен дип намазга кадәр ул гадәттә унбиш минут вакыт бирә. Бу арада алар барысы беррәттән Коръәннәрен кулга алып, аятьләр укыштыралар. Офыклар тагын да яктыра. Тормышның гомер буе ачылып бетмәгән мәгънәсе янә дә ачылгандай итә. Менә намаз вакыты да кергән икән. Гобәйдулла хәзрәт имамлыгында инде уникәү булып өлгергән мөселманнар иртәнге намазны башкарырга тотындылар. Бу бәрәкәттән гүя мәчет эче тулган, шайтанга түгел, хак мөселманнарга да басып торырлык урын калмаган иде.

Намазны багышлап тәмамлаганда алар барысы бергә, барысы бердәм һәм барысы да бәхетле иде. Түшәмнән асылынып төшкән шәмдәлләр бу куанычтан тагын да яктыра төшкән кебек күренделәр.

Алар бер-берсе белән күрешеп чыктылар һәм тавыш-тынсыз гына беренче катка төшеп, һәркайсы үз юллары белән йортлары тарафларына таралыштылар. Аларны иң биек җирдә төзелгән мәчетнең хәнҗәргә охшаган манарасының ярымае озатып калды.

Ничә ел үтте икән Гобәйдулла мөәзиннең бу манара очын корыч арканнан арындырганына? Аһ, егерме ел! Бөгелмә инеше кебек ага да ага бу еллар дигәнең!...

Мәчет ихатасыннан чыккач аны янә шул сөттәй ак бәстә өеган өянкеләр каршы алды. Алар гүя Гарәбстаннан Коръән күтәреп килгән илче Ибн Фадланнар иде. Нинди хикмәт!.. Шул хаҗ ихрамы кигән өянкеләр озатуында ул тагын да үрдәкләре янына килде. Һәм инешкә карады. Су төбендә бер генә алтын солы бөртеге дә калмаган иде. Әгәр бу җан ияләре Гобәйдулла сипкән ризыктан разый булсалар, аның чакыруына җавап бирми каядыр югалалар, әгәр туймаган булсалар, янә дә килеп җитәләр.

— Кил-кил-кил! Кил-кил-кил!...— дип чакырды ул кыр үрдәкләрен.

Каяндыр кар каплаган яр һәм өянке тамырлары асларыннан пылт итеп чыккан үрдәкләр аңа таба йөзә башладылар.

—Аһ, наяннар! Житмәдемени? Хәзер, хәзер!..

Әллә авазлардан, әллә нәзберек җилдән тибрәнгән ботаклардан үрдәкләр өстенә бәс коелгандай итте. Ул Ходайда һәм үзендә исәптә торган кош-кортына өстәмә азык — пешкән солы алып чыгу өчен башмакларының һаман да шул әрекмән яфрагы кебек салынып тышка чыккан телләрен җилләрдә җилфердәтә-җилфердәтә капкасына таба юнәлде...

## Төпсәле йолдызлар

*Каләмдәшем Мөхәммәт*
*Мәһдиев истәлегенә*

Җәйнең язгы чәчүдән соң, печәнгә төшеп өлгермәгән аралыгында була торган гаҗәеп кыска, иркен бер мизгеле иде. Көтмәгәндә безгә, совхозларының ифрат та арык ат ишарәтен җигеп, Зәйпәкүлдән бабабыз килде. Мина, әле балалыктан чыкмаган сабыйга, тыштан шактый кырыс күренгән бу картның нинди йомыш белән кисәк кенә килеп төшүе аңлашылмый да, хәер, миңа моны белү кирәкми дә иде. Минем өчен иң

зур куаныч шул иде: инәй сөйләвенчә, утызынчы еллар башында унлаган баш атыбыз оешып кына килгән күмәк хуҗалыкка тартып алынганнан соң инде ничәмә еллар елкы малы күрмәгән ихатабызга елкы керде!..

— Иптәш тондыральный дирихтыр[1] үзе биргәч, жиктем инде... — диде ул ат турында сүз чыккач. — Сикертми генә апкилде бит әле. Ходай кушса, сикертми генә апкайтыр да...

Бабабызның озын юлдан соң да, минем уйлавымча, болай кансыз кыйланып, атын тугармый-нитми, камытын да салдырмыйча, аркалыгын гына бераз бушата төшеп, алдына арбасыннан бер кочак яшел үлән салып кайнар кояшта калдыруы минем өчен сер иде, әлбәттә. Сүзен кешегә карамыйча, ничектер оялгандай итеп, күзен яшереп сөйләве дә сер иде. Нигә ул атын абзар күләгәсендәге аранга кертмәде? Ашыга идеме? Ашыкса, ни өчен болай ашыга иде? Атның җәфалы сәфәрдән пыялаланып тонган күзләрен коя-коя печән жентекләвен, мышный-мышный тын алганын күзәтеп торганым әле дә хәтердә.

Кышлау умарта кебек таза гәүдәле бабабызның гадәттән тыш җитди кыяфәттә тирән фикер төенендә бикләнгәнлеге һәм сәфәре өчен кунып китәрлек кичне түгел, кызу көн уртасын сайлап, шундук кайтыр юлга чыгарга ниятләнүе аның һич кенә дә тәгаен Минсорур балдызына гына кунакка килмәвен сиздерә иде...

Зәйпәкүл — бездән утыз чакрымнар чамасында яткан авыл. Моннан ике ел элек без инәй белән анда кунакта да булган идек. Зәйпәкүлнең Зәйпәсе бар, тик күле юк икән. Анда сыерчык оясы кебек кечкенә йортлар, тирәсенә ауган-шуган читәннәр. Хәтта пумала башлы зәңгәр шайтан таяклары да анда чәчкә урынында йөри. Шыр дала, кисеп аударып, кая ди утынга, чыра теләрлек тә агач тапмассың, юк. Мичләренә салам, кирпеч сыман сугып киптерелгән тизәк ягалар. Янәшәләрендә Блюменталь дигән авыл. Нимесләр. Блюменталь нимесчә чәчкә оясы дигәнне аңлата имеш. Менә кызык: үзләре нимес, үзләрен без җиңдек, ә үзләре безгә төкереп тә бирмичә, ут-күршебездә, ихластан да чәчкәләр арасындагы мундирлы солдат кебек ялтырап торган йорт-кураларда яшәп яталар. Кайбер елларда Ырымбур якларыннан безнең авыл аша Зәйпә тарафларына дөягә атланган ач казакълар кәрваны үтә.Казакълар башларына самавыр канфәркәсе кебек телле-телле башлык кигәннәр. Бу кәрваннар нишләптер кире әйләнеп кайтмыйлар. Блюменталь тарафларында тамаклары икмәккә туйгач, туган якларын оныталармы?

Зәйпәдә әтәебезнең шул Зәйпә егетенә тормышка чыгып, сыйнфый таланудан котылып калган бертуган апасы яши. Без, аны исемен бөтенләй онытып, «Зәйпә әби», киявен исә, ягъни мәсәлән, безгә килгән шушы җизни-бабабызны, ихластан да исемен белмәгәнгә, «Зәйпә бабай» дип кенә йөртәбез. Ул безгә, фронтта һәлак булган кайнешенең ятим балаларына, тыныч кына карый алмый. Күзе яшьләнә дә куя. Мин аның мулла кушкан исеменең Хәбибулла булуын, Зәйпәдә «Каты Кул Хабул», шуна өстәп ни өчендер «Шаблай Хабулласы» дигән кушамат йөрткәнен, әбиебезнең исеме Минеямал булганлыгын соңыннан гына беләчәкмен. Ул заманнарда гореф-гадәт алтын бәрабәренә тигез, кеше исеме-кушаматы исә паспортның үзеннән дә мәгънәлерәк һәм тәэсирлерәк иде шул!..

Инәй кисәк кенә килеп төшкән Зәйпә бабайга самавырын чыжлатып җибәрде. Җәмәгате туып-үскән «кулак хуҗалыгы»ннан исән калган бердәнбер байлык — самавырның корсагына икешәр рәт итеп «Самоварная фабрика братьев Баташевых» дигән мидәл[2]ләр сугылган. Инәй аны барынча

[1] Тондыральный дирихтыр *(гади)* — Утызынчы елларда оешкан кайбер бик мөһим совхоз җитәкчеләренә «генеральный директор» дигән исем бирелгәләгән булган.
[2] «Бертуган Баташевларның самавыр фабрикасы» дип язылган медальләр.

кыстый-кыстый чәй эчерде һәм, ахры, бик озак уйланганнан соң, тартынып кына, жизнәсе каты бәрелмәс микән дип шөлләп[3], жаен-унаен сайлап-сыйпап, чак кына ишетелерлек аһән белән гозерен әйтеп салды:

— Жизни... Ягарга утын...атың белән... Якындагы Яшел Түбә урманына... коры-сарыга барып килергә рөхсәт итмәссен микән дигәнием...

Өйдә тынлык урнашты. Бабайның жир сөрә торган агач сука шикелле гади, бик тә анлаешлы һәм кискен якты чырае буйлап күләгә үтте, кинәт бу чырай күләгәсе тар чөй булып түбәнгә төшкән мөслимин сакалга күчеп тартышты. Аның йөзен яшен суккан, күзән жыергандай итте, карт, жан газабын сиздермәскә тырышып, эчтән сыкранды. Ниһаять бу жаныя сыкрау имчәк баласының кечтеки йодрыгыдай төергә әверелеп, өстән аска таба шуышты... Балдызына әйтелергә тиешле булып та, ошбу бала алдында әйтелмәскә тиешле нинди уйлар уйлап өлгергән иде икән ул шушы берничә секунд эчендә? Бүген кайтып житмәсәм, шушы ат өчен үземне чыгарып атмасалар да, гыйбрәт тактасына кадаклаячаклар, дип дөресен әйтергә тиеш булганмы? Үлеп арыган-алжыган малкай утынга барган жиреннән күтәрәмгә калып жан бирсә, нишләрмен? — диярге теләгәнме? Әллә аның матурлардан да матур тол инәсен берәр иргә кодаларга килгәнме? Каян беләсең?

Картның керфек очлары тагын да яшьләнде. Күзен челт-челт йомгалады.

— Утынга, дисең, балдыз... Ат кына бит әле менә... Ат дисәң ат, димәсәң, чыгар да ат... Күтәреп диярлек килдем... Һм, ярар... Булмаса, барып кайтырсыз... — диде ул авызыннан һәр сүзен санап кына чыгарып. — Сина кирәк булыр дип әле дә фурман жиккәнмен, ә? Житмәсә, кабыклыны. Мин сез кайтканчы утынлыкта чыбык-чабыкларыгызны тураштырырмын...

— И-и-и, жизни, маташма. Син ятып хәл ал!.. Чыбык-чабыкны аны минем улым да тураштыра... — дип кабынып киткән инәй кинәт монсуланды. —Безнең эше ятим-йолпы йортында балтасы да берәү генә бит әле аның...

— Ярар, алырсыз. Мин... йорт-тирәсенә күз-колак булып, абзар-ихаталарыгызны каккалаштырган-суккалаштырган булырмын... — диде карт, жирдән күзен алмыйча. — Жәһәтрәк булырга тырыш инде, балдыз. Кайтасым да бар...

Мин атны колаксыз бидрәбездән эчердем. Ул әлләни эчмәде дә. Аның да минем кебек умырып ашыйсы килә иде, күрәсең. Әмма, нишлисең, алдындагы яшелдән аерып, аны тагын юлга алып чыгалар иде. Без урыны-урыны белән язгы ябагасы иегеп бетмәгән кызгылт-коба алашаны борып, чалшаеп каткан урыс капкабыз аша чыктык та, урам буйлап килгәннән соң «Яшел Түбә» юлына төштек. Атны чыбык-чыбыркы белән өркетеп түгел, кем әйтмешли, бот арасын ут белән гөргеләсәң дә йөгертү мөмкин түгел иде. Утын табалмый мәш килеп, кичкә калуыбыздан курыккан инәй урманга мөмкин кадәр тизрәк барып житәргә ашыга иде. Вакыт-вакыт, түземе бетеп, зәңгәр күлмәкле калкавыч кебек, арбадан сикереп төшә, адымын ешайтып алгарак китә дә, аннан башындагы ак яулыгын бер унга, бер сулга ышырып безне көтеп тора да, янадан арбага утыргандай итә. Ә мин барыргамы-бармаскамы дигәндәй лыкы-лыкы килеп әйләнгән, дегете беткәнгә чыелдап, ара-тирә шакылдап куйган тәгәрмәчләрнең тугымнарын күзәтеп барам.

Менә без авылыбызны уратып алган тауларның иң биек, текәсенә өстерәлеп кенә күтәрелеп, алпавыт Кралов утарының әллә кайларга агарып күренгән таш нигезләрен дә үттек. Ниһаять, атыбызның пошмас атламнары белән теркелдәп, Яшел Түбә урманына да килеп життек.

[3] Шөлләү *(җирле сөйләм)* — курку, шөбһәләнү, тартыну.

Авылыбыз урманлы-яланлы, чишмәле-инешле бай табигатьтә гомер кичеп ятса да, яланда һәрчак ялан рәхәтлеге патшалык итә иде. Монда рәхәт, мондагы чәчкәләрнең хуш исле әчесеннән сулыш алулары җинел, без, инәле-уллы ике җан иясе, тегендә-монда фырлап очкан Аллаһ бөҗәкләрен беренче тапкыр күргән кешеләр сыман, хозурлана, боларыннан тыш, арбалы атта утынга килү шатлыгын йөрәкләренә сыйдыра алмаган сугыш ятимнәре, үзебездән читтә гомер кичкән хаятнең ләззәтен татый идек. Әле җиләк пешмәгән, ул үлән өстен кызарып килүче төймәләр белән тутырган. Тәгәрмәчләрем белән изүдән коткарырга теләгәндәй, мин арбамны унга-сулга боргаладым, әмма әле җиләк булып өлгермәгән бөреләр барыберизелә иде...

Үргә таба янбашлары һәм койрык аслары ак тиргә батып сабынланган ат, кайчан туктарбыз икән дигәндәй, ләштер-лөштер атлап урман эченә керә башлады. Кысыктан үтүгә, алдыбызда кечкенә, әмма түм-түгәрәк аклан ачылды.

— Тукта, балам, — диде инәй, арттан фурманга асылынып. — Моннан да ары кермә. Анда бик куе лабылык...

Ул нишләптер күккә карады. Дөнья мәшәкатендә чуалып, күптән күкләргә караганы булмагангамы. Күк йөзе кайчы канатлы кошлар белән мыжгып тора икән ләбаса. Аннан карашларын сөзеп тирә-ягына карады. Анда тенкәсенә тиеп беткән персидәтел-бригадирлар, налук инспекторлары да юк иде. Анда бары сугыш вакытында киселгән йөзьяшәр имәннәрдән калган гарип төпсәләр генә иде!..

— Син әнә теге лабылыктан ботак-сатак ташырсың, ә мин монавы төпсәләрне мәтәштерермен. Төпсәдән дә яхшырак утын юк!.. Әнә, күпме алар монда!.. — Һәм шундук астыбызга түшәп утырган бишмәт җиңеннән ялтыратып балтаны тартып чыгарды да, бераз кукраеп утырган кара төпсәгә таба атылды.

Әйе, төпсәләр бихисап иде. Бу кадәр күп төпсә күреп, мин сугыш елларында оборонага дип Хлебороб кахулларының «Яшел Түбә»урманнарын кискәнлекләренә инандым. Әйткәндәй, бу, җиз сакаллы абзыйлар урманнарны бездә фатирда ятып кисkәннәр иде. Төнгә каршы, урманнан кайтканда, алар пычкы тешләрендә ялтыратып, безнең өйгә айны да алып керәләр иде. Тагын да шунысы хәтердә калган: абзыйлар эштән кайткач ниндидер әшәке исле эчемлек эчә, кычкырып сөйләшә, кайвакыт сугышып та китәләр иде. Әмма мин үз эшемне яхшы белә идем: аларурманга китүгә, караваt астына кереп, аларның төрле савытларга салынган майларын тырышып, бик нечкә пөхтәлек һәм төгәллек белән ялый идем дә, алар шаулап-гөрләп ишек алдына кайтып кергәндә бу хезмәтемнән туктап, бер гаепсез бур песи кебек, караңгы карават астындагы чүлмәкләрдән майланып һәм ялтырап якты дөньяга чыга идем.

Әле бер тапкыр:

— Кайтып китсеннәр! Барлык майны ашап бетерәләр инде! — дип карават аягын кочаклап елаганым да хәтердә.

Болары борынгы — шактый черегән, муртайган төпсәләр иде.Төннәрен аларның нык черекләре йолдыз таккан гуардиннар кебек мезләп яналардыр. Үзләре черек, әмма ләкин йолдызлы!.. Ә менә яшь тамырлы, йолдызсыз төпсәләрне безнең сыек беләкләр белән генә төпләп булмый...

Мин үрәчәсе кабык белән көпләнгән фурманны авыл ягына борып, атның башын җилпәзәдәй эре яфраклы чикләвек куакларына төрттердем. Ерак юлдан соң ял да күрмәгән, тамак туклык та итмәгән малкай, ачуыннан шарт-шорт китереп, чикләвекнең назлы, сусыл хәтфәсен бөтереп тыга башлады. Ботакларны тешләре белән тартып өзгәндә куаклыкларның кобаралары коелып, калтыранып алалар иде...

Урман эчен дым сугарган. Мин муртаеп яткан вак агач төпләрен, авып, череп яткан кәүсәләрне, былтыргы һәм быелгы коры-сарыларны, урман караклары кискәннән соң өелеп калган агач, ботак-сатак ишарәтен кочак-кочак җыештырып, фурманга чыгарып салдым. Ул арада инәй дә ярыйсы гына зур ике имән төпсәсен китереп киткән. Арба үрәчәсен тутыра алсак ярый инде. Урманда утын юк бит ул. Барлыкка бар ул. Безнең өчен юк. Әбйәщик[4] кистерми. Чүп-чары өчен дә түлә. Түләми киссәң, балтанны ала. Ә ул заманнарда безнең төрки-татар кавеме өчен тимер балта, бүгенге тел белән әйткәндә, «валюта»ның үзе булмаганмы? Йә син урман хуҗалыгына кол булып, бушка печәнен чап, урманын кис, агач орлыгы җый, киптер, тапшыр, яшь үсентеләр үстер. Шуңа, күрәсең, инәсе күбрәк әбйәщикләр бәйләнми торган борынгы төпсәләр белән эш итә. Аның шундый гадәт, урманга утынга дип килсә, дөньясын онытып төпсә эзләп йөгерә. Бар белгәне — шул корып-караеп беткән төпсә. Ничек кенә мактамый, ничек кенә данламый, ничек кенә олыламый ул төпсә утынының җегәрле җылысын. Төпсә анынча — чын утын. Йолдыздай шангырап кипкән, коры утын. Агач кәүсәсенең иң татлы өлеше. Җир тәбикмәге. Бу тамырларда илаһи кодрәт бар.Уты күкшел тыгыз, кайнар, ярсып, җырлап яна, ялкыныннан буш очкыннар очырмый. Шундый бер төпсә белән мунчаның йөз ташынкыздырырга, өйне җылытырга мөмкин, имеш. Һәм башкалар, һәм башкалар...

Шулай, бер килгәнендә, ул төпсә турында тоташ бер вәгазь сөйләде.

— Атаң мичкә, аеруча мунча миченә төпсә ягарга ярата иде. Ул тамырлары тирә-якка тырпайган төпсәләрне авыр озын чөйләр белән суерып чыгара, яра алганынча яра һәм пүләннәрне шикәр кисәкләре кебек итеп өеп куя иде, мәрхүмкәй. Төпсә төпләү, төпсәләр белән көрәш — безнең язмыш, без үзебез дә төпсәләргә бәйле икән, балам. Бабаларыбыз кайчандыр Пугач яуларыннан соң өстебезгә төшкән җәзалардан, чукындырулардан качып, Идел-Чулман буйларыннан Урал тарафларына килеп чыккач, падишаһ аларга чәчүлек җир итеп урман-таулыклар гына биргән. Рәхим ит, чәч, тик башта кәҗә маеңны чыгарып урманын төплә, тавын тигезлә, ташын чүплә.Шуңа безнең күп кенә абзар-ихаталар да, хәтта чакрымнарга сузылган зират коймасы да таштан. Таштан өелгән кибет-келәтләр дә бихисап. Без борыныбыз белән таш, урман сөреп кенә кеше һәм җирле булганбыз. Тора-бара падишаһ ул җирләребезне дә тартып алып, көнбатыштан килгән урыс-кахулларга өләшкән. Колларына урман төпли торган чөйле сөңгеләрен кочкан бабаларыбыз янә дә кара урманнарга чигенгән.

Күк йөзе яшәреп яшелләнде. Яңгыр булмаса ярар иде.

Әнә минем вак зәңгәр чәчкәле, әче тирдән, ачы җилдән изрәп беткән күлмәген киеп алган инәм әле дә, үз алдына сөйләнә-сөйләнә, чираттагы төпсәсен төпләп азаплана. Коры-сары артыннан урман эченә кереп чыккан арада күземә ташлана: ул гүя судагы кармак калкавычы кебек туктаусыз бер урында талпына. Берсеннән берсе мәһабәт, игелекле, таза бәдәнле, ниндидер ата тамырлы, үзәкләреннән җылылары ташып торгандай күренгән төпсәләрнең берсеннән икенчесенә йөгереп бара, аның уенча, инде тәмам картайган-бәлҗәйгән, җинел генә кубарылып чыгарга тиешлеләрен төбе-тамыры белән актарырга тырышып, каккалый-суккалый, эткәли-төрткәли, әмма төпсә һич кенә дә бирешми, эһ тә итми, тун тимер тавышлары чыгарып кына аваз бирә; менә инәй аның тирәнгә киткән тамырларын балта белән кисәргә, киселмәгәч, ничек кенә итеп булса да өзәргә теләп, бернәрсә ишетмәгән, бернәрсә аңламаган төпсә өстендә ана бөркет булып кагынырга, тибенергә, өзгәләнергә тотына,

[4] Объездчик — дәүләт Урман фонды хезмәткәре, урманчы.

әмма балта үтми, бар тирә-як нинди дер саңгырау ухылдау-аһылдаулардан исәнгери башлый...

— Кил әле!.. — ди күз-башы ачулы ялкында дөрләгән инәй. — Син кил, ичмасам!..

Мин йөгереп киләм. Беләм: мондый вакытта инәйнең күз кырыеннан ачулы ялкыннар коела башлый. Яулыгы канаты сынган кош кебек төпсә тирәсенә очып төшә, дөньялыкка чыккан чәчләренең уртадан ярылган ак ызаны, чәчүргеч белән үргән ике толымы кояш давылы эчендә торып кала.

— Тарт!..

Без төпсәне икәүләп тарта башлап, этә, алга-артка кымшатырга, какшатырга, ниһаять, кузгатырга тырышабыз. Әмма таш төрмә кыяфәтләре белән утырган төпсәләр селкенми дә иделәр. Комарыбыз көчәеп, икенче, аннан өченче, аннан дүртенче төпсәгә ташланабыз, әмма һәркайсында шушы хәл кабатлана. Ачуы чыгырыннан чыккан инәй балтасы белән төпсәнең тамырларын янә кисәргә итә, әмма кисә алмый; балтабыз да үзебез кебек ятим һәм үтмәс булганлыктан, теләгәненә ирешмичә, гарьлегеннән елый, үкси, тамырларны кыйнарга, тукмарга, бармаклары белән суырып чыгарырга, инде, аптырагач, карашлары белән булса да чәйнәргә тотына...

Бу минутта миңа бу төпсәләрнең һәркайсы безне бәхетсез иткән кәнсәләр[5], шул кәнсәләргә иялəшеп алган пыяла күзле кемсәләр булып күренде. Бер төпсәсе — абзарында булмаган малы өчен май, сөт, йомырка түләткән силсәвит, икенчесе — асалы паласыбыз арасында сакланган буш акча янчыгыннан салым һәм заем[6] талап өебездән чыкмаган инспектор, өченчесе — сажин[7] тотып, яз саен җир үлчәп, бәрәңге бакчабыздан чыкмаган зимләмир[8], дүртенчесе — инәйне елаткан исерек бригадир, бишенчесе — кышкы салкында туңган көлтә суктырган күмәк хуҗалык рәисе, алтынчысы — яшел галифе-гимнастеркада районнан наган тагып килеп, айлар буе мир җилкәсендә яшәгән упалнамуч[9], тагын да әллә ниткән, әллә ниткән нәчәнникләр[10] иде...

Болар хәзер минем нәселемне «дошман» ясаган, атамны сугышка озаткан һәм аның башына җиткән йолдызлы төпсәләр иде.

Алар гыйфритләр иде!..

Һәркайсы чынлап та үзенә бер төрмә иде!..

— Атаң да юк... Ичмасам... син дә... — ди чәчләре тузгыган инәй, минем нишләргә тиешлегемне аңлата алмыйча. — Һаман кул арасына керә алмыйсың!..

Һәм җан ачуы белән тагын да юан тамырга чаба. Шул чак балта сабыннан чыгып ычкына.

— Их!..

Ул инде балтаның сабын шундый нәфрәт белән җиргә ора һәм гарьлеген кая куярга белмичә, зәңгәр итәкләре белән айкала-чайкала, урман эченә кереп чума...

Минем колак төбемдә аның бер генә сүзе эленеп кала:

— Син дә!..

Төпсәләр миңа сабын кергән күз сыман әчетеп карагандай күренә. Кинәт баш очымда күк күкри. Гүя башымдагы ми ярымшарларым тетри.

Бу минем бердәнбер Атам һәм Ватаным икән.

---

[5] Кәнсәләр *(халык.)* — канцелярия.
[6] Дәүләтнең кешеләрдән акча алып торуы. СССРда салымның аерым бер төре.
[7] Сажин *(халык.)* — сажень, Рәсәйдәге озынлык үлчәве: өч аршынга, ягъни 2 метр 133 сантиметрга тиң.
[8] Зимләмир *(халык.)* — землемер. Бу очракта – саженьлы озынлык үлчәвеч.
[9] Упалнамуч *(халык.)* — уполномоченный. Язгы чәчү, печән өсте, урак өстендә район партия комитетыннан, район советы башкарма комитетыннан һәр хуҗалыккажибәрелә торган махсус вәкил.
[10] Нәчәнник *(халык)* — начальниктан.

Кинәт аяк табаннарым астымда җир ярымшарларым тетри. Тетри. Монысы минем бердәнбер Анам һәм Ватаным икән.

Кем ул, «син дә!?» Соң ул «син» дигән «мин» син үзең түгелмени?!

Мин үзем «син» түгелмени?!

Тар күкрәгем упкын булып кинәя, анда убыр көчләре кузгала, мин, иркен тын алып, урынымнан күтәреләм, инәкием өйрәткән бисмилламны әйтәм һәм мин, әлегә кадәр һәркем кебек, бер генә булган кеше заты, кеше кисәге, кешечек, малай актыгы, берәүдән менәүгә, менәүдән миллионга әвереләм һәм һәр «мин мин икән, мин кем икән» дип масаеп утырган мең-миллион йолдызлы төпсәләрне бармак кына кыймылдатып тамырлары белән урыннарыннан куптарам һәм, кысып кочып, йолдызларга ашам!..

Бүгеннән башлап мин күктә яши башлыйм.

Бүгеннән башлап күк гөмбәзендәге һәр тамырлы йолдыз мин ул.

Бүгеннән башлап күк йөзендә төпсә кочаклаган һәр чатлы йолдыз улмин булам. Үзләре кара черек, әмма яналар. Менә гаеш!.. Шулай итеп, төпсәләрне җирдә куптармый саклаган өчен мин аларга күкләрдә дә түзеп яшәү җәзасын алганмын. Күк гөмбәзеязгы һәм көзге чәчү чорларында эре чатлы йолдызлар белән тула икән, димәк, ышанygыз, төпсәләргә тамырлары белән тырпаеп җиргә төшәргә мин ирек бирмим...

Бүгеннән башлап җир йөзендә гаделсезлек бетәргә тиеш. Чөнки мин, төпсәле йолдыз, һәр изелгәнне изүчеләрдән яклаячакмын. Сугыштан тол калган хатыннарны, ятим балаларны беренче чиратта. Сырт басуларында аларның кулларыннан карлау[11], аркаларыннан чыбыркы төшмәде. Алар — фәрештәләр, ә мин аларны житәкләп йөртүче пәйгамбәр. Моннан ары бер генә гаделсезлеккә дә юл куймаячакмын. Төпсәле йолдыз булып күккә ашарга һәм бу бурычны үтәргә миннән башка беркемнең дә кулыннан килми. Пушкинның да. Толстойның да. Моның өчен икеләтә ятим — үзең ятим һәм халкың ятим булырга тиеш. Пушкин, Толстой ятим түгел. Алар — алпавытлар, графлар. Җир йөзендәгеләр, сез дә мине күзәтеп торыгыз, ярдәм кәтегез. Ярдәмсез калмам. Моңа кадәр ул сезгә килде. Килер. Һәм киләчәктә дә киләчәк.

... Күк йөзе караеп куерды да яңадан яктырды. Без кабыклы фурманны коры-сары белән тутырып, алашабызның ташбака адымы белән кайтырга чыктык. Үрәчәбездә әтәй васыяте кебек берничә йолдызлы төпсә дә яткач, инәй дә инде тәмам тынычланган һәм башындагы яулыгына кадәр канәгать елмая иде. Яшел Түбә тавыннан төшкәндә йөгебез атны үзе этәреп алып китә башлады. Атыбызны чаптырып дулата күрмәсен дип без төшкәндә тәгәрмәчкә каен чаукасыннан тыюлык тыгарга да мәҗбүр булдык.

Өстерәлеп кенә ихатабызга кайтып кергәндә Зәйпә бабай күрше Мөсаббихә әбиләрдән алып торган балтасы белән утынлык тирәсендә чыбык-чабык турап мәшәләнә иде. Шунда гына игътибар иттем: ул сулагай икән. Мин сабый чагымнан ук нишләптер сулагайларны кызыклы, серле кешеләр дип уйлый идем. Бу чынлап та шулай икән. Зәйпә бабабыз серле түгелмени?! Без алып кайткан коры-сарыны һәм йолдызлы төпсәләрне бабабыз ярдәмендә аерым бер горурлык белән утынлыгыбызга бушаттык.

Кояш кичлеккә тәгәри башлаган иде инде.

Бабай, «Яшел яланда туктап ял иттерермен әле» дип, артык мыштырдамыйча юлга чыгарга булды. Фурманына утырырдан алда инәйне чакырып, колагына пышылдагандай гына итеп:

— Бу нигә килде икән дип уйлыйсыңдыр инде, балдыз... — диде ул күзен читкә алып. Аннан минем тарафка ымлады. — Чамалап сөйлим, оланның колагы тишек... Безнең күрше Блүминтәлдә нимесләр яшәгәнен беләсен...

[11] Карлау — җир сөргәндә сука төрәненнән балчык кыра торган кыргыч.

Яхшы халык... Безгә, татарга, сугышка кадәр дә, сугыштан соңгы ачлыкта да нык ярдәм иттеләр. Менә шул Блүминтәлдән... минем Вүлфәнге Грутсиг дигән дустыма... үзләреннән читтә... берничә көнгенә яшәп торасы урын кирәк... Килеп чыкса, куып чыгармассың, яме, балдыз? Курыкма, бозык кеше түгел...

Бу — инәлү иде. Ул һаман да читкә карап, ничектер авыртынып, сыкранып, җир йөзендә кылынган барлык гаделсезлекләрне үзе кылган кешедәй оялып һәм унайсызланып сөйли иде.

— Ярар, җизни. — диде инәй. — Юлы төшсә, килә күрсен...

Озакламый Зәйпә-бабай атының кичке шәүләсе башыннан койрыгына кадәр сузылып Җидегән авылына таба шуыша иде.

Башкасын мин хәтерләмим.

## Антон Павловичның үлеме

*А.П.Чеховның үлеменә*
*110 ел тулу уңаеннан*

Мәскәүгә килгәндә үк хәле мөшкел иде. Ютәле җәфалады, өстәвенә ашказаны борды, аркан ишкән сыман тәне авыртты. Гомерендә булмаганча, урын өстенә үк менеп ятты. Сырхавын эһ тә итмичә ирләргә хас сабырлык белән кичерсә дә, шунысы ачык иде: кичектергесез рәвештәниндидер өстәмә чаралар күрергә кирәк. Доктор Таубе Германиягә — Шварцвальд тарафларына, атап әйткәндә, үпкә чирләрен дәвалый торган Баденвейлер курортларына юлга чыгарга киңәш бирде.

Юл уңаеннан Берлинда туктап, атаклы табиб профессор Э.-дан киңәшләр дә алдылар. Профессор Антон Павловичның сөян тактасы сыман кипшенгән гәүдәсе буйлап бармагын-бармакка тукылдатып чыкты. Гәүдә гүя очыннан очына буш түмәр умарта сыман яңгырый иде. Бу чакта оялчан Антон Павловичның йөзенә чыккан елмаюыннан аның салкын суга керергә курыккан, яисә чит шәһәрдә бәдрәф эзләп кысталган кеше халәтен күзалларга мөмкин иде.

Менә ул бичәсе Ольга белән Баденвейлерда. Шау-шуны болай да җене сөймәгән Антон Павлович санаторий нумерларында туктарга теләмәде. Алар «Romerbad» кунакханәсендә урнаштылар. Табигатькә килгәндә, биредә оҗмахның оҗмахы иде. Әүвәлдә алар Антон Павлович белән шул оҗмах кошлары шикелле җитәкләшеп, йорт тирәсеннән ерак китмичә ара-тирә генә йөрештерделәр. Аннан, көн саен диярлек күлгә төшеп, көймәдә сәяхәт кылдылар. Ике яктан да котырып чәчкә аткан чия аллеясы буйлап атлап, арыклардан челтерәп аккан суларның ясалма сугарулары нәтиҗәсендә рәхәтләнеп үскән бакча-җимешлекләрне күреп, Ходай биргән җирнең һәр карышын гөлбакча итәргә өйрәнгән немес кристияненең чиксез тырышлыгына сокландылар. −Ихатасыз-киртәсез бакчалардагы лилияләр, раузалар, канәфер чәчкәләр үзләренең кушучтай зур, тантаналы таҗларын гүя Антон Павловичны күрер өчен генә урам якка сузганнар иде. Берлиндагы «агач профессордан» бераз айный төшкән әдип бу күренешләрдән кәефе килеп, кайчандыр киләчәктә урыс кристияненең дә җирне шушылай кадерли ала торган көннәрен тизрәк җиткерү турында хыялланды. Менә гаҗәп, озакламый ул үзен яхшы хис итә башлады. Үпкә эмфиземасы йомшара төште. Агарган йөзенә алсулык йөгерде, күзенә нур кайтты.

Баденвейлерда алар мөрәҗәгать иткән доктор Шверер бик мөләем кеше, үз эшен белгән табиб булып чыкты. Ул Антон Павловичның хәле кискен булуын аерым тоем белән тоеп, үзен галәттән тыш итәгатьле, нечкә, искиткеч

йомшак, хәтта ниндидер кызларча сак мөнәсәбәттә тотарга тырышты. Мондый вакчыл педантлык кеше табигатендәге барлык нечкәлекләрне ин нечкә кешеләрдән дә нечкәрәк сизә торган Антон Павловичның кытыгын китерә иде. Ачуын сиздермәскә маташса да, бу хәл сизелми калмый иде. Гомумән, үзе табиб булганга, ахры, Антон Павлович табибларны яратмый, хәтта эчке бер нәфрәт белән куралмый иде. Сырхау белән табиб арасы аның өчен коткаручы белән җинаятьче түгел, ә бәлки җәллад һәм җәллад алдында башын бүкәнгә салган гаепләнүчегә тиң иде. Үзенең катына табиб киләсе булса, унайсызлана, анасын җуйган болан баласы кебек, фыр-фыр килә, аны якын җибәрмәс өчен чаралар әзерли, тозаклар куя. Хәтта Ялтадагы өй табибы Альтшуллер да Антон Павлович янына сырхау янына дип түгел, ә үзенең төп максатын яшереп, имеш,борынгы әшнәсе янына «үтеп барышлый», һава хәлләрен уртаклашу өчен генә күрешеп чыга торган керсез күңелле «танышы» рәвешендә генә керә иде.

Өч атна эчендә алар ике урын алыштырдылар. «Romerbad»та халык бик тыгын булып чыкты. Шәхси утарның беренче катында биләнгән бүлмәдән Антон Павлович иртән иртүк кояшка чыгып утыра һәм кирәк чакта ятып та тора торган булды. Шатлыгына күрә, урамның аргы ягында почта урнашкан булып чыкты. Ул, почта-телеграф, тарантас кебек, гомумән, алга тәгәрәгән һәр нәрсәгә беркайчан да битараф калмаган, һәркайда почта-телеграф хезмәте булдырырга яраткан сәяхи җанлы зат, почта күтәрмәсендә дөнья бетереп кайнашкан хат ташучыларны күзәтеп, вакытын мавыктыргычрак итеп үткәрә иде. Ул түземсезлек белән үзенә дә хатлар һәм газитләр көтә. Сәясәткә чирканып, хәтта җирәнеп караса да, Япония белән Россия арасында кузгалып киткән сугыш аны үтә дә кызыксындыра иде. Почта бинасы каршына килеп туктаган дилижансларның күргәзмә өчен эшләнгән кебек эшләнгән купшы тәгәрмәчләрен күреп, ул Николай Гоголь сыман, «Бу тәгәрмәчләр Сахалинга кадәр түзәрләр иде микән?» дигән ахмак сорау куеп, аңа «Юк, Сахалинга ук булмас, ә менә Читага кадәр түзәрләр» дигән кебек ахмак җаваплар биреп утырырга да кыенсынмый иде. Күп тә үтми Антон Павлович бүлмәсе накысланып калгандай, кояш нурлары сүнгән-сүрелгәндәй булды, ул элеккечә өши, калтырана башлады. Бүлмәдән ютәлләгән тавышлар ешайды, якын, бик якын, яраткан кешеннең янәшәндә генә шулай каты ютәлдә газаплануы Ольга өчен аңлата алмаслык газапка әверелде. Алар янә дә яна урынга, бу юлы кояш үзе кереп оялагандай нурлы бүлмәгә күченделәр. Авыру җылынды, үзен яхшы тоя башлады. Сәгатьләр буе балконга чыгып утыра, Баденвейлер кебек уймак шәһәрчекнең бер хәйләсез тормышын күзәтә; вакыты житкәч, төшке, кичке ашка дип гомуми залга кереп утыра... Бәхетенә күрә, биредә дә почта бар икән. Ул гүя балкон читлеге аша очып, шушы дилижанслар — почта атлары канатларында тагын да Сахалинга, инде бу юлы рус-япон фронтына ук барып кайтырга хыяллана иде. Мәскәүдән тарантаста Сахалин ярыматавына барган үпкә чирле Антон Павлович Тын океан ярларыннан «кюз киряк!» дигән татар сүзе алып кайткан. Җае туры килгәндә ул бу тәгъбирне үзе дә яратып куллана иде. Тарихы болайрак. Коя дигән елга ярында урнашкан алтын юучылар бистәсендә каторжан татар гаиләсендә алтын ташлар белән уйнап утырган малайга тап була ул. Кызык өчен генә, нишләр икән дип, малайдан шушы ташларны үзенә бирүен сорый. Малай аларны ике дә уйламыйча бирә. Бу кадәр беркатлы сафлыктан сәяхәтчегә уңайсыз булып китә. Күзенә яшь бәреп чыга. Ул малайның рус телен белүенә бик шикләнеп кенә «Бу алтыннар өчен сиңа алмашка мин нәрсә бирим?» дип сорый. «Мине кюз киряк! — ди малай татарча, аннан тырыша-тырыша русча да өстәп куя. — Ти мене клас давай!».

Кюз — глаз икән. Малай тома сукыр икән!

Кеше матурлыгын күбрәк тәннән түгел, җаннан эзләгән Антон Павлович, сөйләүләренчә, шул минутта татар баласына бер күзен бирергә дә карар кыла. Никадәресе дөрестер. Әмма мондый катлаулы операция үткәрү өчен, имеш, шартларның житмәве генә туктатып кала әдипне.

Күптән түгел Ольганы чакырып алды да, колагына, гадәттәгечә, йомшак бәрхет тавышы белән «Минем ап-ак фланель костюм киясем килә», — дип пышылдады. Үзе як-ягына каранды. Гүя бу хакта беркем дә белмәскә тиеш иде. «Син нәрсә, Тоша, — диде Ольгасы аптырап. —Курортта юньле костюм табып була диме?» «Ә син тап. Мин бит синең киявең». «Каян? Ничек итеп?» «Минем шыксыз зифа гәүдәмнең үлчәмен ал. Күршедәге Фрейбург шәһәренә бар. Тегүчегә заказ биреп кайт». Һәм шулай итте дә Ольга. Ак костюм артыннан йөреп тулы бер көнен үткәрсә үткәрде, әмма тегүче таба алды. Кайтканда аны үз аягы белән каршыларга чыккан Антон Павлович, костюмының өч көннән әзер булачагын белгәч, сабый бала кебек куанды.

Җәйге чиллә эсселәре башланды. Иртән, коридордан барганда, Антон Павловичның тыны бетә, буыла иде. Ул бу юлы тәрәзәләре һәм балконы төньякка чыккан җиләсрәк бүлмәгә күчәргә теләде. Шулай иттеләр дә. Мәһабәт тауларга һәм эре кәүсәле имән урманнарына күренеш ачылган югары каттагы бу хөҗрә әдипкә ифрат та ошады. Антон Павлович яткан җиреннән генә Ольганың Берлин банкына хат язуын үтенде. «Безнең анда бераз гына калган акчабыз бар. Бирегә җибәрсеннәр», — диде ул. Аннан ниндидер монсулык белән өстәп тә куйды: «Минем исемгә түгел, синең исемгә». Мондый сәер үтенечкә асаба мәгънә бирмәгән Ольга кыңгырау тавышлары чыгарып көлеп җибәрде. Ул кәләшнең акча мәсьәләләрендә булдыксыз икәнен белә иде, шуна күрә ике дә уйлап тормыйча, реквизитны Антоны исеменә тутырды.

Ике көн буе авыруның тыны кысты, буылды,ютәле тотты. Әмма, шөкер, температурасы күтәрелмәде. Ул урыны өстенә менеп үк ятмады, шулай да астына өч-дүрт мендәр салып, шулар өстендә төрек пашасы кебек утыра торган булды. Ольга ана туктаусыз кислород «мендәрчекләре» ташыды. Вакыт-вакыт кислородтан аерылып, йөзләрен җыера-җыера кәһвә эчте, күрәсең, эчкән нәрсәсе тәмсез иде.

Моннан алдагы төн аеруча куркыныч төн булды. Көндезләрен түзә алмаслык эссе, төннәрен суына, томан төшә иде.Житмәсә, дөнья җимертеп күк күкри, яңгыр ява. Мондый вакытта аеруча тын җитми. Антон Павлович бертуктаусыз тәрәзләрне һәм балкон ишеген ачуын үтенә. Әмма болай итү авыру өчен тагын да куркынычрак: угыз кебек куе, лычма дымдан авырайган, нәкъ теге фланель тукыма кебек ап-ак томан тәрәзәдән һәм ишектән кереп бүлмәгә тула, мебель һәм әйберләр арасына тулып, сузылып, ниндидер фантастик күренешләр тудыра һәм килбәтсез филләр, аюлар сыман бар нәрсәне изеп, туктаусыз бүлмә эчендә йөзә башлый... Менә электр утын да сүндерделәр. Чөнки ул Антонның күз карашын газаплый. Өстәлдә бармак башы кадәр янып бетмәгән шәм пыскый, аңа карасаң, ул таң атканчы җитәрме, җитмәсә, янып бетсә, сүнсә нишләрбез дигән кечкенә фикер зур итеп җәфалый башлый.

Төн үзенең авыр, юеш, пошлыккан тынлыгы, ялгызлыгы һәм шомлы тынычлыгы белән чынлап та куркыныч иде. Бер үк вакытта мендәрләрендә тәхет өстендәге падишаһ кебек утырган иренең куе томандагы сынын күргән яшь бичә Ольга тормышның мондый авыр чакта да бөек, тантаналы булуын күреп куана һәм таң ату белән доктор Швеверның килүен түземсезлек белән көтә иде.

Мендәрләр өстеннән дөньяга шикләнеп, тартынып кына карап утырган Антон Павлович инде алар кайчандыр өйләнешкәч тә үпкәләрен дәваларга дигән зур өмет белән башкорт кымызына — Аксеново[12]га барган Антон Павлович түгел иде. Мона кадәр мондый да бай кыргый чәчкәләр патшалыгын күрмәгән Антошасына чәчкә тузаныннан аллергия булды. Ул анда да гадәти шаянлыгын югалтмады. Мәсәлән, анын озын гәүдәсе үзе йоклый торган тимер караваткa сыя алмый, аяклары таяк кебек чыгып тора. «Бар әле, хирургны алып кил, — ди иде ул мондый чакларда. — Ак Фәтхулладан аркылы пычкы алырга онытмасын. Гәүдәнең артык өлешен кисеп ташларга кирәк.» Кәфенгә төренгән кебек актан киенергә яраткан татар Фәтхулла исә соңгы урыс-төрек кампаниясендә кулын өздереп кайткан чулакай, аларны көн аралаш тарантаста авыллар буйлап Дим буйларына йөртә...

Менә куе томан катламнарын эчтән изрәтеп, ниһаять, җәфаланып булса да офыкта таң чишелде. Доктор Шверер килде, беренче чиратта Ольганы тынычландырды. Антон Павлович белән зәгыйфь, әмма ихтыяри аһәң белән сөйләште, байтак кына гамәли киңәшләр бирде... Күпмедер дәрәҗәдә җинел дә булып киткәндәй тоелды. Антон Павлович, күңеле күтәрелеп, сыек кына солы боткасы да капкалагандай итте. Аннан, бала кебек, «Тү-тү барыйк», — дип,тәрәзгә якынрак китерүләрен үтенде. Ул анда кәртләрдән озак кына вакыт үзе яраткан «унөчле» пасьянсын[13] салып, фал ачты. Ул арада Ольга аптекага йөгереп, җәһәт кенә кислород алып килде. Кичәге төн мәңге кабатланмас кебек иде. Ольгасынын кайтуын көткән арада, ашыйсы килмәсә дә, гадәте буенча төшке ашка чакырып чаң сукканны көткән Антон Павлович яна хикәясенә сюжет кораштырган булып чыкты. Германиядәге курорт. Байлар. Миллионерлар. Барысы да эт талагандай ачыккан. Һәркемнең күз алдына үзе ашарга теләгән затлы ризыклар килә. Барысы да төшке ашка чакырып чаң сукканны көтәләр. Менә, ниһаять, чанны да сугалар. Йотыккан миллионерлар аш залына керсәләр, өстәлләрдә салфеткалардан башка бернәрсә дә юк: хосусый милке өчен салымын түләмәгән пешекче эшен ташлап качкан.Ачлыктан нишләргә белмәгән миллионерлар ачуларыннан үзара талаша башлыйлар...

«Менә, күрәсең, мина яхшырак бит», — дип Антон Павлович астындагы артык мендәрләрне алырга кушты, унайлырак итеп сузылып ятты һәм озакламый йоклап та китте. Өч сәгать чамасы йоклагандыр. Төнге берләр тирәсендә уянды, урын астынын каты булуына, күңеле болгануга зарланды. Эчтән яна иде. Һәм гомерендә беренче тапкыр үз теләге белән докторны чакырырга кушты. Авыру янында берьялгызы булган Ольга докторны дәшәргә танышлары — Россиядән килгән яһүд студенты Рабенекны җибәрде. Швейцар әлүмин табакта боз алып керде. Алар аны Ольга белән иләндә тезләнгән килеш ваттылар һәм, чүпрәккә төреп, Антон Павловичнын күкрәгенә куйдылар. Елмаерга итсә дә, кыяфәте гадәттән тыш җитди булып, гүя ул гади бер доктор кисәгeн түгел, ә каяндыр еракта, галәми үзәктән бик мөһим хәбәр көтә иде.

Доктор Шверер килде, Антон Павловичны кочаклап алып, сораштыра башлады. Авыру гадәттән тыш көчәнү белән гәүдәсен турайтырга тырышты һәм бар тирә-юньгә ачык һәм ишетелерлек итеп: «Доктор, ich sterbe»[14], — диде. «Син нимес кызы булгач, сина өйләнеп мин дә нимес булдым бит инде», — дип шаяртырга яратса да, Антон Павлович нимесчә ипилектозлык кына белә иде. Доктор «Һи-и, картлач, син нәрсә сөйлисең, безгә

[12] Транссиб буйлап, бүгенге көнбатыш Башкортстандагы тимер юл стансасы. Әлшәй районы биләмәсендә.

[13] Пасьянс — кәртләрне тиешле конфигурация килеп чыкканчы тезеп фал ачу.

[14] Мин үләм. (Немецчәдән.)

әле яшәргә дә яшәргә!» дигән булып аныгынычландырырга тырышты, какча иненә шапылдатып сугып та алды. Антон Павлович анын колагына нәрсәдер пышылдагандай итте. Доктор шприцын кадап, тире астына камфара кертте. Һәм көтмәгәндә Ольга ханымнан шампан шәрабе сорады. Менә швейцар шампан да китерде. Шверер шәрабны ике зур бокалга мөлдерәмә салды һәм берсен Антон Павловичка сузды.

— Күптән шампан эчкәнем юк иде! — Антон Павлович бокалны эһ дигәнче төбенә кадәр киптереп тә куйды.

Шулай диде дә сул ягы белән караватына сузылып ятты. Күзен йомды. Нииндидер мәшәкать белән аш-су бүлмәсе белән ике арада йөргән Ольга, жинелчә хырылдауга якын тын алыш сизенеп, йөгереп килде:

— Антончик!..

Ул инде суламый кебек иде.

— Дусик!..

Алар бер-берсен үзләре генә аңлаган сәер исем-кушаматлар белән «дусик, песик, аткаем, эткәем, песикәем, кара борынкаем» дип атап йөртәләр. Юк, анын дусигы, бердәнбере-жанкисәге, шулай шаярып кына бер хатыны өчен генә түгел, ә бары тик чит дөнья өчен генә тамаша куеп ята иде. Юк!.. Бу кадәр камил, бу кадәр нечкә, бу кадәр акыллы талант иясенең Россияне ятим итүе мөмкин түгел!..Чеховтан башка ул нишләр? Юкка чыкмасмы? Менә хәзер... менә хәзер...менә хәзер уяначак ул!

— Дусик!.. Антончик!.. Антуан!..Венгерчик!.. Черномордик!..Китмә!..

Шверер чал башы белән әдипнең күкрәгенә капланып, йөрәген тыңлады.

Йөрәк типми иде.

Булмас!.. Ольга тораташ булып катты. Ул яшь сытмаган, әмма ышанмаган күзләрен шар ачып елмайган килеш, бар булмышы, бар гәүдәсе, жаны-тәне белән тоташ бер яшь тамчысына әверелгән иде. Ольга аңлады: Антоны анын белән менә шушы шампан шәрабын эчеп мәңгегә хушлашкан икән... Нибары тулыр-тулмас дүрт ел гомер итеп, алар бергә яшәп тә өлгермәделәр бит, Ходаем!.. Нигә алар Ходай биргән жәннәт рәхәтләреннән баш тартып, шулай бер-берсен газапладылар?! Бүлмәгә каяндыр урамнан тәрәз аша чегән алкасы кебек зур, кара төн күбәләге очып керде. Ул да жан өстенә жан бирергә теләп, үзенә урын тапмагандай, диварларга, түшәмгә, электр куыкларына һәм ут сүнгән хәлдә өстәлдә кизү торган гади шәмнәргә кадәр кагылып-сугылып бәргәләнде. Яшьтән үк үпкә белән авырган Антон гомер буе жылылык, жылы урын, жылы жир, сөю жылысы эзләде. Ольгасы ана сөюе жылысын бүләк итеп, театрдан китәргә һәм кайдадыр бергә тынычлап кына яшәргә ничә тапкырлар тәкъдим итте. Әмма Антон Павлович «Син сәхнә кешесе, сәхнәнә тугры кал, Мәскәүдә яшә, театрларында уйна, мин табиблар кайда кушса, шунда яшим, бер-беребезгә барып-килеп йөрербез», — дип баш тартты. Гаделлек жылысын эзләп, Ерак Көнчыгыштагы урыс булмаган милләтләрнең хәлен өйрәнү өчен ул унике мең чакрымлык Сахалинга юлга чыкты, тишек үпкә белән дөньяны урап кайтты. Жан жылысын эзләп, ул, күбәләк кебек, Мәскәүдән Леонидовкага, Леонидовкадан Аксеновога,Аксеноводан Мелеховога, Мелеховодан Ялтага күчте. Һәркайда сирень, чияләр, зур тажлы раузалар үстерә торган булды. Ул бадәм[15] бөреләренен яшәргән чагын түгел, ә яфрак ярыр алдыннан агарган мизгелен күрә белде һәм әдәбиятта шуны сурәтләп калдыра алды.

Бүлмәдә кабер тынлыгы иде. Төн күбәләге бәргәләнде-бәргәләнде дә, кечкенә ноктага әверелеп юкка чыкты.

Менә шулай, ир белән хатын булып алар күбрәк хатларында һәм

[15] Миндаль.

телеграммаларында гына яшәп калдылар. Мәскәү-Симферополь арасындагы ашыгыч поездлар ике якка һәр көн саен диярлек хатлар һәм бүләкләр ташыды. Ул хатларда искиткеч тирән сөюгә төрелгән кызык, кызганыч һәм фаҗигале тормыш манзаралары, аларга хас сагыныч һәм иркәлек ачыла иде. Ольга: «Быел җәен Швейцариягә китәрбез һәм анда бары тик мәхәббәт хисеннән исереп ял итәрбез.Мин сине тирәннән аңлыйм, җанкисәгем.Сине кысып һәм кайнар кочаклыйм.Пьесанны тәмамлар өчен бирегә килсәң, ә? Фатир әйбәт, саф һава мулдан, кояш. Син минем нинди булганымны да онытып бетергәнсеңдер инде...» Антон:» Швейцариягә бару мине куандыра. Син минем синең нинди булуыңны да онытканмын, дисең. Әйе, дуся, мин инде синең ак чәчлеме, кара чәчлеме икәнеңне исемнән чыгардым, әмма синең кайчандыр минем хатыным булганыңны хәтерлим...» Ольга: «Син әле «Чия бакчасы» пьесасына утырдыңмы? Безнең театр аны күз өстендәге каш кебек ничә ай көтә инде? Тизрәк, дусик! Синең кебек язучының бер генә минут телсез торуы да Россия өчен зур югалту...» Антон: «Пьесага тотынырга дип торам. Өстәлемә бер кочак кәгазь китереп салдым. Пьесаның исемен дә язып куйдым хәтта. Үзен генә язасы калды. Бик тә мунчага барасым килә. Табибым Альтшуллер рөхсәт итми, явыз. Син миңа, мөмкин булса, тирән төпле калушалар сал әле». Ольга: «Мин сиңа кызыл балык, куертылган сөт, кипкән җимешләр салдым. Галуша да, галстук та җибәрәм. Тагып йөрерсең микән?» Антон: «Җибәргән нәрсәләреңне алдым. Галстукны тагып карадым. Әмма ул корсаклы кешенеке сыман озын, аны бераз кыскартып та җибәрә алмассыңмы?...»

Югалтуның никадәр зур булуын әле тәмам сеңдереп бетә алмаган ханым, айныгандай итеп, тирә-ягына карады. Доктор киткән икән. Алар сөйгәненең үле гәүдәсе белән икәүдән-икәү генә торып калганнар.

Студент Рабенек Россиягә телеграммалар язарга тотынды.

Таң ата башлады. Электрны да сүндерделәр. Кайдадыр янәшәдәге католиклар, костелда таш коедан яңгыраган гармоник аһәңнәр тавышын чыгарып, орган уйнап алды. Бу хәл үлемнең тууга тиң бөек гамәл икәнлеген искә төшереп, зур югалтудан борчуга төшкән халыкны тынычландырды. Аккордлар бөек кешенең бик гади үлеменә мәрсия булып яңгырады. Иртәнге җидедә Баден сараеның министр-резиденты килеп, мәрхүм каршында тезләнде, король исеменнән кайгы уртаклашты һәм мәрхүм Баден туфрагында җирләнсә, бу адым герман кавеменә зур ихтирам күрсәтү булыр иде, дип белдерде. Үз чиратында Ольга ханым министрга рәхмәтен әйтеп, әдипнең Россиянең бөек улы һәм бөек әдибе булуын, җәсәденең дә Россия туфрагында християнлык хөрмәте күрсәтеп җирләнәчәген житкерде.

Шул ук көнне Берлин банкыннан Антон Павлович исеменә хат килде.

Калган акчалар Ольга кулында яшькә манчылдылар.

Фрейбургтан ак фланель костюмны да китерделәр.

Ольганың үтенече буенча Антон Павловичны табутка шул кар кебек ак костюмга киендереп салдылар. Ул Ак Фәтхулла кебек акчарлакка әверелде дә куйды. Гүя ул аны ахирәткә — Тәңре каршысына кияр өчен махсус тектергән иде. Акчарлак!.. Ә бит алар беренче тапкыр куелуга әзерләнгән «Акчарлак»ка репетиция вакытында танышкан иделәр!..

Доктор Шверернең хатыны костелга аналой[16], иконалар куйдырып, Карлсруэдән христиан руханиын чакыртты. Якын-тирәдән якташ руслар килде. Шулай итеп, костел тиз генә православие чиркәвенә әйләнде дә куйды. Мәрхүмгә мәрасим кылдылар.

Антон Павлович динне таный,ихтирам итә, әмма гамәле белән дини кеше түгел иде. Дөрес, аның кайсы диннең хакыйкате кешегә якынрак диган

[16] Гыйбадәт вакытында уку өчен китап куя торган күтәрмә.

сорау борчый иде. Бер мәлне ул мөселманнарның биш вакыт намазларын уку вакытларының серен аңларга тырышып күп китаплар актарды. Намаз вакытының Аллаһның күк капусын көненә биш тапкыр ачуына бәйле булуын, мөселманның шул мизгелләрдә, бигрәк тә төннең дүртенче, соңгы, таң намазын укылган өлешендә кулларын күккә күтәреп нинди теләкләр теләсә, Аллаһ шунын теләкләрен кабул иткәнлеген ачыклады. Мөселманлыктагы мондый галәми глобализм аны ихластан да таң калдырган иде. Әмма аны, рус кешесе буларак, бер нәрсә аптырата иде: төнге намазга, йокы калдырып, ничек торырга мөмкин? «Әллә син мөселман инде?!» — диде ана бер тапкыр тәмам аптыраган Ольга. «Мөселман ук түгелмен, әмма, тау кебек, Мөхәммәдкә якыная барам!» диде ул киная белән елмаеп.

Шул ук көнне кичләтеп запас юлда торган курьер составына өстәмә вагон тагылды. Антон Павлович үлгәннән соң да үзе яраткан «почта вагоны»нда өч тәүлек буе ватанына таба теркелдәячәген һәм аның гәүдәсен станция саен эндәдән үткәргәндәй үткәреп, ниндидер городовой-полицмейстерлар түгел, ә бәлки әле берничә ел гына элек өйләнгән алмадай кәләшенең күз карасы кебек карап алып кайтачагын күз алдына китерә алыр иде микән? Юктыр. Россиянең иң бөек язучыларының да уй-хыялы җитмәгән булыр иде мона. Вагонны якташлары кайгылы кәгазь чәчкәләр-гирляндалар белән бизәгәннәр иде. Иң соңыннан мәрхүмнең гәүдәсе салынган имән табутны керттеләр. Тагын җеназа чыгылды. Тирә-юньдә бер генә тәртип бозучы да күренмәгәч, бер генә тәртип саклаучы полицейский да күзгә чалынмады.

Вокзал директоры изгелек күрсәтеп Ольгага инде ничәнче тапкыр бүтән вагонга күчеп утыруын үтенде. Шулай унайлырак булыр дип ышандырырга тырышты. Ольга да инде ничәнче тапкыр мондый унайлыктан баш тартты. Мин ирем белән бергә кайтам, диде.

Перронда соңгы чаң тавышлары яңгырады. Поезд Россиягә таба юлга чыкты.

Россия аны көтми, каршыларга әзерләнми, махсус элемтәдән хәбәр алган полиция генә көтә һәм каршыларга әзерләнә иде.

Курьер поездының почта вагонында алар икәү иде.

Табутта, акчарлактай ак костюмда, русның Гоголь, Толстоена тиң өченче язучысы, сәүдәгәр улы Антон Павлович Чехов һәм аның белән рәттән хатыны — заманның танылган сәхнә остасы, чыгышы белән Эльзац нимесе булган тау инженеры кызы Ольга Леонардовна Книппер-Чехова иде.

# ЗУР ТАРИХЛЫ ТЕАТР

## К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫНА 80 ЯШЬ

### Башлангыч чор

Кешелек бүген компьютерлар, лазерлар, космик корабльләр ясарлык үсеш алган икән, монда борынгы бабаларыбыз башлап җибәргән гореф-гадәт, төрле йолалардан, уеннардан оеткы алган матурлыкны яклаучы һәм саклаучы сәнгатьнең роле бик зур. Сәнгать төрләре арасында кешене тәрбияләүдә иң югары урыннарның берсен театр сәнгате били. Милләтләрнең үзенә генә хас матурлыгын, телен, йолаларын, шулай ук холкын саклап калуда да театр сәнгате мөһим урын алып тора.

Үткән гасыр ахырында таркалган СССР дәүләтенә бүген каршылыклы мөнәсәбәт булса да, ул дәвернең уңай яклары җитәрлек булган икән. Большевиклар властьны үз кулларына эләктерү белән пропаганда-агитация эшенә бик зур игътибар бирә. Шул рәвешле профессиональ театрлар, консерватория, филармонияләр, җыр-бию ансамбльләре ачарга җирлек тудырыла. Гражданнар сугышы баруга карамастан, 1918 елдан башлап дәүләт җитәкчелеге халыкның аң-белемен, мәдәниятен, сәнгатен үстерүгә мөмкинлекләр ача. Бер генә чит ил дә бу мәсьәләдә большевиклар төзегән Совет дәүләте белән ярыша да, аны узып та китә алмый. Әлбәттә, дәүләт театрлары буш урында барлыкка килми. Алдагы чорда алдынгы фикерле байларның матди ярдәме белән яшәгән, иҗат иткән фидакарь труппалар нигезендә оеша ул. Авыл җирлегендә зур каршылыклар белән барган күмәк хуҗалыклар төзү башлангач, бу җирлектә идеологияне көчәйтер өчен, 1930 елда РСФСР Халык комиссарлары советы театрлар үзенең төп эшен район үзәкләренә, шәһәрләрдә яшәүче эшчеләргә, берләшкән авыл хезмәткәрләренә юнәлтергә тиеш», дигән карар чыгара. Яңа Указ нигезендә Татсоюз һәм Татколхозсоюз барлык райсоюзларга һәм колхоз идарәләренә: «килгән артистларга ярдәм итәргә, ашатырга-эчертергә, бушлай фатирга кертергә, бер авылдан икенчесенә озатканда транспорт белән булышырга», диелгән тәкъдимнәр дә җиткерелә. Бу әмерләр мохтаҗлыкта көн күрүче труппаларның хәлен шактыйга җиңеләйтсә дә, әле авыл җирләрендә тәгаен эшләргә тиешле, дәүләт карамагында торган коллективлар булмый. Әлеге мәсьәләдә танылган драматург, актер, режиссер К.Тинчурин колхоз-совхоз театрларын ачуда зур активлык күрсәтә. Рәсәй халкының күпчелек өлеше ул елларда авылларда яшәвенә басым ясап ялкынлы чыгышлар ясый. 1933 елның 9 маенда «Кызыл Татарстан» газетасында академия театрын: «Үз кабыгында гына кайный», дигән тәнкыйть белән чыга. Ниһаять, шул ук елның көзендә яңа бер төркем оештырылып, иҗат сәфәренә озатыла. Аның җитәкчесе итеп Сәет Булатов билгеләнә. Алар үзләре чыгарган беренче афишалары белән 1933 елның 6нчы ноябрендә Питрәч районының Шәле авылында «Булат бабай семьясы» дигән спектакль уйныйлар. К.Тинчуринның К.Нәҗми белән берлектә язылган әсәре өч керосин лампасы астында уйнала һәм тамашачыларны әсир итә. Бу хәл авыл халкы өчен чын мәгънәсендә тетрәнү ясаган яңалык була. Спектакльдәге төп рольләрне ул чактагы әйдәп баручы актерлар Х.Уразиков, Ш.Шамильский, Х.Әбҗәлилов, Н.Таҗдаровалар башкара. Р.Ишморат: «Бу әсәр колхоз темасын

яктырткан иң яхшы спектакльләрнен берсе», – дип бәя бирә. Киләчәктә күчмә, аннан соң К.Тинчурин исеме белән аталып китәчәк, данлыклы театрның тарихы әнә шулай башланып китә. Яна туган труппаның беренче спектакле дә К.Тинчурин исеме белән бәйле, әйтерсең лә шул чакта ук киләчәккә ишарә ясала.

Театрда бу авыр, болганчык чорларда танылган артистлар Г.Болгарская, Ф. Ильяская, Г.Камская, Ә.Яһүдин, Г.Гыйматовлар иҗат итә. Колхоз-совхоз театрының иң беренче куелган әсәрләре арасында «Булат бабай семьясы»ннан башка тагын А.Арбузовның «Алты гашыйк», Жидкин белән Ильинскийның «Адашлар»ы, Н.Сәләховның «Ярату», Ш.Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» пьесалары Г.Ильясов режиссерлыгында дөнья күрә. Коллективны иксез-чиксез Рәсәй җирләре, юлсыз авыллар көтә. Ләкин, яңа гына колхоз-совхозлар оештырылган авылларда театрларны һәрвакыт көтеп алмаганнар. Революция һәм гражданнар сугышының афәтле җилләре авыл халкын хәерчелеккә төшергән, өстәвенә, күпчелегендә һәрбер яңалыкка каршы чыгучылар табыла, сәнгатьне бозып, кара буяуларга буяп күрсәтүчеләр житәрлек була. Шул сәбәпле, кайбер җирлекләрдә халыкны тамаша карарга җыю да авыр була. Андый очракларда, труппаның гармонисты йә җәяүләп, йә ат арбасында урам буйлап клубка өндәп йөргән. Күпчелек очракта, махсус урыннар булмау сәбәпле, спектакльләр элеккеге авыл баеннан тартып алынган өйләрдә, йә булмаса иркен ишек алларында үткәрелә. Бу елларда, соңрак та репертуарда концерт программалары да зур урын ала. Шул сәбәпле, труппада гармунчы, җырчылар, биюче-мәзәкчеләр, сүз осталары да була. Инде җайлы гына эшләп барган коллективны яңа афәт көтеп тора. 1937 елда массакүләм репрессияләр башлана. Театрның баш режиссеры Гали Ильясов кулга алына. Озакламый артистларның зур терәге булган Кәрим Тинчурин да кызыл террорның корбаны була. Труппа хәлсезләнә, тынсыз кала, идарә итәрлек кеше юк, үзләренә яраклы пьеса табуы да зур мәшәкатькә әйләнә.



*Т.Гыйззәт. «Башмагым».*

## Күчеп йөрүләр чоры

Кыерсытылган театрның базасын бер районнан икенчесенә күчереп йөртә башлыйлар. Мамадыш та, Арча да, Балтач та калмый. Афәтле сугыш барган 1942 елның салкын шыксыз октябрь аенда «Шәһәр театры» исеме белән коллектив Буа каласына күчерелә. Биредә аларга күркәм генә бина да бирелә. (Бүгенге көндә анда, капиталь ремонттан соң, күптән түгел ачылган Буа театры көн күрә).

Алда иҗатчыларны сугыш вакытының ачлы-туклы көннәре, кышкы салкын клублары көтә. Барыр юлларына көрт салып, буран котырып, баралмыйча тилмереп яткан чаклары да бик еш була. Ул да түгел, 1944 елның 1 мартында «Иҗади яктан зур үсеш ясадылар, 4нче төбәктән 3сенә күчерелә», дигән әмер килә. Коллективны Казанга кайтаралар. Тик, кин колачын җәеп каршы алмый аларны башкала, өстәвенә рәхимсез сугыш дәвам итә, театр өчен буш бина да булмый. Театр хәтле театрны элеккеге Болгар кунакханәсендәге коммуналь фатирның кухнясына урнаштыралар. Иҗатчылар берничә ел шушы аш әзерләү бүлмәсендә чиләнә. Соңрак аларны печән базарында урнашкан Нурулла мәчетенә күчерәләр. Сугыш чоры буларак театр репертуарында патриотик рухта язылган әсәрләр күп урын ала. Т.Гыйззәтнең «Серле

казна», Р.Ишморатнын «Кайту», Г.Насрыйнын «Патриотлар гаиләсе» дигән әсәрләре сугыш михнәтеннән жәфа куручә тамашачыларнын юатучысы да, юанычы да була. Бу елларда коллектив белән А.Мәжитов житәкчелек итә. Үзе язып үзе куйган «Шул ук кешеләр», «Сөекләләр»не санамасак, репертуарда шул ук спектакльләр кала. Бу анлашыла да: эшләргә артистлар житми, күпчелеге фронтта. Ижат төркеме дә 9 гына артисттан тора – Х.Исмәгыйлов, М.Рәхмәтуллина, С.Хөснетдинова, Г.Гиматов, Б.Галимуллина, С.Сәгыйтов, З.Камалова, А.Әхмәтжанов һәм А.Мәжитов үзе. Артистлар житмәү сәбәпле, кайбер очракта ирләр ролен хатын-кызлар башкара. Ул чакта патриотик рухны ныгытуда агитацион концертлар бик еш куела. Төрле авырлыклар, кытлык кичерүгә карамастан, А.Мәжитов яна пьесалар куярга, репертуарны үзгәртергә керешә. Казанга кайту белән ук классик драматургиягә алына. Н.Островскийнын «Үз кешеләребез – килешербез» (1944) һәм «Ярлылык кимчелек түгел» (1946) әсәрләрен сәхнәләштерә. 1949 елда исә халыкны елаткан да, жырлаткан да М.Әмирнен – «Минлекамал»ы театр сәхнәсенә менә. Режиссер С.Вәлиева-Сульва тарафыннан куелган спектакль халыкнын яратып караган әсәрләреннән берсенә әйләнә.

Ниһаять, дәһшәтле сугыш тәмам. Утны-суны кичкән фронтовиклар кайта башлый. Кайгыдан да, шатлыктан да бу көннәрдә күз яшьләре бик күп була. Күчмә театрга сугыш кырларыннан шактый гына ижатчылар – З.Хәлиуллина, З.Туишева, Т.Кичубаев, М.Хәмзин, Ф.Юнысов, А.Абдрәшитов, Г.Нигъмәтуллина, С.Шәкүровлар әйләнеп кайта. Үзләренен гаризаларына «эшкә алыгыз» дип кенә түгел, «фронттан кайттым, артистлык эшенә керешәм» дип тә язалар. Әйтерсен лә эштән китеп тә тормаганнар, бусагадан атлап керүгә эшкә керешәләр, күчмә театрга жан өрәләр. Күпмедер вакыттан сон фронтовикларнын бер өлеше Әлмәт драма театрына күчеп китсә, С.Шәкүров, Ф.Юнысов, М.Хәмзиннар биредә жин сызганып ижат эшенә керешә.

...Ни кызганыч, 1946 елнын жәендә коллектив кабат зур югалтуга дучар була. Сугыш елларынын бөтен авырлыгын үз жилкәсендә күтәргән тынгысыз житәкче Ә.Мәжитов вафат була. Шул ук елнын 20 июнендә сәнгать эшләре буенча Идарәнен указы белән республика Күчмә театрынын житәкчесе итеп Йосыпов Габдулла Фәтхулла улы билгеләнә. Әстерхан, Ленинград, Мәскәү, шулай ук Казан рус театрында да хезмәт кылып алырга өлгергән тәжрибәле режиссер эшкә керешә. Кырыгынчы елнын ахырында үзенчәлекле татар пьесалары: М.Фәйзинен «Яшьләр алдатмыйлар», М.Әмирнен «Тормыш жыры», К.Насыйринын «Күнел дәфтәре» дөнья күрә. Тәржемәләрдән А.Корнейчукнын «Украина далаларында» дигән комедиясе, Н.Задонскийнын «Мәшәкатьле ай», А.Островскийнын «Көн дә бәйрәм булмый» пьесалары да театр репертуарында урын ала. Ике спектакль – «Тормыш жыры» һәм «Украина далаларында» – Күчмә театрлар фестивалендә югары бәя ала. Кызганыч ки, 1948 елда Г.Йосыповны Академия театры коллективына режиссер итеп күчерәләр. Озак та үтми театрларда эшләүчеләрне кыскарту турында карар чыга: ошбу сәнгать учагында гына да 11 хезмәткәр кыскартылуга дучар була. Театрнын директоры һәм режиссеры итеп С.Вәлиев куела, 1950 елда исә яна житәкче итеп тәжрибәле, күпне күргән С.Вәлиева-Сульва билгеләнә. Ул театр репертуарын лирик әсәрләр белән баетуга өстенлек бирә. М.Фәйзинен «Галиябану», әзәрбайжан драматургы Ж.Жаббарлынын «Гөлчәчәкле кыз», М.Гафуринын «Кара йөзләр», Т.Гыйззәтнен «Башмагым» пьесалары сәхнәгә күтәрелә. Ләкин «хужалык эшләрендә йомшак» дип, 1962 елда аны да эштән алалар. Күптән түгел генә фронт киемен салган М.Хәмзин театрга житәкче итеп билгеләнә. Анын тырышлыгы белән төрекмән драматургы Б.Рахмановнын «Йөрәк серләре» , Р.Ишморатнын «Тормыш юлында» дигән пьесалары буенча спектакльләр куела.

М.Хәмзин 1952 елдан алып 1975 елга хәтле директорлык вазыйфасын башкара. 1975 елдан башлап икенче бер фронтовик С.Шәкүров коллектив белән идарә итә. Театр сәхнәсендә 1986 елны «Саф күнелгә тап төшми» драмасы, режиссеры – П.Исәнбәт, 1992 елда «Сөяркә», режиссеры – Ә.Зарипов, 1992 елны «Карт гашыйк» комедиясе дөнья күрә. Сонгысын театрнын баш режиссеры Р.Заһидуллин

ярдәме белән Татарстанның халык артисты М.Җаббаров сәхнәгә чыгара. Сугыш утын кичеп, театрыбызда эшләгән фидакарьләрнең икесе бүген дә безнең арада: берсе – Әлмәт дәүләт театрында эшләп лаеклы ялга киткән З.Туишева, икенчесе – быел 90 яшен тутырган, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Р.Тумашев. Бу олуг шәхескә аерым тукталып китмичә мөмкин түгел...

Сугыштан соң театрның художество житәкчесе булып Ә.Мәжитов, Г.Йосыпов, С.Вәлиева-Сульва, М.Хәмзиннар эшләсә, ә инде 1956 елда бу урынга Кәшифә апа Тумашева билгеләнә. Югары режиссер белеме булган талантлы хатын-кызның килеп чыгуы татар театры тарихында моңа хәтле күрелмәгән хәл була. Нык холыклы, сүзендә тора белүче Кәшифә ханым, алты ел гына эшләп калса да, 25 спектакль куя. Ул читтән чакыртып, яңа күтәрелеп килгән Г.Йосыпов, С.Өметбаев кебек талантлы яшь сәнгатькарләргә дә пьесалар куйдырта. Труппаның яшь артисты Гата Нуруллинга үзе язган әсәрләрен үзенә куярга мөмкинлек тудыра. Бу елларда театр эчендә демократия ныгый, хөсетлеккә урын калдырылмый. Кәшифә апа куйган Хәй Вахитның «Яшерен эзләр», «Беренче мәхәббәт» драмалары, Н.Исәнбәтнең «Рәйхан», М.Фәйзинең «Галиябану», Р.Ишморатның «Үлмәс жыр», К.Тинчуринның «Сакла, шартламасын» әсәрләре халык алдында зур уныш казана. Бу елларда М.Шәһидуллина, Л.Фарсина, Ф.Фарсин, М.Хәмзин, Г.Нуруллин, А.Сәйфетдинов, С.Мөхәррәмов, С.Әхмәров, Х.Хәмзин, Р.Кәримулин, К.Нуруллина С.Исмәгыйлова, Г.Вәлиев, Р.Кушловская, Г.Юнысова, Ф.Йосыпов, З.Хәлимуллина, З.Камалова, В.Минкина, А.Әхмәтжанова, Б.Галимуллина, С.Хөснетдинова, Г.Гыйматов, Х.Исмәгыйловлар сәхнә тота. 1963 елда күренекле режиссер дилбегәне сугышчан офицерга – улы Равил Тумашевка тапшыра. Күчмә театрның яңа үсеш чоры башлана. Коллективка яңа буын артистлары килә. Р.Мифтахов, Х.Шәкүрова, Н.Латыйпова, В.Хөснетдинова, Ә.Галиуллин, И.Мәхмүтова, Р.Хәбибрахманова, Н.Шәйхетдинов, Н.Сафин, З.Дусаева, М.Җаббаров, Х. Мәхмүтов, соңрак Р.Зәйнуллин, Ф.Фәтхуллиннар да иҗат коллективына килеп кушыла. Яшь артист Р.Мифтаховның махсус театраль белеме булмаса да, К.Тумашевада чирканчык алып, үзенең хезмәтен Р.Тумашев житәкчелегендә дәвам итә. Табигатьтән бирелгән моңлы тавышы белән жырлы рольләр уйнап, тамашачыларын әсир итә. Фидакарь педагогның тагын бер укучысы – И.Мәхмүтова да халкыбызның яраткан артисткасына әйләнә. Х.Мәхмүтов белән тормыш корып жибәреп, бүгенге көндә кызлары Лилия белән кияүләре Ринат Шәмсетдинов та өлкәннәрнең эшен театрда дәвам итә. Шулай ук бу Театр тарихында үзенчәлекле күренеш буларак, шофер булып эшли башлап, аннары артист сыйфатында хезмәт юлын дәвам иткән Роза ханымны бүген дә сагынып искә алабыз. Беренче иҗади чыныгу алып, академия театрына эшкә күчкән Г.Фәтхуллин, В.Минкина, И.Баһманов, Ф.Хафизова, Ю.Сафиуллин, Д.Касыймов, А.Хафизов, Л.Шакиржанова, И.Әхмәтжановларның да эзе бар күчмә театр тарихында. Сәнгатькарләрнең иҗади язмышында Р.Тумашев мәктәбе бик зур роль уйный.

Коллективта эшли башлаган елларында Р.Тумашев, интернациональ рухта тәрбияләнгән коммунист буларак, тәрҗемә пьесаларга күбрәк урын бирә. С.Алешинның «Тынгысыз йөрәк», В.Коростылеванын «Мин сиңа ышанам», К.Гольдонинның «Бирәү дә берни белмәсен», В.Шкаваркинаның «Чит кеше баласы», М.Горькийның «Мещаннар» пьесалары дөнья күрә. Сүз дә юк, тәрҗемә әсәрләргә татар тамашачысы начар йөри. Аңа үзенең менталитеты кирәк. Труппаның үз эчендә дә бу хәлгә каршылыклар туа. Озакламый министрлыктан режиссерга «тәрҗемә пьесалар белән генә мавыгасыз», дигән кисәтү ясала. Бу хәл бөтен дөнья җәүһәрләре белән татар халкын таныштырырга ныклап алынган иҗатчының кәефен төшерсә дә, соңыннан билгеле булганча, репертуарны татар драматургиясе белән баета. А.Гыйләжев, И.Юзеев, Т.Миңнуллин кебек яшь авторларның әсәрләренә алына. Ю.Сафиуллин, И.Юзеев, Р.Хәмит, Ә.Сафиуллин, Ю.Әминов, З.Шаһиморатов, А.Гыйләжев, Ф.Яруллин, Ә.Гаффарның драматург булып китүләрендә остазлык итә. Равил аганың иҗатына югары бәя биреп, «Литературная газета»да Инна Вишневская: «Бүгенге көндә татар драматургиясе бөтенсоюз күләмендә зур масштаблы», – дип яза. 1960-1980 елларда театрның баш режиссеры

тарафыннан Т.Закировның «Урман егете» (1964), Ш.Камалның «Хажи әфәнде өйләнә» (1965), Т.Миннуллинның «Умырзая чәчәкләре» (1968), И.Юзеевның «Бөркетләр кыяга оялый» (1970), авторның «Кыр казлары артыннан» (1974) дигән пьесалары сәхнәгә куела. Соңгы әсәрдә төп рольне уйнап И.Мәхмутова җыр-моңы, үзенең уены белән киң танылу ала. 1979 елны Т.Миннуллинның «Кырларым-тугайларым», 1980 елда Р.Хәмитнең «Кайтыр идем», 1984 елда Т.Миннуллинның бик озак еллар яратып каралган «Без бит авыл малае» драмасы да репертуарда урын ала. Төп рольләрне И.Мәхмутова, Х.Мәхмүтов, Т.Зиннуровлар башкара һәм бу әсәрләр белән алар Совет дәүләтенең татарлар яшәгән бөтен төбәкләрендә диярлек була. Татар телен, гореф-гадәтен саклап калуда, шуны төрле төбәкләргә илтеп җиткерүдә театрның күчмәлек чорында гаҗәеп зур хезмәт куела. Р.Тумашев режиссерлыгында 60 тан артык спектакль дөнья күрә. Театр сәнгатенең теориясен яхшы белгән остаз, актерлар гына түгел, драматурглар да әзерли. Ә күренекле драматург Т.Миннуллинның үз авызыннан шуны ишетергә туры килде: «Минем сәхнә язучысы булып китүемдә иң беренче чиратта Равил абыйның өлеше зур. Ул язган әсәрләремне сүтеп җыярга, анализларга өйрәтте». 1985 елны күренекле режиссерыбыз Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Р.Тумашев лаеклы ялга киткәч, күчмә театрда тотрыксыз чор башлана. Озак та үтми, чираттагы режиссер Ф.Хәбибуллин да эшеннән азат ителә. Моңа кадәр директор вазыйфасын башкарган М.Шиһаповны 1984 елда Р.Әбүлмәнбетов алыштыра. 1985-1988 елларда хәтле танылган язучы Р.Батулла, 1988-1991 елларга Д.Сиражиев баш режиссер булып хезмәт итә. Дамир шушы чорда яна бер драматург Разил Вәлиевнең әсәрләрен сәхнәгә менгерә. Бу сәнгать дөньясында үзенә күрә бер яналык иде. Халык Р.Вәлиевнең ике тамашасын да яратып карый. 1988 елда куелган мюзиклда күпчелек рольләрне режиссерның үз шәкертләре башкара. Менә шунда инде яхшы җырчы буларак Резеда Төхвәтуллина халыкка таныла. «Әйдә барыйк, кызлар карыйк» – яшьләрнең яратып караган спектакленә әйләнә. 1990 елларда Разил абый белән берлектә эшләнеп, сәхнәгә чыккан икенче әсәр «Әй машина, машина, житте минем башыма» диеп атала. Әлбәттә, бу иҗат дуслыгы әле бик озак еллар дәвам иткән дә булыр иде (кызганычка ки, театр эчендәге каршылыклы мохиткә бәйле), Д.Сиражиев эштән китә. Шуннан соң коллектив ике ел дәвамында читтән чакыртылган режиссерлар белән житәкчелек итә. Режиссерларга кытлык һәм бертуктаусыз алышынулар Р.Әбүлмәнбетовны бик борчый. Иҗат коллективын бергә туплый алырлык көчле рухлы җитәкче кирәк, тик каян алырга?! Ниһаять, 1992 елны, сынау йөзеннән Щукин исемендәге училищеда укып йөрүче Р.Заһидуллин әсәр куеп карарга чакырыла. Р.Заһидуллин театрга килүгә К.Тинчуринның «Йосыф илә Зөләйха» сатирик комедиясен тәкъдим итә. Спектакль 1992 елны сәхнәгә куелып, унай бәя ала алды. 1993 елның 10 мартында яшь булуына карамастан, Р.Заһидуллин баш режисер итеп билгеләнә.



*Н.Фәттах. «Итил суы ака торур».*

## Хәзерге чор

Хәзергене тулырак аңлар өчен, әз генә үткән елларга кайтып, кайбер тарихи хәлләргә дә күз салып алырга кирәк. 1950 елларда нык кысынкылыктан иза чиккән театрга Бауман урамындагы йорттан ике бүлмә табып бирәләр. Әлбәттә, бу театр

хәтле театрга әллә ни җиңеллек китерми. Ничек кирәк шулай спектакль әзерләп куялар, алар ел дәвамында төрле төбәкләрдә гастрольдә йөриләр. Шуңа күрә Күчмә театр артистлары читтә яшәүче татар халкының сагынып көтеп алынган кунагы да, рухландыручысы да, тарихи ватаннары белән бәйләүчесе дә иде. Ниһаять, 1960 елда кечкенә генә сәхнәсе дә булган Спассдагы мәйданчыгын манарасын коллективка тапшыралар. Монда хәтта җиһазлар сакларга да, административ бүлмәләр ясарга да урын табыла. Артистлар шулай да үзләренең эш урыннарын ирония белән «Кремль театры» дип атап йөртәләр. Ни генә булмасын, бу инде үзенә күрә аерым театр йорты! Мона кадәр күп борчу-михнәт күреп яшәгән труппага барыбер бәхет килгән кебек була. Шуның нәтиҗәсе буларак, иҗади көчләргә гомере буе кытлык кичергән театрга белемле яшьләр килә башлый. Т.Фәйзуллина, М.Җаббаров, З.Досаева, Н.Шәйхетдинов, Н.Сафин, Х.Шәкүрова, Л.Миннуллина, Н.Нәҗмиев, Ф.Ситдыйков, Г.Закирова, Л.Галләмова, Н.Вәлиева, Ә.Хәсәнова, И.Хәсәнов, З.Хәкимҗанова, Т.Нуруллин, З.Харисов, Т.Зиннуров, Г.Гарапшина, М.Нәҗмиева, З.Зарипова, Р.Төхфәтуллина, Ж.Әсфәндиярова һ.б. тупланеп хезмәт итә. Аларга соңрак И.Сафиуллина, И.Фәизов, Р.Шәмсетдинов, Л.Мәхмүтова, Ш. Фәтхетдинов, С.Вәлитов, И.Әхмәтханов, Э.Үтәганов, Г.Хафизова, И.Хафизов, Г.Гайнуллина, А.Фәтхуллина, Ф.Насыйбуллина, Х.Хөснетдинов кебек яшьләр кушыла.

...1985 елда Спасс манарасының түшәме ишелеп төшкәч, Күчмә театр коллективы кабат урамда кала. Тагын бер урыннан икенчесенә тинтерәп йөрүләр башлана. 1986 елны Татар дәүләт Академия театры әле яңа гына төзелеп беткән Кабан күле ярында урнашкан бинага күчә. Ә иске бина өчен көрәш башлана. Форсаттан файдаланып калыр өчен Күчмә театрның директоры Әбүлмәнбетов һәм ул чакта ук танылган артистлар М.Җаббаров, И.Мәхмүтова, Х.Мәхмүтов һәм башкалар кабинеттан кабинетка чабалар. Һәм, ниһаять, 1988 елда җиңү яулана: Горький урамындагы иҗат йорты күчмә театр коллективына тапшырыла. Шул ук елны аңа күренекле драматург, режиссер, актер К.Тинчурин исеме бирелә.

...1993 елда яңа гына театр бусагасын атлап кергән яшь режиссерга җиңел булмый, әлбәттә. Төрле холыклы төркемнәрдән стационар театр төзергә кирәк була. Р.Заһидуллинга театр директоры һәм беренче чиратта, яңа буын артистлар таяныч була. Аңа эше белән дә, түземлелеге белән дә үзен күрсәтергә туры килә. Яшь режиссер Н.Фәттахның «Итил суы ака торур» романы буенча язылган (Ф.Ситдыйков инценировкасы) зур масштаблы спектакльгә алына. Әсәрне куярга әзерли башлаганда ук каршылыклар килеп чыга. Н.Фәттахның ни сәбәпледер куйдырмаска аяк терәп каршы торуы нык гаҗәпләндерә. Димәк, язучының да башын кемнәрдер бутаган. Инде бар көчләрен биреп зур темага алынган иҗатчыларның кәефләре кырылса да, эшләрен көне-төне дәвам итәләр. Ләкин бер кирәкмәгән көрәш дәвамлы була, түзмәгәч режиссер: «Яхшы, Нурихан ага, без хәзергә әсәрне әзерлибез, генераль репетициягә сезне дә чакырабыз, ошамаса, чыгармыйбыз», – ди күңеле төшкән Р.Заһидуллин. Автор моның белән килешә, соныннан исә спектакльгә сокланаун белдерә. Тарихи әсәрдә инде халык алдында танылган И. Мәһмүтова, Х. Мәхмүтов, М.Җаббаров, Р.Мифтахов кебек артистлар белән беррәттән рольләргә яңа гына театр училищесын тәмамлап килгән яшьләр дә билгеләнә. Баһадир гәүдәле И.Әхмәтханов Тотыш ролен әйбәт кенә башкарып чыга. Ш.Фәрхетдинов, Р.Әкбәров, Ж.Әсфәндиярова да тамашачыда уңай тәэсир калдыра. Соныннан «Ватаным Татарстан» газетасында А.Юнысова «Бу спектакль – яшь режиссерның гына түгел, актерларның да зур уңышы. Әсәрдә мәхәббәт темасы бала белән ана мөнәсәбәте аша бирелеп, татар халкының үткәндәгесе оста чагылдырыла», дип үзенең сокланауын белдерә. Тотыш ролен башкарган И.Әхмәтханов 1994 елны К.Тинчурин исемендәге фестивальдә махсус призга лаек була. Бу зур күләмле әсәрдән соң Р.Заһидуллин Х.Вахитның «Кияүләр» комедиясен үзенчәлекле итеп сәхнәләштерә. 1994 елда дөнья күргән спектакльне дә тамашачылар җылы кабул итә. Шул ук елны баш режиссер, актер Ф.Ситдыйков белән иҗади хезмәттәшлеген дәвам итеп, И.Грекованың «Тол хатыннар көймәсе» повесте буенча инценировка яздыра һәм аны да сәхнәгә чыгара. Әлеге әсәргә тукталып китмичә мөмкин түгел. Әсәр эчтәлеген тамашачы күңеленә

илтеп житкерер өчен геройлар тормышы белән үзенә дә яшәргә, алар кичергәнне үзенә дә тояргa кирәк. Актерлар өчен зур тырышлык сораган инценировка, шул ук вакытта режиссердан да зур түземлелек һәм тырышлык таләп итә. Спектакль барышында сугыш вакытындагы коммуналь фатирнын ачлыктан, хәерчелектән явызланган, ирләрен, якын туганнарын югалткан совет режимы мескеннәренен авыр тормышы ачыла бара. Ирсез, баласыз калган хатын-кызларнын ачы язмышы чагылдырыла. Төп персонажларнын берсе – Әнисәнен үз-үзен таба алмаган улы Вәлим. Артистка Л.Миннуллина үз героенын бөтен фажигасен йөрәге аша үткәреп, тетрәндерерлек итеп житкерә. Икенче героиня Паркизәне – сүгенергә, орышырга, башкаларны кыерсытырга яратучы хатын образын Г.Закирова да тиешле дәрәжәдә башкара. Әсәр барышында шунысы да анлашыла: ул бүреләр арасында гына үзен бүреләрчә тота икән. Йомшаклык күрсәттенме, тотып ашыйлар, янәсе. Өченче ханым – Кәримә. Аны Л.Галләмова уйный. Биредә инде бөтенләй башка холык. Карап торырга йомшак кына, елмаючан. Тик үзенә генә кагылып кара, кара еланга әверелеп шундук чага. Аларга капма-каршы образ – сугыш афәтен үз башыннан кичергән, Ленинград блокадасында көчкә исән калган интеллигент, тәрбияле Флера ханым. Бу рольне уйнаган ике актриса да анын холкын дөрес чагылдыра. Шулай ук холыксыз Вәлим ролен, яшь актер булуына карамастан, И.Әхмәтханов оста башкарып чыга. Спектакльгә шул көннәрдә бәя биреп республика матбугатында татар газеталары «Яна әсәр – театрнын зур унышы» дип язып чыга.



*К.Тинчурин. «Сүнгән йолдызлар».*

«Тәгәри китте йомгагым» дигәндәй, яшь режиссернын әсәрдән әсәргә осталыгы, кыюлыгы, үз-үзенә булган ышанычы арта гына бара. Бер-бер артлы төрле драматургларга тукталa ул. 1994 елда татарнын Чеховы булган Р.Хәмитнен «Исәнлеккә-саулыкка», Н.Гаетбаевнын «Тынгысыз төн кәмитләре» дөнья күрә. Башкорт язучысы Гаетбаевнын да пьесалары ин беренче буларак ошбу театрда куела. 1995 елны П.Бомаршенын «Фигаронын өйләнүе», шул ук елны яшь актер Ш.Фәрхетдиновнын »Йолдызлы янгыры» дөнья күрә. Бу чорларда Р.Заһидуллин балалар тәрбиясенә дә нык игътибар итә, хәтта драматургларны театр коллективы арасыннан эзләп табу һәм үстерүне максат итеп куя. Сәхнә законнарын яхшы белгән профессиональ артистлар Ш.Фәрхетдинов белән Р.Сәгъдиевкә балалар өчен әкиятләр яздыра, төзәттерә, юнәлеш бирә, үзенә кирәгенчә сюжетын төзетә. Шул унайдан 1993 елны Ш.Фәрхетдиновнын «Әкият турында әкият», 1997 елны «Мыгыр, мыгыр мыгырдый», Р.Сәгъдинен «Баһадурнын бәхете» – 1994 ел, «Баһадурнын яна дуслары» – 1995 елда театр сәхнәсенә күтәрелә. Драматургия дөньясына яна көчләр, яна һава кирәклеген анлаган режиссер яшьләрне тарта. Бүгенгә кадәр Р.Заһидуллин тарафыннан куелган 50 дән артык сәхнә әсәре бар. Алар арасында Б.Брехтнын «Мамаш кураж һәм анын балалары», Ф.Лорканын «Канлы туй», Г.Зәйнашеванын «Гайфи бабай, өйлән давай», Ш.Камалнын «Хажи әфәнде өйләнә», Н.Исәнбәтнен «Хужа Насретдин», К.Тинчуриннын «Американ», «Сакла, шартламасын», «Сүнгән йолдызлар» һәм башка бик күп спектакльләр бар. Татарстаннын атказанган сәнгать эшлеклесе, Россиянен атказанган артисты төп эшенә тәнгәл рәвештә мөгаллим буларак, Казан театр училищесында, сәнгать академиясендә дә дистәләгән актерлар әзерләде. Аларнын күпчелеге төрле театрларга таралып, иҗат итә. Үзенен күне-

ленә хуш килгәннәре бүген К.Тинчурин театры сәхнәсендә уйный. Х.Хөснетдинов, И.Хафизов, Г.Хафизова, А.Фәтхуллин, Г.Гайнуллина, Ф.Насыйбуллин, З.Вәлиева һ.б. Р.Заһидуллин шәкертләре.

1988 елны театрга К.Тинчурин исеме бирелсә дә, жисеме кайтмый әле аның. Р.Заһидуллин бер гөнаһсызга корбан ителгән шәхеснең зур, даһи драматургның якты образын сәхнә әсәрләре аша тамашачыга кайтара. Язучының пьесаларына, иҗатына бәя биреп: «Ул татарның Шекспиры», – дип атый. 1993 елда К.Тинчуринның «Хәйләсез дөнья – файдасыз» комедиясеннән башлап» киткән режиссер 1999 елны «Сүнгән йолдызлар» драмасына туктала. Бу спектакль тамашачылар һәм театр белгечләре тарафыннан да югары бәяләнә. Төп рольләрнең күпчелеген үзе тәрбияләгән шәкертләре башкара. Сәрвәрне, җырчы актриса З.Вәлиева, Исмәгыйльне – И.Әхмәтханов, Надыйр Мәхдүмне уйнаган Ш.Фәрхетдинов исә Уфада уздырылган «Туганлык» фестивалендә «Иң яхшы ирләр ролен башкаручы» дигән бүләккә лаек була. Бу куелыш режиссер һәм актерларның чираттагы уңышы булып театр тарихына кереп калды. Шул уңайдан тагын бер кызыклы фактны искәртеп китәсе килә. Төркия дәүләт театрларының генераль директоры Леми Белгин Казанга килгәч, аңа К.Тинчурин театрында «Сүнгән йолдызлар» драмасын карарга насыйп була. Ул спектакльне яратып, аңа зур бәя бирә. Шул уңайдан Р.Заһидуллинга мөрәҗәгать итеп Төркия сәхнәсенә дә чыгаруын үтенә. 2011 елның кояшлы апрелендә спектакль Әнкара театры сәхнәсендә дөнья күрә. Тамашачылар үзләренә зур яңалык ача, ерактагы татар туганнарының пьесасын төрек телендә карап соклана. Хәтта бу әсәрне Алманиягә барып уйнап кайтулары да билгеле. Леми Белгиннан: «Ни өчен комедиясен куйдырмадыгыз», дип сорагач, ул болай ди: «Комедияне сатуы җиңел, ә драма әсәре йөрәккә үтеп керә һәм күңелдә озак саклана».

Даһи драматургыбызның исемен йөрткән театрның баш режиссеры бер-бер артлы К.Тинчурин пьесаларын театр сәхнәсенә чыгара. Аның берсе «Американ», икенчесе «Сакла, шартламасын!» комедияләре. Төп рольләрне яшь-яшь актерларга ышанып тапшыра. Һәм ялгышмый. «Американ»да Искәндәрне уйнаган Р.Гайзуллин, Дилбәр ролен башкаручы Гөлназ Нәүмәтованы тамашачылар яратып кабул итә. Шулай ук «Сакла, шартламасын!»да Резедә Сәләхова да үзенә тапшырылган Гөлҗамал ролен кәмит бизәкләргә баетып үзенчәлекле итеп башкара. К.Тинчуринның театрда «Зәңгәр шәл», «Җилкәнсезләр» кебек әсәрләре дөнья күрмәгән әле. Режиссерның әйтүе буенча, аның шул ике пьесасы гына түгел, башкалары да киләчәктә безнең сәхнәдә дөнья күрәчәк. Театрда, дүрт елга сузылган капиталь ремонттан соң, иркенләп эшләргә мөмкинлекләр кабат туды. Сүз дә юк, бүгенге көндә театрның бинасы тамашачыларны балкып каршы ала икән, монда аның директоры Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Ф.Мөсәгыйтовның өлеше бик зур. Өлкән буын артистларның сәламәтлеген саклауга да зур игътибар бирелә. Бина үзенең киң ишекләрен ачу белән 5-6 ел элек туктатылып торган К.Тинчурин фестивале дә директор тарафыннан кабат торгызылды. 2012 елның сентябрендә Россиядәге татар театр коллективларын ошбу сәнгать бәйрәменә җыйды. Киләчәктә дә бу иҗат бәйрәме ел саен диярлек дәвам итәр дигән ышаныч бар.

Борынгы бинада, ниһаять, иҗади эшчәнлек бар, ул бар көченә эшли, кайнап яши. Соңгы ике-өч ел эчендә генә дә театр репертуары бик күпкә яңартылды. Х.Ибраһимовның «Төн яна учакта», күренекле драматургыбыз Т.Миңнуллинның «Яшьлегем, җыраларлыгем», «Төш» пьесалары да сәхнәгә күтәрелде. Туфан ага соңгы спектакльне бик яратып кабул иткән иде. Ул аны кат-кат дуслары, Госсоветтагы хезмәттәшләре белән килеп карады, театрның баш режиссеры исеменә рәхмәтләр белдерде. Шулай ук башкорт язучысы М.Кәримнең «Айгөл иле» әсәре Казан тамашачысына ошады. Бу әсәрдә Ж.Әсфәндиярова, Г.Гарапшина, Л.Мәхмүтова, Р.Шәмсетдиновлар төп рольләрне башкара. И.Хәсәнов белән Т.Зиннуровлар да тәҗрибәле артистлар буларак, үз образларын тамашачы күңеленә хуш килерлек итеп уйный. Соңгы өч-дүрт ел гел уңышлардан гына тормады, әлбәттә. Театр үзенең искитмәле талантлы артистларын – Х.Мәхмүтов, А.Әхмәтова, Р.Хәбибрахманова, Ф.Ситдыйковларны югалтты. Ләкин тормыш дәвам итә, аларны И.Хафизов,

Л.Вилданова, А.Пискунов, Р.Сәләхова кебек талантлы яшьләр алыштырды. Яшь артистләр Г.Тукайның тууына 125 ел тулу уңаеннан үзләре үк музыкаль драма язып, мәктәп балаларына тәкъдим итте. Озак та үтмәде, М.Мәһдиев әсәрләре буенча инсценировка язып, шуны искитмәле оста итеп башкарып чыктылар. Шундыйрак жанрда күренекле язучыбыз, җәмәгать эшлеклесе Р.Вәлиевнең шигырьләреннән торган «Язмышым юллары» исеме астында яңа лирик спектакль дә дөнья күрде. Режиссер белән яшь актерлар шушы өч спектакльләре аша әдәбият-сәнгать белән кызыксынган мәктәп балаларының күңеленә юл тапты: 2012 елның ахырында Н.Хисамов язган әсәрдән «Йосыф илә Зөләйха» спектакле дә дөнья күрде. Спектакльнең декорациясе генә дә үзенчәлекле һәм бик катлаулы иде. Орбиталар әйләнешен хәтерләткән, сәхнә борылган саен җирлеге үзгәргән әлеге декорациянең һәм искитмәле бай киемнәрнең авторы – танылган сәнгатькәр Р.Моров. Масштаблы спектакль буларак, анда театрның барлык артистлары һәм театр училищесының шәкертләре дә катнашты. Төп рольне – Йосыфны – И.Хафизов уйнаса, Зөләйханы – Р.Сәләхова башкарды. Бу аларның четерекле, авыр образларга беренче алынулары иде. Казан халкы борынгы тарихка зур кызыксыну күрсәтеп, әсәрне сокланып карады. С.Мифтахов Кол Гали образын яшь артистларга үрнәк булырлык итеп, бөтен тәҗрибәсен эшкә җигеп уйнап чыкты.

Татарстанның халык артисты З.Харисов уенын да тамашачылар бик җылы кабул итте. Баласын җуйган Якубның өзгәләнүләренә җан газабын үзенең йөрәге аша үткәреп тетрәндерерлек итеп уйнады ул. Әсәрнең музыкаль композициясен күренекле композитор Резеда Әхиярова аеруча сихри итеп иҗат иткән. Спектакль барышында музыкаль яңгыраш аша әкият дөньясына җинел генә кереп китәсең. 2012 елны К.Тинчурин театрына Р.Заһидуллин шәкерте режиссер Р.Гарипованың да килүе куанычлы хәл. Чөнки иҗат коллективын эш белән дә, репертуар белән дә тәэмин итеп торыр өчен ике-өч куәчы кирәк. Татар сәнгатендә хатын-кыз режиссерлар бик күп түгел. Алар С.Вәлиева-Сульва, З.Тумашева, К.Тумашева һәм менә, ниһаять, Р.Гарипова. Тагын шунысы кызыклы, 1956 елны иң беренче эш итеп К.Тумашева Х.Вахитның «Яшерен эзләр» пьесасын куйса, туры килә бит, яңа килгән яшь режиссерыбыз Р.Гарипова да Х.Вахитның «Туй алдыннан» дигән әсәреннән башлады. Агымдагы елның апрелендә Резеда туташ К.Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» әсәрен, театрның традицияләренә тугры калып, сәхнәдә яңә кабызды. Спектакльгә өлкән буын артистларга оныклы булырдай яңа буын, ягъни театр училищесы шәкертләре эшкә җәлеп ителде. «Мәдәни җомга» газетасында спектакль турында Ч.Фәрхетдинова: «Резеда Гарипова спектакльне классик өслүптә хәл иткән. Төп басым актерлык осталыгына юнәлтелгән. Баш рольләрне театрга моннан берничә ел элек кенә килгән яшь актерлар башкара, өстәвенә һәрберсенең музыка коралларында уйный белүләре дә зур хәзинә. Шунысы шатлыклы: араларында инде бүген үк зур рольләр иҗат итәргә сәләтле шәкертләр дә бар», – дип язып үтте.

...Әлбәттә, өлкәннәр китә, яшьләр килә. Бу – табигый. Иң беренче чиратта, талантлылары килүе мөһим. Театр яшәреп торырга тиеш. Эченнән дә, тышыннан да балкып, үзенә чакырып торган сәнгать сараенда янадан-яңа сәнгать җәүһәрләре иҗат ителә, театр бүген дә җиң сызганып халкыбызга хезмәт итә. 80 еллык бәйрәмең белән, данлы театр!

**Радиф СӘГЪДИ,**
*драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.*

# РӘССАМДА КУНАКТА

## Тарихка тартылу

Һәркемнең үз аурасы була. Аура — бераз сәеррәк яңгырый кебек... Холкына күрә җеннәре дияргәме инде аны. Кеше аралашуда җиңел, якты күңелле икән — язма да шулай языла. Авыррак холыклы, үзсүзлерәк икән — чиләнергә әзер тор инде. Канәфи абый Нәфыйков белән эшләү исә искиткеч җиңел булып чыкты: тиешле вакытында тиешле кешесендә телефон номеры табылды, очрашып сөйләштек... Мәкаләсе дә үзеннән-үзе әкият кебек кенә үрелә дә бара.



Инде көз исе чыккан бер сентябрь иртәсендә студиясендә очрашырга булдык. Җиңел таптым — нәшрияттан ерак түгел икән. Күргәзмәләренә барганым булса да, якыннан беренче тапкыр танышу иде бу: эчтә ниндидер борчылу, каушау, тетрәнү бар. Әмма аралаша башлауның беренче минутларында ук шик-шөбһә таралды: Канәфи абый җылы, кешеләрне якын итә торган, аралашучан кеше икән.

«Ике остаханәгез бар инде, алайса?» - диеп сорыйм. Бусы улыныкы икән, улы Рамин да рәссам. Абстракция белән шөгыльләнә. Ә абстракция ул, Канәфи абыйның сүзләре белән әйткәндә, хисләрнең матурлыгын төсләр аша җиткерә белү. Әлегә Ригада ди, тиздән кайтырга тиеш, әтисе бик көтә инде, сизелә. Кызы Фирүзә — модельер. Оныгы исә — дизайнер, архитектура университетында белем ала, алдынгыларның берсе... Канәфи абыйның шөгыле шулай балаларына да «йоккан». Аларны сөйләгәндә олыларча гамь белән караган күзләре яна башлый. Ирен читләрендә тыйнак кына елмаю барлыкка килә.

Канәфи абыйның әсәрләренә карыйм да, үзеннән-үзе сорау бирәсе килеп тора: «әллә тарих җене дә кагылган инде сезгә?» Кабат балкып китә әңгәмәдәшем. Чыннан да, рәсемнән кала иң яраткан өлкәсе тарих икән. Мәктәптә тарих белән мавыгып алган. Рәссам булып киткәч тә гел үткәндәгеләр үзенә тартып торган аны.

Билгеле, Канәфи абый кабат-кабат барысын да җентекләп өйрәнә. Белми генә рәсемгә төшерү дөрес булмас. Инде тора-бара үз карашы да формалаша: «Безнең тарихны югалтырга тырышканнар: 1552дә яулап алучылар гарәп язулы китапларны, истәлекләрне юк итү эше алып баралар. Бу сәясәтне руслар гына алып барган дию дөрес үк тә түгелдер. Минә шул яулап алучыларның төп максаты — тупланган мәмләкәт белән идарә итү, моның өчен кешегә үткәнен оныттырырга кирәк бит инде. Тарих чыганагы — китап. Аларны халыктан җыеп, өеп-өеп яндыралар. Ул чакта китап кыйммәтле була, кеше ихтирам белән карый, саклап калырга тырыша. Шуңа гарәп язулы китапларны изге дип тану тарала. Бу исә генетик кимәлдә бездә әле дә бар...»

Әгәр мәктәптә тарих белән кызыксынса, рәссам булу теләге кайчан туган соң? Баксаң, чагыштырмача соң гына сайлаган икән бу юлны Канәфи абый: армиядә вакытта дивар гәҗитләре, «боевой листок» чыгаруда катнаша. «Башта язуың матур дип язарга гына чакырганнар иде. Аннан ничектер карикатуралар ясаган идем, охшаш, күңелле килеп чыккан, ахры, гәҗит чыгаруны гел мина куша башладылар...» - дип сөйләп китте.

Яхшы гына килеп чыккач, күңеле үсеп китә, күрәсең, ныклап кызыксына башлый. Казанга кайткач, рәсем студиясенә языла. Аннан юллар училищегә илтә. Диплом яклау вакытында болар янына галим Фоат Галимуллин килә һәм Фәннәр Академиясенә эшкә чакыра. Канәфи абый бара, анда бит тарихи китапларга иллюстрацияләр

ясарга кирәк була. Ике кызыксыну да бер ноктада кисешә сыман. Фоат Галимуллин китаплар бирә, материал белән таныштыра. Булачак рәссам кызыксына, ләкин барысын да тиешле дәрәҗәдә башкару өчен белем һәм техника житеп бетми кебек. Ә ул вакытта бер дусты Үзбәкстанга укырга киткән була, Аны да чакыра. Имтиханнарны яхшы гына тапшырып чыккан егетне шунда ук күреп алалар, бер мөгаллим хәтта үз канаты астына сыендыра аны.

Анда укыган елларны исенә төшерергә ярата Канәфи абый. Үзбәкләр, ди, тарихларын күтәрә энә. Тәрбиясе, атмосферасы ук башка ул җирләрнең, ди. Безнекеләрдә исә басып алынган халык психологиясе бар...

## Милли җанлы дигәндә...

Татар милләте, татар халкы үткәненә кереп чумабыз. Канәфи абый белән башкача булмый да, һәр рәсеме — тарихка бер караш. Портретлар булсынмы ул, күренешме, мөһим түгел, һәркайсында - кеше язмышы. Менә без Болгар дәүләтенә аяк басабыз, монда җир туе, беренче буразнага йомырка, балык ыргыталар, ат ярышында җиңгән батырга он сибәләр, ул ап-ак була. Баксаң, әкиятләрдәге Камыр Батыр нәкъ шушы йоладан кереп калган икән. Шулай рәсемнәр арасында «адашып йөргәндә», сәнгать фәннәре кандидаты Г.П. Тулузакова сүзләре искә төшә: «...Егерменче гасыр котылгысыз рәвештә үзеннән милли яктан башкаларга тиңлегенне таныту заманы булды. Алда торган мәсьәләләрнең берсе — татар профессиональ рәсем сәнгатен булдыру иде. Ислам диненең рәсем сәнгатен үз максатларында кулланудан баш тартуын һәм нәкыш белән скульптураның тотрыклы формалары үсешен билгеле бер дәрәҗәдә чикләвен дә искә төшерсәк, милли татар сәнгатен формалаштыруның шактый четерекле бурыч булганлыгын аңлау кыен түгелдер». Уйлап карасаң, Канәфи абый пумаласыннан рәсемнәр тама башлаганга кадәр турыдан-туры дәвам ителгән традицияләр, татар милли рәсем сәнгате кануннары, сәнгать теле урнашмаган диярлек. Шуна да Канәфи Нәфыйковның төп таяну нигезе булып урыс, Аурупа, Көнчыгыш илләрдәге рәссамнар хезмәте тора кебек. Шул ук вакытта, милли җанлы татар кешесе буларак, Нәфыйков милли төсмерләр булдырырга омтыла. Чыганак итеп сакланып калган декоратив-кулланма иҗат билгеләрен сайлый. Һәм ялгышмый. Тора-бара, кулы остарган саен, дөньяга берсеннән-берсе үзенчәлекле әсәрләр туа башлый. Аларга бакканда төрле хисләр бәйләнә күңелгә: кайчак сурәтләр җанлы кебек — һәр хәрәкәтенне күзәтә, һәр сулышынны тоя сыман. Үзенә күрә вакытлар аша күчеш.

Сурәтләрен төшергәндә, Канәфи абый гүя шул чорның бер кешесе күзлегеннән карый. Мәсәлән, «Нардуган» (2010) сериясе берничә күренештән тора: «Салкынны җиңү», «Күчтәнәч җыю», «Шайтан тавын ишү», «Бәйрәм иту. Корбан ашы пешерү». Яки 1984 елдагы «Батырша Шлиссембург төрмәсендә» хезмәте, 2000 елда иҗат ителгән шагыйрь Габделҗаббар Кандалый портреты, Габдулла Тукай белән Сәгыйть Рәмиевны күрсәткән «Йөрәк уты» (1976) — һәркайсы сине үз эченә суырып алып керә төсле. Чынлыгына, бу вакыйга нәкъ шулай булганына ышана башлыйсың сымак. «Сөембикәнең иле белән бәхилләшү» (2003) картинасы үзенә патшабикәнең генә түгел, ә татар халкының барлык моңын, фаҗигасен җыйган төсле. Ләкин бу әсәрдә без өмет чагылышлары да таба алабыз. Гүяки Аллаһ ярдәме белән әле барысы да үзгәрә ала. Ә менә «Сөембикәнең иленнән сөрелүе»ндә тойгылар басынкыланган, өметне вакыйгалар белән килешү, әрнү алыштыра.

Канәфи абый портретлар, пейзажлар белән таныштыра... "Туган якка мәхәббәт нәрсә ул?" — дип сорарга кирәк тапмыйм. Үз нигезенә булган тойгыларын чагылдырмый кала алмыйдыр инде ул рәссам. Иҗат кешесе бит хисләр алдында көчсезрәк була. Ә Канәфи абый өчен туган авылы — изге урын, андый җирләрдә кеше үз-үзенә кайта, вакыйгаларны җентекләп өйрәнә һәм гомерлек нәтиҗәләр ясый. Менә хәзер дә бит рәссам шәһәр читенә омтыла: анда тынычрак, анда сулыш иркенрәк, ди. Шулай булырга да тиештер инде ул: уйлану, эзләнү, фикерләү, хис-кичерешләргә корылган иҗат тын-тавышсыз җирдә, кеше күзеннән ераграк туадыр.

## Дин һәм сәнгать

Кеше сурәте төшерү гөнаһ, дин мона каршы чыга, диләр. Әлеге сорауга әңгәмәдәшемнен җавабы әзер: «Бакый Урманче белән бу сорауны өйрәнеп утырдык. Шундый карарга килдек: бу табу көчләп чукындыру вакытында килеп чыккан булырга тиеш. Ул вакытта йорт түренә иконалар куйдырганнар, аларны алырга рөхсәт булмаган. Әлеге табу шул вакыттагы рухи яралар сәбәбе дип беләм. Коръән тәфсирләрен укып беләм, андый әйбер табалмадым».

Авыр чаклар булгандыр инде, дип кенә сорамакчы идем, әйтерсен, Канәфи абый уйларымны укып алды: «Хатыным — иң зур таянычым иде минем. Училищенын өченче курсында өйләнештек, ә Үзбәкстанга ул мине бала белән озатып калды,» - ди Канәфи абый. Чыннан да, башта җинел булмый, тар гына фатирда яшәгәннәр, шунда ук буяу исе, рәсемнәр, такталар... "Тормышнын вак-төягенә бирешмичә, иренен киләчәгенә ышанып, алай гына да түгел, канатландырып та торган ханымнарга рәхмәт әйтелергә тиештер. Рәссамнар язмышындагы иң җете төсләр — аларныкы". Мондый җылы сүзләр елмайдыра.

## Балачакка сәяхәт

Рәсемнән рәсемгә сәяхәт итә-итә, авылга килеп чыгабыз. Нигәдер балачак искә төшә. Рәссамыбыз Чирмешән районынын Иске Үтәмеш авылында 1938 елнын 15 ноябрендә туа. Бер елдан сон әтисе вафат була һәм әнисе туган авылына — Чыгадайга күчеп китә. Әнкәйнен ир туганнарынын сугышка китүен, бер-бер артлы дүрт улын озаткан Шәмсиҗиһан әбекәйнен акылын җуюы күнелгә сенеп калган, ди ул. Канәфи абыйнын балачак истәлекләрен сөйләвен үтенәм. Аларны сезгә түкми-чәчми тапшырыйм әле...

«Балачак — иң матур һәм тәмле вакыт инде ул. Рәсемнәрдә, истәлекләрдә гел шунда әйләнеп кайтасын. Абыйлар сугышка киткәндә, тәрәзәдән карап калган идем. Ике яшь тирәсеме икән мина: тәлинкә - кружкасын алып чыгып китте. Күз алдында картина кебек сакланган. Белмим, алай рәссам булам дип хыялланмадым кебек тә, ләкин бер күрешкәндә укытучым Хәдичә апа әйтмәсенме: рәссам буласы булганга икән, дәфтәр читләрен буяп бетерә иден. Бәлки, берәр тартылу булгандыр, ул вакытта кем ана игътибар итә инде. Тагын шул истә калган, малай-шалай белән су буена төшеп, кош сыман балчыктан сыбызгы ясый идек: күгәрчен, чыпчык. Эченә тишек тишкәч, сызгыра ул. Менә шуны һич онытасым юк.

Бервакыт мин югалдым. Әнкәй урманга җиләккә җыена. Мин дә иярдем. Башта өйдә калдырырга уйлаганнар иде дә, үземнекен иттем, калмадым. Ләкин ярты юлны узгач, кире китәсе килә башлады. Кайттым да киттем. Тик үз өебезгә түгел, ә күрше авылга: башта шунда торган идек. Әни кайткач карый икән — мин юк. Кичкә кадәр эзләгән... Табылдым тагын аннары. Сугәр диган идем дә, ачуланмады үзе, нык итеп кочагына кысты.

Малай халкы шук була бит инде ул. Төрле «батырлык» эзләп кенә йөри. Күршедә бик уңган бакчачы бабай бар иде. Малайлар белән җыелып, шунын бакчасын кердек бер җәйдә. Бер кердек, ике кердек... Анда алма, чия, карлыган дисенме — нәрсә генә юк. Теге бабай яхшы кеше иде үзе, ләкин туйгандыр бездән, бервакыт алма агачы төбенә бүре капкыны куйган. Шунда ялгыш кына эләксән — бетте, аксак каласын. Мин экрен генә капкынны кистем дә, сүтеп алып кайттым өйгә. Мине дә ачуландылар, теге кешене дә. Икебез дә гаепле калдык».

Шулай сөйләшә-сөйләшә, бер рәсемнән икенчесенә сәяхәт итә-итә, көн кичкә авышты. Казан урамнарын фонарьлар куе сары төскә буяды, эштәге халык өйләренә ашыкты... Ә мин инде моннан ерак — каядыр Болгар җирләрендә, патшалар-ханнар арасында. Шул ук мизгелдә язучылар белән таныштыра Канәфи абый, авылына кайтып төшәбез... Ничек кенә булмасын, һәр сәяхәт тәмамлана. Рәссам остаханәсеннән үзем белән бер кочак күнелле һәм якты истәлекләр алып киттем. Кеше — дәрья диләр, ә иҗат кешесе океандыр ул, океандыр...

**Эльвира ҺАДИЕВА**

# ЯЗМЫШ БУРАЗНАЛАРЫ

Айдар Садри улы Хафизов Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры труппасына 1970 елда — Казан театр училищесын тәмамлаганнан соң кабул ителә. Сәхнәдә уйнаган беренче роле Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» пьесасы буенча куелган спектакльдәге Сәйяр була. Яшь артистның уйнавы җәмәгатьчелек тарафыннан уңай бәяләнә. Театрга темпераменты һәм сөйкемлелеге белән үзенә җәлеп итеп торучы, музыкаль әзерлеге һәм сәхнә пластикасы белән сөендерүче өр-яңа герой килүен искәртә тәнкыйтьчеләр. Театрның ул вакыттагы сәнгать җитәкчесе Марсель Сәлимҗанов Айдар Хафизовка һәр яңа әсәрдә берсеннән-берсе җаваплы рольләрне тапшырып кына тора, шул рәвешле яшь артистка ышанычын һәм зур өметләр баглавын күрсәтә ул. Һәм яшь егет бу ышанычны аклый да — татар театр сәнгатенә гомере буе зур бирелгәнлек һәм тугрылык белән хезмәт итә.



Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә Айдар Хафизов тудырган образлар жанры һәм стиле буенча гаять киң колачлы. Бу образлар арасында дөнья һәм рус классик драматургиясе ядкәрләре белән беррәттән, татар классик драматургиясенә караган әсәрләр дә, заманча пьесалар да бар. Айдар Хафизов иҗат иткән образлар ихлас һәм күңелгә үтеп керә торган. Иҗтимагый яссылыктагы геройлар икән, алар, кагыйдә буларак, кешелек идеаллары өчен көрәшәләр, ялганга, гаделсезлеккә кискен каршы төшәләр. Аяз Гыйләҗевның «Китмәгез, тургайлар!» пьесасындагы Азамат, Кәрим Тинчуринның «Казан сөлгесе»ндәге Салих, Карло Гоццинның «Болан-Патша»сындагы Дерамо, Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ындагы Җиһангир хан, Уильям Шекспирның «Явызлыкка авызлык» пьесасындагы Транио, Эдуардо де Филиппоның «Гаугалы гаилә»сендәге Пеппино, Юныс Сафиуллинның «Идегәй» әсәрендәге Кадыйрбирде, Туфан Миңнуллинның «Хушыгыз!»ындагы Шәһит, «Әлдермештән Әлмәндәр»ендәге Газраил һ.б. күпсанлы рольләрен тамашачы бүген дә рәхмәт хисләре һәм сагынулы бер ярату тойгысы белән хәтерендә яңарта.

Айдар Хафизов һәр яңа образга бик җитди карый: героена хас булырга тиешле сыйфатларны җентекләп барлый, аңа хәтердә озак сакланырлык, кабатланмас төсмерләр, җете буяулар өсти. Характерны тудырганда, гадәти булмаган алымнар куллана белә ул. Бигрәк тә классик әсәрләргә караган рольләрдә ачык чагыла бу. Артист искиткеч бай фантазиясе һәм нечкә тоемлавы белән сокландыра. Геройларын да бай һәм кабатланмас эчке дөньяга ия шәхесләр итеп гәүдәләндерергә нәкъ менә шул югарыда санап чыккан сыйфатлар булыша аңа. Тамашачысын еллар буе әсирлектә тотуының сере дә — шунда.

Соңгы елларда иҗат иткән рольләрен генә саный китсәк тә, аларга сокланмый кала алмас идек. Иҗатының бу чорында тудырган образларга нинди уртак сыйфатлар хас соң, диярсез. Аның соңгы елларда иҗат иткән геройлары халкыбызның иң асыл, затлы сыйфатларын туплаган: алар акыллы, зирәк, зыялы, кешелекле... Айдар абый татар менталитетының бөтен нечкәлекләрен тоемлавы һәм рольләре аша бу хәзинәне халыкка да җиткерә белүе белән зур хезмәт башкара.

Туфан Миңнуллинның «Шулай булды шул» пьесасындагы Нургали образы, әйтер-

сен, Айдар Хафизов өчен махсус язылган. Болай әйтүем юктан гына түгел, чөнки бу геройны тудырганда, артист образның эчке дөньясына шулкадәр тирән үтеп кергән ки, вак кына, беренче карашка, әллә ни күзгә ташланмый торган нечкәлекләр дә Нургалины тулы психологик бөтенлегендә гәүдәләндерүгә хезмәт итә. Тамаша залында утыручы халык аны сәхнәгә килеп чыгуга образ буларак кабул итә. Моңа ирешү өчен артистка жиде кат тир түгәргә, һәр детальне, нечкәлекне юктан бар итәргә, ә аннан камилләштерергә кирәклеген күз алдына да китерә алмый тамашачы. Әсәр сәхнәдә яши башлаганчы, актёр белән режиссёр арасында катлаулы озын диалог баруын, кыскасы, искиткеч зур хезмәт башкарылуы турындагы уйны инде әйтеп тә торасы юк... Һәм бу — дөрес тә, тамашачыга моны күзалларга кирәкми дә! Сәхнә иллюзиясе тудырган иң камил табигыйлеккә бары тик чын һәм гажәеп талантлы актёр гына ирешә ала! Нургали образын «тотып торучы» төп идея — кешелеклелек, үз бәясен яхшы белү һәм башка кешеләрдә хөрмәт хисе уята алырлык зирәклек. Хәтта кызына кияү «сатып алганда» да ул әдәп-әхлак кагыйдәләреннән тайпылмый. Чөнки ул әле яшьләр белеп бетермәгән хакыйкатьне, язмыш пышылдавын тоеп эш йөртә.

Тагын бер нәрсәне искәртеп үтәсем килә: Айдар Хафизов беркайчан да режиссёр сызган юлдан тайпылмый, нечкә тоем, әдәплелек, үздисциплина кебек асыл сыйфатлар әсәрне сәхнәгә куючы һәр оста белән уртак тел табарга ярдәм итә аңа. Ләкин режиссёр әйткәнгә бер карусыз буйсынып, аның шәрех-тәкъдимнәренә генә разый булып йөрүчеләрдән дә түгел Айдар ага. Киресенчә, режиссёрга оригиналь фикерләрен, рольнең көтелмәгәнчә «укылышы»н тәкъдим итәргә әзер тынгысыз, эшлекле актёр ул.

2007 елның мартында театр җәмәгатьчелеге шау-гөр килеп татар театрының 100 еллыгын тантана итте. Беренче татар актрисасы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская турында Нәкый Исәнбәт иҗат итеп калдырган «Гөлҗамал» әсәре дә сәхнәгә махсус, юбилей уңае белән, куелды. Бу спектакльдә Айдар Хафизовка төп героиняның капма-каршысы булган иске карашлы, катып калган фикерле сәүдәгәр Ишмаев ролен башкарды. Нәкый Исәнбәт пьесаны әле совет хакимияте чорында иҗат иткән, ул чакта Ишмаевны ул шулай күргән. Образда чор штамплары сизелеп тора. Әмма Айдар абый, рольгә алынгач та, үзенең яңа, заманча шәрехен тәкъдим итте. Аның Ишмаевы тар фикерле фанатик түгел, ә, киресенчә, барысын да яхшы белеп, алдан күреп, ситуацияне үз файдасына борып эш йөртүче кеше. Мондагы Ишмаев яңа туган һәм күтәрелеп килгән татар театрының җәмгыятьтәге житешсезлекләрне калкытып күрсәтәчәген, гуманизм идеяләрен алга сөрәчәген бик яхшы аңлый. Ә идеологик кыйбласы җәмгыятьтәге чирләрне күрсәтеп, халыкның үзаңын үстерүгә, аны агартуга юнәлтелгән театрның монополь сәүдә эшенә дә янавы бар бит! Менә нәрсә борчый аны. Бу геройның сөйләмен дини төшенчәләр, Коръәннән өземтәләр чуарлый, әмма, асылда, алар бары тик тышкы ябынча гына. Бу бизәкле ябынча кыңгыр эшләрне каплап тору һәм халыкта шик уятмау өчен бик уңайлы. Рольнең болай укылышы автор (бу очракта Нәкый Исәнбәт) идеясе белән һич тә каршылыкка керми, заман сәхнәсендә исә бик тә актуаль яңгыраш ала.

Гаяз Исхакый әсәрләренә нигезләнеп Мансур Гыйләжев һәм Ризван Хәмид әзерләгән «Курчак туе» әсәренең сәхнәләштерелүе соңгы еллардагы иң зур вакыйгаларның берсе дип саналырга хаклы, минемчә. Бу спектакльнең композицион-эстетик бөтенлеген Гайни бай образыннан башка күз алдына китереп булмый. Нәкъ менә шушы образ әсәрнең иҗтимагый яңгырашын да билгеләүче булып тора. Чөнки ул — үз заманының гына түгел, ә бүгенге җәмгыятьнең дә иң авырткан проблемаларын бергә җыя. Бу персонажның интеллекты, акылы мал җыю, табыш алуга юнәлтелгән, әлеге максатын тормышка ашырганда, ерткычларча кылана, якыннарының кичерешләре, язмышы турында да уйламый ул. Мәскәү һәм Санкт-Петербург, Әнкара һәм Ташкент, Казан һәм Будапешт театр тәнкыйтьчеләре «Курчак туе» спектакле турында сөйләгәндә яки язганда, Айдар Хафизов иҗат иткән Гайни бай образын искә алмый калмыйлар. Бу рольнең камил эшләнешенә сокланалар, артистның осталыгына югары бәя бирәләр.

Зәки Зәйнуллин әсәре буенча куелган «41нең арбалы хатыннары» спектаклендәге

кулак Зәйнулла роленә дә тукталып үтәсем килә. Улын һәм анын гаиләсен йорттан куып, аларны ач үлемгә дучар итеп, Зәйнулла дөрес хөкем кылдым дип ышана. Айдар Хафизов тамашачыга тәкъдим иткән бу персонаж һавалы, саран, үз фикерендә катып калган адәми зат, анын өчен бу дөньяда бер генә хакыйкать бар — көчле кеше хакыйкате. Шушы күнелне кайтара торган яклары өчен генә дә Зәйнулланы инде куралмый башларга мөмкин, әмма болай тупас шәрехләнгән роль Айдар Хафизовныкы булмас иде. Ул безгә Зәйнулланын будыклылыгын, жиргә нык басып торуын күрсәтә, дөнья куа белгән бу кешенен бар нәрсәгә кайнар тир түгеп, зур көч куеп ирешеүен исбатлый. Зәйнулланын психологиясе ачыла барган саен, тамашачы аны анлый һәм хәтта теләктәшлек тә белдерә башлый. Шул рәвешле, тискәре гамәлләре белән шактый кешенен язмышына тәэсир иткән персонажнын «икенче яссылыгы» ачыла, тормышта һәр нәрсәнен сәбәбе булган кебек, сәхнәдәге образнын да кылганнары тормыштагыча — нигезле һәм котылгысыз булуына инанасын. Айдар Хафизовнын артист буларак зур унышы — рольне тормыштагыча калку һәм ышандыра торган итә белү, аны тамашачы хәтеренә сендереп калдыру.

Айдар абыйнын тагын бер зур роле — «Хан кызы Турандык» спектаклендәге Альтоум. Хәтерләсәгез, Карло Гоццинын бу әсәрен Камал сәхнәсендә Кытай режиссёры Ма Джэньхон сәхнәләштергән иде. 2012 елда әлеге спектакль белән безнен театр Пекин шәһәрендә Кытай милли театрынын Халыкара фестивален ачып жибәрде.

Уку-укыту эшчәнлегенә дә тукталасым килә Айдар абыйнын. 2004 елда ул Казан дәүләт мәдәният университетында актёрлар курсын укытып чыгарды. Шушынын белән генә дә Татарстан Республикасында театраль белем бирү юнәлешендә зур эш башкарды дип саныйм, гәрчә театрда яшьрәк буынга ул һәр репетиция саен чын осталык дәресләре биреп барса да. Анын күпчелек укучылары бүгенге көндә республикабыз театрларынын алдынгы сафларында уйныйлар, монысы да укытучыларынын педагог буларак зур казанышы турында сөйли.

Талант — сүз белән анлатып булмый торган бөеклек, күкләр бүләге ул. Сайлаган һөнәреннен нечкәлекләренә, осталыкка өйрәтеп була, әмма кешегә талантны өстәп куеп та, тартып алып та булмый. Һәркем дә сәхнәдә яшәр өчен яратылмаган. Айдар аганын педагог буларак талантын күрсәтүче тагын бер факт: тормышын сәхнәгә багышламаган укучыларын да ул театрга тугры булып калырлык итеп тәрбияләгән. Аларнын күбесе бүген административ вазыйфалар башкаралар, театрны яшәтер, үстерер өчен зур көч куялар. Айдар Хафизов әзерләгән ике диплом спектаклен — Эмиль Золянын «Рабурден варислары»н һәм Туфан Миннуллиннын «Ай булмаса йолдыз бар»н — үз заманында Камал театрынын репертуарына да кертkәннәр иде, бу факт спектакльләрнен югары дәрәжәдә әзерләнгән булуы турында сөйли, билгеле.

Айдар Хафизовнын практикасындагы тагын бер зур ижади юнәлеш — ул театральләштерелгән концертлар әзерләү, юбилейлар һәм ижат кичәләрен сәхнәгә кую. Айдар ага бу кичәләрне әзерләгәндә, кичә геройларынын ижатына, тормыш-биографиясенә чын мәгънәсендә кереп «чума», кыскасы, яратып эшли ул бу эшләрне. Монда ана зур тормыш тәжрибәсе, әдәбиятны һәм тарихны яхшы белүе, заманны тоемлавы, эстетик тәрбиясе, зәвыгы ярдәмгә киләдер дип уйлыйм. Шуна да ул уздырган кичә-тантаналар «юбилейлар рәтеннән берсе» буларак кына түгел, ә кабатланмас рәсеме, аһәне белән истә кала. Бөтендөнья татар конгрессы делегатлары бөек татар шагыйре Мөхәммәдьярнын тууына 500 ел тулу унае белән Айдар Хафизов сәхнәләштергән тамашаны юкка гына бик озак вакытлар буена сокланып искә алмаганнардыр.

Үзенен житмеш яшьлек юбилеен Айдар абый Хафизов Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрынын күренекле һәм ихтирамга лаек артисты, Татарстан Республикасынын халык артисты, педагог-тәрбияче, режиссура өлкәсендә яна тәжрибәләрдән курыкмаган эзләнүче, кин жәмәгать эшлеклесе буларак каршы ала.

Юбилей алдыннан мин кадерле артистыбыз белән әнгәмә корырга булдым. Күп нәрсәләр турында гәпләштек без — артист язмышынын бәхетле һәм аянычлы яклары, 70-90нчы еллар театры һәм заманча формалар, актёрлык таланты, бу һөнәргә өйрәтү серләре, драматургия, режиссура, үз буыны вәкилләре һәм яшь коллегалары...

**— Айдар абый, сез XX гасырның икенче яртысыннан башлап Камал театры сәхнәсендә күренгән барлык актёрлар белән дә уйнаган, барлык режиссёрлар кулы аша да узган кеше. Әйтегез әле, бу вакыт аралыгында театр нык үзгәрдеме? Кайсы якка үзгәрде? Хәзер кай якка юл яра? XXI гасыр театры XX гасыр театрыннан нәрсәсе белән аерыла?**

— Мин театр училищесына 1961 елда укырга кердем. Ул чакта безнең укый торган аерым бинабыз булмаганлыктан, дәресләр театрларда уза торган иде. Актёрлык осталыгы буенча дәресләр Камал театрының репетицияләр залында уза, шунда ук сәхнә сөйләмен, кайбер башка дәресләрне дә үзләштердек. Ә дәресләр арасында «тәрәзә»ләр була бит инде. «Тәрәзә»ләрдә күпчелек студентлар кайсы кая таралыша, ә мин театрда калам. Репетицияләрне күзәтергә. Галеркада утырам һәм күзәтәм: ничек туа спектакль дигән могжиза... Әле үзем эшли башлаганчы ук бик күп режиссёрларның эшләрен күрү бәхетенә ирештем. Мәскәүдән щепкинчыларның кайтып төшкән чакларын бик яхшы хәтерлим, режиссёр Габдулла абый Йосыповның алар белән Аяз Гыйләҗев әсәре буенча «Көзге ачы җилләрдә» спектаклен әзерләвен. Щепкинчыларның һәр адымын күзәтә идем. Әле япь-яшь Марсель Сәлимҗановның диплом спектаклен ничек эшләвен дә хәтерлим. Островскийның «Котырган акчалар»ы иде ул. Моның белән бәйле бер эпизодны да сөйләп узасым килә.

Менә спектакль әзер диярлек, прогоннар бара. Спектакльдә театрның әйдәп баручы артистлары уйный — Ильская, Әбҗәлилов, Празат Исәнбәт. Чираттагы прогоннарның берсе башланды, 10-20 минут уздымы икән, Васильков ролен уйнаучы Празат Исәнбәт кинәт кенә персонажының кул таягын алып идәнгә атып бәрде, һәм ярсып кычкырып җибәрде: «Сез нәрсә, кем өчендер уйнаган булып кыланасыз? Ник әзерләнмәдегез?! Каян бу сүлпәнлек?!» Мин аның белән 40 ел буе ингә-ин эшләгән кеше, болай кабынып киткәнен күргәнем булмады. Ул бик тыныч, сабыр кеше. Шул мәлдә барысы да тынып калды. «Әйдәгез, әзерләнер өчен 10 минут, прогонны яңадан башлыйбыз!» Игътибар ит, моны режиссёр түгел, актёр әйтә. Ә Сәлимҗанов үз урынында тын гына утыра бирә, ул чакта әле беребез дә аның нинди шәхес булачагын күз алдына китерә алмый идек бит. Беренче эше. Эндәшми генә тып-тын утыра. Ә 10-15 минуттан соң артистлар шундый итеп уйнап күрсәттеләр... әле дә күз алдымда тора аларның уены — бөтенләй башка эмоцияләр, характерларның психологиясе һәр детальдән, жесттан, мимикадан аңлашыла, бөтенләй яңа темпоритм... Әйтерсең, аларны сәхнәгә өр-яңадан әвәләп менгергәннәр! Асылда, аларга режиссёр кычкырырга тиеш иде ул урында, әмма Марсельнең әле студент чагы, диплом спектакле, монда эре, җитди актёрлар составы, ул аларга кычкырырга, әлбәттә, кыенсынгандыр. Ә Празат абый, үзе дә режиссёр кеше буларак, яшь коллегасының хәленә кергән. Башка режиссёрлар белән дә андый хәлләрне хәтерлим.

Педагогым — Рифкать Бикчәнтәев, мин аның репетицияләрендә булырга ярата идем. Камалдан китеп, Кучмә театрда эшли башлагач та, репетицияләренә шунда йөрүемне дәвам иттем. Аның репетицияләре башкаларныкыннан бик нык аерылып тора иде. Беренчедән, аның искиткеч юмор хисен искә аласым килә. Нәкъ менә шул юмор репетиция вакытындагы четереклерәк моментларны менә дигән итеп җиңеләйтеп җибәрә иде. Икенчедән, аның үзендә дә ниндидер очкынлы дәрт, җиңеллек бар иде. Кайбер башка режиссёрларда вакыт-вакыт «академик» сыйфатлар да чагылып куйгалый, аңарга бу бөтенләй хас түгел иде.

Минем күз уңымда тулы бер йолдызлы актёрлар плеядасы үсеп чыкты: Шәүкәт Биктимеров, Ринат Таҗетдинов, Равил Шәрәфиев, Нәҗибә Ихсанова, Гөлсем Исәнгулова... Алар сәхнәдә бөтен көчләрен биреп уйнадылар, үзләрен тулаем татар театрына багышладылар. Бу фидакарьлекне күреп торган мин дә аларга охшарга тырыштым: беркайчан да, бер ролемне дә ярым-йорты уйнаганым булмады, булдыра алганча, булган бөтен көчемне, энергиямне эшкә җиктем. Әлбәттә, ул чактагы уен рәвеше һәм режиссура хәзергедән бик нык аерыла иде. Соңгы ун ел эчендә театр сәнгате, һәм шул исәптән, татар театры да бик зур яңарыш һәм үсеш кичерде.

Театр — элитар сәнгать төре, ул һәркем өчен дә кызыклы булмаска мөмкин. Сәхнә әсәрен кабул итә алыр өчен кызыксыну гына җитми, бөтенләй башка әзерлек,

эрудиция, зәвык та кирәк, һәркем чын мәгънәсендә тамашачы булып та китә алмый. Чын тамашачы еллар буе тәрбияләнә. Театрга килгән кеше үз профессиясенең остасы, җәмгыятьнең хөрмәтле вәкиле булырга мөмкин. Мәсәлән, минем туганнарым арасында да бар андыйлар. Хокук өлкәсендә зур уңышларга ирешкән, үз бизнесын булдырган кешеләр, барысы да югары белемле, киң эрудицияле, ләкин театрның бар эчке хасиятләре, тирәнлеге белән кабул итә алмыйлар. Алар ана өйрәтелмәгән, димме соң.

Шуңа «халык моны кабул итәчәк, ә монысын – юк» дигәндә, бик сак булырга кирәк: халык фикере төп критерий түгел. Халык менә дигән спектакльне дә кабул итмәскә, яратып китмәскә мөмкин. Шул ук вакытта, әллә ни зәвыклы булмаган тамашага йөриячәк. Әлбәттә, театр тамашачыдан башка да яши алмый. Ләкин репертуарны тамашачы зәвыгына карап кына төзү – сәнгати яктан дөрес юл булмаячак. Тамашачы фикеренә таянырга кирәк, ләкин аңа буйсынырга, иярергә ярамый, дип саныйм мин.



*«Курчак туе» (Г.Исхакый) спектаклендә Гайни бай ролендә.*

Тамашачыны балачагыннан тәрбияләргә кирәк. Үземнең балачагымны искә алам. Һәр бәйрәмгә укытучылар безне – мәктәп укучыларын – җыеп-туплап, спектакль әзерлиләр иде. Гади скетчлар, инсценировкалар гына түгел, ә катлаулы, авыр, озын спектакльләр. Без бишенче сыйныфтан башлап мәктәп спектакльләрендә катнаша башладык. Үзешчән театрлар мәктәп һәм авыл яшьләре тормышының аерылгысыз бер өлеше иде ул заманнарда. Үзебез дә уйныйбыз, чын театрлардан да артистлар килә – Әлмәттән, Минзәләдән, Күчмә театр, хәтта Академия театрыннан да. Үзешчән коллективлар – алары турында инде әйтеп тә торасы юк. Ул чакта авылларда телевизорлар юк диярлек, халык егылып йөри иде.

Ә менә эстрада ул кадәр үк популяр иде дип әйтә алмыйм. Мин моны бик яхшы беләм, чөнки берничә ел филармониядә эшләдем. Эстрада концертына авыл җирендә дә тамашачы җыю шактый кыен иде, спектакльгә караганда – күпкә кыенрак. Хәзер исә – киресенчә. Дәүләт җитәкчеләрен генә алыйк. Алар бит театрга йөрмиләр, ә менә Салават концертына баралар. Чөнки анда сәхнәдәге тормыш эченә кереп китеп, күзәтеп утырырга, персонажлар белән бергә нидер кичерергә кирәкми. Мелодия, ритм, аранжировкалар – барысы да әзер рәвештә тәкъдим ителә, алар акыл көчен эшкә җигүне таләп итми, кул чабып, теләктәшлек белдереп утырсаң, шул бик җитә. Мин үзем алай булдыра алмыйм. Миңа Салават концертында булырга туры килде. 15 минутлап профессиональ буларак карап, тәкъдим ителеше ягыннан бәяләп, нидер аңларга тырышып утырдым. Ә аннары, аның ел да тамашачысына тәкъдим итә торган концертларында бернинди дә яналык тапмагач, бертөрлелектән эчем поша башлады. Бу Салават турында гына әйтүем түгел, татар эстрадасындагы гомуми халәт турында сүз алып барам...

Сәхнәдәге бүгенге җырчылар бер-берсенә шулкадәр охшаган ки, аларны аеру мөмкин түгел диярлек. Режиссёр буларак, миңа һәртөрле концерт программалары, юбилей кичәләрен куярга туры килгәли. Әлеге концертларны әзерләгәндә, күз алдымнан дистәләрчә җырчы уза, ләкин ул «йолдызлар»ның берсен дә хәтергә сеңдереп калдырып булмый, шунысы гаҗәп. Тетрәндерсәләр, сокландырсалар, хәтерләр идем бит инде мин аларны.

Театрга әйләнеп кайтсак, ул техник яктан да, ягъни костюмнар, сценография ягыннан, музыкаль бизәлеш буенча да эстрададан күпкә катлаулырак сәнгать төре. Һәм – югарырак. Минем фикеремчә, Марсель Хәкимович бик акыллы, киләчәккә күз тотып эшләүче һәм яшәүче кеше булган, театрга Сергей Скомороховны чакыруы – шуның ачык бер дәлиле. Менә минем хатыным режиссёр ярдәмчесе булып эшли, ул театрның техник ягы белән һәр көн күзгә-күз очраша. Ә бу техник як профессиональ дәрәҗәдә булмаса, актёр уены да тамашачыга тәэсир итү көчен югалтырга мөмкин. «Мәскәүдә һәм башка шәһәрләрдә гастрольләрдә булганда, яки безгә кунаклар килгәндә, һәрвакыт Скоморохов сценографиясен югары бәяләп, соклануларын белдерми калмыйлар», дип әйтә Фәридә. Безнең телне белмәгән, спектакльне тәрҗемәдә караган кешеләр турында сүз бара, аларда спектакльнең үзен кабул итә алмау, менталь каршылык булырга мөмкин, әмма сценографияне әле берсенең дә кабул итми калганы юк. Театрның универсаль символикасы бар, Скоморохов бу нечкәлекләрне бик яхшы тоеп эш итә. «Телсез күке»нең сценографиясе генә ни тора!

**— Шулай да татар театрында рус рәссам-бизәүчесе ник эшли? диючеләр бар. Алар фикеренчә, татар театрында татарлар гына эшләргә тиеш!**

— Ну, Нияз, нәрсә, хәзер андый фикерләрнең барысына да игътибар итә башлыйбызмы инде?! Безнең хакта кем нәрсә әйтмәс, адәм баласы иренми бит андыйга... Андыйларның театр, сәнгатькә генә түгел, гомумән, тормышка карата да катып калган берьяклы фикер-бәяләре була, әмма мин театрның миссиясен бу фикерләрдән җитдирәк һәм өстенрәк күрәм. Драма театры хәтта опереттадан да югарырак баскычта тора, дип исәплим мин. Опера, балет – әлбәттә, алар аерым бер ягы белән театрдан югары, әмма театр тормышка караш-мөнәсәбәтне үзгәртергә сәләтле, кешенең тормышын үзгәртергә...

Кызганычка каршы, бүгенге көндә иң зур проблемаларның берсе – актёрларны әзерләү дәрәҗәсе. Монда бик зур җитешсезлекләр күрәм мин. Без укыганда (1961-69 еллар), бу мәсьәләгә икенчерәк төрле карыйлар иде. Бездә бию дәресләрен опера һәм балет театрының элеккеге прима-балеринасы Анна Федоровна Гацулина алып барды. Аның яңа гына пенсиягә чыккан чагы. Алар бит 15 ел бииләр дә — шуның белән вәссәлам! Яшь, энергиясе ташып торган ханым иде Анна Федоровна ул чакта. Станок янына бастыра да... тәмам изә. Биергә өйрәнеп үскән җегетләрмени без, гәүдәбезне тота беләбезмени?! Әмма, юк, калак сөякләрен тәя-тәя өйрәтте... Наил Әюповка аеруча каты эләгә иде! Хәзер мондый кырыслык һәм җаваплылыкны очратканым юк, кызганыч...

Габдулла Шамуковны гына кара! Аның нинди шәп артист булуы турында сөйләп тору кирәк дип санамыйм, СССРның халык артисты булуы турында да искә алып тормасам да мөмкин булыр иде... Менә өйрәтте ул безгә ичмасам сәхнә сөйләмен! Аның чын мәгънәсендә үз мәктәбе, үз юнәлеше бар иде! Ирек Баһманов, Наил Әюпов, Хәлим Җәләлов, мин, Дания Нуруллина – барыбыз да аның укучылары. Ул безне сөйләмнең бөтен нечкәлекләрен тоярга өйрәтте. Бездә — куелган сәхнә теле! Аңлыйсызмы? Бүген сәхнәгә чыккан яшьләрнең сөйләме белән чагыштырганда, җир белән күк арасы! Юк, мин яшьләрне гаепләргә теләмим, аларда түгел гаеп, әмма бу затлы сөйләм мәктәбенең юкка чыгуы әрнетә йөрәкне. Безнең буын белән бергә юкка чыгып бара ул. Гомумән, грамоталы сөйләмгә ихтыяҗ югалып бара, менә бик озак еллар күз йомып килделәр-килделәр дә, хәзер нәтиҗәсен күрәбез. Сәхнәдә чиста, дөрес, камил сөйләмсез буламыни?! Эш бит хәрәкәттә, үзеңне ничек тотуда гына түгел, ә сөйләмдә дә! Теле, сөйләме булмаган театр ул – театр түгел, ә пантомима.

**— Бу хакта сүз күп булды, әмма уйлап карагыз әле: сез театрга килгән чорда Казанда бер генә профессиональ театр була – академик театр, калган икесе – периферияда – Әлмәт белән Минзәләдә. Авыл-район тамашачысы өчен Күчмә театр эшли. Ә хәзер профессиональ театрлар – 11әү, һәр шәһәрнең үз театры бар диярлек. Бәлки, сез әйткән тел мәсьәләсе театрларның күплеге белән дә бәйледер? Сез укыганда, һәр студент белән индивидуаль эшләү мөмкинлеге булган, чөнки курс бәләкәй, берничә кешедән генә торган. Ә хәзер – башкача.**

**Мәсәлән, Фәрит чираттагы курсын җыйганда, башта 12 кеше кирәк була, дигән иде, 4 кыз һәм 8 егет. «Ал тагын 8 кешене түләүлегә, алардан кергән акчаны педагогларга эш хакына тотарсың», – дигән шарт куйдылар анарга. Ул мәҗбүр булды. Һәм нәтиҗәсе – талантлы кызлар-егетләр белән бергә... таланты шикле булганнар да Фәрит Бикчәнтәев курсына эләгеп, укып чыга. Бер искәрмә: таланты әллә ни булмаганнарның түләү мөмкинлеге бар. Нәтиҗәсе хакында инде югарыда әйттем... Шамуковтан соң да озак еллар сөйләм культурасын Асия Хәйруллина укыткан бит. Ә бүген тәҗрибәле, олпат актёрларның кайсысы театр училищесына яки мәдәният университетына сөйләм культурасын укытырга педагог булып килер иде?! Андыйларны әле очратканым юк. Сәбәбе бер генә – эш хакы юк дәрәҗәсендә.**

— Юк, эш түләүдә генә түгел, Нияз. Мина, мәсәлән, берәүнең дә бу тәкъдим белән мөрәҗәгать иткәне булмады. Юкса мин Шамуковның ин әйбәт студентларыннан исәпләнә идем. Өченче курстан мине армиягә алдылар. Аннан кайткач, мин инде башка курс белән укып бетердем. Филармониядә сөйләм жанрында – актёр һәм конферансье булып эшләдем, Күчмә театрда куелган берничә спектакльгә чакырдылар. Мин кабат училищега кайтканда, сәхнә телен инде Асия апа укыта иде. Ләкин мин анарга ул кадәр мөкиббән түгел... Безнең театрның гаҗәеп талантлы актрисасы Фирдәвес Хәйруллинаның тавышы белән килеп чыккан хәл – Асия апага да бәйле. Педагог буларак бик мактыйлар инде аны, әмма мин бу мактауларга кушыла алмыйм...

Асия апада шөгыльләнә башлагач, ул күрә, мина кызык түгел, яныма килде дә: «Айдар, син дәресләргә килеп йөрмәсән дә була, имтиханга гына килерсен», – диде. Сөйләм осталыгы дәресләрен әле ул вакытта Габдулла Шамуков та алып бара һәм, чагыштырып караганда, Асия апа белән араларындагы аерма шунда ук күзгә ташлана иде. Бу аның беренче укыткан еллары гына, билгеле, алга таба ул да уңышлы гына эшләп китте, әмма Шамуков белән Асия апаны бер яссылыкка куеп бәяләү мөмкин түгел.

**— Сезнеңчә, хәзерге көндә сәхнә телен өйрәтерлек бер генә педагог та юкмыни?**

— Ярый, әйдә, минә синнән сорыйк: Асия апаның сәхнә сөйләме буенча педагогы кем булган? Ул бит Мәскәүдә, ГИТИСта укып кайткан кеше. Каян белә ул татар сәхнә теленең нинди булырга тиешлеген?! Мәскәүдә укып кайтучыларның, шул исәптән, щепкинчыларның да сәхнә теле шактый аксый иде. Аларны, монда кайткач, шул ук Шамуков, Сарымсаков, Празат Исәнбәтләр эш барышында яхшылап «шомарттылар». Дөрес анла, милли сөйләмнән аерылып торган артист, чын татар теленең сәхнәдә ничек яңгырарга тиешлеген нығытып күзалламый башлый.

Марсель Сәлимҗанов мине үзенең соңгы курсына укытырга чакырып алгач, бу проблема белән эш процессында күзгә-күз очраштым. Марсель Хәкимович вафатыннан соң, әлеге курсны үземә генә чыгарырга туры килде. Бер имтиханнарын да калдырмадым мин аларның – әдәбият буенча булсынмы, тарих, сәхнә теле буенчамы... Һәм тәмам хафага төшкән идем.

Университетта булачак актёрга кирәге булмаган предметлар укытыла, ә кирәклеләре никтер укытылмый – сәхнә биюләре юк дәрәҗәсендә, сәхнәдә хәрәкәт итү кагыйдәләрен югары дәрәҗәдә өйрәтү юк, бездә мондый дәресләр иң мөһимнәрдән санала иде. Без хәтта музыкадан диктант яза идек! Күз алдына китерәсеңме?! Педагог композицияләрне уйнап күрсәтә, ә без диктант язабыз. Менә ничек әзерләделәр безне!

**— Ноталар турында сүз бара, аңлавымча?**

— Әйе, ноталар белән яза идек. Ә хәзер нәрсә? Актёрлык осталыгын чарлыйсы, аны үз һөнәренең остасы итеп әзерлисе урынга, студентларга политология, икътисад кебек гомуми предметларны өйрәтәләр... Минемчә, бу вакытны бушка сарыф итү генә...

Бүгенге актёрлар мөстәкыйль эшли белмиләр. Теләсә нинди вак-төяк өчен дә режиссёрны көтеп утыралар. Өйдә нәрсәдер эшләргә, әзерләнергә кирәклеге турында уйлап та карамыйлар! Ә режиссёр нишләргә тиеш?! Репетициядә әзерлексез актёрлар белән интегергә генә кала инде анарга! «Курчак туе» спектакленең репетицияләре

вакытында мин Фәритнең яшь актёрлар белән ничек интеккәнен күреп тордым. Чөнки яшьләрдә ныклы фундамент, әзерлек юк. Аннан да бигрәк – сирәкләре генә үзлегеннән әзерләнә, эшли белә.

Искәндәр Хәйруллинның эшләве ошый миңа: белеме, әти-әнисе аша геннардан күчкән таланты бар, ул театрны һәр күзәнәгенә сеңдергән кеше. Шуның өстенә, бирелеп эшли, эзләнә. Һәр репетициягә яңа идеяләр, фикерләр белән килә. «Хан кызы Турандык» спектаклен әзерләгәндә, Искәндәр Кытай режиссёры Ма Джен Хонг белән бик еш һәм озаклап бәхәсләшә иде, аларның карашлары, фикерләре туры килмәгән урыннар күп булды спектакльдә. Ни өчен әйтәм моны: бу тере бәхәс Искәндәрнең жаны-тәне белән бирелеп, спектакль дөньясына кереп китүен күрсәтә, сәхнә әсәренең ахыр чиктә ничек килеп чыгуы борчый аны. Әлбәттә, һәркем дә болай булдыра алмый. Ләкин бит спектакль әзерләгәндә, берсе, икесе генә түгел, күпчелеге процессның эченә Искәндәрдәй кереп китә алмый яшьләрнең. Мин аларны гаепләмим – күбесенә уку вакытында ачылырга мөмкинлек житми кала, икътисадтыр, сәясәттер кебек фәннәрне үзләштереп, сәхнәдә кирәк булачак төп белгечлекне үзләштерергә өлгермиләр алар. Актёрлык һөнәренең үзеген тәшкил иткән күпчелек предметларны гомумән өйрәнмиләр! Кайбер педагогларның ни дәрәжәдә профессиональ булуы турында әйтеп тә тормыйм инде!



*«Гөлжамал» (Н.Исәнбәт) спектаклендә Исмаев ролендә.*

**— Шул ук училищега чын белгечләрне чакыра алмыйлармыни? Ничек уйлыйсыз, нигә шулай килеп чыга?**

— Ә менә син әйт әле, ул училище кайсы дәүләт идарәсенә карый? Мәдәният министрлыгына, шулаймы? Без укыганда, Мәдәният министрлыгыннан безгә бик еш килделәр, һәр имтиханда министерство кешесе утыра торган иде. Диплом эшләрен карарга гына түгел, ә курс эшләренә, гадәти имтиханнарга да йөриләр иде. Безнең әзерлеккә мөнәсәбәт бөтенләй икенче булды, аңлыйсыңмы!

Ә хәзер профессиональ әзерлеккә мөнәсәбәт мәктәп дәрәжәсеннән дә түбәнрәк. Мине өченче курстан армиягә алдылар, дип әйттем ич инде. Шушы билгесезлеккә чыгып китүче егетне курс житәкчесе Сарымсаков кына түгел, ә Хөсәен абый Уразиковка кадәр тынычландырып, сөйләшеп утырган иде. Хәзер, бәлки, күз алдына китерү кыендыр: әмма ул чакта өч елга каядыр китү, курсташлар сафыннан төшеп калу – язмышың жимерелүгә тиң иде.

Мин Хөсәен абыйның сүзләрен мәңгегә истә калдырдым. Ул безнең белән Нәкый Исәнбәтнең «Зифа»сын куярга тиешле иде, диплом эшебез. Мине анда төп роль көтеп тора... Ул хәтта пьесаны да мине күздә тотып сайлаган иде, төп рольдә нәкъ менә мине күргәнгә... Ә безнең частьне ил чигеннән чыгарырга тиешләре инде билгеле, кая жибәргәннәрен генә төгәл әйтмиләр... Шул чакта Хөсәен абый әйтте: «Кайда гына барып эләксәң дә, шул халыкның телен, гореф-гадәтләрен өйрәнеп кайт, Айдар, күзәт аларны, культураларын үзеңә сеңдер. Икенче киңәшем: армиядә китапханә бар – өзлексез укы! Анда, әлбәттә, татар китаплары булмас, Достоевскийны, Гюгоны укып чык. Бу ике язучыны тулысы белән укырга кирәк, барлык әсәрләрен һәм хезмәтләрен. Үзеңне камилләштер! Шулай эшләсәң, бу өч ел синең өчен бушка үтмәячәк!» Өч елга дип киттем, өч ел да өч ай йөреп, әйләнеп кайттым...

Ник уйланам бу турыда... Менә син, Нияз, театр белгече, элек ничек булган да, хәзер ничек дип үзен дә еш уйланасыңдыр. Аерма күзгә ташланып тора бит! Мин менә Ильтани Иляловага кадәр бездә театр тәнкыйте гомумән булмады дип әйтә алам. Ничек язалар иде?.. Менә монысы ошады, ә монысы – юк, дип... Шулайрак... Анализ, фикер белдерү, нәрсәнең ничек икәнен анлату гомумән юк иде...

**— Ә Рауза Фатыйховна Усманова турында ни диярсез?**

— Әйе, ул бар иде. Ләкин ул рецензияләрне сирәк яза иде бит, бик сирәк. Барлык спектакльләргә дә язды дип әйтеп булмый. Аннары тәнкыйтькә синең әтиең – Рәуф Игъламов килде. Ул һәм Илялова. Дөрес, соңгы вакытта ул да нидер югалтты кебек. Белмим, бәлки театр үскәндер. Без башкача фикерли башлаганбыздыр, театр башкача фикерли башлагандыр. Театр үсеше өчен тәнкыйть кирәк, ләкин профессиональ тәнкыйть. Соңгы елларда менә син күренә башладың. Бу баш режиссерга репертуар сайларга ярдәм итә, ин беренче чиратта.

Безнең репертуар житди бит. Шул ук Фоссе. Марсель ана алыныр идеме? Юк дип уйлыйм. Аннары, хәзер чикләр дә юылып килә. Интернет. Без хәзер барын да Интернеттан беләбез. Тормыш ритмы да бөтенләй үзгә хәзер, соңгы егерме елда дөнья әнә ничек үзгәрде! Моны бит күз алдына да китереп булмый иде. Һәм без яна ритмга күнегәбез, театр да гел үзгәреп тора, монарчы булмаган тизлек белән үзгәрә. Кем нәрсә әйтсә дә, минем үземә яхшы якка үзгәрәдер кебек тоела. Кайвакыт, корифейларыбызны, остазларыбызны, үткәннең бөек актерларын искә алганда, бигрәк тә алар куйган спектакльләрнең сакланып калган язмаларын караганда... аларның уеннары олы ярату хисе белән бергә... жинелчә елмаю да уята. Актерлык сәнгате бер урында тормый чөнки. Үсә.

**— Бәлки бу театрның хәзер күп гастрольләргә йөрүе, чит илләргә чыгуы белән дә бәйледер...**

— Күз алдына китерә аласыңмы, ел саен 1,5-2 айлык гастрольләргә чыгып китә идек. Ижевск та, Свердловски да, Ташкент та, Алма-Ата, Баку, Әстерхан, Куйбышев та калмый иде. Театр ул чакта да күп йөрде, ләкин үз илебездә, СССРда. Ә хәзер, әйе, читкә чыгабыз. Шунысы да бик мөһим: хәзер безгә – Казанга да еш киләләр. Без бит, әйтик, Някрошюс дәрәжәсендәге режиссерның килүен күз алдына да китерә алмый идек. Ләкин менә нәрсә гажәпләндерә мине... Бәлки ялгышамдыр... Күптән синең белән шуны сөйләшәсем килә иде. Менә безгә алмаш гастрольләргә Малый театр килә, без аларны карыйбыз, МХТ килә, БДТ, Додин театры килә – барын да күрәбез. Һәм кайвакыт ул спектакльләрдән соң мин аптырап утырам – бик йомшак уен. Сәхнә һәм кино йолдызлары, шул ук Хабенский, Дюжевлар, белмим, ләкин безнең театрда алар йолдыз була алмас иделәр.

Менә МХТ «Гамлет»ны алып килде, гафу ит инде, бик йомшак спектакль бит. Сурәтләү чаралары — ярар да инде, ләкин актерлар уены, мезансценалар... Һәм алар һич тетрәндерми, антиэстетика бу. Минем күпкә көчлерәк куелышларны күргәнем булды. Яки менә баш рольдә Дюжев уйнаган «Примадонны» француз комедиясе. Беләсеңме, безнең дә андый нәрсәләр уйнаган булды, касса — касса инде ул, ләкин мин аларны шәп уйнадылар дип әйтмәс идем, без күпкә яхшырак, нечкәрәк уйныйбыз. Ә менә Басилашвили белән Фрейндлих «Дядюшкин сон»ны уйнадылар – менә бу бөтенләй башка инде. Менә бу сәнгать мина якын, анлаешлы.

Иң мөһиме, без хәзер карый һәм чагыштыра алабыз. Һәм мин безнең спектакльләрне (әйтик шул ук «Телсез күке») ниндидер Мәскәү спектакльләреннән йомшаграк дип әйтмәс идем. Бер танышым «Күке»не караганнан соң, Мәскәү театрларында бик күптән мондый уен күргәнем юк иде, диде. Ә бу соңгы спектакль – «Жәйнең бер көне»... Юк, театрда үсеш бар, һәм бик көчле үсеш. Фәрит ул, ни генә дисәң дә, бик нечкәләп эшли. Актерлар белән бик жентекле эш алып бара. Шуна күрә режиссура бездә традицион көчле, ә менә кайбер актерларның әзерлексезлеге шулай да сизелә. Һәм, анлыйсыңмы, бу каршылыклы тойгылар уята.

Менә «Мулла»ны алыйк – бик яхшы куелган спектакль бит! Яратам мин Талиповны, ләкин аның герое шулкадәр жебек була алмый бит инде, ул бит төрмә

тормышын үткән, хакыйкатьне тапкан, көчле кеше, ә Эмильнен ул йомшак, тотрыксыз кеше булып чыккан... Ә спектакль ничек куелган! Берсендә мин бер генә сәхнәне карыйм дип кергән идем – кире чыга алмадым, ахырынача карап бетердем, җибәрми спектакль. Күргәнем дә бар иде инде, һәм бер генә тапкыр да түгел, ә торып чыгып китә алмыйм. Кайбер моментлар шулкадәр уңышлы табылган, һәм режиссерның да ни әйтергә теләвен шунда ук аңлыйсың. Үтә нечкә алымнар. Шуна, Аллага шөкер, театр дөрес юлда, дөрес юнәлештә үсә.

**— Бу сорауны да бирми кала алмыйм инде – хәзерге татар драматургиясе – ул турыда ни уйлыйсыз? Театр үсешен заманча драматургиядән башка күз алдына китерү кыен бит. Сер түгел, актёр үсеше дә күп очракта көчле, сәнгати тулы характерларны уйнавына бәйле.**

— Драматургия кризислары һәрвакыт булып торган инде ул. Монда бер генә котылу юлы бар – классикага мөрәҗәгать итү. Һәр сезонда бер генә булса да классик әсәр куелырга тиеш. Менә җыелышта Фәрит, ниһаять, Камалның «Банкрот»ын куябыз диде. Без куярга тиеш аны, безнең театр шул драматург исемен йөртә. Үз заманында аны Празат Исәнбәт бик уңышлы куйган иде. Исемдә калган икенче спектакль уңыш казанмады. Гомумән алганда, бу спектакльне бик еш куелды дип әйтеп булмый... Ләкин Фәрит аны ерып чыга алыр дип уйлыйм. Әнә бит «Кайнеш, көндәш һәм башкалар»ны ничек шәп куйды. Бусын да куяр.

Ул әйткән икенче спектакль – Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»е – монда эш бераз катлаулырак. Бу пьеса буенча куелган соңгы спектакль әллә ни уңыш казанмады. «Насретдин»ны Тинчурин театрында да караганым булды. Анда бөтенләй караңгылык, башка бармыйм дип кайттым. Ник алай икәнен аңлатам хәзер. Нәкый Исәнбәтнең юморы, ирониясе бик үзенчәлекле, режиссер Рәшит Заһидуллин аны тоймый, актёрлар исә, нәрсә уйнарга белмичә, су куша башлыйлар. Чабышалар, кычкырышалар – нидән, ни өчен, аңлашылмый... Исән вакытта бу пьесаның яхшы куелышын күреп каласы килә, бөтен өмет Фәриткә инде... Нәкый Исәнбәт бит ул татар классикасында бик үзенчәлекле урын алып тора. Бүген әле без аны драматург буларак ачтык дип әйтеп булмый.

**— Фәрит аны бик нечкә тоемлый, «Җирән Чичән һәм Карачәч сылу», «Гөлҗамал» спектакльләрен генә исегезгә төшерегез. Классика классика инде ул, әйдәгез әле хәзерге драматургиягә килик, театр бит үз заманы проблематикасын да яктыртырга тиеш. Җәмгыять тормышындагы үзгәрешләрне тотып алып, тамашачыга җиткерүдә арадашчы ролен барыбер бүгенге көн пьесалары уйный бит. Менә без Россиядә әкрен генә Демократия кояшы батуын күзәтәбез, авылның хәлсезләнеп үлеп баруын күрәбез, халыкта Сталинны ярату хисләре уянуга шаһитбыз... Боларның барысы хакында да драматурглар язарга тиеш. «Яңа татар пьесасы» конкурсы жюриенда мин инде 10 ел эшлим. Ел да конкурска 50-80 әсәр килә, ә куяр әйбер юк. Араларыннан 2-3 пьеса килеп чыкса, бу инде бик зур бәхет. Менә шул хәл белән нишләргә? Язучыларыбыз укый торган «Казан утлары» сәхифәләрендә дә әйтмәсәм, кайда әйтим мин менә боларны?**

— Мин болай уйлыйм. Бүгенге татар әдәбиятын тулаем алсак, һәм драматургияне шуның бер тармагы итеп карасак, бүгенгеләре егерме генә ел элек басылганнар белән янәшә торырлык та түгел. Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев заманындагылар белән... Нишләтәсең, бер буын язучыларыбыз китеп барды. Бүгенгеләрдән кем Нурихан Фәттах белән тиңләшә ала? Кем? Юк андыйлар. Бу мине бик борчый. Язучыларда да шул ук проблемадыр, минемчә. Бер яктан, белем җитмәү, үз хезмәтенә куллану объекты итеп карау, сатылу, популяр булырга теләү. Ә икенче яктан, укучы зәвыгын Интернет та, телевидение дә боза, сыйфатсыз әдәбият та. Аннан да мөһимрәге – профессиональлек җитмәү.

Пьесаларны күп язалар дисең, аларны элек тә күп язалар иде. Һәм яхшылары һәрвакыт бик күпкә азрак була иде. Ләкин ул заманда йомшаграк пьесаларны үзешчән театрлар өчен махсус аерым җыентыкка җыеп бастыралар иде, үзешчән театрлар исә, үз чиратында, профессиональ сәхнәгә дәгъва итмиләр иде. Ә яхшы драматурглар элек тә күп түгел иде. Туфан, Хәмид, тагын берничә исем. Театрның соңгы елларда Мансур Гыйләҗев кебек драматургтан читләшүе кызганыч. Кара,

Ризван Хәмид белән нинди катлаулы һәм көчле әйберне башкарып чыктылар алар – «Курчак туе»н әйтәм. Ә Марсель Хәкимович үз вакытында Хәмид белән эшләүдән туктаган иде. Бәлки, бар хикмәт тә шундадыр, талантлы авторларны театрдан ерак җибәрергә ярамыйдыр, бәлки.

Шул ук Ркаил Зәйдулланы гына алыйк. Беренче килгәндә үк сәхнәгә бүген тотып куярлык, әзер пьесалар алып килә идеме әллә, юк, бу бит мөмкин дә түгел. Без аның белән юбилейлар, кичәләр әзерләгәндә еш кына бергәләп эшлибез, ул бик игътибарлы, башкаларның фикерләренә колак сала торган кеше. Текстның да һәрчак берничә вариантын эшли. Сценарийны пьеса дип әйтеп булмый, билгеле, ләкин сәхнәләштерәсе әйбер бер үк принципларга нигезләнеп эшләнә бит инде барыбер. Зөлфәт Хәким, кызганычка каршы, соңгы елларда җинелрәк жанрлар белән мавыгып китте. Күрәмсең, эчке мантыйк буенча шулай булырга тиеш иде. Ә яшьләрдән берәү дә күренми әлегә, бары Илгиз генә...

**— Айдар абый, бүген татар поэзиясендә – чын шартлау. Никадәр яшь исем, аларның һәрберсе – үзе бер шәхес! Равил Фәйзуллин, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмнәрнең дәвамчылары булып, тулы бер буын килде, үз сүзен әйтте... Ә нигә драматургиядә алай түгел?**

— Авторлар белән активрак эшләргә кирәк, минемчә. Ркаил Зәйдулла белән бәйләнеш булгандай, башкаларны да тартырга, аралашырга... Мин Ркаилнең шигъриятенә караганда, аның публицистикасын бигрәк тә югары бәялим, хикәяләрен бик яратам. Алардан менә дигән сатирик пьесалар эшләп булыр иде! Әмма моның өчен кеше театр мохитен, сәхнә кануннарын күздә тотып язарга тиеш, гомумән, театрның эчендә кайнаган кеше генә әйбәт драматург була ала. Хәер, без гел проблемаларны калкытып куеп сөйләшәбез, бездә генә түгел, рус драматургиясендә дә хәлләр әллә ни мактанырлык түгел...

**— Мин алай димәс идем, Россиядә соңгы елларда бик көчле яңа драматурглар барлыкка килде – Иван Вырыпаев, бертуган Дурненковлар, Юрий Клавдиев, Ярослава Пулинович... Сүз уңаеннан: соңгысында татар каны ага, ул безгә Орхан Памукның «Меня зовут Красный» романы буенча инсценировка әзерли... Русларда бар әйбәт драматурглар, ләкин аларның темалары һәм образлары безнең милли менталитетка туры килми, безгә үзебезнекеләрне үстерергә кирәк...**

— Әйе, Нияз, нәкъ менә синең вазыйфаң инде бу – өметле, талантлы авторларны табып алып, театрга алып килү һәм театр дөньясына чумдыру. Театрның эченә кереп чummаган кеше шәп, бүген үк куярлык әсәр тудыра алмый, чөнки ул театрның эчке механизмнарын белми. Туфанның беренче пьесаларын гына алыйк, алар да бит камил килеш килеп кермәде режиссёрлар кулына. Әмма режиссёрлар аны хуплап каршы алды, кайсы урыннарын ничек эшләп бетерергә кирәклеген күрсәтте, киңәшләр биреп, үсендереп җибәрделәр. Һәм Туфан берсеннән-берсе шәбрәк әйберләр язып алып килә башлады! Гениаль пьеса килер дип көтеп ятарга кирәкми, алай җиңел генә булмый ул. Алып килсәләр дә, йә, ничәне китерергә мөмкиннәр инде? Ну берне! Репертуарны ул гына хәл итми бит!

**— Мин бик тар даирә авторлар белән эшлим – Ркаил Зәйдулла, Илгиз Зәйниев һәм Равил Сабыр. Ни өчен алар белән дигән сорау туадыр күпләрдә. Әйтәм: чөнки алар үзләре камилләшергә омтылалар, киңәш сорап киләләр, фикер алышалар... Ә миндә шундый принцип бар: кешене көчләп язарга өйрәтеп булмаган шикелле, камиллеккә дә чәченнән тартып ирештереп булмый. Әгәр үзләре телиләр икән – кайда икәнемне беләләр, килсеннәр. Кызыксынучылар бар, мәсәлән, шул ук Рүзәл Мөхәммәтшин. Әлегә шактый йомшак әйберләр булса да, аларның инде умырткасы бар, бу текстлар белән эшли башларга мөмкин...**

— Рүзәл – акыллы һәм булдыклы егет, аны театр белән мавыктырып булса, шәп әйберләр күтәргә була, минемчә. Ләкин әйбәт драматурглар, шагыйрьләр кебек, күп була алмый. Ул беркайчан да алай булмаган һәм булмас та, мөгаен.

**— Күпчелек драматурглар, күнеккән буенча, һаман да авыл темасына язуларын дәвам итәләр. Алар үзен түгел, ә бүгенге тамашачыны нинди темалар борчуы**

**турында уйлап карыйлар микән? Тамаша залында, гадәттә, яшь яки урта яшьләрдәге казанлылар утыра, алар өчен авыл темасы инде ул кадәр актуаль түгел...**

— Әмма авыл күренешләре фон булып кына да бара ала бит, дөресрәге, вакыйгалар бара торган җирлек. Ул тема булмаска да мөмкин. Темасы мәхәббәт йә үлем, тугрылык йә хыянәт була ала. Безнекеләр артык турыдан ярырга ярата – вакыйгалар үстерелеше бирелгән җирлек авыл икән, димәк, әсәр дә авыл турында... Предметлыктан, турыдан-туры хикәяләүдән тирәнгәрәк китәргә, авыл җирлегендә дә мәңгелек темаларны ачарга, фәлсәфи оетқы салырга мөмкин ләбаса...

**— Театрдагы артистлар арасында канәгатьсезләр еш очрый, карьерасыннан, рольләрдән разый булган бер генә артистны беләм мин – ул да булса Шәүкәт ага Биктимеров. Аңа бу сорауны биргәч, уйлап, хәтерендәге рольләрен барлап чыкты да, әйе, теләгән барлык рольләрне дә уйнадым, диде. Шулай да аннан өстәп куйды: «Менә без Фәрит белән «Король Лир»ны эшләргә ниятләгән идек, барып чыкмады. Лирны ничек уйнар идем мин! Ә болай... канәгатьмен...» Сезнең хыялланып та уйный алмаган ролегез нинди? Ник чыңга ашыра алмадыгыз ул хыялны?**

— Мин беркайчан да буш хыяллар белән яшәмәдем... Вакытыңны һәм нервларыңны булыр-булмас хыялларга сарыф итеп утыру кирәк дип санамыйм. Минем өчен рольнең зур яки кечкенә булуы да әллә ни мөһим түгел, һәр рольгә зур җаваплылык белән карыйм. Репетицияләр башлангач, йокыдан калам, аппетитым югала, үзем дә, тирә-юнь мохитем дә үзгәреш кичерә. Теге яки бу роль турында хыяллана идем, булмады инде, дип борын төшереп утырырга вакытым да, теләгем дә юк...

Әгәр син язмышыңны театрга багышлагансың икән инде, бер гади хакыйкатьне анларга тиешсең: син нинди генә даһи булсаң да, театр синең берүзең өчен генә яшәми. Театр ул – коллектив хезмәт, монда үзең турында гына уйлап утыру мөмкин эш түгел... Роль эләкмәдеме? Моннан гына дөньяң җимерелергә тиеш түгел. Димәк, кемнедер синнән лаеграк дип исәпләгәннәр. Сиңа, әлбәттә, үзеннән дә лаеграк кеше юк кебек тоеладыр, әмма ул кеше дә бит үзен иң лаеклы дип саный. Әйе, авыр да, газаплы да чаклар була, ләкин театрда иң мөһим сыйфатлар – талантыңны югалтмау һәм көтә белү. Монда синнән башка да никадәр шәп артист җыелган бит, моннан тыш, режиссёрның спектакльгә үз карашы, үз концепциясе бар һәм ул булган артистлары арасыннан иң туры килгәнен сайларга тырыша. Режиссёр актёрларның күпме спектакльдә уйнавына-уйнамавына карап та сайларга мөмкин, берәү дә өлешсез калмасын, диеп. Шуңа да рәнҗеп, бүселеп йөрү – килешми.

Яшь чакта күбесе моны аңламый, авыр кичерә, ә аннан олыгаялар, фикерләре дә олпатлана, йә булмаса аларның театр белән аралары өзелә. Станиславскийның бик дөрес фикере бар: «Сәнгатьтәге үзеңне түгел, ә үзеңдәге сәнгатьне ярат». Чынлап та шулай бит. Әгәр син бу хакыйкатьне үзләштерәсең икән, шәхси амбицияләрең белән генә яшәүдән туктыйсың, үзеңне зур бер гаиләнең өлеше итеп тоя башлыйсың. Барысы да тәрбиядән тора: үз театрыңда булган һәр вакыйга сиңа кызыклы, мөһим булырга тиеш, болай булганда, «мин» һәм «башкалар» дигән бүленеш юкка чыга, башка артистларның уңышлары да синеке булып әверелә, аларның уңышсызлыклары өчен инде чын йөрәктән кайгырасың. Чөнки бу – синең гаиләң. Ләкин бу сыйфат күктән төшми, аны тәрбияләргә кирәк.

Празат абыйдан бервакыт: «Ни өчен сез үзешчән коллективларны карарга йөрисез?» – дип сорыйлар. Ә ул бик акыллы җавап бирә: «Үзем дә алар дәрәҗәсенә төшмәс өчен генә булса да», – ди. Кеше үзен объектив бәяли белергә тиеш, артист өчен бу бигрәк тә мөһим. Әгәр башка артистлар, ягъни коллегаларыңның уңышлары, үсеше өчен сөенә алмыйсың икән, театрдан китүең хәерле... Әгәр кеше үзе турында гына уйлый икән, ул театрны үзенең йорты, гаиләсе, язмышы дип исәпли алмый әле...

**— Зур рәхмәт, Айдар абый, сәламәтлек, яңа рольләр, уңышлар Сезгә!**

*Әңгәмәдәш* — **Нияз ИГЪЛАМОВ.**

# ТӘРӘЗӘ КЫЕГЫН КЕМ ТӨЗӘТЕР?

Рус әдәбиятында тирән иҗтимагый-фәлсәфи фикерләр психологизм остасы булган Ф.Достоевский иҗатында кин чагылыш таба. Ләкин аны укуы авыр, ул тормышның бары тик күнелсез якларын гына күрә кебек. Дәһшәтле буяулардан искиткеч караңгы дөнья тудыра үзенең әсәрләрендә. В.Вересаев Ф.Достоевскийны «томан, янгыр һәм караңгылык дөньясы тудыручы оста», дип атый. Матур табигать, кояшлы көн, сәламәт тереклек анын әсәрләреннән ерак йөри, булса да гарип формада чагыла. Ни өчен? Ахрысы, Ф.Достоевский кеше психикасындагы иң яшерен почмакларны күрә, властька омтылышның сәламәт рух белән яраша алмавын тирән аңлый. Шулай да рус халкының Достоевский иҗатын кабул итәрдәй укучысы бар.

Минемчә, татар әдәбиятында дөньяны зәһәр сөрем аркылы күрүче, дәһшәтле буяулар белән сурәтләүче бер генә шагыйрь – Һади Такташ кына бар. «Кайтса кире җир өстенә: нинди дәһшәт! / Сөякләрдән таулар, каннан күлләр күрде. («Газраилләр», 1916), «Фахеш җир! Куенына шомлы / Еланнар ояласын инде!» («Караңгы төннәрдә», 1916), «Хәнҗәр очлыйм, әнкәй, кискен хәнҗәр, / Синең кунагыңны суярга!» («Үтерелгән пәйгамбәр», 1918), «Балаларың исрек, / Исреп-исреп, / Нәслең черегән / Барысы тилергән!..» («Такташ үлде», 1923).

Әдәбият фәнендә «Такташ үлде» (1923) шигыре белән шагыйрь моңа кадәр булган иҗат принципларыннан баш тартып, яна заман, яна идеология таләп иткән рельсларга кучүен игълан итә, дип аңлаталар. Ф.Бәйрәмова: «Без бүген классика итеп, аның «пролетариат идеологиясенә чит булган» шигырьләрен өйрәнәбез», – дип яза (Бәйрәмова Ф. Мишәрнең бөек улы. Казан: «Аяз» нәшр., 2001). Ләкин шунысы бар, Такташның гади кеше, гади обыватель аны кабул итә алмастай куркыныч сүзләре, канны катырырдай аяусыз шигъри картиналары нәкъ менә 1923 елга кадәр иҗат ителгән. Ә 1923 елдан соң аның искиткеч лирик эчтәлекле, шук, тиктормас малай-шалайның эчке рухи дөньясын ачып бирүче, үткәннәр белән бүгенгене тоташтыручы, сагыш белән сугарылган «Нәни разбойник»ы (1926) («Кышкы төннең салкын күкрәгеннән / Чаналар да шаулап үттеләр, / Чаналарга салып, еллар мине / Бик еракка алып киттеләр...»), мәхәббәтнең хис-тойгылар гына түгел, ә зур җәмгыяви җаваплылык икәнен ачып биргән «Мәхәббәт тәүбәсе» (1927) (Ана / Бөек исем, / Нәрсә җитә ана булуга; / Хатыннарның бөтен матурлыгы, / Бөтен күрке ана булуда...) һ.б. бик матур әсәрләре дөнья күрә.

Без бүген әдәбият фәнендә кабул ителгән рәсми карашларга ияреп һәм шул карашларны сөйләп йөрүне һөнәр иткәннәргә ияреп, тар карашлыкта гаепләүдән куркып кына классикларны «бөек» дибез (беренче чиратта, Достоевскийны, Толстойны). Акыллырак булып күренер өчен ара-тирә әсәрләреннән цитаталар китерәбез. Мин моны татарларның, милләтнең гаебе димим, мин моны татар язучыларына атап әйтәм.

Югары дәрәҗәдәге иҗтимагый фикерне тиешле дәрәҗәдә иярли алмаган әдипләрнең әдәбият мәйданына хуҗа булып яши башлавы Казан ханлыгы егылгач, әйдәп баручы катламы – морзалары – юкка чыгарылгач башлана. XVII – XVIII гасырларда язма әдәбиятыбыз дини эчтәлекле, чөнки милләтне саклап калу турыдан-туры мөселман булып калуга бәйле. XIX гасырдан дөньяви белем алуны пропагандалау алгы планга чыгарыла, алга киткән халыклар ирешкән

унышларны үзләштереп, татарлыкны саклап калып була, дип ышаналар мәгърифәтчеләребез. XX йөз башында милли үзаң үсеше күзәтелә, ләкин монда да әлеге үсеш, үз эчендәге кадимчелек белән көрәшеп, бик нык көчен югалта. 1917 елдан соң әдәбият тар идеологик кысаларга куып кертелә. Ләкин ни гаҗәп, бу чор искиткеч тирән эчтәлекле әсәрләргә гаять бай. Язмыш һәм шәхес проблемасын күтәргән «Тапшырылмаган хатлар» (Г.Кутуй), чорның кырыс үзенчәлекләрен күрсәтә алган «Тирән тамырлар» (Г.Ибраһимов), «Легион юлы», «Гает корбаны» (Ш.Усманов), татар яшәешенең гүзәл күренешләрен чагылдырган «Намус» (Г.Бәширов) әсәрләрен атау да әдәбиятның киеренке эзләнү юлы белән яшәвен күрсәтә. Хрущев «җепшеклеге», Брежнев «торгынлыгы» чорларында да сабыр-салмак стильле Ә.Еники, ярсу-экспрессив һәм бунтарь А.Гыйләҗев, йөгерек-юмор телле Ф.Хөсни, тормышчан шат рухлы М.Мәһдиев, буйсынмас, милли җанлы С.Батталлар иҗатында татар яшәешенә рухи азык таба иде.

Бүгенге әдәбият исә бик нык авыру. «Замана балалары» (Т.Галиуллин), «Ир-Мамай» (М.Әмирхан), «Ялгызак» (Р.Сибат), «Мәүлет гусар» (З.Зәйнуллин), «Кара аксөякләр» (Р.Мирхәйдәров), «Бию җене кагылган егет» (Р.Батулла) кебек әсәрләре белән куандыручы өлкән буын әдипләребез булмаса, бүген прозабызны юк, дияргә мөмкин. «Татар гомергә бер-берсен саткан», «татар гомергә таркау булган», «татар кебек көнче халык бүтән юк», «без эшли алабызмыни соң» дип сыктаучылар, әсәрләрендә күңел сафлыгы, сабырлык үрнәге итеп мич башы карчыкларын сурәтләүчеләр, армиягә киткән егетләрне йә гарипләтеп, йә үтерелгән итеп чагылдыручылар, горурлык хисе урынында укучыны елатуны максат итеп куеп язучылар – үз халкына аю хезмәте күрсәтүчеләр генә. Иманым камил, менә хәзер язылачак сүзләремне редактор кисәчәк, һичьюгы үзе белеп торсын фикеремне – мондыйлар теләсә нинди түбән сүз белән аталырга да хаклы. Чаллыда чыгучы «Мәйдан» журналы редакциясенә бара алмас дәрәҗәгә җиттем инде, барган саен журнал редакторы, күп санлы тарихи романнар авторының татарны хурлап сөйләгәнен ишетеп, саруым кайнауга чыдый алмый башлыйм.

Ф.Баттал бер мәкаләсендә коммуналь хезмәтләр күрсәтүнең сыйфаты начар икәнен яза да, Универсиадага әзерләнгән Казанны бизәнеп-ясанып кунак каршыларга чыккан шапшак хатын белән чагыштыра. Афәрин, Фәнзаман ага, бөтен Россия шәһәрләре арасында энҗе кебек ялтырап утырган башкалабызның тырнагы астыннан да кер табарлык үткен тәнкыйди акылыгыз бар икән. Бу унайдан бер мәзәк искә төшә. Казармага генерал килер алдыннан бөтен җирне юып тазарталар. Генерал исә, килеп кергән унайга бер карават янына туктый да, иелеп, эчке тимерен бармак белән сыпыра һәм, табигый ки, бармак битенә тузан ияреп чыга.

– Как это называется? – ди генерал үрә катып торган сержантка.

–Свинья всегда грязи найдет, – дип җаваплый тапкыр егет.

Яшь, фикерле, кыю-кыю язмалары белән танылып килүче Р.Мөхәммәтшин да Универсиаданың кирәкле шәй булуына шик белдерә. Бары тик Россиянең спорт министры гына – бөтенләй чит, урыс кешесе – соклана безнең шундый зур эшне ерып чыга алуыбызга: «Республика җитәкчелеге, әгәр проектның 50 процентын федераль бюджет күтәрсә, һичшиксез, аны гамәлгә ашыра! Теләсә нинди проектны – спортка кагылсынмы ул, фермаларгамы. Ә башка төбәкләр берәр проектны гамәлгә ашыру өчен үзләренең 5 тиен акчасына 90 сум сорый. Минем янда бер губернатор булган иде, ул берничә миллиард сумлык проект тәкъдим итте. Мин әйтәм: «Бик шәп, мин сине хуплыйм. Күпме акча кирәк инде?» Ә ул «90 процентын бир», – ди. Яки киресенчә... Нәрсәдер төзи башлыйлар, мин финанслыйм, ә аннан алар эш барышында үзгәрешләр кертергә тотына. 500 меңлек проект миллиард сумлыкка әверелә дә куя. Казанда алай түгел. Монда беркем дә өстәп акча сорамады» («Алабуга нуры», 2013, 19 июль).

Конкрет кешене күрсәтеп, аерым әдипнең иҗатындагы җитешсезлекләрне атарга кирәк булса, тәнкыйтьчеләр ләм-мим, чөнки фамилиясе аталган кеше үпкәләргә мөмкин бит. Ә ана йомышын төшеп куйса? Менә бу «денем өчен түгел, көнем өчен яшәү», дип атала. Бу – куркыныч, афәткә алып бара торган яшәү. Моны аң асты (подсознание) белән аңлыйлар язучылар. Тәнкыйть кирәген

дә таныйлар, үзләрен кыю, халык гаме белән яшәүчеләр итеп тә күрсәтәселәре килә. Шуна күрә ин отышлы адымга баралар — аерым шәхесне атамыйча гына тәнкыйть итеп була торган гомум күренешләргә бәйләнәләр. И батыр булып тоелалардыр инде үзләренә республика төзелешләрен, татарнын куркаклыгын, таркаулыгын сүккәндә!

Зиннур абый Мансуров әйтмешли, дөньяда гел «негатив» кына күрәм бугай мин. Кемгәдер шулай да тоелырга мөмкин. Юк, Аллага шөкер, әдәбият мәйданын чүп-чар басса да, унышларыбыз да юк түгел. Алдарак, өлкән буын, дип атап үткәннәрнен кайберләренә тукталасым килә. М.Әмирхановнын «Ир-Мамай» әсәре автор тарафыннан «тарихи бәян» дип тәкъдим ителә. Татар тарихында үзенчәлекле урын тоткан шәхес образына мөрәҗәгать итүе әйбәт, күркәм гамәл. Гомумән, тарихи темага мөрәҗәгать итү иҗтимагый фикер яралгысы булуга ишарә. Ләкин... ләкин яралгы яралгы гына булып кала, үстерелми. Бердән, Мамайнын ил гаме белән яшәүче образ булып формалашып бетүен хатыны Толымбикә белән ике арадагы төче мөнәсәбәтләрне бик төче итеп, күпләп-күпләп сурәтләү боза. Иҗтимагый ан — ул күнелсез әйбер, ул акылны психик саташу чигенә житкереп, киеренкеләтеп яшәтә торган нәрсә. Дөнья тар һәм ана хуҗа булырга теләүчеләр күп һәм акыллы. Монда Толымбикә белән «Мамуг та Мысык» дип, бер-беренә тәтәйләнеп утырышып кына җинеп булмый. Язма башында телгә алынган Достоевский һәм Такташ — шунын ачык мисалы. Дөньянын кара, алдаучан ягын күрә белгәннәр генә дөнья белән идарә итә ала. Аннан сон, көн саен кеше башлары тәгәрәвен күргән, җир тетрәтеп яшәргә күнеккән, менәрләгән ирләрнен берсүзсез буйсынып, артыннан иярүләрен максат итеп куйган Мамайнын сентиментальлегә ышандырмый. Монда күпкә тирәнрәк рухи кичерешләр, ан эшчәнлегенен кара, күнелсез, вакыты белән кешелексез якларын күрергә һәм ачарга кирәк. Әллә ил тотунын нәрсә иканен оныткан татар язучыларынын башы юкамы боларга?

Икенчедән, тарихи дөреслеккә тугры калам дип, вакыйгаларны объектив тасвирларга омтылу, татар сугышчылары белән горурлык уятуга китерми. «Изге ялган» дигән төшенчәгә хезмәт итәргә чакырмыйм, ләкин әсәргә татарларнын өстен булган, җинеп чыккан моментларын күбрәк кертергә була бит инде, мәсәлән, Чәлүби белән Пересветнын бергә-бер сугышуын. Белмим ничек, монысы язучы проблемасы, әмма Чәлүбинен игътибарсызлыгы, бәлки артык үзенә ышануы аркасында, очраклы һәм шуна күрә фаҗигале ничьяга тәмамланган орыш итеп сурәтләргә була иде бит!

Шулай да Т.Галиуллиннын «Замана балалары» *(«К.У», 2013, № 7-8)* исемендәге истәлекләре кайбер ирләрдә ил тоту гаменен томан рәвешендә булса да яшәвен күрсәтә. Автор укучыга үткәндәге тормыш тәҗрибәсен житкерә һәм — «Йә, Хода!» — татар тәнкыйтендә күптән онытылган, әмма ачы дару кебек кирәк булган адымга, аерым шәхесләрнен конкрет исем-фамилияләрен атау юлына баса. Татар мохитендә нинди куркыныч күренеш иканен беләм бит мин монын! Бу бит, ничә исем атыйсын, шунын хәтле дошман җыясын, дигән сүз.

Тәлгат аганын «Замана балалары»нда әнә шул йокы сүрәсен ертырга омтылыш, кабатлап әйтәм, омтылыш бар. Әгәр шушы исемдә 1993 елда чыккан истәлекләрендә аерым шәхесләрнен исемнәре үзгәртелеп бирелгән булса, хәзергеләрендә — ничек бар шулай. Шунысы бар, әдип үзе күреп белгән, үзе дәрәҗәсендә, ягъни үзенә яхшы таныш булган эшчәнлеккә һәм кешеләргә генә кискен бәясен чыгара. Әйтик, Көнчыгыш телләр бүлеген аерып чыгарып, институт итеп оештыруда «армый-талмый» хезмәт иткән Жәмил Зәйнуллиннын директор кәнәфиен биләгәч тә татар факультетына, ягъни татар мәнфәгатьләренә арка белән борылуын ачыктан-ачык әйтергә җөрьәт итә. Чөнки безнен халык әле милләт белән диннен икесе ике нәрсә булуын һәм гарәп телендә сөйләшкән һәр кемсәнен татар җанлы булмавын аңлап бетерми.

Т.Галиуллин тормышта да оптимистик рухлы кеше, иҗатында да шулай булып кала. Яшәү белән үлем арасына китергән авыру белән көрәшүен ярым елмаеп хикәяли. Тормышка мондый матур омтылышнын үрнәген Т.Миннуллиннын «Әлдермештән Әлмәндәр»ендә генә күрергә мөмкин. Күпләр авыр халәтне

тасвирлаганда мавыгып китеп, чаманы оныталар, укый-укый күнелләр болгана башлый. «Замана балалары» «Казан утлары»нда чыгып озак та үтмәде, миңа Казанга барырга туры килде. Башкала җәмәгатьчелеге «дерт» иткән дисәм, артыграк булыр, ул әле беренче төртүдән үк уянырлык түгел, ләкин мактау-мактану исереклегеннән иләсләнгән күзләрен ачып, берни аңышмыйча гына, як-ягына карана башлаган иде. «Тукта әле, ни булды? дигән сорау иде сымак аның карашы — бик рәхәт яши идек бит әле. Үзеннен бөеклеген турында — бармы ул, юкмы, анысы икенче мәсьәлә — өзлексез ишетеп торудан, юбилейларда яңгыр урынына яуган ялагай сүзләрдән кем туя инде? Күрәсен, туючылар, тынычлыкны бозарга тырышучылар бардыр. Гасырлар дәвамында изсәләр дә, кырсалар да, татарнын сау-сәламәт күзәнәкләре, дәүләтчелек рухы, иҗтимагый ан яралгысы кайдадыр, кемдәдер сакланып калырга тиештер бит инде.

Язучы, гомумән, макталырга тиеш түгел. Макталса бетә ул, сүнә, оеп йокыга китә. Буа суы тынчый, аккан су гына яши. Ә иҗат кичәләрендә, бенефисларда әдипләр, шагыйрьләр күпме мәдхия ишетә. Милләт, тел бетү алдында, ә без (сез) мәҗлесләрдә ләззәт алабыз (аласыз). Чын мәгънәсендә «Пир во время чумы!»

Әлбәттә, Т.Галиуллиннын вакыйгаларны җиңелчә юмор белән сурәтләве укучыны ияртеп алып керүгә, мавыгып укуга ярдәм итсә дә, олы тәҗрибәле аксакалдан, классиктан, әдәбият галименнән без иҗтимагый яшәешкә айның икенче ягына караган анализ да көтәргә, көтәргә генә түгел, таләп итәргә дә хаклыбыз һәм, барыбыз да татарлар буларак, мона хокукыбыз да бар. Кем сон, Тәлгат, Марат, Зәки агайлар да язмаса, кем сон язар, Достоевский, Толстой, Шолоховлар рухында, заман-чорга бәяне? Татар күптән мохтаҗ инде мона. Ил гаме белән, интим хисләр, сөю-сөелү, ир-ат, хатын-кыз мәхәббәте белән түгел, ил гаме белән психик саташу дәрәҗәсенә җиткән геройнын рухи дөньясын ачкан әсәргә мохтаҗ татар әдәбияты.

А.Хәлим мескен образларны үзәккә алып тасвирлавы белән, минем карашымча, бик үк дөрес булмаса да — чын язучы, рухы белән әдип. Я.Шафиков — иҗат темасы белән чын язучы... Шайтан алгыры, хуплаганнарым барысы да Чаллы җирлегеннән булып чыга, Казаннан да бер-икене әйтергә иде, ләкин кемне? Әнкәйләр җырчысынмы, мәхәббәт шагыйренме, З.Зәйнуллиннымы? Әмма Зәки абый да Казанны ташлап китте. Такташ сүзләре искә төшә: «Казан! Фахеш шәһәр!» Әйе, галәттә, эшсез, гайбәтче хатыннар җыелышып бер-берсен макташалар. Дөрес, арттан ияләре үзләре күренмәгәндә исемнәрен эттән алып, эткә дә сала. Йорт салган ирләр исә, читтән карап, тәрәзә кыегынын кайсы ягы дөрес утыртылмаганын бер-берсенә күрсәтә, кинәш бирә, бер-берсен төзәтә.

**Гомәр ДАУТОВ**

# АТКА МӘДХИЯ
## яки
# «ИДЕГӘЙ» ДАСТАНЫ АТ ТУРЫНДА НИ СӨЙЛИ?

Даһи тарихи-фәлсәфи эпос булган «Идегәй» дастанының әдәби тормышка әйләнеп кайтуына егерме ел үтеп тә китте. Шушы вакыт эчендә тулы бер буын үсеп-өлгереп житеп, тормышка аяк басты. Әлеге дастан яшь буын арасыннан кемнен дә булса берәүнен яраткан китабына әйләндеме икән? Ата-бабаларыбызның тарихи вакыйгаларга үрелеп бирелгән фәлсәфи күзаллаулары сере күңелләренә кереп урнаша алдымы икән? Бүген «Идегәй»не ныклап өйрәнүчеләр бармы, әллә инде галим-голәмә, барысын да ачыклап бетердек дип, дастанны өйрәнүне ябып та куйганмы? Сораулар, сораулар...

Белгәнебезчә, «Идегәй» дастаны XIVгасыр азагы XV гасыр башларында Алтын Урда дәүләтендә барган, дәүләтне таркатуга китергән тәхет тирәсендәге көрәш вакыйгаларына таянып язылган. Ул тарихи вакыйгаларны тулысынча кабатламый, әлбәттә. Ил һәм халык гаме, туган жир хисе, яхшылык һәм яманлык, кан үче һәм кичерә белү кирәклеге турында бәхәсләшә төп каһарманнар. Әсәрдә идарәче катлам тормышы, идарә ысуллары, хан хакимлегенә дәгъва итәрдәй көндәшне ачыклау, аннан арынырга омтылу, качу-эзәрлекләү, сугыш-орыш, хәйлә-мәкер белән тотак алу, жәза күренешләре зур осталык белән һәм калку итеп сурәтләнгән. Дастан, сүзләргә, сурәтләүләргә тирән мәгънә салып язылган әсәр буларак, тарихи хәтерне хәрәкәткә китерә. Анда халкыбызның дәүләтчелек тоткан чорларда ирешкән казанышлары зур урын алган. Дастан аша безгә житкерелгән казанышларның берсе — татарларның ат иярләве, дөньяны атлы итүе һәм ата-бабаларыбызның атка мөнәсәбәте.

Дастанда сурәтләнгән вакыйгалар Бөек Дала кинлекләрендә бара:

*Болгар белән Сарайда,*
*Жаек белән Иделдә,*
*Алтын Урда, Ак Урда –*
*Данлы кыпчак жирендә,*
*Татардан туган Нугай илендә.*

Бөек Дала Евразиядә Тын океаннан Әдрән дингезенә кадәр ун мен километр, Себер тайгасыннан Тянь-Шань, Кавказ таулары арасында ике-өч мен километр кинлекне тәшкил итә. Бинибая бу мәйданны колачлау, аны бербөтен итеп оештыру фәкать атлы кеше көчендә-кодрәтендә генә булган. Ат, шушы чиксез кинлекне инләүче ирләрнең армас-талмас корабы да, жилкәне дә булып, меңнәрчә ел кешегә хезмәт иткән. «Атларда жилдердек» диелә Күлтәгин хөрмәтенә куелган Мәнге ташта. Бөек Дала халыклары үз яшәешләрен атка атланып-аркаланып-таянып корган. Халыкларның зур көчеше фәкать ат ярдәмендә генә мөмкин булган. Атлы кешеләр Далада ныклы тәртип урнаштыра алгач кына төбәкара сәүдә барлыкка килгән. Далада ат иярли белмәгән халыклар өчен дөнья ябык, ул үз төбәге белән генә чикләнгән.

Ни гажәп, бездә атның кешелекне үстерүдә тоткан роле турында мәктәп дәреслекләрендә бөтенләй сөйләнелми, ә махсус фәнни хезмәтләр юк дисәм дә

ялгышмам кебек. Кешелек тормышына космоска чыгуга тиң үзгәрешләр керткән Ат тарихы өйрәнелмәгән тема булып кала бирә. Без – дөньяны атлы иткән кавем – үзебезнең күп казанышларыбызны өйрәнмичә, белмичә, хәтерләмичә яшибез. Нинди булганнар алар ат иярләп илләр төзегән ир-егетләр? Нинди атларга атланып дөнья яулаганнар? Ничек оешканнар? Дастан бу бушлыкны тутыра. Ул безне атлы тормыш турында хәтерле итә, атның дәүләтле тарихыбызда тоткан урынын кайтара кебек.

Дастан юлларына атлы тарих бик ерактан үрелеп бирелгәнгә, без дә ат иярләү тарихын кыскача гына күз алдыннан үткәрик. Атны кулга ияләштерү якынча моннан алты мең еллар элек башланган дип исәплиләр. Кешеләр бу вакытта эт, сарык, кәҗә, сыер кебек хайваннарны кулга ияләштергән булган инде. Ат кебек сизгер җан иясен үзенә буйсындырганчы, күрәсең, борынгы кешегә җитәрлек көч һәм тәҗрибә тупларга кирәк булган. Кыргый хайваннарны кулга ияләштерү ничек булуы турында фаразлар аз түгел. Акрынлык белән кеше үзенә ияләштергән атларның бик акыллы, сизгер, кирәк вакытта хуҗасын яклый да белгәне ачыклана (ат бит ул бүредән дә курыкмый). Моны дастан юллары да раслый кебек:

*Таяк тайга җиткерер,*
*Тай дүнәнгә җиткерер,*
*Дүнән атка җиткерер,*
*Ат морадка җиткерер.*

Атны кулга ияләштергән кеше тормышында эзләнүләр, зур ачышлар чоры башланган: ат белән йөк ташу, юл йөрү h.б. Моның өчен металл кулланып ат дирбияләре, тәгәрмәч, арба, ыштан кебек әйберләр уйлап табылган. Даhи ачышлар булган бу. Авызлык, йөгән, өзәңге, ияр – һәрберсе атны хуҗалыкта файдалану өчен уйлап табылган, атлы дөнья мең еллар дәвамында кулланачак җайланмалар (дирбияләр) бит. Ат иярләгәч, иген игү, мал асрау, ерткычлардан саклану, төзелеш эшләре, казылма байлыклар эзләү күпкә җиңеләйгән һәм җитештерү арткан. Ат борынгы кешенең авыр эшләрен үзенә алып кына калмаган, аңа тирә-якны танып белергә, табигатьтәге урынын аңларга да ярдәм иткән. Атның көче, сизгерлеге, сакчыл кыюлыгы кешегә дә күчкән. Әлеге мал кешегә көч һәм дәрт өстәгән, тормышында оешканлык һәм тизлек тудырган.

Ат – гаҗәеп камил җан иясе. Ул – көчле, житез, чыдам, бик сизгер һәм сак. Текә ярга якын килмәс, куркыныч җиргә керер алдыннан туктап калыр, колакларын боргалап шомрайтап, башын сузып, зур дымлы күзләрен алга төбәп, бөтен гәүдәсе белән калтырап билгесезлектән хәбәр алырга омтылыр. Ат башын бормыйча гына тирә-якны тулаем һәм карангыда да күрү сәләтенә ия. Ул йөзә белә. Атның тәм тоюы һәм ис сизүе бик көчле. Үзенең колынын ул иснәп таба, үз йөгәнен таный, пычрак суны, бозылган ризыкны капмас. Әгәр солы белән ясмыкны кушып алдына салсаң, ат аларны аера – солы бетә, ясмык кала. Атның тәне бик сизгер. Ат сүзләрне аңлый, кешенең халәтен тоя, мактаганга, ачуланганга битараф түгел, ул гаделлекне ярата. Ат кешегә тугры, шул ук вакытта бар кешегә дә тигез карамый. Авыл кешеләре атның аягы да күрә, диләр. Шундый очрак булганы бар – ике яшьлек бала ат көтүе кайта торган юлга чыга. Көтү үтеп китә – бер генә ат та балага басмый. Ат бер үткән юлны яхшы хәтерли. «Ат бер юлга күнеп алса, йоклаган килеш тә йөри», – диган сынамыш яши.

Мондый искиткеч зирәк җан иясен кулга ияләштергән кешенең үз тормышында ныклы, ышанычлы дус булдырганы бәхәссез. Ат иярләү шул ук вакытта җир масштабында иң беренче энергетик һәм транспорт революциясе булган. Ат иярләгәннән соң, салмак аккан кеше тормышы зур сикереш ясау мөмкинлеге алган. Галимнәр тикшереп шуны да ачыклаганнар: атны кулга ияләштергәнче кешенең уртача гомер озынлыгы егерме ел булса, ат иярләгәч, ул кимендә ун елга арткан. Озын гомер – акыл җыю, белем туплау, тарих барлыкка китерү мөмкинлеге дә бит.

Атны беренче иярләгән кешеләр безнең бабаларыбыз – төрки-татарлар булган. Борынгы рун язуына күчергәндә «татар» сүзе «т» – корал, «ат» һәм «ар» булып таркала, ягъни «кораллы атлы ир» мәгънәсен бирә, «ир-ат» сүзе дә ир егетләрне ат белән бәйли,

ир кешене аттан аерым күзалламый. Кеше тормышына шундый зур үзгәрешләр кертүгә китергән ат, билгеле инде, изгеләштерелгән, төрле мифлар тудыруга этәргән. Кояш балкыган мәңге зәңгәр күк алласы Тәңре бүләге дип караганнар атка. Тәңрегә багышлап тау итәгендә ак атны корбан иткәннәр. Борынгылар атны канатлы дип санаганнар һәм күкләргә күтәрелә ала дип тә уйлаганнар.

Кешенең кыргый табигать баласы икәнен дә онытмыйк. Атка атлангач, уй һәм акылы аның бу ягына да дәрт өстәгән – атлы кеше киек-җанварларны гына түгел, кирәк икән үзе кебек адәм балаларын да хәзер җинел кулга төшерә алганын аңлаган. Ауда кулланган ук-җәяләрне камилләштерү, металлдан корал ясарга өйрәнү, аның сугышчан дәртен тагын да арттырган. Хәзер инде атлы кешеләргә үз ыру-кабиләләрен якларга, сакларга өйрәнү кирәк булган. Башка кабиләләрдән саклану һәм үз халкын үстерү максатында беренче дәүләтләр барлыкка килгән. «Өстә күк Тәңре, аста – көрән җир кылынганда (барлыкка килгәндә) ике арада кеше углы барлыкка килде. Кеше угыллары өстеннән борынгы бабаларыбыз Бумын каган, Истәми каган идарә иткән. Тәхеттә утырып төрки халыкның илен һәм кануннарын саклаганнар, үстергәннәр. Дүрт ягында дошман күп булган, сугышып, дүрт ягындагы халыкны буйсындырганнар: башлының – башын идергәннәр, тезлене – тезләндергәннәр», – диелә Күлтәгин истәлегенә куелган Мәңге ташта (VIII гасыр). Нинди бөек, беркайчан әһәмияте кимемәячәк сүзләр бу ташларда! Ташъязмадагы «Тәңре», «канун» , «ил» сүзләре безнең яшәү рәвешебезнең нигезе бит.

Борынгы кешенең Җир-ананың һәр төбәген яшәү урыны итүе, аның канына салынган йөремсәклек сыйфаты, күрәмсең. Атка атланганчы ук адәми затлар дөньяның төрле кыйтгаларына таралып, җирле шартларга яраклашып, төрлечә оешып, үз биләмәләрен кинәйтеп яшәгәннәр. Ат – оешканлыкны тизләтүче һәм колачлырак итүче, житештерүне арттыручы һәм тирә-якны эзлекле үзләштерүгә этәрүче Күкләр бүләге, могҗизаи бер көч булган. Җирне беренче үзләштергән йөремсәк кешеләр дулкынын атлы кешеләр дулкыны алыштырган. Атлы кешеләрнең көчлерәк тә, булдыклырак та булуында шик юк.

Безнең эрага кадәр (б.э.к.) ике меңенче еллар азагында Һиндстанга төньяктан атлы кешеләр – арийлар үтеп керә. Алар тимер эшкәртү техникасын җәелдерә. Шул чорда анда төрле эш кораллары, сабан, ау, балыкчылык кирәк-яраклары ясарга өйрәнәләр. Үгез җигеп җир эшкәртүгә күчәләр. Күпләп ат үрчетәләр. Ат сугыш максатларында, хәрби сугыш арбаларында кулланыла. Шул ук чорларда Көнбатыш Европага атлы күчмә кабиләләр үтеп керә. Гайрәтле сугышчылар булган бу кабиләләр җирле халыкны кысрыклый. Хәзерге Европа халыкларының күбесендә шул атлы җайдаклар каны ага дип исәплиләр.

Б.э.к. III гасырда Кытай белән чиктәш Һун дәүләте оеша. Күп санлы атлы гаскәргә ия Модэ (икенче исеме Баһадур) шаньюй төрле җирле кабиләләрне буйсындыра. Һуннар үзләренә каршы сугышка чыккан Кытай гаскәрен камап алуга ирешә. Император үзе җитәкләгән гаскәр кышкы суыкта камалышта кала һәм һуннарга буйсынырга мәҗбүр була. Килешү буенча Кытай императоры Һун дәүләтен үз дәүләтенә тиң дәүләт дип таный, һуннарга бүләкләр җибәреп торырга вәгъдә итә һәм кытай принцессасын шаньюйга кияүгә бирә. Кытайлар шул вакыйгалардан соң үзләре дә күпләп ат үрчетүгә керешә. Кытай елъязмаларында Баһадур шаньюйның кытайлар белән Байден калкулыгындагы әлеге сугыш алдыннан үз атлы гаскәрен түбәндәгечә тезгәне теркәлеп калган: көнбатыш канаттагы атлар барысы да акбүз, көнчыгыштагылары соры (кашка), төньяктагылары кара, ә көньяктагылары җирән булган.

Модэ шаньюй дәүләт белән идарә итү өчен күп яңалыклар керткән. Ул керткән үзгәрешләр Бөек Дала халкы өчен яшәү рәвешенә әйләнеп, мең елдан соң да әһәмиятен югалтмый. Модэ төрки дәүләтнең ныклы структурасын барлыкка китерә. Үзгәрешләр нигезендә ыру башлыклары ирекле сайланмый, ә вазифаларын варисларына тапшыру хокукы ала, ягъни ыру аксөякләре барлыкка килә. Шул ук вакытта ыру башлыклары шаньюй җитәкләгән югары идарәгә буйсынырга тиеш була. Дәүләтнең ныклыгы өчен өченче көч кертелә – гади сугышчылар арасыннан талантлы, көчле кешеләр ил идарәсенең югары катлавына кадәр күтәрелә алган. Модэ шаньюй керткән үзгәрешләр дәүләтне берләштерүгә, ныгытуга һәм көчәюгә

китергән. Һун дәүләте өч йөз ел буена Кытай басымына бирешмичә яшәвен дәвам иткән. Шулай итеп, татар дәүләтен Кытай үзенә тиң дәүләт дип таныганга 2100 елдан артык вакыт үткән икән.

Аннан соң оешкан Атилла дәүләте, Бөек Төрки каганлыклары һәм Алтын Урда төрки дәүләтләр булып, борынгыдан килгән дәүләт тоту, идарә итү ысулларын дәвам иткән һәм үстергән. Монгол исеме белән тарихка кергән бөек Чыңгыз хан үз биләмәләрен Көнбатышка кинәйткәндә Бөек Төрки каганаты җирләрен кабат берләштерә. Бу җирләрдәге халыкта дәүләт тәртибен тану, сакларга омтылу көчле булган дип уйларга кирәк. Төрки телнен монгол теле белән беррәттән рәсми дәүләт теле булып китүе дә шуны раслый. Чыңгыз ханны икенче меңъеллыкның иң бөек кешесе дип игълан итү – дәүләт һәм атлы гаскәр белән идарә итүдә ул керткән яңалыкларның кешелек үсеше өчен әһәмиятен танудан килә. Бинибаса зур территория белән идарәдә элемтә урнаштыру һәм куркынычсыз юллар барлыкка китерү, бихисап гаскәрне туплау, коралландыру, өйрәтү, яңа сугыш тактикасы кертү, утлы корал һәм җимерү машиналары уйлап табу һәм төрле ыру-кабилә кешеләренең көчен Бөек Тәңрегә инандырып бер максатка – Бөек дәүләт төзүгә юнәлтү – Чыңгыз ханның казанышлары санала. Дәүләт Чыңгыз хан керткән Яса нигезендә идарә ителгән. Яса буенча аңлы рәвештә алдау, урлашу, ришвәтчелек, казна талаучыга үлем җәзасы каралган булган. Борынгы төрки дәүләтләрдә тыелган һөнәр булмаган, кешенең мал-мөлкәте чикләнмәгән һәм талап алынмаган. Яса житештерүче катламның мал-мөлкәткә хокукын тагын да ныгыткан. Дала кешесенең иң зур байлыгы ат булганлыктан, Ясада мондый юллар бар: «Әгәр кем дә кем ат урлауда тотылса, ул кеше ат хуҗасына өстәп шундый ук ун ат кайтарып бирергә тиеш; ...бурычын кайтарып бирә алмаса, аны сарык урынына суярга».

Чыңгыз ханның шәхесе һәм идарә ысуллары бик күп галимнәрнең тикшерү үзәгендә булган һәм бүгенге көндә дә эзләнүләрнең кимегәне юк. Тикшерүчеләр дөньяны яулаган тиңдәшсез җиһангир Бөек Тәңре ачкан ун хакыйкатькә таянып идарә иткән дип исәплиләр. Күкләрнең боерыгы түбәндәгеләрдән гыйбарәт: «Яхшылыкны онытма. Гади бул. Үз-үзеңне кулда тот, ачуыңны йотарга өйрән. Акыллы, талантлы кешеләрне эзлә, аларны үзеңә хезмәт иттер. Дошманыңны кызганма. Рәхимсез булма. Җайлаша бел һәм яңача идарә итүдән курыкма. Күкләр синең терәгең икәнне исеңнән чыгарма. Үзеңнең варисларыңны һәм көрәштәшләреңне дә шуңа инандыр. Диннәр ирегеннә хөрмәт ит».

Башка халыклар төрки-татарлар казанышы булган бик күп яңалыкларны үзләренеке иткән. Ат иярләү, металл эшкәртү, камил язу барлыкка китерү, хәбәрләшү өчен юлларны тамгалы күрсәткечләр (агачлар) белән билгеләүне дә кертеп ямчылар (почта) хезмәте оештыру, атлы гаскәр тоту – Бөек дала халкы иҗаты. Төркиләр мәңге зәңгәр күк иясе Тәңрегә табынган һәм үз бөеклекләрен Тәңре кушуы буенча яшәгәндә генә саклый алган. Төркиләр тырышлыгы белән Европа һәм Азияне тоташтырган сәүдә юллары барлыкка килгән. Кытай, Һиндстан, Әфганистан, Урта Азия, Иран, Борынгы Римгә сәүдә кәрваннары төрледән-төрле мал (ефәк, кәгазь, металл һ.б.) ташыган. Бу юл Бөек ефәк юлы дип йөртелсә дә, анда алыш-бирешкә йөртелгән иң кыйммәтле мал ат булган. Моның шулай икәнен тарих үзе раслый. Борынгы Афинада һәм Рим империясендә аты булган кешеләр аерым катлам тәшкил иткән (шулай дип аталганнар да – атлылар), дәүләт иерархия баскычында аристократия һәм сенаторлардан кала икенче урында торган, ат һәм сәүдәгәрлек белән туплаган байлыкларына таянып зур көчкә ия булган. Бу дәүләтләрдә сугыш өчен атлы гаскәрне дала халыкларыннан махсус яллый торган да булганнар. Атка табыну бу борынгы дәүләтләрдә архитектура бизәлешләрендә үзенчәлекле чагылыш тапкан. Игътибарлы сәяхәтче бүген дә ат сыннары белән бизәлгән Афина Акрополе фризларын күреп соклана ала, ә Римда ат сыннары шәһәр үзәгендәге зур мәйданнарда горур басып тора.

Илләр төзегән ирләрнең хыялы, омтылышы, тормышта төп терәге Ат булганлыктан, «Идегәй»дә аттан башка бер генә күренеш тә юк. Туктамыш хан дастан хикәяләвенә акбүз атка атланып килеп керә. Акбүз ат – хакимлек билгесе, ханнар өчен махсус үрчеткәннәр андый затлы атларны. Ауда йөргәндә Шаһ Тимердән кинаяле хат ала хан. Ул анардан горурлыгы булган ау лачынын үзенә

бирүен таләп итә. Кем мондый түбәнсетүгә түзсен? Лачын сораучыга: «Тешен житсә, таш кимер!» — дип жавап хаты юллый Туктамыш. Ә күнелендә кош караучы Котлыкыя Шаһ Тимергә сатылган дигән шик давылы кузгала. Дәлилләнмәгән шиге аркасында туры сүзле Идегәйнен атасы Котлыкыянын башын чаптыра. Идегәйне үлемнән, бишеккә үз баласын куеп, атасынын дусты Жантимер коткарып кала.

Күпмедер еллар үткәч, далада үзен — олы ханны! — сәламләмәгән балалар төркеменә тап була Туктамыш хан. Бик аптырый ул — ни өчен олы ханга илтифат итүче юк. Моны Кобогыл исемендә йөргән Идегәй оештырган була. Ул далада көрәшеп туксан баланы жингән һәм шаяртып: «Туктамыш хан тәхетенә мин мендем!» — дип яр салган икән. Шуна ханнын :

*Ханыгыз булган минме өлкән,*
*Әллә юкса сезме өлкән?! —*

дигән сүзләренә Идегәй бик кыю:

*Туксан башлы урданың*
*Янымда туксан баласы,*
*Шушы туксан баланың*
*Яшен санап салсам мин,*
*Анда чыгар без өлкән, —*

дип жавап бирә.

Идегәйнең кыюлыгы, тапкырлыгы ханны өч көн, өч төн йокысыз итә. Бераздан ханга аның белән кабат очрашырга туры килә. Урман би турында «Балалар менгән агач ат — аны урлап тотылды», — диелә дастанда. Һәм балалар өч урлашып дүртенчесендә тотылган Урман бинең караклык өчен башын чабалар. Бу жәза өчен жавап тоткан Идегәй:

*Илеңдә йөргән каракчы*
*Өч ат урлап котылса,*
*Дүртенчедә тотылса,*
*Синең түрәң буенча*
*Дүртенчедә чабылса, –*

дип, Урман бинең дә нәкъ шушы хан түрәсе (хөкеме мәгънәсендә) буенча жәзага тартылганын исбатлый. Туктамыш хан аның гамәлен дөрес дип таба. Борынгы төрки дәүләтләр заманыннан килгән гадәт буенча, хан мондый кыю, тапкыр, башкаларга баш була белгән егетне үзенә хезмәткә ала, гаскәр башлыгы итеп куя. Ялгышмый Туктамыш хан. Идегәй кул астында илдә тәртип урнаша. Ил «яу белән даудан котылды», «ил казнасы бай булды» — яңа гаскәр башлыгынын тырышлыгы дастанда шулай бәянләнә. Тирә-якта да шундый батыр егет турында инде ишетеп беләләр. Ана өмет һәм ышаныч белән карыйлар, илне тота-жыя алучы, ил сүзен тотучы, коллыктан коткаручы итеп күрәләр. Идегәй турында:

*Аты юкка – ат булды,*
*Чүлләгәнгә – су булды,*
*Адашканга – юл булды,*
*Ялгызга – ясак,*
*Җаяугә – таяк ул булды, —*

дигән сүзләр дала халкы арасында таралган була.

Батырлыкны тану белән рәттән көнчелек тә бар бит әле тормышта. Идегәйнең булганлыгы, үзен бәйсез тотуы Туктамыш хан ханәше Йәникә күнелен корт булып кимерә башлый — элекке көтүче үзен хан каршында шулай иркен тотсын инде. Күр әле син аны — олы хан ул кергәндә үзе ирексездән калкып куя! Мондый көчле

кешене сарайда калдырып булмый, ул тәхет өчен куркыныч. Идегәйне агуларга мәкер коралар, барып чыкмый – Идегәй сарайдагы дусларының вакытында кисәтүе ярдәмендә мәкерне ача. Һәм агулауны оештыруда Йәникә кулы уйнаганын сиздереп: «Иләмле икән иләген,/Куксымый микән чиләген?...» – дип, сарайдан аны мыскыллап чыгып китә. (Иләмле – ямьле. Сөйләнгән сүзе матур күренсә дә, төбендә бозыклык ятканына ишарә) Яңа фикер өлгерә – Идегәйнең кем икәнен ачыклау максатында сарай тормышында борынгыдан кулланылып килгән сынау мәҗлесе җыярга булалар. Зур мәҗлеснең төп кунагы – атаклы Субра ерау. Ханның юмарт бүләкләренә тәмам эреп киткән ерау Кобогыл исемендә йөргән егетнең хан башын кистергән Котлыкыя улы икәнен ачып бирә. Димәк, каршында үч алырга мөмкин кан дошманы улы басып тора! Идегәйгә сарайдан чыгып качудан башка юл калмый. Аны урамда, гадәттәгечә, тугрылыклы аты көтеп тора:

*Токымы толпар яралган*
*Тимгел Чуар ат икән;*
*Өзәңгегә бер тиде,*
*Җирдә яткан садагын*
*Иелеп алып бер киде,*
*Тим Чуарның янбашы*
*Җиргә ятып бер тиде.*
*Әйләнеп карап күргәндә,*
*Идегәй инде юк иде.*

Җайдакны җирдән күтәреп алырга – «янбашы җиргә ятып бер тиде» –сугыш атларын махсус өйрәткәннәр. Өйрәтелгән ат яраланган хуҗасының янына ятып, ияргә утырырга булышкан һәм аны яу кырыннан алып чыккан. Бу юллар Идегәй атының да махсус өйрәтелгән сугыш аты булуын күрсәтә.

Үзен куа килеп, кайтырга үгетләгән Җанбайны ат тоткан кеше өчен иң ямьсез чагыштыру: «Син – бетләгән соран ат!» – дигән сүзләр белән мыскыллый Идегәй. Ханның усал боерыгын күңелендә тоткан Җанбай аның сүзләрен ишетмәмешкә салыша, дала кешесе һич каршы тора алмаслык ымсындыргыч тәкъдим – ат бирергә ышандырып, качакны кире бормакчы була. Менә ничек сурәтли ул вәгъдә ителгән атны:

*Колагын бездәй кадаган,*
*Кәгелен кыздай тараган,*
*«Чу!» дигәндә очкан кошны*
*Узып китмәгә яраган,*
*Йөргәндә эзен санаган,*
*Куш йөрәкле яралган,*
*Кысыр елан үзәкле,*
*Калтыраудай танаулы,*
*Сахтияндай иренле,*
*Сарымсактай азаулы,*
*Кыйган камыш колаклы,*
*Тустагандай тояклы,*
*Ал өркәче май баскан,*
*Арт өркәчле дөядәй,*
*Арысландай күкрәкле,*
*Юлбарыстай сөйрәкле,*
*Чапкан чакта җил җитмәс,*
*Табаны ялпак Тарлан бүз*
*Ат бирәдер ханиян,*
*Менсәнә, Идегәй, менсәнә!*

Шигырьнең һәр юлында атны ярату, аңа соклану, атны зурлау янгырый. Далада атның хайваннар патшасы булганын тоябыз әлеге юллардан. Мондый мәһабәт атка

хужа булган ир егетнең дә аты кебек үк соклануга һәм дәрәҗәгә лаек булуында беркемнең дә шиге юктыр. Куа килгән Җанбайга Идегәй үзе хөрмәт итмәгән куркак кешегә «Ап-ак бүз ат мендермәм!» – ди.

*Кола-алалы күп елкыңны*
*Куып әйдәп алмасам;*
*Боты савырлы кәрән ат*
*Ботка тартып менмәсәм,*
*Ике саклык турыны.*
*Олауга җайдак алмасам, –*

дип, максатының Туктамыштан атлар алу икәнен дә белдерә һәм көченең кыдырау атны егарга җиткәнен, үзенең Чыңгызга тиң булганын әйтеп, юлын дәвам итә.

Кеше тормышы табигатьтән аерылгысыз. Аның холык-кыяфәтендә баскан туфрагы, эчкән суы, ашаган ризыгы белән бергә ул йөргән тау-урманнар, искән җилләр, эссе-суыклар, аралашкан тереклек-хайваннар һәммәсе дә үз эзен калдыра. Шул шартларда меңнәрчә ел яшәгән адәм баласында ул эз беркайчан да югалмый. Без бит аттан яралганбыз. «Ир-егетнең эчендә иярләгән ат ятыр», – дип, мәкаль дә ир егетнең холкын һәм омтылышын ат белән бәйли. Ат кебек ышанычлы, ат кебек түзем, ат кебек житез, кайбер чакта ат кебек ярсу – чынлап та бу сыйфатлар безнең ир-егетләребезгә аттан күчкәндер. Ат тоткан кеше ул бик эшчән, күзәтүчән, кайгыртучан булганда гына уңышка ирешә ала. Безнең холыктагы каударлык, кырыслык, таләпчәнлек кебек сыйфатлар да кырыс тормыш һәм табигать шартларына яраклашып барлыкка килгәндер.

*Тауга оялар шоңкармын,*
*Тау аркылы юртармын!*
*Торлаксыз үскән коланмын,*
*Мизгелсез юшап уртлармын,*
*Ярлыштан асаумын,*
*Бугалак салсаң туктамам! –*

дип, алты яшендә атка атланган, далада атлар көткән, дау бастырган Идегәй үзенең холкын кош кебек оча торган, бәйсез үскән ат белән чагыштыра.

Берничә урында Норадын да үзе турында :

*Буралкы аттан ярсумын,*
*Бугалак салсаң, туктамам, (буралкы – иясез ат) –*

дип, әтисенең сүзләрен кабатлый, холкын Идегәй холкына тәңгәл итеп куя.

Яхшы ат әсәрдәге һәр геройның иң татлы хыялы. Хәтта йөз туксан биш яшәгән, «чүбин аяк ат менгән» (үләр вакыты житкән) Субра ерау да ханнан: «Ни бирерсез безләргә?» – дип сорый һәм аның:

*Алпан да тилпән йөгертеп,*
*Адымын җиргә куыртып,*
*Аргымак ат бирием, –*

дигәнен, күп бүләкләр белән бергә ат бирәсен ишеткәч кенә мәжлестә кемлекне сынауга (ачуга) керешә.

Дастан дала кешесенең тормыштагы һәр адымын ат белән чагыштырып, атны хәтердә тотып бәян итә. Әсәрдән без дөньяга яңа аваз салган «ат башыдай ул» туганын, аттагы егетнең «очкан кош белән ярышып» барганын, батырның кыяфәте «ярашык аттай ярсынган, аргымак аттай типсенгән» булганын, «жабага тайга мендерү»нең егетне мыскыллау өчен эшләнгәнен, иң зур гаепнең «кара аргамак катыру» икәнен беләбез. Идегәй иленә яу белән килгәндә «бия сауган сөтле йортын»,

«күк тугайга бия бәйләшеп, колын тайдай уйнашып» йөргән вакытларын сагынып искә ала һәм иленең «елкы белән тулган йортын» кире үзенә кайтаруны максат итеп куя.

Үзенең дуамаллыгы, рәхимсезлеге, акылсыз идарәсе аркасында илен-халкын күп бәлаләргә төшергән Туктамыш хан гомеренең соңгы минутлары якынлашканда, иле турындагы үкенечле уйлары белән бергә, үз гаебе аркасында һәлак булган атларын да искә төшерә. Ил-көн тормышы кебек кадерле, газиз булган икән бит аның атлары да. Ни үкенеч:

*Минем газиз байтагым*
*Тубыктан канга батты ла!*
*Тугыздан урмә кыл аел*
*Аргамакка батты ла!*
*Өзәңгесе өзмә алтын,*
*Нукталары сум алтын,*
*Азаулары бер карыш*
*Аргымаклар бауда катты ла!*

Гомерен ат өстендә үткәргән дала кешесенең төшенә дә ат керү бик табигый. Тормыштагы кебек, төштә дә атны йөгәненнән тотканны, атлы булганны яхшыга юраганнар. Качып киткән Идегәйнең төшенә «алтынлы ияр акбүз ат» тотканы керә. Моны морадка ирешүгә юрыйлар. Ә Туктамыш хан төшендә «Ашлы суга ат салдым, акбүз атым батырдым», – дип күрә. Төш юраучы монын Идегәй белән сугыш булачагын, татарның күп каны агасына ишарә дип таба һәм сүзләре өчен зинданга ябыла.

Ат иярли алмау, начар атка атлану, җәяүгә калу турындагы уйлар дастанда дала кешесенең үлем сәгате килгәнен, шуны сизгәнен белдерә (ат сизгерлеге!). Үлем турындагы бу уй, зур оркестрда яңгыраган куркыныч аһән кебек, дастанда берничә урында яңгырап-яңгырап китә. Яше өлкән Субра ерау «сыбай менеп килмәстер» диелә. Идегәйнең улы Норадынны ябага (начар, кыргыйлашкан) атка атландырып чүлгә үлемгә чыгарып җибәрәләр. Туктамыш ханның күнелен, Идегәйнең үзенә яу белән килгәнен белмәстән дә, җәяүгә калу турындагы уйлар бимазалый башлый.

Дастан, мәһабәт атлар иярләгән ир-егетләрнең ашкынулы көрәш утын яңгыраткан зур симфония кебек, иң сагышлы авазда – төп геройларның үлеме белән тәмамлана. «Алар атта, ул җәяү» – бу Идегәйнең соңгы минутлары, үлемнең котылгысызлыгын белдергән, аны аттан аерып үлем кочагына алып киткән мизгел.

Шулай да бу сагыш авазы тәмам бетү дигән сүз түгел. «Алдагы көн агырга без барабыз, ул килмәс!..» Идегәйнең сүнеп барган аңы безгә бу сүзләрне васыять (бәлки күрәзәлек) итеп житкерә. Ат иярләгән ир-егетләребезнең курку белмәс, түзем, тырыш, эшчән, ил төзүче-тотучы булачакларына, аларның бу сыйфатлары беркайчан да югалмаячагына ышанып, алдагы көнгә «без барабыз», – ди бит батыр. Амин!

**P.S.**

Планета күләмендә атны зурлаган бер тамаша Сиднейда 2000 елда җәйге олимпия уеннарын ачу тантанасында булды – мәйданга чабып килеп кергән атлар төркеме атның кешелек тормышында уйнаган ролен тану жыры булып яңгырады анда. Дулкынландыргыч иде бу мизгел – тизлекне чапкан аттан да камил гәүдәләндерүче гүзәл күренеш юк бит.

«1988 елдан бирле дүрт елга бер тапкыр (октябрь аеның икенче якшәмбесендә) дөнья күләмендә «Ат көне» билгеләп үтелә», – дип яза «Миллият сүзлеге»ндә Аллер ага Тимергалин. Атның кешелекне үстерүдә тарихи ролен танып, аны хөрмәтләү көне дә бар икән бит. Әкренләп без дә тарих битләренең ат турындагы данлы-шанлы чорларын ачарбыз һәм танырбыз шәт. Ат рухы шуна дәшә.

**Зәрия ХӘБИПОВА,**
*Әлмәт*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Кырым−Сарай

Кырым-Сарай авылы район үзәге Баулыдан 18 чакрым ераклыкта урнашкан. Бу авыл янында археологлар борынгы болгар чорларына мөнәсәбәтле курган тапканнар.

Авыл 1788 ел датасы белән җир сату документларына кереп калган. Атама тарихи чыганакларда еш искә алына.

Сарай берәмлеге катнашкан авыл атамалары Татарстанда шактый гына: Сарай-Чокырча Арча районында, Югары Ослан һәм Кукмара районнарында Бакча-Сарай бистәләре, Минзәлә һәм Тукай районнарында Сарай авыллары бар. Шушы ук ояга Тукай һәм Сарман районнарындагы «сарайлы» атамаларын да кертеп карыйбыз. Безнең уебызча, Татарстандагы Сарайлы бистәсенең һәм Яна Сарайлы авылларының халкы Идел Сарай шәһәрендәге үзара ызгышлардан туеп, бер өлеш халык Кама аръягындагы тынычрак урыннарга килеп утырган һәм яна нигезләнгән авылларга Сарайлы дип исем биргән, ягъни Сарайдан килгән − Сарайлы. Югарыда саналган атамаларны без этнонимнан ясалган дип уйлыйбыз. Сарай этнонимы төрек халыкларның күбесендә бар. Үзбәкләрдә ул Дәште Кыпчак далалары белән бәйләнешле ыру-кабилә атамасы итеп карала, нугайларда да шундый ыру атамасы бар. Мең кабиләләре составындагы Сарайлы мен − татар ыруы атамасы. Аксак Тимернең өлкән хатыны (Казан ханы кызы) исеме Сарай-Мөлек-Ханым булган. Алтын Урда дәүләтендәге ирләр исеме арасында Сарайбуга (Менгү Тимер улы, XIII − XIV йөзләр) аты билгеләнгән. Сарай берәмлеге белән ясалган рус фамилияләре икенчел булган. Сараев дигән шактый борынгы фамилия теркәлгән, шулай ук Куземка Сарайник дигән шәхес билгеле (XVII йөз башы), Сарай топонимының һәм гидронимнарының таралу ареаллары бик киң. Башкортстанның Әлшәй һәм Благовар районнарында Сарайлы, Сарайсино, Сарайтау, Сарай авыллары бар, Сарайчик − борынгы кыпчак шәһәре (хәзер Урал суының түбән агымындагы Сарайчык авылы). Украинаның көньягындагы Сарай суы Днестр, Яблонка, Стрия елгалары кушылдыклары, Кырымда Бакчасарай исемле район бар.

А.Гусейнзаде язуына караганда, Сарай, Сарай-Беркә, Сарай-Бату, Сарай-Мансур һ.б. кебек атамаларның барлыкка килүе бу урыннарда сарай (дворец) төзү белән бәйләнешле дип тартып-сузып карарга мөмкин булса да, Татарстандагы Сарайлы, Яна Сарайлы һәм Апшерон ярымутравындагы Сарай атамалары бу фикерне җимереп ташлый. Чыннан да, шул ук галим язганча, беренчедән, төрки телле халыклар яши торган торак пункт атамаларының күпчелеге кеше исемнәре белән бәйләнешле этнонимнардан ясалганга, икенчедән, сарай термины элеккеге вакытларда төрки һәм монгол телле халыкларда шәхес исеме һәм этноним буларак билгеле булганга, өченчедән, төрки халыкларда борын-борыннан яшәп килгән күнелгә якын атамаларны яңа үзләштерелгән урыннарга алып килеп географик берәмлек атамалары итеп кую традициягә кергәнлектән, Апшерон ярымутравындагы Сарай

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

атамасын шул исемдәге этноним белән бәйләп карарга һәм әлеге этнонимның бу төбәккә XIII – XIV йөзләрдә монгол-төрки ташкыны белән килгән дип уйларга кирәк. Э.М.Мурзаев мондый фикер әйтә: «...Шунысы анлашылмый, бу берәмлек Якын Көнчыгыш, Урта Азия, Идел буе, Украина җирләрендә актив кулланыла, ә Себер, Урал топонимиясендә яна атама буларак очрый».

## Кысна

Кысна авылы Арча районында, район үзәге Арчадан – 31, җирле үзидарә советы үзәге Ташкичүдән – 2, Казаннан 96 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл Березник, Березник (Ксна) атамалары белән тарихи белешмәләргә теркәлгән. Д.А.Корсаков бастырып чыгарган тарихи белешмәдә (XVIII йөз мәгълүматларын үз эченә ала) күрсәтелгәнчә, Березник пүчинкәсендә ясак түли торган 113 татар кешесе гомер кичергән. 1859 ел мәгълүматлары теркәлгән тарихи белешмәдән билгеле булганча, Березник (Ксна) авылы Ашыт суы ярына утырган. Андагы 64 хуҗалыкта 202 ир-ат һәм 211 хатын-кыз гомер иткән, мәчет эшләгән.

Кысна авылы халкы июнь ахырында күршедәге Ашытбаш, Иске Иябаш, Яна Иябаш, Яна Кырлай авыллары белән бергә Иябаш җыены яки Кырлай җыенын бәйрәм иткән (Борһанова).

Кысна авылы матур гына урынга утырган. Аның бер башында Шиһап чишмәсе челтерәп ага. Аны шул исемдәге бабай казып чыгарган һәм карап, чистартып тоткан. Авылның икенче ягындагы Кызыл яр буенча чишмәләр шатланышып йөгерешкән. Монда зур буа ясалган һәм чишмәләр су астында калган. Ләкин күп тә үтмәгән, алар яна юл ярып, буа алдына килеп чыкканнар. Халык аларны чистарткан һәм улаклар куйган. Элек Кызыл ярда урнашкан бу чишмәләр хәзер дә Кызыл яр чишмәләре дип йөртелә. Көмеш сулы чишмәләрне дә үз кочагына алып, авыл уртасыннан Ашыт елгасы ага.

Авылда элек мәчет булган. Манарасын кискәннән сон, аны мәктәп итеп файдаланганнар. Бу бина искереп, ташландык хәлгә килгәч, балалар күршедәге Ташкичү авылына йөреп укый башлаган. 1982 елда иске мастерской башлангыч мәктәп итеп ачылган. 1996 елда авылда агачтан өч классны башлангыч мәктәп төзелгән. Хәзер авыл уртасында яна мәктәп һәм балалар бакчасы балкып утыра, балаларның шат тавышы белән бу урын гөр килеп тора.

Авылның урамнары кин һәм матур. Авылда хуҗалыклар саны 50. Өч урамы бар, аларны Югары оч, Түбән оч, Аргы як дип атыйлар.

Кысна авылында мулла гаиләсендә язучы Хәй Хисмәтуллин туып-үсә (1895 – 1977).

## Ленино–Кокушкино (Черемыш–Апакай)

Ленино-Кокушкино авылы Питрәч районында, район үзәге Питрәч авылыннан 28 чакрым ераклыкта урнашкан. Казан белән ике арасы 40 чакрым. Ленино-Кокушкино авылы үзе җирле үзидарә советы үзәге.

Җөри юлы өстенә урнашкан бу авыл Казан ханлыгы чорында Черемшан-Апакаево дип аталган. Үшнә суы ярына утырган Черемыш-Апакай авылында чукынмаган, ясак түләүче крестьяннар көн иткән. Авыл исеме РСФСР Югары Советының 1964 елгы указы белән В.И.Ленин (Ульянов) хөрмәтенә Черемыш-Апакаеводан Ленино-Кокушкино итеп үзгәртелә.

Авыл Черемышево (Апакаево), Малое Черемышево, Черемышево Поганое, Малое Апакаево, Апакай Чирмеш, Чирмеш иле атамалары белән тарихи белешмәләрдә шактый еш очрый.

А.Артемьев бастырып чыгарган тарихи белешмә мәгълүматларына караганда, авыл Апакаево (Черемышево) дип йөртелгән, Үшнә яры буена утырган. Авылдагы 47 хуҗалыкта 150 ир-ат һәм 162 хатын-кыз яшәгән, анда гыйбадәт кыла торган бер йорт та булган. Ч.А.Износков бастырып чыгарган белешмәдән күренгәнчә, XIX гасыр ахырларында авыл Черемышево (Поганое), Малое, Апакаево, Апакай Чирмеш, Чирмеш Иле атамаларын йөрткән. Авыл Үшнә суы ярына һәм Җөри юлы

өстенә урнашкан. Авылда хужалыклар саны 65кә житкән, аларда 86 ир-ат һәм 75 хатын-кыз гомер кичергән. 1898 елда басылып чыккан белешмәдән күренгәнчә, авыл Черемышево (Апаково) исемен йөрткән һәм анда татарлар белән руслар аралашып яшәгәнлеге искәртелгән. К.П.Берстель бастырып чыгарган белешмә мәгълүматларыннан күренгәнчә, авыл Черемышево Апакаево (Малое Черемышево) дип бирелгән, анда 512 татар һәм рус кешесе яшәгән. Черемыш авылы Үшнә суының сул ярына утырган һәм аның янында соңгы болгар — Алтын Урда чорларына нисбәтле авыл хәрабәсе табылган. Бүгенге көндә Ленино-Кокушкино бистә (поселок) тибындагы торак пункт. Биредә 20ләп милләт вәкилләре яши һәм хезмәт итә.

Анда заман таләпләренә җавап бирерлек урта мәктәп, авыл мәдәният йорты бар. Авылда тулы сәүдә комплексы төзелгән. Авыл кешеләренә һәм тирә-як авылларда яшәүчеләргә заманча җиһазландырылган медицина учреждениесе хезмәт күрсәтә.

Кокушкинолыларның күбесе районда һәм республика күләмендә эре саналган агросәнәгать предприятиесе — Питрәч бройлер кошчылык фабрикасында эшлиләр.

Черемыш (Апакай) атамасы кайдан килеп чыккан соң?

Атаманың килеп чыгышы турында фикерләр шактый. Жирле тарихчы мәрхүм И.М.Ишморатов бу авылның 1964 елга кадәр булган исеме Апакайны русларның «коко» сүзеннән алынган дип аңлатырга һәм аны Кокушкино топонимы белән бәйләргә тырыша. Ләкин бу тарихи яктан нигезләнми һәм тарихи фонетика законнарына да туры килми. Профессор Г.Ф.Саттаров 1960 елларда «Татарстан яшьләре» газетасында бастырып чыгарган мәкаләсендә Апакай топонимын «Ап-ак ай» дигән сүзтезмәдән ясалган дигән фикер әйтә.

Авыл атамасы Казан ханлыгы чорында Черемыш-Апакаево исеме белән яшәгән. Олылар сөйләвенә караганда, авылның беренче атамасы Черемыш, ягъни татарларның мари ирләрен атый торган «чирмеш» сүзенә нисбәтле. Монда, күрәсең, татарлар килеп утырганчы чирмешләр яшәгән. Шул чирмешләр янына Абакай исемле кеше килеп урнашкан һәм аның янына башка татар кешеләре дә килеп утырган.

Апакай җирләре басу-кырларга, коры елгаларга һәм табигый сулыкларга бай. Күренекле елгаларның берсе — Үшнә суы. Ул авылның төньяк тарафыннан ага. Елганың борынгырак исеме Юра булган. Су тегерменнәре корылганчы бу елга бик сай булган, тегермәннәр салынганнан соң суы тирәнәйгән. Кызганыч, хәзер елга саекканнан-саега. Үшнә суының сул ярында бик күп чишмәләр тибеп чыккан. Аларны Завод чишмәсе, Зират чишмәсе, Урыслар чишмәсе, Ташчишмә дип атап йөртәләр. Дөрес, завод чишмәсе хәзер ябылган, эзе дә калмаган. Аның исеме заводка нисбәтән бирелгән булган. Кайчандыр гөрләп эшләгән бу заводта керамик әйберләр житештергәннәр. Чишмә завод янында булган. Зират чишмәсенең атамасы аннан ерак түгел төньяктарак урнашкан татар зиратына мөнәсәбәтле. Урыс чишмәсе аннан урыс халкы су алганга шулай аталган (ул Олы Чирмеш авылына бик якын). Ташчишмә ташлыктан тибеп чыккан һәм хәзер дә Үшнә бистәсе халкын су белән тәэмин итеп тора.

Рәбига күперенең ни өчен шулай аталуы шактый игътибарга лаек. Салкын-Чишмә авылында күп балалы Рәбига исемле хатын бик ярлы һәм авыр тормышта яшәгән. Көннәрдән бер көнне утыны беткәч ул бик аптыраган һәм елга аша салынган күпер агачларын сүтеп алып кайтып яккан. Бу хәл совет хакимияте чорында булган. Көннәр жылытып киткәч, Рәбига апага күперне кире салдырткannar.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# Р

**РЕАЛИЗМ**, 19 йөздән башлап әдәбият һәм сәнгатьтә чынбарлыкның, иҗтимагый тормышның һәм кеше шәхесенең асылын кабат тергезү чарасы буларак кабул ителгән төп әдәби-иҗат методларының (ысулларының) берсе, иҗат тибы. Реалистик сәнгатькә хас үзенчәлекләр: чынбарлыкны объектив чагылдыру, типик характерларны, конфликтларны, ситуацияләрне үзләренә охшатып тасвирлау, сурәтләнгәннәрне автор күңеленнән уздырылган, ләкин иҗтимагый-тарихи вакыйгалар тәэсирендәге күренешләр итеп (социаль детерминизм) карау. Гомумэстетик атама буларак Р. 18-19 йөзләр киселешендә күренә башлый. Бүгенге мәгънәдә «Р.» термины беренче тапкыр Россиядә әдәби тәнкыйтьче П.В.Анненков, Франциядә — Ж.Оссон тарафыннан кулланыла; рус әдәбият белемендә ул Н.А.Добролюбов, Д.И.Писарев, Ф.М.Достоевский һ.б. тәнкыйди мәкаләләре аша урнашып кала. Татар әдәбият белемендә бу атама 1910 елдан соң пәйда була; Г.Ибраһимов, Ж.Вәлиди хезмәтләрендә теоретик нигезләнә һәм файдаланыла.

18 йөз ахыры — 19 йөз башында татар иҗтимагый фикеренә мәгърифәтчелек идеяләре үтеп керә һәм Г.Курсави, Г.Утыз Имәни, бигрәк тә Г.Кандалый әсәрләрендә (руханиларны тәнкыйтьләү, белемгә, тәрәккыяткә чакыру, югары әхлакый идеалларны яклау) чагылыш таба. 19 йөзнең 2 нче яртысында барлыкка килгән татар мәгърифәтчелек хәрәкәте Россия һәм Европа мәгърифәтчелегенең аерылгысыз өлешенә әверелә. Мәгърифәтчелек б-н бәйле яңа идея-эстетик эзләнүләр татар поэзиясендә аеруча көчле яңгыраш ала. Г.Чокрый, Акмулла, Я.Емельянов әсәрләрендә җәмгыятьтәге тәртипләр тәнкыйтьләнә, гаделлек, тигезлек, кешелеклелек принциплары, мәгърифәтле кеше образы раслана. Хатын-кызның җәмгыятьтә тоткан урынын билгеләү татар мәгърифәтчелек Р.ының мөһим темасына әйләнә. Татар драматургиясенә нигез салучылар Г.Ильяси һәм Ф.Халиди пьесаларында (вакыйгаларның асылын «мәгърифәтлеләр» һәм искегә ябышып ятучылар арасындагы гаилә-көнкүреш конфликты тәшкил итә) да хатын-кыз мәсьәләсе үзәккә куела. Татар прозасында мәгърифәтчелек Р.ын кузгатучы М.Акъегетзадә, З.Бигиев тиралекне бәяләүдәге бердәнбер кыйммәт итеп акыл көчен күрсәттеләр. М.Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» романының төп герое кешедә актив тормыш позициясен югары бәяли, сәләт һәм белем изге максатта, милләтенә хезмәт итү өчен файдаланылырга тиеш дип саный. Романда татар җәмгыятенең социаль-икътисади яктан артта калуы мәсьәләсе куела, милләт язмышы мотивы пәйда була. Мәгърифәтчеләр тәҗрибәсе 20 йөз башында драматургиядә — Г.Исхакый, Г.Камалларның беренче пьесаларында, поэзиядә — М.Гафури шигырьләре һәм поэмаларында, Г.Тукайның тәүге шигырьләрендә һ.б., прозада — Р.Фәхретдин, Ф.Кәрими, Г.Исхакый, Г.Чыгътай, З.Хади, Ш.Мөхәммәдов һ.б. (мәсәлән, Р.Фәхретдин, Ф.Кәрими әсәрләрендә беренче планга укымышлы, тәрбияле кеше идеалы чыга) әсәрләрендә үстерелә һәм баетыла. Язучылар әдәбият кешене гражданлык әхлагы рухында тәрбияләргә, бозыклыкка бирешмәскә өйрәтергә тиеш дип саныйлар. Ә бу, үз чиратында, әсәрләрдә публицистик, үгет-нәсихәт пафосы көчәюгә китерә; яңаның иске б-н (җәдитчелек һәм кадимчелек) көрәшү мотивлары активлаша; яңалык, яхшылыкның чагылышы төсендә, авыр көрәштә явызлыкны җиңеп чыга. Р.Фәхретдин повестьларында тәнкыйть искечә укыту ысулына һәм кадимче муллаларга каршы юнәлтелә (кара Кадимчелек). З.Һади, Ш.Мөхәммәдов иҗатларында иҗтимагый тәнкыйть элементлары көчәя төшә: язучылар татар сәүдәгәрләре, мәдрәсә хуҗалары, муллаларның наданлыгын һәм әхлаксызлыгын фаш итәләр. Г.Исхакыйның «Тәгаллемдә — сәгадәт» дидактик хикәясендә аталар буынының наданлыгы тәнкыйтьләнә, мәгърифәт-

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынан басылып килә.*

ле аналар образы идеаллаштырыла; «Кәләпүшче кыз», «Бай угълы» әсәрләрендә татар җәмгыятендәге әхлаксызлыкка тискәре мөнәсәбәт чагыла.

20 йөз башында татар әдәбиятында формалаша барган тәнкыйди Р.ның төп бурычы татар халкын гасырлар буе дәвам иткән «йокыдан» уяту була. Бу агымның асылын яшәп килүче вазгыятьне тәнкыйтьләү, кешенең камил булмавы хакында уйланулар, искечә яшәү формасын янасына алмаштыру кирәклекне раслау, татар халкы язмышы өчен борчылу тәшкил итә. Милли тормыштагы, җәмгыятьтәге аерым катламнар көнкүрешендәге теге яки бу күренешләрдән көлү аша авторлар үзләренең идеалларын укучыга җиткерергә омтылалар (Г.Камалның «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре», «Бүләк өчен», И.Богдановның «Помада мәсьәләсе» комедияләре, Ф.Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» повесте, «Яшьләр», «Тигезсезләр» драмалары, «Сәмигулла абзый» хикәясе, Г.Исхакыйның «Кыямәт», «Җәмгыять» пьесалары һ.б.). Җәмгыятьтәге иҗтимагый-әхлакый кимчелекләрне шелтәләү, көлкегә калдыру сәнгати идеянең бер өлешенә әйләнә. Тәнкыйди Р. татар әдәбиятында берьяклылыгы, автор позициясен ачыктан-ачык белдерүе б-н аерылып торды. Г.Исхакыйның «Мөгаллим» драмасында, С.Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!», Г.Камалның «Беренче театр» комедияләрендә һ.б. авторлар геройларга карата үзләренең тискәре мөнәсәбәтен белдереп кенә калмады, искечә яшәүне гыйбрәт итеп, ялгыш юл буларак бәяләде. Тәнкыйди Р. татар әдәбиятына яна геройлар бирде, аерым катламнар көнкүрешен тасвирлаудан башлап милләт язмышын чагылдыруга кадәр юл узды.

1920-30 еллар соц. Р. формалашуы чоры булды. Ул, үз чиратында, марксизм-ленинизм классиклары моделе буенча, көрәш аша һәм көч кулланып, тарихны тудыруда катнашучы актив шәхесне тәкъдим итте. Рәсми эстетика ноктасыннан караганда, бу сәнгать пролетариат һәм социалистик җәмгыять мәнфәгатьләрен чагылдыра. Р. тарихи оптимизмның чыганагы — кешене «гадел җәмгыять» төзүгә тарту, шәхси бәхет — «кешелекнең бәхетле киләчәгенә» фидакарь хезмәт итү икәнлеге турындагы фикерләрнең һәм тарихилыкның зарурлыгын раслый.

Аерым бер социаль заказ үти торган, сәяси тенденциозлыкка ия әсәр тудыру ысулы буларак соц. Р. татар әдәбиятында 1917-32 елларда барлыкка килде. Ш.Усманов, М.Гафури, Ф.Сәйфи-Казанлы һ.б. язучылар әсәрләрендә кешенең яшәү мәгънәсе үз-үзенне корбан итүгә кайтып кала торган яңа җәмгыять төзелү тасвирлана. Татар соц. Р. әдәбияты оптимизм һәм коммунистик идеяләрнең җиңүенә ышаныч пафосы б-н сугарылган. 1930 елларда соц. Р. әдәбиятта бердәнбер рөхсәт ителгән эстетик концепция буларак раслана (М.Әмирнең «Агыйдел» повесте, «Саф күңел» романы, «Миңлекамал» драмасы; Г.Бәшировның «Сиваш» повесте, «Намус» романы; И.Газинең «Онытылмас еллар» трилогиясе; К.Нәҗминең «Язгы җилләр» романы; Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы; Ш.Камалның «Матур туганда» романы сәяси мәсьәләләрне хәл итү әхлакый нормаларны үтәүдән өстен куела. Бер үк вакытта, 1941-56 елларда татар әдәбиятында гуманистик башлангычның көчәюе күзәтелә: беренче планга халык мәнфәгатьләре чыга, гомумкешелек кыйммәтләре рәтенә ватан, туган як төшенчәләрен кертә башлыйлар. 1960 еллардан башлап шәхеснең үзкыйммәте турында караш туа, җәмгыять һәм шәхесне үзгәртүче көч буларак хезмәтне пропагандалау көчәя (Г.Ахуновның «Чикләвек төше» повесте, «Хәзинә» романы), милли яшәешнең күпгасырлык мәдәни, психологик, этнографик, көнкүреш һәм әхлакый традицияләре б-н кешенең бәйләнеше ассызыклана. Бу чорда агым нигезенә «кешелеклелеккә йөз белән борылган» социализм идеясе салына. 1980-90 нчы елларда дәүләт мәнфәгатьләренең шәхси мәнфәгатьләрдән өстенлеге турындагы караш сакланса да, җәмгыятьнең кеше язмышы һәм бәхете өчен җаваплылыгы темасы барлыкка килә. Бу хәл соц. Р.ның үз-үзен инкарь итүенә китерә.

«Авыл проза»сы чикләрендә язылган әсәрләрдә крестьян (авыл) Р.ы агымы тәкъдим ителә. Аның үзәк темасы — авыл, төп герое — җир хуҗасы булудан читләштерелгән крестьян. 1970 еллар СССР халыклары әдәбиятларында заманча проблемалар һәм ситуацияләр күмәкләшү авырлыгын кичергән крестьяннар язмышына бәйле рәвештә яктыртыла торган әдәби әсәрләр языла. Халык яшәешенең авылда сакланып калган рухи терәкләре илне яңарту нигезләре итеп күрсәтелә башлый. Крестьян Р.ның бер төркем концептуаль кагыйдәләре рәсми совет идеологиясенә каршы килә. Эшчеләр сыйныфын идеаллаштыру урынына, тарихи һәм эстетик идеал буларак, авыл кешесен югары күтәрү, интернационализм идеяләре урынына милли идея (А.И.Солженицын, В.И.Белов, В.П.Астафьев, В.М.Шукшин, В.Г.Распутин әсәрләре) тәкъдим итү шундыйлардан. Татар әдәбиятында мөстә-

кыйль агым буларак крестьян Р.ы 1960 елларда аваз сала. Аның кысаларында язылган әсәрләр элегик мотивлар б-н сугарылган, татар авылының милли үзенчәлеген югалтуы сентиментальлек һәм өметсезлекнең сәбәбе булып тора. Үткән һәм бүгенге көн киләчәккә каршы куела (А.Гыйләжевнең «Язгы кәрваннар», «Берәү», Р.Төхвәтуллинның «Йолдызым», «Авылдашым Нәби», М.Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» повестьлары; С.Рәфыйковның «Авыл иртәсе» романы). 1970 елларда әхлакый мәсьәләләргә игътибар көчәя, автор позициясе тәнкыйди юнәлеш ала (А.Гыйләжевнең «Жомга көн, кич белән», «Әтәч менгән читәнгә» повестьлары; М.Мәһдиевнең «Каз канатлары» романы, «Исәнме, Кәшфи абзый!» повесте; Ә.Баянның «Тау ягы повесте» һ.б.). Ш.и. әдәби әйләнешкә яна характерлар кертелә, традицион әхлакый кыйммәтләр кабат торгызыла, халыкның милли яшәешенә, традицияләренә, гореф-гадәтләренә аерым игътибар бирелә башлый.

Магик Р. үзендә бүгенге көнне һәм тарихны, гадәти күренешләрне һәм гадәттән тыш хәлләрне бергә туплый. Анда фантастика һәм чынбарлык арасындагы аерма югала, хыялый күренешләр гадәти чынбарлык кануннары буенча үстерелә. Р.нын бу төрен файдалану кешеләргә берләшү кирәклек турындагы фикерне расларга, яшәп килгән канун һәм нормаларны тәнкыйтьләргә, изгелеккә ышанычны торгызырга мөмкинлек бирә. Татар әдәбиятында магик Р. мөстәкыйль агым буларак формалашмады, ләкин аның аерым чалымнары Н.Гыйматдинова әсәрләрендә («Сихерче», «Ут күбәләге», «Кыргый», «Китәм, димә») күзәтелә. Аларда реаль тормыштан «читтә калган» геройлар ике дөнья чигендә сурәтләнәләр.

20 йөзнең 2-нче яртысы дөнья әдәбиятында барлыкка килгән психологик Р., интеллектуаль Р., неореализм кебек агымнар игътибарны кешенең эчке дөньясына юнәлтәләр. Ф.Бәйрәмованың психологик прозага караган «Болын», «Битлек», «Кем?», «Су кызы» повестьларында тәрле сәнгати чаралар ярдәмендә кешенең тышкы шартлар тәэсирендә үзгәрми кала торган аң төпкеле, тирән психологиясе ачыла. Бу күренеш совет әдәбияты кысаларында формалашкан детерминизм традициясе җирлегендә сәнгати яналык булып кабул ителә.

Бүгенге татар прозасында Р. үсеше социаль-тарихи контекст б-н билгеләнә: авторлар әсәрләрендә бүгенге көнне тасвирларга, заманга хас проблемаларны чагылдырырга омтылалар. Тәнкыйди Р. традицияләрен дәвам итеп, алар кеше һәм иҗтимагый тиралек мөнәсәбәтләренә (Ф.Садриевның «Таң җиле» романы, «Бәхетсезләр бәхете» трилогиясе), реаль тарихи вакыйгаларга (Ф.Бәйрәмованың «Караболак» романы) мөрәҗәгать итәләр. Тәнкыйди тасвирлау объекты булып бүгенге көнне генә түгел, тарихи үткәннәрне дә күрсәтү урын ала (Ф.Сафинның «Саташып аткан таң»). Бүгенге татар әдәбиятында тәнкыйди юнәлеш төрле жанр һәм стиль вариантларында тәкъдим ителә. Әйтик, Т.Галиуллинның «Сәет Сакманов» исемле трилогиясенә кергән романнары детектив формага карый.

Реалистик тасвирлау кысаларында бүгенге татар әдипләре еш кына социаль, милли һәм фәлсәфи мәсьәләләрне берләштерергә омтылалар.

20-21 йөз чигендә дөнья сәнгатендә һәм татар әдәбиятында барлыкка килгән яна агымнар, эстетик чаралар куллану аша әсәрнең аңланылыш мөмкинлекләрен киңәйтеп, текстның күпмәгънәлелеген тәэмин итә башлады.

Әдәб.: Гайнуллин М. Татарская литература и публицистика начала XX века. К., 1966; Николаев П.А. Реализм как творческий метод: Ист.-теорет. очерки. М., 1975; Халит Г. Яна гасыр поэзиясе: XX йөз башы (1905-1917 еллар) татар поэзиясендә иҗат методы, лирик герой, традиция һәм новаторлык мәсьәләләре. К., 1979; Сверигин Р. Яна геройлар һәм яна алымнар. К., 1985; Ганиева Р.К. Совет көнчыгыш әдәбиятларында иҗат методы мәсьәләләре. К., 1988.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# «АЛТЫН ЧОР»НЫҢ АЛТЫН ШӘХЕСЛӘРЕ

*2013 елның декабрендә XX йөз башы татар яңарышы хәрәкәтенең әйдаманнарыннан булган Ә.Хәсәнинең тууына 130 ел тула. Төрки-татар дөньясында фикри тирәнлеге һәм сәнгати зәвыге белән аерылып торган «Аң» журналының укучы кулына барып ирешүенә 100 ел тулу да шушы шәхес белән бәйле.*

XX йөз башы татар дөньясындагы фикри күтәрелешнең, фән, мәгариф, сәнгать, мәдәниятнең төрле өлкәләрендә тизләнеп үсүнең – аерым шәхесләр, милләт язмышын үз язмышы итеп кабул иткән кешеләр хезмәте нәтиҗәсендә булуы мәгълүм. XX йөз башы тарихында алар аз түгел. Ләкин бу чылбырда татарлар өчен киләчәкне формалаштырган, үзгәрешнең һәр адымын алдан күзаллаган кешеләр – идея әйдәманнары бар. Татар иҗтимагый–мәдәни күтәрелешендә үз юлларын, сукмакларын булдырган зыялыларны да бер йодрыкка туплап, аларга юнәлеш биреп, рухландырып, кайгыртып торучы – зыялы һәм милләтпәрвәрләрдән бердәм агым булдыручылар. Акыл һәм сәләтен, хезмәтен һәм көчен, гаиләсенең һәм нәсел–нәсәбенең матди байлыгын милли мәдәниятне, халыкның үзаның үстерүгә тотучылар.

Шундыйларның берсе – Әхмәтгәрәй Сибгатулла улы Хәсәнов, XX йөз башы мәдәни тормышында иң күренекле урын тоткан «Гасыр» нәшриятының хуҗасы, үз заманын күпкә узып киткән «Аң» журналын чыгаручы, язучы, драматург, тәрҗемәче. Ул – Г.Тукайның, Ф.Әмирханның, Г.Кәрәмнең, Г.Гобәйдуллинның, Г.Рәхимнең, Г.Ибраһимовның дусты, мәсләктәше, фикердәше. Университетларда белем алган, рус-европа мәдәниятен яхшы белгән, житеш гаиләләрдә тәрбияләнгән татар яшьләренең рухи-фикри лидеры, аларны милли мәдәнияткә хезмәткә тартучы. Замандашларының мөнәсәбәте, үзенең хатлары аны интеллектуал һәм эстет, тыныч–сабыр холыклы, эзләнүчән һәм максатчан, матурлыкны яратучы, йомшак күңелле кеше итеп күз алдына бастыра.

Күп замандашлары, фикердәшләре кебек үк, житеш тормышлы гаиләдән: 1883 елның 15 декабрендә[1] Казан өязенең Әтнә волосте Олы Әтнә авылында сәүдәгәр гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килә. Әтисе Сибгатулла Гайнулла улы 1888 елны Казанга күченә, мануфактура белән сәүдә итә. Әхмәтгәрәй һәм аннан ике яшькә кече энесе Габделбарыйны әтиләре өйгә укытучылар чакырып укыта. Аннары егет «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә заманча төпле белем ала, документлар аның «5»кә укуы турында сөйли. Әхмәтгәрәй, татар һәм рус телләреннән тыш, төрек, алман, гарәп һәм француз телләрен белгән, Европа, рус, шәрык мәдәниятләре белән яхшы таныш. Аның аеруча әдәбият, сәнгать белән кызыксынуы, укырга яратуы мәгълүм. Әхмәтгәрәйнең шәхес буларак формалашуына әтисе йортына күрше булып, аралашып яшәгән күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйриның тәэсире зур була.

1903 елның 1 ноябрендә Әхмәтгәрәй шулай ук мануфактура белән сәүдә итүче Ногман Габделкәримовның кызы Зәйнәпкә өйләнә. Арча ягыннан, хәзерге Түбән Көек авылыннан чыккан Ногман хаҗи мәчет-мәдрәсәләр төзеткән, аларга һәрчак

[1] Бу дата метрика кенәгәсе буенча билгеләнде. Әхмәтгәрәй Хәсәнинең нәсел дәвамчылары чынлыкта аның 1 гыйнварда туган булырга тиешлеген әйтәләр, шуңа күрә кайбер чыганакларда шушы дата кулланыла.

ярдәм иткән шәхес буларак билгеле. Белемле, акыллы, сабыр холыклы Зәйнәп Әхмәтгәрәйнең алдагы тормышында якын киңәшчесе, хезмәттәше, мәсләктәше булып, аның мануфактура сәүдәсен сайламыйча, бәлки китап—журнал бастыру, чыгару юлыннан китүендә дә зур роль уйный.

Мәгърифәтчелек хәрәкәтен әйдәп баручы XIX гасыр зыялылары китап басуга, халык арасында басма сүзне таратуга аерым игътибар бирәләр. Әйтик, шулай ук XX йөз башы янарышының әйдәманнарыннан булган бертуган Рәмиевләр гаиләсе тарихында сакланып калган, Шакир Рәмиев 1881 елны Истанбулдан 21 яшьлек энесе Закирга җибәргән хатында татар милләте өчен иң кирәкле мәгърифәт чарасы — китап булуны ассызыклый, типография хәрефләрен сатып алып илгә кайтаруны кайгыртырга куша[2]. Шуна күрә XIX—XX йөзләр чигендә, мөмкинлек булуга, күпләп татарлар өчен нәшриятлар ачылу гаҗәп түгел. Әтисе янында сәүдә-сәнәгать эшенә өйрәнеп килгән яшь Әхмәтгәрәй дә 1907 елны шундый китап басмаханәсе оештырып җибәрә, 1908 елның 30 июненнән (105 ел элек) ул «Гасыр» исемен йөртә башлый — милләт тарихында яңа гасыр туып килүне, үсеш-күтәрелеш заманына аяк басуны хәбәр итә. Нәшрият 1921 елга кадәр эшли, төп юнәлеше булган татар, рус, гарәп матур әдәбиятын халыкка җиткерү мәсләгенә тугры кала. Аның тарихын өйрәнүчеләр басылып чыккан китапларның яхшы сыйфатлы, югары зәвыклы булуына, хуҗаның сан яки табыш артыннан кумавына аерым игътибар итәләр.

Әлеге басмаханә эшчәнлеген тулырак күз алдына бастыру өчен, берничә факт китереп үтү урынлы булыр. Әйтик, 1907-1921 еллар аралыгында бирeдә 153 исемдәге китап 437500 тираж белән дөнья күрә! С.Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин» комедиясе, Ф.Кәриминең «Морза кызы Фатыйма»сы, Г.Ибраһимовның «Сөю — сәгадәт», «Карак мулла», «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә»се, Ф.Әмирханның «Татар кызы» һәм «Фәтхулла хәзрәт»е, «Яшьләр» һәм «Тигезсезләр»е, С.Җәлалның «Дим буенда»сы, Г.Камалның «Беренче театр», «Безнең шәһәрнең серләре» — татар әдәбиятының иң күренекле әсәрләре шушы басмаханә аша татар укучысына барып ирешә. Югары сыйфатлы күпсанлы тәрҗемәләр, фәнни әдәбият (әйтик, Г.Ибраһимовның тел белеменнән китаплары), дәреслекләр, халык авыз иҗаты җәүһәрләрен туплаган җыентыклар, балалар әдәбияты, сүзлекләр, хәтта аш-су, медицинага караган китаплар, татар язучыларының, сәнгать эшлеклеләренең портретлары белән почта открыткалары — ниләр генә юк аның репертуарында! 1916 елны «Гасыр» хуҗасы халыкка бушлай өләшү өчен мең данә Сөембикә рәсемен эшләтә. Халыкның милли аңын кем шәүкәте—авторитеты ярдәмендә күтәрү, милләтне кайсы шәхесләр тирәсенә туплау мәсьәләсендә дә аның алдан күрүчән булганлыгы бәхәссез.

XX гасыр башы зыялылары татар яшьләре өчен клублар оештыра башлагач, аларның иң затлысын — 1907 елның 1 декабрендә ачылган «Шәрык клубы»н нигезләүчеләрнең берсе дә Ә.Хәсәни була. «Болгар» номерларында, башка биналарда аренда хисабына яшәгән клуб 1911 елдан М.М.Апанаева йортында урнаша. Клубта театрлар, концертлар куела, лекцияләр укыла, кичәләр уздырыла. Хәсәниненең энесе, Казан музыка училищесында белем алган Габделбарый кыллы оркестр оештырып җибәрә, китапханә эше җайга салына. Беренче Бөтендөнья сугышы барганда, 1915 елны йорт госпиталь итеп үзгәртелү сәбәпле, клуб эшчәнлеген туктата. Ләкин ул чын мәгънәсендә татар булып, татарның киләчәген кайгыртып яшәргә теләгән бер буын яшьләр өчен милли мәдәниятне пропагандалау һәм үстерү үзәгенә әверелә. Шушы клуб Ә.Хәсәниненең аралашу даирәсе формалашуга йогынты ясаса, бу даирә рус мәдәниятендәге «Весы», «Золотое руно» тибындагы, үз укучысын заман сәнгате белән таныштыруны, шулай гакъльй-мәдәни яктан камилләштерүне максат итеп куйган, XX йөз вакытлы матбугаты мәйданында иң эчтәлекле һәм иң югары сыйфатлы «Аң» журналы тууга сәбәпче була.

Журнал чыгару карарының кабул ителү вакыйгасы Т.Мамлиевның 1912 елның 31 июлендә язылган доносында түбәндәгечә сакланып калган: «Татар әдәбият түгәрәге июльнең 26-сында Евангелистовский урамда Хәсәнев йортында җыелды. Җыелыш тиз көннән калын рус журналлары шикелле бер әдәби, сәяси журнал чыгарырга

[2] Шура.1913. № 6. 189 б.

карар бирде. Бу журнал яшь татар милләтчеләрен берләштерергә тиеш булачак. Журнал Хәсәневлар исеменнән чыгачак. Жыелышта булган кешеләр: Гәрәй, Барый Хәсәневлар, Фуат Туктаров, Габдулла Гыйсмәтуллин, Габдулла Тукаев, Фатих Әмирхан, учитель Гафур Колахмәтов, Исмәгыйль Аитов, Гыйльметдин Шәрәф, Галимҗан Ибраһимов, Габдеррахман Кәрәм»[3].

Ә.Хәсәни журнал оештыру идеясен күп еллар күнелендә йөртә. Исемен Г.Тукай тапкан журнал Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Г.Рәхим, Г.Гобәйдуллин, Г.Коләхмәтов, Һ.Атласи, Ж.Вәлиди, Ш.Камал, Ф.Агиев, С.Сүнчәләй, Ш.Камал, С.Рахманколый кебек иң талантлы иҗатчыларны үз тирәсенә берләштерә. 1912 елның 15 декабреннән 1918 елның мартына кадәр айга ике тапкыр басыла килеп, 123 сан тәшкил иткән «әдәби, фәнни, сәяси вә иҗтимагый рәсемле журнал» татар халкы өчен мөһим идеологик, рухи, мәдәни проблемаларны күтәрә, яналыкларны мәйданга чыгаручы гына булмыйча, бәлки әдәбиятта тәҗрибәләр ясаучы үзәккә әйләнә.

1912—14 елгы номерлар әсәрләрнең идеясе белән бәйле урнаштырылган репродукцияләргә бай. 1914—15 елларда фотоматериаллар журналның бизәгенә, мәгънәви тәэсир көчен арттыру чарасына әверелә. Журнал чыгаручылар әдәбиятны алга җибәрү, үзгәртү, татар укучысының зәвыгын камилләштерү максатында сәнгатьнең башка төрләрен мөмкин кадәр киңрәк файдаланырга тырышалар. Журнал белән чикләнмичә, 1914 елны редакция әдәби әсәрләр тупланган «Әдәби альманах», 1915 елны күренекле рәссамнарның иҗат үрнәкләре җыйналган «Альбом (Сәнаигы нәфисә мәҗмугасе)» эшли һәм «Аң» мөштәриләре-әбунәчеләренә һәдия-бүләк итеп тарата. Әлеге басмаларны булдыруга Г.Ибраһимов күп көч куя, альбомдагы рәсемнәргә аның аңлатмалары урнаштырыла. Шулай итеп, редакция әдәбият-сәнгать үрнәкләрен халыкка җиткерүнең яңадан-яңа юлларын эзли. Боларның башында, әлбәттә, акыллы һәм максатчан Хәсәни тора.

«Аң» — исеменә тугры калып, татар кешесенең аңын, дөньяга карашын үзгәртүгә хезмәт итә. Журналда даими рәвештә, әдәби әсәрләр белән беррәттән, фәнни, сәясәт, икътисад мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр, сәнгать, театр, музыка өлкәсендәге яңалыкларга күзәтүләр, тарих һәм дин, мәгариф һәм тәрбия, матбугат торышы, аерым шәхесләргә кагылышлы язмалар тәкъдим ителә. Ләкин иң мөһиме — яшь авторлар югары мәдәниятне чит телдәге басмалардан эзләгән милләттәшләре өчен дә кызыклы булырлык, Европа фәлсәфәсе тибындагы яңа өйрәтү, яшәеш хакында милли концепция табарга телиләр. «Аң» авторлары татар укучысын дөнья мәдәниятендә барган процесслар белән таныштыруны махсус башкара, проблемага төрле яклап якын килә. Бу эшне журналның редакторы Әхмәтгәрәй Хәсәни әйдәп бара. Ул Г.Ильяс тәхәллүсе белән бастырган, рух гыйлеме — психологиягә караган «Гакыл һәм калеб» исемле язманы алыйк[4]. Анда Ницшенең «Әхлакый идеал» китабындагы «яхшы кеше»не тәнкыйтьләве нигезендә кешенең ирегe («воля» мәгънәсендә), калеб (хис) һәм акыл төшенчәләренең яшәештәге ролен шәрехләү бирелә. «Кешенең ирегeн ике куәт идарә кыла» — дип, шул көчләр буларак акыл һәм хисне күрсәткән мәкаләдә аларның көрәше яшәешне алга җибәрү механизмы кебек аңлатыла.

Журнал шушы юнәлештәге язмаларны даими бастырып килә. Чөнки, М.Хәнәфинең «Хәят вә фәлсәфә» циклында[5] ассызыкланганча, милләт үссен өчен фикер, фәлсәфә үсеше кирәк, ләкин ислам фәлсәфәсе белән генә чикләнмичә, яңа рухи мәсләк эзләү зарур. Бу эзләнү көтелмәгән, башка басмалардагы төп лейтмотивка каршы килерлек фикерләр дә китереп чыгара. Әйтик, М.Хәнәфи «Хатын — кем?» дигән публицистик мәкалә яза[6] һәм «хатыннар һәм кызларга ирләр мөнәсәбәте нинди булырга тиеш?» дигән сорауга фәлсәфә тарихыннан җавап эзли. Һинд, кытай, юнан, рум фәлсәфәләре, Шопенһауэр һәм Ницше, Кант һәм Джон Стюарт Миль карашлары белән таныштыра. Татар әдәбиятын үз идеаллары итеп «колларга — азатлык, ачларга — ашамлык, хатыннарга — иркенлек»не куюда

[3] Мансуров Г. Татар провокаторлары. М., 1927. Б.51.
[4] Ильяс Г. Гакыл һәм калеб // Аң. 1913. № 12. 17-18 б.
[5] Хәнәфи М. Хәят вә фәлсәфә // Аң. 1913. № 11. 359 б.
[6] Хәнәфи М. Хатын – кем? // Аң. 1914. № 4. 80. 81 б.

гаепли. Яки «Жинаять һәм җәза»[7] исемле мәкаләсендә М.Хәнәфи хатын-кыз мәсьәләсенә шулай ук Ф.Ницше фәлсәфәсе аша карый: илаһига, идеалга табыну әлеге идеалны колга әйләндерә дигән фикер уздыра. Шушы позициясе белән Хәнәфи татар әдәбиятында, иҗтимагый фикердә, зыялы даирәләрдә яшәгән – хатын-кыз азатлыгын милли проблема, татар җәмгыятенең гасырлар төпкеленнән алып чыккан чире, наданлык нәтиҗәсе — дигән караш белән килешмәвен белдерә. Анынча, хатын-кызның коллыгы – ирләр акылының җинаяте: хатын-кызны акылына карап түгел, тышкы матурлыгына карап пьедесталга күтәрү һәм табынган сынын үзенә буйсындыру нәтиҗәсе. Автор Ницше артыннан «шәхескә – азатлык» таләбен куя, аны хатын-кызга шәхес дип карап азатлык бирү кебек шәрехли. Әйтерсең, тар милли кысаларда фикер йөрткән милләтпәрвәрләрне бөтендөнья әдәбияты масштабына алып чыгарга тели, шушы журнал битләрендә күпләп дөнья күргән әдәби әсәрләре эчендә дә шушы фәлсәфәне татар дөньясына җиткерү омтылышы ясый.

Тагын бер перспектива Ж.Вәлиди мәкаләсендә[8] билгеләнә. Күренекле тәнкыйтьче һәм галим татарларга рус, Европа мәдәниятенә якынаю кирәклегенә басым ясый, моны «тарихи вә иҗтимагый канун тудырган мәҗбүрият» саный. Хуҗалык итү, фән, техника өлкәләрендә артта калган татарлар Европага ияреергә тиешләр, шул вакытта фәлсәфә, әдәбият үсү өчен шартлар туар иде, дип, сүзне әдәбият белән чикләп куюга каршы төшә.

Журнал фикер төрлелегенә, дискуссиягә өстенлек бирә.Әйтик, Ж. Вәлидигә җавап итеп язылган Н.Думави мәкаләсе дә «Аң»да басыла[9]. Думави татар әдәбиятының үз традицияләренә (шәркый традицияләргә) таянып, үз эзе белән, үз алымнарын файдаланып үсәргә тиешлеген ассызыклый. Бөтендөнья әдәбияты мәйданына чыгар өчен милли тормышны милли тасвират ярдәмендә сурәтләргә, милли темалар күтәреп, милли өслүбтә, рухта язарга кирәк дигән йомгак ясый.

Чын мәгънәсендә фәлсәфә кору бары тик яшәеш һәм аң мәсьәләләренә бер яссылыкта – тарихның, җир тормышының ахыргы максаты күзлегеннән караганда гына мөмкин. Татар дөньясында шушы максат миллилекне, милләт язмышын да исәпкә алып билгеләнә. «Аң» битләрендә милләтнең иртәгесе, киләчәге турында сөйләшү бара, иҗтимагый–мәдәни яңарышның милли үсеш-үзгәреш ихтыяҗына буйсындырылырга тиешлеге ачыклана. Моның теоретик нигезләре күзаллана.

1913 елны Г.Газиз «милләт, миллият» сүзләренең әдәбиятка мөнәсәбәтле кулланыла башлавына игътибар итә[10], 1911 еллардан башлап, рухи бердәмлек кебек аңлануын билгели. «Милләтнең асылы тарихи ганганәләргә[11], хатирәләргә теркәлгән була, ягъни бер милләттән булган кешеләр бер-берсенең якынлыгын хис итәләр, һәркайсының бабасының бабалары вә нәселләре бер дошманга – дошман, бер дуска – дус, бер җирдә торганга яисә бергә күчеп йөргәнгә халык тарихын җырлар кыяфәтендә күңелдә саклыйлар. Шулай итеп, бер милләткә хазир рухи бер тәгъриф бирәбез: милләт – тарихи ганганәләре бер булып, берлек хис иткән адәмнәрнең җыеныдыр».

1913-1914 елларда «Аң» журналы «Милләтне ничек аңлыйсыз?» дигән анкета уздыра, шуның җавапларында Г.Газизнең милләткә билгеләмәсе тагын да төгәлләшә: «Милләт – тарихи ганганәләре бер булып, үз араларында берлек хис кылынган, бер юл тарткан – бергә хәрәкәт иткән һәм бер даирәдәрәк яшәгән яисә тарихта күп вакыт бергә торган, асыл телләре бер булган ифрат адәмнәрнең җәмгыятедер»[12]. Милләтнең киләчәгенә ышану «һәрвакытта сәнгать нәфисә кыяфәтендә заһир итәдер»[13] дию белән, автор иртәгәге юлны эзләү эше әдәбиятка йөкләнгәнне дә ачык әйтә.

Г.Газиз язмалары милләт мәсьәләсенең татар әдәбиятында ничек куелышына зур

[7] Хәнәфи М. Җинаять һәм җәза // Аң. 1915. № 9-10. 194 б.
[8] Вәлиди Җ. Шәрыктан – Гаребкә // Аң. 1916. № 4. 69-71 б.
[9] Думави Н. Шәрыктән Гаребкә мөнәсәбәте илә // Аң. 1916. № 9. 158-159 б.
[10] Газиз Г. Милләтне ничек тәгъриф кылырга? // Аң. 1913. № 8.137-138 б.
[11] Ганганә – традиция.
[12] Газиз Г. Милләтне ничек аңлыйсыз? Мөкаддәмә // Аң. 1913. № 22. 396 б.
[13] Газиз Г. Киләчәк көннәр // Аң. 1914. № 2. 37 б.

тәэсир ясый. Аннан соң анкетага җавап бирүчеләр, нигездә, шушы ук позицияне яклый. Мәсәлән, Җан Шәрәф[14] (Галимҗан Шәрәф) тә «дәүләтләрнең күтәрелү вә төшүләре күп вакытта миллият хисенең күтәрелү вә төшүеннән килгән» дип билгеләп һәм, милләтне «тел якынлыгы», «нәсел якынлыгы», «тарихи кардәшлек» барлыкка китерә дигәндә, Г. Газиз кебек үк, милли рух, «милли вөҗдан» – үзенне милләтнең бер кисәге итеп хис итү, милләтнең гомуми күтәрелү вә төшүен үз шәхси күтәрелү вә төшүеннән артыграк итеп» хис итүдән гыйбарәт, дип өсти. Шулай итеп, милли хис, миллилек мәгънәсендә «миллият» сүзе урнаша. Матбугат битләрендә «миллиятле милләт дөньядан югалмый»[15] дигән караш ныгый.

Журнал битләрендә әдәбиятның нинди булырга тиешлегенә караган бәхәсләр бара, Г.Ибраһимовның, Х.Кәримнең, Г.Рәхимнең, Н.Хәлфинның һ.б. әдәбиятчыларның теоретик характердагы язмалары дөнья күрә. Аларда әдәбиятның сәнгатьлелеген күтәрергә чакыру, иҗат эшенең «максаты түгел тормыш көзгесе, бәлки йөрәк, күңел көзгесе булудыр»[16] дигән фикер әйдәп бара.

«Аң»ны булдыручы иҗади төркемнең татар әдәбиятын алга җибәрү теләге нинди әсәрләргә өстенлек бирүдә бик ачык күренә. Яңа тип әдәбият тормышта гармониягә, бәхеткә ирешү мөмкинлекләрен, яшәүнең мәгънәсен эзләүдән башлана. Бер үк вакытта каләм тибрәтүчеләр гармонияне кешенең күңел төпкелләрендә, аң һәм фикерләү, хис-кичереш, теләк-омтылыш, хыял-күзаллау катламнарында, рухи өлкәдә табарга омтылалар.

Әлбәттә, әдәбиятта үзгәрешләр пәйда булу, үзенчәлекле әсәрләр язылу өчен сәләтле, эзерлекле язучылар булу шарт. Тәҗрибәләрне әйдәп баручы, «Аң» журналының һәр санында берничәшәр әсәр белән катнашучы Фатих Әмирхан, Шәриф Камал нәкъ менә шундый сыйфатларга ия булалар. Дөнья әдәбиятындагы идея–эстетик эзләнүләр кимәлендә әсәрләр язып, әдипләр аларның милли, бер язучыны да кабатламый торган, яңгыраш һәм моң җәһәтеннән укучыга үз һәм якын булуына ирешә. Фәнни-фәлсәфи җәһәттән көчле, үткен фикерле, киң карашлы, дөнья әдәбиятын бик яхшы белүче, укымышлы М.Хәнәфи татар укучысы өчен күтелмәгән тирәнлекләргә үтеп керә, «укучы кабул итмәс» дигән киртәләр алдында туктап калмый, әдәбиятыбызны лирик-фәлсәфи эчтәлекле, хисси–эмоциональ, чын мәгънәсендә җәүһәрләр белән баета. Филологик эзерлекле, укымышлы, әдәбият тарихы һәм тәнкыйте өлкәләрендә дә актив эшләп килүче, әдәби күренешләргә бик сизгер, тоемлы, зәвыклы Газиз Гобәйдуллин һәм Гали Рәхим әсәрләре эшкәртелү дәрәҗәсе, тәгаллләнгәнлеге белән аерылып тора. Алар артыннан журнал битләренә Фәйзи (Вәлиев), Ә.Таңгатаров, К.Тинчурин, Н.Гасрый һәм башкалар аяк баса. Гасыр башы әдәбиятында янарыш олы бер хәрәкәткә әверелә.

Журнал татар мәдәниятендә фәлсәфи әдәбият тудыручы үзәк булып танылa. Татар фәлсәфи әдәбиятында җир тормышының чикләнгәнлегенә, яшәешне таныp белә алмауга нисбәтле метафизик сагыш, кеше гомеренең мәгънәсенә, хакыйкатькә төшенә алмау кайгысы, рухи камилләшүгә омтылыш һәм тормышны үзгәртә алуга ышаныч, яшәешнең чиксезлеге алдында баш ию алга чыга. Кешедәге илаһи башлангычны тергезү, кешене камилләштерү аша дөньяны яктырту омтылышы яңа әдәбиятта яңа идеяләр тудыра. Ләкин яңа заман әдәбияты үткәндә калган мәдәни байлыкларга, дини-суфичыл өйрәтүләргә дә битараф түгел. Аларга мөрәҗәгать итү – милли тамырларны барлау, дөньяга шәркый караш үзенчәлеген саклау кебек аңлашыла. Болар бөтенесе XX гасыр башында иҗат ителгән фәлсәфи әсәрләргә тәэсир ясый, аларны серле һәм күпмәгънәле, күпкатламлы текстларга әвереләдерә.

XX йөз башы әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр язылу, психологик тенденцияләрнең көчәюе белән янәшә, татар дөньясындагы үзгәрешләргә сәбәп була. Әгәр мәгърифәтчелек әдәбиятында кешене татар җәмгыятенең бер вәкиле итеп рәсләү әйдәп барса, «кешене камилләштерү – җәмгыятьне алга җибәрү» схемасы тәкъдим ителсә, фәлсәфи әдәбияттагы «кешене камилләштерү – кешелек дөньясын

[14] Шәрәф Җан. Ничек аңларга? // Аң. 1914. № 2. 40 б.
[15] Кадыйри З. Миллият агымнары // Тормыш.1914. 12 февр.
[16] Мөхетдинния Ә. Кем ул мөгаллимә Фатыйма? // Аң. 1914. № 23. 417 б.

камилләштерү» формуласы һәркемнең кешелек язмышы өчен дә җаваплы булуын искәртә. Озак вакытлар изелү, рухи торгынлык халәтендә, «икенче сорт» милләт булып яшәгән татарларга фәлсәфи әдәбият аларнын гомумкешелек тарихында аерылгысыз элемент, мөһим бергәлек булуын аңлата. Милли әдәбиятта еш кабатланган, нәкъ менә татар фәлсәфи фикере өчен генә хас, «бер милләтнең үзенә йөкләнгән бурычларны үтәп чыга алмавы кешелеккә кайгы китерә» кебегрәк гомумиләшүче фикер — шуна дәлил. «Гомумкешелек — милләт — шәхес» чылбырынын әдәбиятка, мәдәнияткә үтеп керүе татар кешесенен үз—үзенә ышаныч көчен, милли үзанны үстерүгә хезмәт итә.

Бу яктан, Әхмәтгәрәй Хәсәнинен үз тәрҗемәләре дә күп нәрсә сөйли. Ул А.П.Чехов, А.Амфитеатров, А.Аппенянский, А.Франс һәм Ф.Ницше һ.б. рус, чит ил авторлары әсәрләрен тәрҗемә итә. Моннан тыш, Г.Ильяс псевдонимы белән балалар өчен халык әкиятләре мотивлары буенча «Батыр тегүче» һәм «Үги ана» исемле хикәяләр бастыра.

Әхмәтгәрәй Хәсәни тәрҗемә иткән әсәрләр ике төркемгә туплана ала. Аларнын беренчесе — фәлсәфи юнәлеш. Әйтик, А.П.Чеховтан, Б.Тогановтан тәрҗемә ителгән хикәяләрдә сайлау иреге, рухи азатлык мәсьәләсе үзәктә тора. Ул байлыктан да, үлемнән дә өстен куела. Күрәсең, зыялы Хәсәни бу хакта сөйләшүне татар укучысы өчен иң актуаль мәсьәләләрдән дип саный. Болар арасында модернистик юнәлештәге язмалар аерым урын тота. Мәсәлән, «Нинди кинлек» хикәясе көчле кеше концепциясен әдәби шәрехләүдән гыйбарәт булып, журнал битләрендә шушы мәсьәләгә кагылышлы күп хикәяләр дә, стиль ягыннан — каршылыклы хисләр агышын күрсәтү аша фәлсәфә коруга нигезләнгән нәсерләр дә туура китерә.

Икенче төркем — психологизм көчле билгеләнә торган әсәрләр. Әйтик, үзе дә психоаналитик буларак мәгълүм А.Аппенянский, Катулл Мендос хикәяләрендә кеше холкы-характеры аша тормышны сурәтләү өстенлек ала. Психологизм башлангычы нәкъ менә XX гасыр башы татар әдәбиятында нык үсеп китә. Хәсәни тәрҗемә иткән хикәяләрдәге мотивларнын татар язучылары әсәрләренә үтеп керүе татар әдәбияты өчен яна күренешләрнең милли әдәбиятыбызга махсус тәкъдим ителүе, «чит туфракка утыртылуы» — яна күренешләр тудыруы хакында, Хәсәнинең әдәби барышка аңлы рәвештә йогынты савы турында дәлилләп тора.

Әхмәтгәрәй Хәсәни үз чоры укучысына язучы буларак та мәгълүм. 1907 елны «Гасыр»дагы драма әсәрләре сериясе Хәсәнинен «Денщик Гали» һәм «Хат болгатты» комедияләре белән ачыла. Сюжеты шәһәрдә яшәүче яшь татарлар тормышыннан алып язылган, нигездә аңлашылмаучылыкка корылган бу көлке әсәрләр үз чорында тәнкыйтькә дучар була. Ләкин алар озак еллар татар театр труппаларынын репертуарыннан төшми. Чөнки юк кына каршылыкнын барлыкка килүе, үсүе һәм чишелүе фонында драматург гаять тә үзенчәлекле, тулы характер булып житешкән татар типлары бирә. Бу яктан, әсәрләр Г.Камалнын бер ел сонрак дөнья күргән «Беренче театр» комедиясен хәтерләтә. Әйтик, «Хат болгатты» комедиясендә Сара исемле яшь хатын ире Зәки Фирүзовка килгән хатны укый һәм анда язылганнарны дөрес анламау нәтиҗәсендә ирен хыянәттә гаепли. Кияүгә карата болай да тискәре фикердә булган әти-әнисен чакыртып, хәлне кискенләштерә. Хат Зәки ярдәме белән ислам динен кабул иткән чирмеш егетеннән булып чыга — каршылык чишелә. Иркә кыз Сара, энәдән дөя ясаучы, башкаларны гел үз кубызына биетергә торучы әнисе Камилә, әтисе, салырга яратучы, теләмәсә дә шул кубызга әйләнергә мәҗбүр элеккеге капитан Муса, — һәрберсе үз холкы, үз сөйләү рәвеше, үз фикерләү дәрәҗәсе белән укучы күз алдына бөтенлекле бастырыла. Сюжет каршылыгыннан бигрәк, әсәр характерлар каршылыгын көлке тудыру өчен файдалана.

«Денщик Гали» комедиясендәге Гали — «Беренче театр»дагы Бибинен ише. Ул офицернын булдыксыз хатыны Әминә өчен лакей, горничный, кухарка вазифаларын башкара. Хужаларынын әйткән бер әмерен киресенчә үтәве аркасында, әле генә гаилә корган Дамадовлар шактый күнелсез хәлләргә эләгәләр, полктагы дәрәҗәле кешеләр алдында хурлыкка калалар. Г.Камалдагы кебек үк, нәкъ менә шушы

персонаж яшь офицер һәм аның хатынындагы тирәнгә яшерелгән икейөзлелек, дорфалык кебек әхлакый кимчелекләрне ачып салырга, тәнкыйтьләргә, көлү объекты ясарга мөмкинлек бирә.

Никитин типографиясен сатып алып, журнал чыгару өчен 1917 елның октябрь аенда Хәсәни «Ан» дигән типография оештыра. Казандагы иң яхшы басмаханә буларак, 1918 елдан ул яна хөкүмәткә вакытлыча хезмәткә (арендага) алына. 1919 елны хуҗалары Ә.Хәсәни һәм Г.Рәхмәтуллин аны рәсми рәвештә үз теләкләре белән дәүләткә тапшыралар. Китап—журнал бастыру өлкәсендә иң әзерлекле белгечләрдән булган Әхмәтгәрәй эшсез кала. Гаилә архивында сакланган күпсанлы документлар бу чорда гаиләнең матди хәле катлаулы булганны сөйли. Дуслары Хәсәнине шәхси басмаханә оештырырга үгетлиләр. Заманча — «Яңа китап» дип исемләнгән бу басмаханә 1926 елны эшли башлый. Оештыручылары арасында — «Ан»да тәрбияләнгән сәләтле шәхесләр: Ф.Борнаш, К.Нәҗми, М.Гали, К.Тинчурин, С.Җәлал, З.Нуркин, Ш.Байчура, М.Бөдәйли, Ф.Әмирхан, Б.Бикколов һ.б. 1929 елны эшчәнлеге тукталган бу оешма Ә.Хәсәнине 1931 елны кулга алуга, аның гаиләсенә килгән җәфаларга формаль сәбәп була. 1932 елның маенда 3 елга хөкем ителеп, Беломор каналын төзергә җибәрелгән Әхмәтгәрәй, срогын тутырып кайтканда, 1933 елны тиф авыруыннан үлә. Ана бу вакытта бары 50 яшь. Гаиләсе, хәтта, каберенең кайда икәнлеген дә ачыклый алмый.

«Җепшеклек» башлангач Зәйнәп ханым, кабат тикшертеп, РСФСР Югары Судының 1959 елның 29 сентябре карары нигезендә Хәсәнинең акланган исемен тарихка кайтара. Бу көчле, ярдәмчел татар хатыны 1917 елдан соң бик авыр хәлдә калган гаиләсенә, балаларына да, тормыш давылларына эләккән бик күпләр өчен дә таяныч булып яши. Хәсәниләрнең дүрт баласы — Әхмәтгали, Әминә, Рәфкать һәм Чыңгыз — төпле белем һәм һөнәр ала. Аларның югары белем хакында дипломнарындагы гел 5—ле билгеләре, рәхмәт хатлары шул хакта сөйли. Ләкин язмышлары бәхетсез тәгәлләнә: Хәсәнинең турыдан-туры варислары калмый.

Чит илдән хатыны Зәйнәпкә 1913 елны язылган хатларының берсендә мондый юллар бар: «Мин Ватанга якынлашкан саен шатланам. Чөнки анда син бар; анда Гали вә Әминәм; анда «Гасыр»ым вә кәримем бар; анда ата-анам һәм бирадәрем бар! Анда кардәшләрем вә якыннарым бар. Аурупаның бөтен гаҗәсәбәте, бөтен мәдәнияте вә дәүләте мине хәзер әүвәлге кеби кызыктырмый, минем исемне китерми. Мин Ватаным белән анларны алыштырмыйм. Минем Ватанымда ни теләсәм — шул бар. Миңа син кирәк, синең мәхәббәтле сүзен, ягымлы карашың, гүзәл йөзен, алты ел миңа күрсәткән мөлаемең вә илтифатың кирәк. Анлар бунда юк! Миңа киләчәктә ватан углы улачак Гали илә мәхәббәтем Әминә кирәк; миңа гомеремнең сәгадәте булган «Гасыр»ым кирәк. Бөтен Аурупа, бөен дөнья вә анларның байлыклары миңа бу сораганларымны бирә алмый. Шуңа күрә мин Ватанымга кайтып анларга наил булырга бурычлы! Кайтам! Бөтен Аурупаның дәүләт вә сәгадәтен ташлыйм да Ватаными кайтам»[17].

Ватан өчен, милләтне алга җибәрү өчен яшәгән күп шәхесләрнең берсе булган Әхмәтгәрәй Хәсәнинең эш-гамәлләре дә, омтылышлары да хөрмәткә, киләсе буыннар хәтерендә яшәргә лаек.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА**

[17] Әхмәтгәрәй Хәсәни: Фәнни-популяр җыентык. Казан: Җыен, 2011. Б. 292.



*Гомәр Бәширов һәм Мирсәй Әмир «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан») газетасы редакциясендә. Басып торалар (сулдан уңга) Әхәт Гаффар, Әмин Раков, Рәшит Гарипов, Касыйм Тәһау, Рафак Тимергалин. Үткән гасырның 80нче еллары.*




*Композитор Рәшит Кәлимуллин шагыйрәләр белән бергә. Сулда – Фәйрүзә Мөслимова, уңда – Фирая Зыятдинова. 1992 ел.*



*Артист Әзһәр Шакиров һәм галим Миркасыйм Госманов. 2009 ел. Аккош күле буенда.*



*Композитор Ренат Еникеев. Үткән гасырның 80нче еллары.*



*Сынчы Кадим Җәмитов. 1999 ел.*

*Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Шәүкәт Галиев (1928 – 2011) сугыштан соң әдәбиятка килгән буын вәкиле. Танылган балалар шагыйре булу белән беррәттән, аның иҗатында юмор-сатира, лирика да зур урын алып тора. Ш.Галиевнең төрле телләрдә дистәләгән китаплары, 5 томлык сайланма әсәрләре дөнья күргән. Иҗатына шигъри тапкырлык, халыкчанлык хас. Татар әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен Республиканың күп төрле дәрәҗәле исемнәренә лаек булды.*

# Шәүкәт Галиев

## Ышанычым арта

**Күңелемдә яңа шигырь кайта,**
**Туган якта булу бәйрәм лә –**
**Уңышларын күреп шатланудан**
**Моңсулык шат җырга әйләнә.**

**Борчуларга борчу өсти барсаң,**
**Күңел сүреләсен көт тә тор.**
**Ә син, киресенчә, шатлыгыңа**
**Яңаларын гына өсти тор.**

**Ирешкәнгә шөкерана кылыйк,**
**Күтәрелсен әле күңелләр.**
**Ир-атлар да, асыл затлары да**
**Илдә танылмаслык түгел лә.**

**Ышанычың арта, рухың ныгый,**
**Сөенечләр белән сафлансаң.**
**Мактану да гаеп түгел бит ул,**
**Туган ягың белән мактансаң!**

***

**Зәңгәр күкләр офык тулы,**
**Ак болытлар туктап калган.**
**Иркенлекне иңләп гизгән**
**Җилләр, ахры, арган-талган...**

**Җанга якын тын манзара...**
**Үткәннәрме?**
**Бүгенме бу?**
**Бездән соң да җәйрәп ятыр**
**Килер дәвер түгелме бу?**

Офыкларның чиген узып
Уйнар иген дулкыннары.
Минем күзләр белән сыйпар
Кемнәр килеп шул кырларны...

***

Ул җәйләрдә бигрәк кайнар иде,
Ә аланнар шундый җиләкле!
Гел эсседән генә сусадыкмы,
Иреннәрне нәрсә көйрәтте?

Ул көннәрне эзләп бардым да бит,
Моңсу каршылады буш алан;
Җәйләр инде, җәйләр сүрелгәннәр,
Элеккечә янып сусамам...

***

Диңгез буйлап өскә күтәрелдек,
Зәңгәрләнеп калды дулкыннар –
Әнә таулар, биек түбәләре,
Ергаланып яткан упкыннар...

Лачыннар да җитмәс биеклек бу,
Ак болытлар кала җилфердәп;
Күзәтергә кызык манзаралар...
Ә канатка... тигез җир кирәк!

***

Иске гәзит килеп эләгә дә,
Кызыксынып карап үтәсең –
Ни булыр, дип фараз кылуларның
Беләсең бит ничек бетәсен...

Иртәгесе көндә ниләр булыр,
Нинди шатлык анда, ни гамь бар –
Бусын әле белеп тора бары
Тик Киләчәк дигән пәйгамбәр.

## Серле китап

Сүзлек – сүзләр урманы,
Урманы – чытырманы,
Китапның гомер буе
Һаман укый торганы!

## Моңлы ятим

Бу ятимнәр дәүләтендә
Син дә ятим бала шул.
Әнкәм белән сөйләшәм, дип,
Кулга гармун алгансың.

Уйныйм дисәң, тынып кала,
Бу гармунга ни булган –
Күз яшьләрен эчкә йотып,
Кушылып җылый ул да...

Ятим бала моңлы була,
Моңлы гармун да ятим –
Кемнәр генә юатыр да,
Сабырлыкка өйрәтер?

Гармун теле сүзсез көйли,
Сөйли туган телендә.
Гомер буе сайрасын ул
Күңелеңнең түрендә.

Тормыш давыллары яман –
Төрлечә каерырлар...
Татар егете булып кал,
Моңыңнан аерылма!

***

Уңышлардан күз чагылса,
Ки күзлекнең карасын.
Әмма туган төбәгеңә
Якты күздән кара син.

## Яши татар

Урам – урланган,
Тыкрыгы тап-тар,
Үткән-сүткәннәр
Сүгәр дә таптар.

Бирешмәс татар,
Базарны мактар –
Эредән кубып,
Вак-төяк сатар.

Баш сау булсын, дип,
Үзен юатыр.
Күзләрен йомса,
Телен югалтыр.
Кыйбласы аның
Нәкъ дүрт тарафтыр,
Чит кавемнәргә
Нәсел таратыр.

Сөйләп торам бит-
Үзем дә татар.
Без дә кимсетсәк,
Аны кем мактар?
Тарихын саклар –
Яшәсен татар!

## Телсез ил булмас

Киләчәккә карап җилдерик, әй,
Таныш моңнар чыңлый дугада.
Туган телем безгә кодрәт бирә,
Анам теле хәер-догада!

***

Кабаланып, ашыгып яшим һаман,
Тынам дим дә, тагын ашыгам –
Түнтәрергә, юкса, дулкын булып,
Тау-тау бурычым килә каршыма.

Сабыр-салмак булып бу тормышны
Күзләргә дә карыйм тырышып.
Ашыктыра бугай, алда көткән
Хәрәкәтсез мәңге тынычлык...

### Уку зарурияте

Бер яшь язучы Томас Маннга кулъязмаларын алып килгән һәм укып чыгып, үз фикерен әйтүен үтенгән.

— Сезгә мөмкин кадәр күбрәк укырга кирәк! — дигән мәшһүр әдип, теге каләм тибрәтүченең язмалары белән танышкач.

— Ә бу... мәҗбүриме соң? — дип гаҗәпләнеп сорау биргән егет.

— Әлбәттә! Күбрәк укыган саен, язарга вакытыгыз азрак калыр иде ичмасам...

### Өтер

Шулай бертапкыр Һенрих Һейнедан төшкә кадәр ни белән мәшгуль булуын сораганнар.

— Узган атнада язган шигыремне кабат укып чыктым, бер урында өтер куйдым, — дигән шагыйрь.

— Ә төштән соң?!

— Бу шигыремне янә укып чыктым, теге өтерне алып ташладым, чөнки ул артык булган икән.

### Философ кисәтүе

Борынгы грек философы Диоген мичкәсендәге тишектән тирә-юньне күзәтеп утыра икән. Үтеп-сүтеп йөргән бәндәләргә таш атып калучы бер «җилдән туган» малайны күреп алган да бу, битәрли дә башлаган:

— Ташла ташыңны! Әй, кемгә әйтәм, ишетәсеңме?! Ялгыш кына атаңның башына тидерерсең... — ди икән.

### Әкият һәм... югары математика

Мәгълүм ки, «Алисә Могҗизалар Илендә» исемле атаклы әкиятне Льюис Кэррол иҗат иткән.

Англия королевасы Виктория дә бу әкиятне бик яратып укып чыккан, соклануын белдергән һәм авторның бөтен әсәрләрен дә сатып алырга боерган.

Ә инде... Кэрролның югары математикага багышланган хезмәтләрен-китапларын күргәч, шаккатып гаҗәпкә калган королеваның бик нык кәефе кырылган ди.

### Сүз җитмәсә

Мәшһүр поляк әдибе, афоризмнар остасы Станислав Ежи Лецтан, нигә сез шулай бик кыска язасыз, дип сораганнар.

— Сүзләр җитми миңа, сүзләр... — дигән әдип елмаеп.

## Шатлык кичерү

Алман әдибе Георг Лихтенбергтан бер әсәр хакында фикер әйтүен үтенгәннәр. Әдип исә ике җөмләдән генә торган рецензия язып биргән: «Ошбу китапны ябып куйгач та биниһая зур шатлык кичердем. Әмма укыганда мондый канәгатьләнүне тоймаган идем».

## Күрмәгәнен күргән

Инглиз шагыйре Джон Мильтон сукыр булган. Гомере дәвамында ул хатыныннан байтак кына кыен ашаган, кимсетелеп яшәгән, кыскасы, күрмәгәнен күргән. Шулай бер заманны дусты аның хатынын шагыйрьнең аяк астына ташланган роза чәчәге белән чагыштырган.

— Әйе. Нәкъ үзе! – дип тыныч кына җавап биргән аңа Мильтон, — син хаклы икәнне мин аның күп санлы чәнечкеләрен тоеп та беләм...

## Симфония язу сере

Бер егет Моцарттан ничек симфония язарга кирәклеген сораган.

— Сез бит әле бик яшь. Нигә балладалардан башламыйсыз? – дигән аңа композитор.

Егетнең дә үз туксаны туксан икән:

— Ә менә сез, — дигән ул — әле ун яшегез тулганчы ук симфонияләр яза башлагансыз ич?!

— Әйе, — дип җавап биргән Вольфганг Амадей Моцарт, — әмма дә ләкин мин ничек симфония язарга кирәклеген беркемнән дә сорамадым шул!

## Оптимист

Итальян композиторы Джакомо Пуччини бервакытта да күңел төшенкелегенә бирелмәгән, оптимист булган. Иң ачы вә хәтәр тормыш зилзиләләрендә дә аны юмор хисе ташламаган. Шулай бер тапкыр ул, ботын сындырып, хастаханәгә эләккән. Бу хакта ишеткәч тә, дуслары моның хәлен белергә килгәннәр. Сәлам алышканнан соң, Пуччини күңелле генә итеп көлеп куйган да, болай дигән:

— Дусларым, мин шулкадәрле дә бәхетле ки! Ниһаять, миңа да һәйкәл куярга булдылар! – дип, тулаем гипска катырылган аягына ымлаган.

## Рәссам җавабы

Бик тә бай бер бәндә инглиз рәссамы Уильям Тернердан йөз фунт акча бәрабәренә картина сатып алган. Озакламый ул рәссамнын бу картинаны бары тик ике сәгать эчендә язып чыгуын ачыклаган. Байбәтчәнең бик нык ачуы килгән һәм ул рәссамны ялганлаганы өчен судка биргән.

Судья исә рәссамнан болай дип сораган:

— Бу картинаны сез күпме вакыт эчендә яздыгыз?

— Гомерем буе һәм... һәм янә ике сәгать! – дип җавап биргән рәссам.

**Морад ДУСАЙ** *туплады.*

Чулпан Гобәйдуллина

ХИКӘЯ

# ХИС ДУЛКЫНЫ ЯРГА БӘРЕЛӘ

Үләм, мондый кышны инде бернichә ел күргәнем юк иде. Урамда кышның бик зәһәр салкыннары, ничаклы калын итеп киенеп чыгуына карамастан, тәнеңдәге бөтен күзәнәкләр дә әлеге салкыннан «уяналар».

Тукталышта кешеләр башка вакыттагы кебек күп түгел. Әлбәттә, мондый салкында эт тә баласын оясыннан чыгармас. Барысы өч кеше басып торабыз, барыбыз да аз хәрәкәтле юлга карап, үз маршрутыбызны көтәбез. Чыгып басканыма 15 минутлап вакыт узгандыр, ә автобус килми дә килми, үч иткәндәй, аның җиле дә ачы бит әле.

Мондый вакытларда бер укытучыбыз: «Үзегезне пляжда, диңгез янында кебек хис итегез, янығызда агачлар, кошлар сайрый дип күз алдына китерегез. Шуннан соң сезне борчыган әйберләрне онытып торырсыз», — дип әйтергә ярата. Бу алымны да кулланып карадым, тик кая ул, һаман шул салкын җил ыжгырып тора.

Юк, болай түзеп булмый. Валлаһи, ватылгандыр бу автобус. Тукталыштан читкәрәк барып басып кул күтәрергә кирәк. Тик караңгы бит, куркыта. Алла диген, әллә нинди кеше булса шоферы. Яшисе килә, гомеремнең 20 елын гына уздым бит әле. Юк-юк, инде һич түзә алмыйм, яхшы кеше эләгер әле... Күңелемнең бер чите: «көт автобусыңны, хәзер килер», — дип көзге яфрак кебек кыштырдап көтәргә кушса да, аяклар, куркыбрак булса да, тукталыштан читкә атлый, кул да акрынлап күтәрелә, әмма машиналар туктарга уйламый. Кулымны әллә азрак төшереп торыйм микән дип тә уйладым. Их, кошелекта җитәрлек акча булса, такси гына чакыртыр идем дә, юк шул, зарплатаны тоткарлыйлар. Менә кулымны төшерәм-төшерәм дип торганда гына берсе килеп туктады тагын.

— Куда едешь? — дип эндәште руль артындагы егет.

— На Проспект Победы.

— Садитесь, по пути, и тем более мороз на улице.

Ничә сум алачагын да сорамадым, җитәр әле дип кереп утырдым инде. Утыруга эчтән генә белгәннәремне укый башладым. Җиңү Проспектына кадәр бер сәгатьләп кайтасы бар бит әле. Бераз ияләшкәч, салон эчен караштыргалый башладым. Иң әүвәл күземә ташланганы эленеп торган тәсбих булды. Моны күргәч, эчемә җылы керде. Күзем, тизлекне күчергәндә, кулына төште: балдагы юк — өйләнмәгән. Машинасы да чип-чиста тагын. Шулай караштыргалап барганда:

— Что делаешь на улице на таком холоде? — дигән тавыш сискәндереп җибәрде. Тавышы да матур үзенең. Татарча җавап бирергәме моңа, әллә русчамы? Әлбәттә, татарча — мин бит татар кызы, ул да татар.

— Эштә торкарландым, шуңа да соңарак калына, — дидем инде. Тик тавышым әллә ничек калтыранып чыкты бугай. Шулай да җавап биргәндә мин аның йөзен яхшылабрак күрдем. Болай ничава гына егет икән үзе. Алай ук чибәр булмаса да, сөйкемле сөяге бар... Шулай сүз иярә сүз чыгып, сөйләшеп киттек. Әлеге сөйкемле егетнең исеме Рамил икән. Ниндидер бер клубның директоры икән. Гәпләшә торгач, кайтып җиткәнемне сизми дә калдым. Кирәкми дисәм дә, подъездга кадәр китереп куйды. Машинадан чыгып китәр алдыннан үземә бик тә кызыклы тоелган бер соравымны бирми кала алмадым:

— Сез менә, Рамил, үзегез клуб директоры, ә шулай да безнең машинада йөрисез, әллә иномарка алырлык акча керми мәллә эшегездә? — дигән идем, ул рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Чукынчык, көлүе дә бик матур, тешләре дә тип-тигез, ап-ак, көлгәндә хәтта бит очларында чоңгыллар да барлыкка килә икән.

— Юк, нигә алай дисез? Акча ярыйсы керә, тик эштә әле монда, әле тегендә чабарга кирәк, ә шәһәр урамнары ямаулы да тишекле. Дәүләт ичмасам үзенең юлларында йөрерлек машина җитештерә, — дип, сүзен тәмамлады да, сузган акчамны кире этәрде:

— Сезне акча алыр өчен алып кайтмадым мин, кыз кеше салкында туңып тормасын, дип утырттым һәм сездән тагын бер әйбер сорарга булдым. – Моны ишеткәч, өстемә чиләге белән салкын су сиптеләрмени. Йә Аллам, җүнсез егет булып чыкты бит бу! Рамил шунда:

— Телефон номерыгызны калдырыгыз әле, мөмкин булса, — диде. Җиңел сулап куйдым. Кичке ун булуга да карамастан, без тагын ярты сәгатьләп сөйләшеп утырдык та, мин рәхмәтемне әйтеп һәм телефон номерымны калдырып чыгып киттем.

Рамил икенче көнне үк шылтыратты, шулай итеп, атнаның өч көненең икешәр сәгате аның белән сөйләшеп үтте. Тавыкмы, йомыркамы дан башлап, кешенең бакый дөньясына кадәр барып җиттек. Биш минут кына сөйләшә алам дип утырасың да телефонны утыз, кырык минуттан гына куясың, нәкъ контакт сайтына кергән кебек. Кичен йокы килми, иртән йокы туймый башлады. Ул минем өчен күтәрелә башлаган тавыма әверелде: менгән саен менәсе килде, тау башына менеп, аның күңеленә күз ташлыйсым, җанының матурлыгына шик-шөбһәсез ышанасым килү теләге сәгатьләп түгел, минутлап, юк, минутлап та түгел, секундлап арта торды. Аның тавышын ишеткән саен әйтерсең лә күкрәк читлегемнең бер почмагыннан нидер алга таба талпынып очып чыгып китәрдәй булып канатлана, ирекккә чыгып шул биек тауны әйләнә-әйләнә өскә атыласы килә... Килә!..

Җомга көн авылга алып кайтасы кирәк-яракларымны сумкага җыйганда телефоным шылтырады. Күңелем талпынып куйды, уйчан йөземә — елмаю, күземә кояшның соңгы нуры чыккандай булды, йөгереп барып тәрәз төбемдә торган телефонны алдым.

— Шимбә көнегезгә планнар ничек корылган? — диде Рамил. – Минем өчен генә вакыт табылырмы? Йә киногa, йә театрга барырбыз дигән идем.

Их, күрәсем килә бит үзен, театрда да бер еллап булганым юк, тик өйгә кайтырга кирәк шул, якшәмбе — аш, әзерләнәсе бар. Мин акыл һәм йөрәк сугышының уртасында калдым. Янәдән шул кайнарлы-суыклы сугышта. Кайнар йөрәк, аның янына бар, аның белән шимбәнең берничә сәгатен үткәр, дип үз көенә, бары тик минем тормыш көенә тибә. Акыл салкын, үзенекен итә: өйгә кайт, туганнарың янына, әбиеңнең ашына кайт. Әгәр сиңа дигән кеше икән, ул югалмас, әгәр кадерле икәнсең, көтәр, дип тукыды. Нәтиҗәдә, авылга кайтып китәсемне әйттем.

Бүген әбиемнең безнең арада булмаганына кырык көн үтте. Әбием рухына багышланган аш тәмамлангач, табын янына кайткан кунакларны, ир-атларны дәштек. Мин алар янына, түр якка чыкмадым, аш бүлмәсендә аш бүлеп, чәйләр ясап, аларны апага биреп барам, ә үземнең уйларым шул сөйкемле егет турында. Бүген хәерле иртә дип тә язмады, хәлләремне дә белешмәде. Шылтыраткан идем дә,

телефоны тотмый, югалды. Әллә гомерлеккә югалдымы инде? Күңел сорауларына җавап бирә алмый интегеп йөргәндә әнинең түр ягыннан: «Чәй алып чык әле, кызым», — дигән тавышына сискәнеп киттем. Яулыгымны яхшылап бәйләдем дә, чәй ясап түр якка чыктым, Лена апаның миңа арты белән утырган улына чәй сузып: «Алыгызчы», — дип эндәшкән идем, шулчак телефоным шылтырый башлады. Миндә, җиде баллык ук булмаса да, тән тетрәнүе башланды. Ул, ул шылтырата! Каушап китүем нәтиҗәсендә кулымдагы чәй чынаягы чайпалып, Лена апа улының тезенә түгелде. Сизәм, кистереп карый бу миңа туган тиешле абый. Нык пешердем, ахры, нишләргә дә белмичә башымны күтәрдем. Миңа кулын сузып ярты чынаяк чәйне алырга торган егет... ул... ул иде!

***

Бүген инде салкын түгел, киресенчә җылы һава. Бияләй хәтле кар ява, минем мәрхүм әбием әйтмешли: «Әхмәт бияләе хәтле кар ява». Кичке багана уты астында ул тагын да матуррак булып күренә, ялтырап күзне чагылдыра... Без акрын гына парктагы ак элпәне бозып, сөйләшеп барабыз, вакыты-вакыты белән көлеп тә алабыз. Көлми мөмкин дә түгел, туганнар булып чыктык бит, егерме ел күрешмәгән туганнар, гәрчә бер-беребез турында ишетеп белсәк тә. Әле ярый узган атнада аш булган, әле ярый салкын акылны тыңлаганмын. Алайса, гел йөрәгеңне тыңла, ул сине беркайчан да алдамас, диләр, юк, йөрәкне тыңлап кына яшәп булмый икән, акылга да колак салырга кирәк. Акрынлап аңа карата барлыкка килгән очкын, мәхәббәт очкыны, юешләнеп, манчылып җиргә төште. Менәсе тау башымның юллары үзгәрде, туганлык сукмагына кереп кителде. Кардан түшәлә башлаган ак пәрдәне ертып барабыз, юк, аны гына түгел, ә икебезнең дә йөрәгендә түшәлә башлаган ак пәрдәне икегә аерабыз. Киләчәктәге бер тормышны икегә аерабыз: Абыйга һәм Сеңелгә.

---



## Фәнзил Галиев

***

Шундый якты яна күктә йолдызлар,
Үз парларын эзләп яктыралар.
Нурларына күмелеп мин дә йөрим,
Үз парымны төрле яктан күзлим.

Чибәр кызлар йолдызлар күк балкыса да,
Берсен генә сөям өзелеп.
Их, Ай булсам, балкып янар идем,
Сөйгән ярның күңелен өздереп.

Айның да бит сөйгән яры бардыр,
Аны көтеп төннәр саен яктырадыр.
Мин дә сөйгән ярны сагынамын,
Шул ай кебек көтеп һәр төн саен.

## Көне–төне уйлап янам.

**Алай итеп тә карыйм,**
**Болай итеп тә карыйм.**
**Сине үземә каратуның**
**Ник соң җаен табалмыйм?**

**Көне–төне уйлап янам,**
**Башта бер хыял гына.**
**Синең белән бергә булсам,**
**Бәхет шул булыр миңа.**

**Ник син мине күрмисең?**
**Үтәсең тиз–тиз атлап.**
**Йөрәгемә минем кабат**
**Мәхәббәт уты ташлап.**

---

## Мәхәббәт ул...

*Чын мәхәббәт – бирәү генә, ләкин аның ялган кыяфәттәгеләре меңәрләп булырга мөмкин.*

***

*Кешенең күз карашына сүзләр салып һәм аларны укып булса иде. Әнә ул чагында мин синең күзләреңә минем өчен генә язылган мәхәббәт китабы итеп карар идем.*

***

*"Яратам!" дигәнгә беренче апрельдә дә ышанасы килә.*

**Шәүкәт ГАЛИЕВ**

***

*Чын мәхәббәт – әйтеп-сөйләп, язып-көйләп, тоеп-туеп бетергесез бөек шатлык ул.*

**Идрис ТУКТАР**

---

Альберт
Хәсәнов

# ТАБИГАТЬ ТУРЫНДА ПАРЧАЛАР

### Тормыш мәктәбе

Ул үзе сыңар бияләй хәтле генә. Барыбыз да бик яраткан, бик иркәләгән шушы көчегебез Муйнак курчак өедәй матур оясы алдына чыгып яткан да бар дөньясын онытып сөяк кимерә. Сөяге сеңерле, чат җелек кенә. Каршыдагы алма ботагына кунган дүрт саескан шуны бик кызыгып һәм дә көнләшеп карап тора. Чат сеңер, эче тәмле җелек белән тулы сөякне, йә әйтегез, кем генә

яратмый инде аны! Беләсез микән, хәйлә-мәкер коруга килгәндә саесканнар төлкеләрдән бер дә калышмыйлар. Күреп торам, менә бу юлы да көчекне ничектер алдау, тәмле сөякне кулга төшерү турында исәп корып утыралар. «Муйнак, сак бул, болар сине кызык итәргә җыеналар», — дип әйтергә дә уйлыйм, араларына керүне дә килештермим. Шул мәлдә саесканнар, сүз куешкандай итеп, серле генә каркылдашып алдылар.

— Тәвәккәлләдекме, җәмәгать? — диде, ахрысы, арадан берсе, өлкәнрәк күренгәне.

— Килештек! — дип куәтләде аны калганнары да. Боларда әйткән сүз — аткан ук икән. Саесканнар бик тәвәккәл кыяфәттә дүртесе дә шунда ук җиргә сикерделәр. Терт-терт килеп, дүртесе дүрт яктан көчеккә таба якынлаша башлады. Дөнья күрмәгән, тормыш тәҗрибәсе булмаган, моңарчы алданып авызы пешмәгән Муйнакка бу бик кызык тоелды. Әһә, аның белән әнә кемнәр уйнарга тели! Көчек, сөяген онытып, боларны күзәтә башлады. Ә саесканнар вак-вак адымнар белән сикергәли-сикергәли якынлаша бирделәр. Муйнакның күзендә шаян чаткылар ялтырый. Эчендә хисләр ташкыны. «Ау! Ау!» Әмма саесканнар көчек аларны бер сикерүдә эләктерер арада туктап калдылар. «Боларның соң башта кайсысын эләктерергә?» Муйнак, шашып типкән йөрәген тыеп, як-ягына карап алды.

Ау! Әһә, менә монысы иң якыны! Башта шунысын эләктерим!

Бу сәер җан ияләренең берәрсен эләктерәчәгенә, аның белән рәхәтләнеп уйнаячагына көчекнең аз гына да шиге юк иде. Боларны тоту аңа берни тормый. Муйнак үзенә якын торган саесканнарның берсе өстенә сикерде. Күреп торам, алар моңа күптән әзер. Хәйләне дә нәкъ менә шуңа исәп тотып корганнар. Саескан шунда ук ярты адым гына читкә күчеп утырды. Көчек тагын сикерде. Саескан аны тагын да читкәрәк алып китте. Ә ул арада калган өчесе, бик әйбәтләп кенә сөякне эләктереп, агач башына кунды. Үзен ничек оста алдауларын Муйнак шунда гына төшенде. Кызганыч шыңшып, минем янга йөгереп килде. Күзе белән алма ботагына, анда утырган саесканнарга ымлап, ярсып-ярсып өрергә кереште. Янәсе, әнә алар, оятсыз караклар, минем сөякне урлаучылар!

— Инде эш узгач, тавыш куптарудан файда юк, — дидем мин аңа. — Аннары, беләсеңме, дөнья, тормыш дигәнең шундый катлаулы нәрсә ул, Муйнак туганкай. Авызың бер пешми торып аны аңларга һич өйрәнә алмыйсың.

Муйнак шундук өрүдән туктады. Йонлач башын аз гына кыйшайтып, очлы борынын тагын да суза төшеп, миңа төбәлде. Дошманга нәфрәтле, ә дусларына чиксез мәхәббәтле нәни йөрәгенә мин сөйләгәннәрнең барын да чәчми-түкми сыйдырырга, һәммәсен дә аңларга, төшенергә тырышып утыруы иде бу аның.

### Үтерә күрмәгез!

Урамга гына күз салыгыз әле. Бүген анда нинди матур, нинди җылы кояшлы көн! Бакчаларда, паркларда чалма чәчәкләрнең, гладиолусларның, розаларның һәм башка бик күп гөлләрнең шау чәчәктә чагы. Әнә түп-түгәрәк, сип-симез төклетураларны гына күр син. Тамак төпләреннән чыгарган тавышлары үзләреннән зур. Әллә каян ук ишетелә. Жу да жу килеп әле бер чәчәккә куналар, әле икенчесенә күчеп утыралар. Чәчәк түтәлләре өстендә төрле төстәге күбәләкләр тирбәлә. Без яшәгән, ягъни тереклек иткән табигатьнең гүзәллегенә сокланып туймассың. Менә ачык тәрәзә аша сезнең бүлмәгезгә бер бал корты очып керде. Ә сез зур гауга куптардыгыз: өегезне су баса яисә янгын чыккан диярсең.

— Тотыгыз үзен, тизрәк тотыгыз! Үтерегез! — дип кычкырыша башлыйлар бүлмәдәгеләр барысы беравыздан. — Үтерегез үзен тизрәк! Югыйсә ул безнең барыбызны да чагып чыгар!

Нәни дусларым! Ашыкмагыз! Үтерә күрмәгез ул бал кортын. Зинһар, эшли күрмәгез бу вәхшилекне. Югыйсә сез Табигать-анабыз каршында зур җинаять кылырсыз.

Сезнең бүлмәгезгә ялгыш кына килеп керүенә бу бичара корт, бәлкем, үзе дә нык үкенә торгандыр. Аның безләве шундый шау-шу кубарыр дип башына да китермәгәндер. Сезнең бүлмәдән килгән үзләре сәер, үзләре серле тоелган исләргә алданып кергәндер ул. Ә бәлкем, иң изге ниятләр белән кергәндер. Тәрәзә төбегездә утырган гөлләрне күргәндер дә кызгангандыр, аларны серкәләндереп чыгарга булгандыр. Ә кем белә, бәлкем, ул кортларны бүлмәгә әлеге гөлләр үзләре кунакка дәшәдер? Анысы да бик мөмкин. Кызганыч, аларның телен аңламыйбыз шул. Югыйсә күп нәрсәләргә төшенер идек.

Сезнең бүлмәдә купкан әлеге шау-шудан бал корты үзе дә каушап калган. «Моннан ничек кенә исән качып котылыйм икән? Мин кергән ачык тәрәзә кайда соң ул?» дип без-без килә.

Ачык тәрәзәм аша алар минем бүлмәмә дә еш очып кергәлиләр. Керүенкерәләр, ә чыгар юл тапмыйлар. Эчкә кергәч әллә башлары әйләнеп китәме? Шөбһәле аваз белән безелдәп, кабаланып чыгар юлны эзли башлыйлар. Андый чакта мин буш шырпы тартмасын алам. Бал корты тәрәзә пыяласында чәбәләнгән чакта саклык белән генә аның өстенә буш тартманы каплыйм. Кортны иләп кенә шул тартмага кертәм. Аннары, тартманы балконга алып чыгып, кортны үз иркенә җибәрәм. Рәхмәтле җан тартманың капкачын ачкач та очып китәргә ашыкмый әле. Алгы тәпиләрен бер-берсенә ышкып, ике нәни мөгезен як-якка йөртеп нидер сөйли, без дә без килә. Әлбәттә, рәхмәтен белдерә инде. Үзең дә исән бул, сау-сәламәт яшә, ди төсле.

Әйтик, менә сез дә бүлмәгезгә очып кергән бер бал кортын шулай коткардыгыз ди. Белегез, бик тә изге эш эшләдегез. Чөнки шушы нәни генә бал корты да — тере җан иясе. Ул да, безнең кебек үк, тормышны ярата, чыккан кояшка сөенә. Бәләкәй генә бал корты да — Тереклек! Ә Тереклеккә һичкайчан кизәнергә ярамый. Сез аны нинди генә рәвешләрдә, килбәтләрдә, сурәтләрдә очратсагыз да, Тереклекне яшәүдән мәхрүм итәргә ярамый. Моңа берәүнең дә хакы юк.

Менә шул күренешне күз алдына китерик әле. Бакчабызда, урман аланында йә болын түрендә барыбызга яхшы таныш гап-гади тузганак үсеп утыра. Утыра гынамы?! Үзенең барлыгына, шушы дөньяда яшәвенә сөенеп туя алмый. Сапсары төсе, көләч йөзе белән әллә каян ук күренеп, елмаеп, безне ерактан ук сәламләп каршылый. Ә бер әдәпсезе шуны тотты да йолыкты ди. Өзде дә алды. Ни дип? Ни дип ул аның гомерен кисте? Ярты сәгатьтән үк янәдән ташлар өченме?

Кайчакларны урман-болыннардан кочак-кочак шомырт чәчәкләре күтәреп кайткан балаларны күрәм. Шул чакларны йөрәкнең ничек сыкраганын белсәгез икән. Чәчәкләрен өзгәндә, ботакларын сындырганда агачларның да гәүдәләре авырта, сызлый бит. Алар да нык рәнҗиләр. Менә шуны балаларыбыз ник аңламыйлар икән? Ата-аналар балаларына шуны ник аңлатмыйлар икән? И-и, алар гынамы! Кайбер малайлар, әлбәттә, усаллары, тискәреләре — урам этләренә җәяләрдән очлы уклар аталар, песиләрне тотып җәберлиләр. Алар әлегә белмиләр генә, соңыннан үзләре дә зур михнәтләр, кайгы-хәсрәтләр күрәчәкләр. Бәхетсез булачаклар. Шуңа күрә, нәни дусларым, кечкенәдән үк үз-үзеңә хуҗа булып, бар эшеңне үлчәп, бу гамәлем белән берәрсен кыерсытмыйммы, рәнҗетмимме икән дип, үз-үзеңнән сорап яшәргә гадәтләнү кирәк. Моның файдасы беренче чиратта үзеңә булачак. Кайгы-хәсрәтсез бәхетле тормыш кичерерсең. Әйе, нәкъ шулай...

## Мунча яратучы мәче

Башына чиертсәң җаны чыгарга торган бу мескен песи баласын безгә ике нәни кызчык китерде. Җәйге ял чорында алар, әниләренә ияреп, төзелешкә барганнар. Өйдә ялгызына гына күңелсез булыр дип үзләре белән пескәйләрен дә алганнар. Аны гел кулда гына тотып булмый бит инде. Йөгереп-йөгереп уйнасын дип идәнгә төшергәннәр. Ә тегесе чабып балконга чыккан да дүртенче каттан аска очкан. Нык кына имгәнгән. Зур песиләрне Америкада унынчы каттан да ташлап караганнар. Алар һәрчакны аякларына төшкәннәр, имгәнмәгәннәр дә. Берни булмаган. Ә бу пескәй әле бик яшь, бернничә атналык кына шул. Бичараның борыны канга каткан, ирене ярык, бер тәпиенә баса алмый. Кызганыч инде, күрсәң елап җибәрерлек. Бичараны менә шул хәлдә калдырдылар бездә.

Ә безнең мунча яккан көн. Авыл җирендә шул бит инде ул, врачка йөрү юк. Борыныңа томау төшсә дә, йөткереп торсаң да, билең кузгалса да — мунча ләүкәсе. Ләүкә, каен себеркесе барын да дәвалый. Җиңгәгез дә күп уйлап тормады, пескәйне үзебез белән «чәп-чәп»кә алып керде. Битен, колак артларын да хуш исле сабын белән юдык, ләүкәгә салып чәп-чәп тә иттердек.

Ни гаҗәп, башка чакны тәпие белән юешкә басарга кыймаган песиебез «чәп-чәп»не ошатты бит, әй! Яшь каен себеркесе белән аркасын чапканда дөньясын онытып ята. Ник бер тавыш-тыны чыксын.

Хәзер, мунча яга башлау белән: «Мияу, мияу!» — дип, аяк арасында бөтерелә башлый. Мунча ягасыз түгелме, янәсе, «чәп-чәп»тән мине дә калдыра күрмәгез. Кая инде ул калдыру! Мунча өлгерү белән башта аны ләүкәгә менгерәбез.

Гомумән, бик игелекле песикәй булды ул. Соңгы вакытта ишәеп киткән «идән асты халкы», ягъни тычкан-елтыр күзләрне өйдән тәмам биздерде.

Әле менә урманнан каен кисеп кайттым да кышка себеркеләр бәйлим. Песикәй минем янда. Себерке бәйләгәнемне бик зур дикъкать белән карап утыра. Әллә каян гына шунда кигәвеннәр килеп чыга. Тешләмәкче булалар. Эш белән утырган кешегә комачау ясамагыз әле, дип, пескәй, нәни тәпиләре белән кизәнеп, минем яннан кигәвеннәрне куа.

## Тол сыерчык

Бала чактан ук килгән гадәт инде бу минем. Ерак океан-диңгезләр аша күпме җирләр кичеп, туган якларына очып кайтучы сыерчыкларга елның елында кимендә бер-ике яңа оя бәргәләп куям. Әлегә, кем әйтмешли, шөкер, балта-пычкы тота алмастай корышкан куллардан саналмыйбыз. Әмма шунысы кызганыч, безнең якларга бу кадерле кунакларыбыз елдан-ел әзрәк килә. Ишегалдындагы тугызлап ояның тик дүртесенә-бишесенә генә хуҗа табыла. Башкаларына, килештерсәләр, чыпчык-песнәк кереп оялый, ошатмасалар — бөтенләй буш торалар, һи-и, элеккерәк елларны болай идеме соң!

Сугыштан соңгы авыр, хәерче еллар бик хәтеремдә әле. Әмма без, малай-шалай, барыбер җаен табабыз. Аннан каерып, моннан суырып булса да тактасын да юнәтәбез, сыерчыклар килешкә түбә кыегына бер-ике яңа оя менгереп кадакламый калмыйбыз. Менә шул үтмәс пычкылар белән кисеп, тешләнеп беткән балталар белән юнып, кәкре, кыйшык такталардан бәрепсугып ясаган ояларыбызны язларын безнең авылга кара болыттай ишле булып килгән сыерчык гаиләләре үзара бүлешеп туя алмаслар иде.

Ә менә безнең көннәрдә шундыйрак хәлләр шул: яз хәбәрчеләре — көтеп алган кунакларыбыз — туган якларына елдан-ел азрак әйләнеп кайта. Дөрес, әйләнә-тирәне, үзебез яшәгән мохитне саклау, табигать гармониясен бозмау

буенча хәзер бөтен дөнья күләмендә зур эшләр башкарыла. Әмма, күрәсез, бу эшләр әлегә һич кенә дә җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Шушы уңайдан күз алдыбызда булган йөрәк өзгеч драма турында сөйләргә телим.

Бала чактан килгән гадәт буенча, сыерчыклар килешкә кимендә бер-ике яңа оя ясап куям дигән идем инде. Ә бу юлы исә, агач комбинатына барып, эче куыш юкә алып кайттым. Аны станокта кырдырып, балалар белән бергәләп курчак өедәй матур оя ясап куйдык. Менә шушы оябызга, моңарчы гомердә күрелмәгән хәл, бер япа-ялгыз сыерчык оялады. Бу мескенкәй үзенең тормыш иптәшен кайларда югалткандыр, юлда килгәндә нинди һәлакәтләргә очрап беткәндер, теле булмагач, сөйли алмый шул. Югыйсә сыерчыклар да пар күгәрченнәрдәй парлашып яши бит алар. Ни генә булмасын, шунысы хак: безнең матур оябызны сайлаган кадерле кунагыбыз ялгыз, тол иде.

Тормыш шулай көйләнгән бит ул. Вакытлар үтү белән иң тирән яралар да җөйләнә, күңелдән мәңге китмәстәй тоелган кайгы-хәсрәтләр дә онытылгандай була. Әлеге сыерчыгыбыз да, ничәмә мең чакрым араларны узып, ниһаять, туган якларына килеп җитүенә, шундый матур ояга юлыгуына сөенеп бетә алмыйча, берәр атна тирәсе шашынып-шашынып сайрады. Бу матур ояны ясап куючыларны үземнең матур җырларым белән кинәндерим әле дигәндер. Ләкин шулхәтле ерак яклардан безгә алар нибары бер максат белән — ул да булса тизрәк балалар чыгару, аларны очарга өйрәтү нияте белән киләләр. Бу кошкайларның һәр сәгате санаулы. Башка парлы-парлы сыерчыклар белән бергә безнең бу ялгызыбыз да ашыга-ашыга оясына салам-печән кисәкләре ташырга кереште. Бер караганда бар да яхшы, бар да тәртипле төсле. Әмма аны алда зур фаҗига көтәсен, бичара кошкаем, үзе генә белми. Каян белсен, аның белән инстинкт идарә итә. Аны шул ашыктыра. Ләкин бу очракта хәтта инстинкт та ялгыша.

Әлегә тол сыерчыгыбызның анда-монда эше юк. Тизрәк балалар чыгарып, аларны очарга өйрәтеп, ныгытып, ерак юлга хәстәрләргә вакыт. Җылы, һәр иртәсе кояшлы җәйнең дә чиге бар.

Сыерчыгыбыз хәзер бик сирәк күренә. Йомыркаларын басарга утырды, күрәсең. Бу чорда ана сыерчыкларны, җимне ояга ташып, ата сыерчыклар ашата. Әгәр инде тегеләре кыска вакытка гына һава суларга йә канатларын язып керергә тышка чыкса, йомыркалар өстендә аталары утырып тора. Инкубация чорында аларны аз гына вакытка да суытырга ярамый. Ә безнең тол сыерчыгыбызның алай иркәләр иптәше юк. Бу мескен йомыркалары өстендә түзә алган чаклы утыра-утыра да оядан уктан аткан шикелле атылып чыга. Беренче туры килгән бөҗәкне йә суалчанны эләктерә дә кире оясына ашыга. Йомыркаларымны суытмагаем, чәберчекләндермәгәем дип курка.

Ул арада, күп тә узмады, күрше ояларда ыгы-зыгы башланды. Үз вакытында чәчрәшеп чыгып җиткән балаларына ата-аналары җимне ташып өлгертә алмый. Беренче көннәрдә генә эчтә чыр-чу килгән бу ачкүзләр аналарының җим алып кайтканнарын оядан башларын чыгарып ук көтә башладылар. Әлегә ялгыз, тол анабыз утырган ояда гына шомлы тынлык. Берничә көн инде мин аның оядан чыгып йөргәнен дә күрмим. Бу хәл миңа шикле тоелды. Ояны колга башыннан алып карарга булдым. Ни күрәсемне, нинди күренеш белән очрашачагымны алдан ук сизенсәм дә, бу минутта күзләремә яшьләр килде. Оя эчендә йөрәк тетрәткеч фаҗига. Тагын чүт кенә түзим, менә тиздән балаларым да чыгып җитәрләр дип көн-төн кузгалмый утыра торгач, сыерчыгыбыз ачлыктан, ялгызлыктан чәберчек йомыркалары өстендә җан биргән...

# ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

**Шушы башламнарның күңел теләгәнен дәвам итеп хикәя языгыз әле. Күләме бер журнал битеннән артмасын.**

**Җиңүче автор – журналның «Сүнмәс утлар балкышы» дигән уникаль китабы белән, тагын ике автор «Яңа базар» дигән сатирик хикәяләр җыентыгы белән бүләкләнәчәк.**

**Хикәяләр 20 декабрьгә кадәр кабул ителә.**

***

«Көз – кызлар күңеле төсле,

Бер елмая, бер – төксе», — дип язып куйды да Камил, тәрәзәдән урамга күз салды. Алтын тәңкәләрдәй коелышкан каен яфракларына хозурланып, серле генә елмаеп, урамда Рәсимә басып тора иде...

***

Волонтёр кыз, юл уртасына ук чыгып, кабалана-кабалана такси туктатты. Ян тәрәзәне төшерүгә, кабина эченә учлап чәйнәлгән сагыз исе бөркелде.

— Миңа «Кояш»лыга. Срочно!

— Универсиаданың беткәненә ике атна бит инде, кая шулай ашыгасың?

Һәм таксист, бәя турында да килешеп тормыйча, алгы ишекне ачты.

***

Кызның күзе егетнең беләгендәге татуировкага төште. Анда тигез хәрефләр белән «Гөлия» дип язылган иде.

***

— Исәнмесе-е-е-ез! Хуҗалар өйдәме-е-е? — дип сөрән салды Хәсән, зур урыс капканы ачып ишегалдына аяк басуга.

— Исәнме, абый, сиңа кем кирәк?..

Хәсән «дерт» итеп китте. Аның каршында тач үзенә охшаган, зур башлы, зур колаклы җиде-сигез яшьләр тирәсендәге бер малай басып тора иде...

***

Тавышын калынайтып, йөрешләрен никадәр генә үзгәртергә теләсә дә, Кыш бабай булып улын котларга керүченең яшьлек дусты Фирдүс булуын тиз чамалады Әминә.

***

Бу кызны ул троллейбус тәрәзәсеннән күрде. Күрде дә, гашыйк булды! Төшеп калып, бик озак эзләде ул аны. Таба алмады. Кайтып подъезддан керсә... шул кыз... аларның ишеген... ачкыч белән ачып маташа иде!

***

Күке, туктамыйча, санады да санады. Аларга рәхәт иде...

Ictimagi-mədəni
tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ТЕЛЛӘРЕБЕЗНЕ, МӘДӘНИЯТЛӘРЕБЕЗНЕ САКЛЫЙК

17 октябрь көнне Казан федераль университетының Филология һәм сәнгать институтында «Туган телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү» дип аталган II халыкара фәнни-гамәли форум булып үтте. Аның кысаларында 6 халыкара, 2 бөтенроссия конференциясе, «түгәрәк өстәл» сөйләшүләре, мәктәп укучылары арасында татар теле буенча олимпиадалар үткәрелде.

Форум эшендә Германия, Кытай, Төркия, Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Әзербайҗан галимнәре, филологлары катнашты. Россия төбәкләре югары уку йортларыннан да тел мәсьәләләре белән шөгыльләнүче галимнәр килгән иде. Җыенны филология һәм сәнгать институты директоры Рәдиф Җамалетдинов ачып җибәрде. «Туган телләрне саклау — бөтен дөньяда әһәмиятле көнүзәк мәсьәләләрнең берсе. Кешеләрнең яна кыйммәтләр ачуы, башка халыкларның мәдәниятләре аша гомумкешелек кыйммәтләренә тартылуы, мәдәниятара аралашу бик мөһим. Бу максатка ирешү өчен җәмгыятьтә телләрне һәм мәдәниятләрне өйрәнүнең әһәмиятен арттырырга, яшь буында үз халкына һәм мәдәниятенә, шулай ук күрше халыкларның мәдәниятенә хөрмәт тәрбияләргә кирәк», — диде ул кереш сүзендә.

Форум эшендә ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова катнашты. Ул ТР Президентының форумда катнашучыларга хатын укып ирештерде. «Форумның төрле телләр һәм мәдәниятләрнең күп йөзләрчә еллар дустанә мөнәсәбәтләрдә яшәгән Казанда узуы символик мәгънәгә ия. Күпмилләтле Татарстанда телләрне һәм мәдәниятләрне саклауга зур игътибар бирелә. Республикада милли мәгариф системасы үсеш алды, якшәмбе мәктәпләре эшләп килә, телләрне саклау, өйрәнү, үстерү буенча дәүләт программасы гамәлгә ашырыла. Форумның тел белеме буенча сорауларга җавап табарга һәм төп мәсьәләләрне чишү юнәлешендә нәтиҗәле фикер алышуга ярдәм итәчәгенә ышанам», — диелгән иде анда.

КФУның тышкы элемтәләр буенча проректоры Линар Латыйпов уку йорты кысаларында татар, рус һәм чит телләрне өйрәнүгә заманча шартлар тудырылуы турында сөйләде.

ТР Фәннәр академиясе вице-президенты Җәүдәт Сөләйманов җыенда катнашучыларны сәламләп, болай диде: «Без үзебезнең барлыгыбызны һәм зур эшләргә сәләтле халык икәнлегебезне һәрвакыт раслап торырга тиешбез. Без, галимнәр, укытучылар, тел галимнәре белән бергәләп, соңгы 1,5 елда 2014-2020 елларга Телләр программасын эшләү белән мәшгуль булдык. Киләчәктә без аны уңышлы тормышка ашырырга тырышсак иде».

ТР Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан каләм әһелләре исеменнән тел галимнәренә сәламнәрен җиткерде. «Сүз белән эш итүчеләр буларак туган телләрне саклау, үстерү, өйрәнү, тәрҗемә мәсьәләләре безне бик нык борчый», — диде ул.

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ренат Закиров чит төбәкләрдә татар мәктәпләре сыйныфлары ябыла баруга борчылуын белдерде. Ана теле укытучыларын әзерләү өчен конгресс юлламасы белән Казан федераль университетына студентларның елдан-ел күбрәк килүе турында әйтте. Форумда шулай ук Мәскәү, Уфа, Төмән университетлары галимнәре чыгыш ясады. А.Гумилев исемендәге Евразия милли университеты ректоры Ерлан Сыдыковның тәбрикләү хаты укылды.

Форумның пленар өлешендә КФУның Филология һәм сәнгать институты, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты, Рус милли-мәдәни мохтәрияте һәм Татарстанның Актаныш, Кукмара, Чүпрәле, Арча, Саба муниципаль районнары башкарма комитетлары белән хезмәттәшлек турында килешүләргә кул куелды.

## ХАЛЫК ШАГЫЙРЕН ОЛЫЛАУ

Татарстанның халык шагыйре, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллинга быел 70 яшь тулды. Республика җитәкчелеге, Мәдәният министрлыгы, «Татмедиа» агентлыгы, Язучылар берлеге булышлыгы белән җәмәгатьчелек бу юбилейны татар әдәбияты бәйрәме рәвешендә

кин билгеләп үтә. Сентябрь, октябрь айларында үткән чараларның кайберләрен искә төшереп үтәбез.

***

Милли музейда Равил Фәйзуллинның 70 яшьлек юбилее уңаеннан «Шагыйрь күңелендә ниләр бар» дип исемләнгән әдәби салон утырышы булды. Кичәдә Милли музейның генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипова, Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, юбиляр әдипнең каләмдәшләре Гәрәй Рәхим, Зиннур Мансуров, Мөхәммәт Мирза, Камил Кәримов, Газинур Морат, Маргарита Небольсина, җырчылар Миңгол Галиев, Рөстәм Маликов, скрипкачы Марат Әхмәтов чыгыш ясады, мәктәп укучылары шагыйрьнең шигырьләрен укыды. Соңыннан Равил Фәйзуллин укучыларны кызыксындырган сорауларга җавап бирде.

Кичәне әдәби салонның хуҗабикәсе Флүрә Дәминова алып барды.

***

Равил Фәйзуллинның гомер бәйрәме әдәбият көннәре кысаларында, туган төбәгендә — Балык Бистәсе районы авылларындагы мәдәният йортларында, мәктәпләрдә дәвам итте. Очрашулар Югары Тегермәнлек, Котлы Бөкәш, Балтач (Юлсубино) авылларында һәм Балык Бистәсенең үзендә булды. Шагыйрь белән бергә районыбызга аның иҗатташ дуслары да кайтты. Алар арасында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан, Татарстанның халык шагыйрьләре Рәдиф Гаташ, Гәрәй Рәхим, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иялäре, шагыйрьләр Зиннур Мансуров, Мөхәммәт Мирза, Ркаил Зәйдулла, Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Флера Тарханова, Татарстанның халык артисты Искәндәр Биктаһиров, Татарстанның атказанган артистлары Илгизәр Исламов, Әхмәт Кәримов, Фәрит Мирзануров, «Татар кызы» конкурсы лауреаты Энҗе Шәйморзина, скрипкачы Дилә Закирова һ.б. бар иде. Кунаклар бәйрәмдарның тормышына, иҗатына бәйле кызыклы чыгышлар ясады, якташлары исә аның шигырьләрен сәхнәдән яңгыратты.

***

Казан федераль университетының Филология һәм сәнгать институтында Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин иҗатына багышланган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция булып үтте.

Юбилярны иң әүвәл ТР Фәннәр академиясе вице-президенты Җәүдәт Сөләйманов һәм академиянең баш гыйльми сәркәтибе Дания Заһидуллина котлады. Академия галимнәренең юбилярга юллаган котлавында шундый юллар яңгырады: «Сез иҗатыгыз белән 60нчы еллардан башлап татар шигъриятенә яңа сулыш өргән, милли әдәбият өчен әр-яңа юллар ачкан шагыйрь. Әсәрләрегез дә, иң кирәкле чакта әйткән гамьле сүзләрегез дә халык күңелендә һәрчак яңгыраш таба, фикер тудыра. Татар халкы сезнең белән, иҗатыгыз белән горурлана, сез хаклы рәвештә Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле академигы исемен йөртәсез». Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан да шагыйрь иҗатына бәяләмә биреп, болай диде: «Равил ага Фәйзуллин традицион татар шигыре кысаларына гына сыймыйча, үз тавышын, үз язу алымын, үз өслүбен тудырган бертөркем татар шагыйрьләренең башында торган, татар шигъриятен яңа биеклеккә күтәргән күренекле шагыйребез. Равил Фәйзуллин исемен атаганда без бүген әдәбиятыбыз аксакаллары булып җитешкән менә шушы буын әдипләрен күз алдында тотабыз. Тәнкыйтьчеләр аны 60нчы елларда иҗтимагый тормышта татар шигыренең укучылар алдында абруен күтәрүгә алып килгән үзгәрешләрне башлап җибәрүче, хәрәкәткә китерүче әдип дип бәяләде». Язучы, «Татар дөньясы» газетасының баш мөхәррире Ринат Мөхәммәдиев тә шагыйрь иҗатына багышланган чараларда катнашу өчен Мәскәүдән махсус килгән иде. «Минем моннан 30 еллар элек язылган беренче тәнкыйть мәкаләм дә Равил Фәйзуллин иҗаты турында иде», — диде ул. Танылган әдәбият галиме, тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллин шагыйрь иҗатын гомере буе өйрәнгән. «Мин аның шигырьләренә гашыйк, иҗатын өйрәнү дә үзе бер кызыклы сәяхәт булды», — диде Тәлгат ага. Шагыйрьнең иҗаты турында шулай ук институтның әдәбият кафедрасы галимнәре, иҗатташ дуслары, шагыйрьләр дә чыгыш ясады.

Шул ук көннәрдә Татарстан китап нәшриятында конференция материалларын туплаган (йөздән артык доклад һәм чыгышлар) «Равил Фәйзуллин: шәхес, иҗат, заман» дип исемләнгән 400 биттән торган китап басылып чыкты һәм ул конференциядә катнашучыларга таратылды.

***

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында Равил Фәйзуллин иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә булып узды. Зал халык белән шыгрым тулы иде.

Бәйрәмдарны беренчеләрдән булып Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тәбрикләде. «Шагыйрь Равил Фәйзуллинның иҗаты мәгънәле, эчтәлекле, ул күңелгә үтеп керә. Кыска юллар аша да шагыйрь тирән фикерләр күзгата белә һәм уйланырга мәҗбүр итә», — диде ул.

М.Шәймиев Ттатарстан президенты Рөстәм Миннеханов исеменнән юбилярга машина бүләк итте.

Аннары шигырь остасы һәм татар матбугатының йөзек кашы — «Казан утлары» журналы мөхәррирен Истанбул университеты профессоры Мостафа Өнәр, Башкортстанның халык шагыйре Равил Бикбаев, Мәскәүдә яшәүче күренекле язучыбыз Рауль Мирхәйдәров, Кабарда-Балкар Республикасының халык шагыйре Моталиб Беппаев һәм Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан тәбрикләде.

Узган гасырның 60нчы еллары ил әдәбиятында янарыш еллары булды. Шул елларда бер төркем язучылар, шагыйрьләр татар әдәбиятына да зур яналык алып килде. Шагыйрь Р.Фәйзуллин — шуларның берсе һәм әйдаманы. Кичәдә юбилярны 60нчы елларда аның белән ингә-ин торып әдәбият мәйданына чыккан Татарстанның халык шагыйрьләре Ренат Харис, Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гаташ тәбрикләде.

Әдәби-музыкаль кичәдә Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле катнашты. Анна Гулишамбарова җитәкчелегендәге яна музыка оркестрына кушылып, җырчылар Гөлнара Рәхимова, Резеда Галимова, Мөнир Якупов, Гөлнара Мурзиева, Айдар Габдинов һ.б. шагыйрь Р.Фәйзуллин шигырьләренә иҗат ителгән җырларны башкарды. Башкалабыз театрлары артистлары тамашачыларга аның шигырьләрен укып ирештерде. Кичәдә шулай ук шагыйрьнең 12 яшьлек улы Газиз саксофонда уйнап һәм әтисенең шигырьләрен татар, рус, инглиз телләрендә яңгыратып, тамашачыларның алкышларын яулады.

## «ТАТМЕДИА» ААҖДӘ ЯҢА ҖИТӘКЧЕ

«Татмедиа» ААҖнең яңа генераль директоры итеп, элек «Татмедиа» басма һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары булып эшләгән Фәрит Шаһиәхмәтов билгеләнде. Ул әлеге постта бер елга якын эшләгән 32 яшьлек Рөстәм Бикмөхәммәтовны алыштырды.

Без Фәрит Илдус улын яңа җаваплы вазыйфасы белән ихластан котлыйбыз, уңышлар телибез!

## ЖУРНАЛИСТЛАРНЫҢ ҮЗ МУЗЕЕ БУЛА

Республикада тагын бер кызыклы музей барлыкка киләчәк. Ул Татарстан журналистикасы тарихына багышланачак.

Аны булдыру турындагы тәкъдим белән ТР Журналистлар берлеге рәисе, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыятенә мөрәҗәгать иткән. Журналистлар берлеге ТР Министрлар Кабинеты грантына Җәмәгать палатасы оештырган социаль әһәмияткә ия проектта катнашкан булган. «Татарстан журналистикасы тарихы музее» дигән проект исә «Мәдәни җәмгыять — чәчәк атучы дәүләт» номинациясендә җинеп тә чыккан.

Декабристлар урамының 179нчы йортында урнашкан Журналистлар йортында хәзер республика газета-журналларына, радио-телевидениесенә нисбәте булган кадерле ядкәрләрне: сирәк экспонатларны, фотосурәтләрне, документларны, хатларны туплау бара.

Музейны ачу Татарстан Журналистлар берлегенә 95 ел тулган көндә — быелның 26 декабрендә ниятләнә. Музейга ядкәрләр җыю дәвам итә.

## ПРЕЗИДЕНТ РӘХМӘТЕ

Татар әдәбиятын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе, актив фәнни эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты текстология бүлеге мөдире вазыйфаларын башкаручы **Вәлиев Мөдәррис Харис улына** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Тәңре кылычы». **К. Нәфыйков** картинасы.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Маргарита Небольсина**.

# Яңа китаплар




**Гөлчәчәк Галиева.** Әсәрләр: роман, повестьлар, хикәя. - Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. - 431 б. Тиражы — 3500 данә.

Педагог, язучы Гөлчәчәк Галиеваның бу китабына авторның инде укучылар арасында популярлык казанган әсәрләре туплап бирелде.

Бу китапка бер-берсен яратышып кавышкан парларның тормыш сынауларына дучар ителгән трагик язмышларын, уй-кичерешләрен психологик тирәнлектә тасвирлаган «Газзәбану» романы, «Тулгак», «Өзелгән өмет» повестьлары һәм «Барсам» исемле хикәясе тупланган.




**Фирүзә Җамалетдинова.** Хикәяләр. - Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. - 431 б. Тиражы — 3500 данә.

Язучы Фирүзә Җамалетдинованың бу китабына җәмгыятьнең, кешелек дөньясының яшәү рәвешен төрле төс-сурәтләрдә чагылдырган 50дән артык хикәясе тупланган.

Аларда Намус, Тугрылык, Мәхәббәт кебек мәңгелек төшенчәләр психологик тирәнлек һәм нечкә шигъри тоем аша тасвирлана.



Маргарита Небольсина

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)